# казан утлары

4

АПРЕЛЬ—1976




*Габдулла Тукай*

*(1886—1913)*

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ һӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 елның май аеннан башлап чыга

**4**

АПРЕЛЬ
1976


## Бу санда


**Р. ФӘЙЗУЛЛИН.** Көн уртасында килгән уй... Шигырьләр . . . . . . . . . . 3
**Ф. ХӨСНИ.** Язмыш. Повесть . . . . . . . . 11

ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

**Г. ХАЛИТ.** Тукай. Лирик герой. «Җан диалектикасы» . . . . . . . . . . 77
**И. ЮЗЕЕВ.** Шагыйрь җаны типкән җырлы дөнья. Шигырь . . . . . . . . . . 91
**К. МЫРЗАЛИЕВ.** Җыр йөрәге. Шигырь . . . . . 91
**С. МӘҮЛЕНОВ.** Тукай кабере янында. Шигырь . 92
**Р. ГАТАУЛЛИН.** Кырлай юлында Сәгъди абзый белән сөйләшү. Шигырь . . . . . . . . 93
**З. НАСЫЙБУЛЛИН.** «Тәфтиләү». Шигырь . . . . 94
**Ф. САФИН.** Тукай ягы. Шигырь . . . . . . . 94
**М. КАЮМОВ.** Шагыйрьләрне бергә җыя икән дә. Шигырь . . . . . . . . . . 95
**И. НУРУЛЛИН.** Тукай. Әсәрдән өзек . . . . . 96
**Ә. ФӘЙЗИ.** Тукай. Киносценарий . . . . . . 107
**Х. ЗӘБИРОВ.** Шагыйрьнең онытылмас образы. Истәлек . . . . . . . . . . 125
**Н. ИСӘНБӘТ.** Г. Тукайның мәгълүм булмаган бер шигыре һәм Мәхмүт Дулат-Али хакында . . 128
**Ш. ТУРДЫЕВ.** Рухи туганлык . . . . . . . . 136
**С. АКБИЕВ.** Габдулла Тукай һәм кумык әдәбияты . 140
**Д. ГАРИФУЛЛИН.** Шагыйрьнең соңгы рәсеме . . 145

ХИСАМ КАМАЛОВКА 50 ЯШЬ

**Р. МИНГАЛИМОВ.** Гомер шигырьләргә күчкән чак. 146
**Х. КАМАЛОВ.** Бу төбәктә. Шигырьләр . . . . 148

ОЧЕРКЛАР

**КамАЗ елъязмасы** . . . . . . . . . . . 153
**М. МОСТАФИН.** Рәхмәт, доктор . . . . . . . 155

ТАТАР ТЕАТРЫНЫҢ 70 ЕЛЛЫГЫНА

**Р. ХӘЙРЕТДИНОВ.** Беренчеләрдән берсе . . . . 162

ТӨРЛЕСЕННӘН

**А. МАЛЬКОВ.** Алар Ватанга турылыклы булдылар 165



КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА һӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ПУБЛИЦИСТИКА

**К. ФӘСӘХОВ, М. МӨЛЕКОВ. Чынбарлык һәм аны бозып күрсәтүчеләр** . . . . . . . . . . . 169

КИТАП КҮЗӘТҮ

**Г. АХУНҖАНОВ. Җыйнак, табигый тел белән** . . 176
**М. ГОСМАНОВ. Тарихилык — фәннең зарури таләбе** . . . . . . . . . . . . . . . . 178

НӘНИЛӘР ДӨНЬЯСЫ

**Ф. ЯРУЛЛИН. Минем чана.** Шигырьләр . . . . 183
**Н. ГАЙСИН. Халисә.** Шигырьләр . . . . . . . 185

ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

**З. НУРИ. Озын сүзнең кыскасы** . . . . . . . 186

**Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары** . . . . . . 189

Редакциянең адресы: Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-69, поэзия бүлеге — 3-07-69, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: **Зәки Нури**

Редколлегия: **Әхсән Баянов, Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 30/XII-1975 ел. Басарга кул куелды 11/III-1976 ел. ПФ 09014. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 91544 экз. Заказ К-1. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе. Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1976 ел.

## Равил Фәйзуллин

### Көн уртасында килгән уй
### яки
### утыз яшьлек ир егет сүзе

Юләрлеге белән хис ташыды,
яшьлекнең чик-ярларын басып;
Фаҗигасе белән уйлар янды,
ил күңеле ярасын ачып.

Яшәмәкче, яшьнәмәкче булдык
килгән бәхет — яшәү хакына.
Вакыт безне исәпләгәндерме
егерменче гасыр затыннан?..

Таң калдымы, көлдеме икән еллар
без дә сулыш өргән ялкыннан?
Хөкемдарлар гадел бәяләсен,
тарихыннан чыгып, халкыннан.
Гадел булсын...

Хыялларга, омтылышларга тулы
моңсу кичләр шаһит, шаһит таң, —
Күк астында нәрсә кылынса да,
чын күңелдән булды, ихластан.

Күкрәгемнән,
үз иманым кушкач,
очырдым мин
аккошын да, кара угын да.
Җирдә Яхшылык бар, Яманлык бар, —
алар арасында улым да!

Туры атмакчы, тигезмәкче үзем
нәкъ төбәгән төшкә — Яманга,
Шуңа тиярме соң?
Гүя атам
улым башындагы алмага.

Ул
бәлки бер карар уткәнемә,
ул булмаса,

бүтән әйтер
карар да:
күбрәк булган икән шатлыклары —
җирдә ул калдырган ярадан...

...Бүген дөнья безгә калып бара,
тән тулы көч, ә җанда ник моң?
инде еллар безне чыгардылар
алгы сызыгына тормышның.

Чыныгырга да, сыгылырга да,
шартлап сынарга да җай вакыт!
Ил күзенең безгә төбәлгәне
онытыла мәллә кай вакыт?...

Шундый вакыт: үзең аямыйча,
үз-үзеңне кирәк танырга.
Биеклекләрне саташтырмыйча,
үз күгеңне белеп янарга.

... Ташыйсылар шактый ташып алды,
янасылар байтак янылды.
Шау чагыңда иңнәреңә синең
төрле дан да, яр да сарылды...

Хәзер кагын!
Китсен, очсын юк-бар!
Фейерверк тузаннары да,
гайбәтләре, яшьлек чытлыклары
һәм вак-төяк дошманнарың да...

Хәзер эшкә!
Онытылып!
Бар ләззәтен тоеп хезмәтнең!
Вакыт
        әйтер — асылың турында.
...Җиңел түгел үзеңә лаек булу
    Кояш астындагы урыныңда.

1975

## Займище

Уң якта — Иделнең салкын сулавы.
Сул якта — урманның шомлы тавышы.
Баш очымда — тау-тау ямьсез соры болытлар аунавы.
Күңелемдә — бушлык.
Бүлмәмдәге кәгазь өстендә — кипкән күбәләк.

Кинәт — поезд тавышы!
Төнне ярып,
рельсларны нурга манып,
алтын алма булып,
тәгәри,
  килә бәхет!

Уң якта — Иделнең җылы сулавы.
Сул якта — урманның назлы шавы.
  Өстә — биектә — йомшак, күркәм болытлар тавы.
Көз.
Муллык.
Төн.
Син.
Рәхәтлек.
Бәхет.

1975

●

Бәргәләнә суда авыру балык.
Солитерлы диләр белгечләр.
Күрер күзгә таза:
сырты — кара,
үз урынында — канат-йөзгечләр.

Тәне — көмеш.
Дымсу күзләрендә —
салават күпере төсләре!
Шаяра-уйный күк, чәчерәтеп
камышлы су чите өсләрен.

Уйный күк... Хәтта әле кемгәдер
кызык та балыкны күзләве.
Ә аның...
эчтәге утына түзә алмый
җан бирер яр чите эзләве.

«Әй, Идел,
киң дә син, тирән дә!
Яшерче эчкәрәк, түреңә!
Их, бер генә, ичмасам, чумарга
агымның төптәге җиренә!»

...Мин озак карап тордым бу балыкка —
суда сусыз интеккән җанга.
Башка килде охшаш — иш нәрсәләр, —
Ни генә юк дисез җиһанда!

Халыклар бар.
Юк, халыклар түгел, кешеләр бар,
хәлләре шул балык сыманрак.
Сайда гына яшәп китүчеләр,
һай, чын, тирән тормыштан ерак!
(Ә яшәүләр һаман мәгънәлерәк,
һәр көн саен кызык, баерак!)

Үз хәлләрен аңлаганнары бар,
Бар аңламый
мәңге кайтмаска дип киткәннәр.
...Авыру балыкка соң ни әйтә алсын
Иделдәге камыш-җикәннәр!

1974

●

Күк — зәңгәр чатыр иде дә,
Җир — дулкын-түшәк иде...

Өстебезгә тургай егылгач,
нәрсәләргә икән юрадың?
Арышларны кочып еладың!..
Сөенечтән булгач, тыймадым.

Сүз куештык кабат килергә.
Зәңгәр чәчәк калды озатып.
...Сискәндереп җанны, оялтып,
бер көн хәтер куйды кузгатып.

Килдем ялгыз.
Кыр буш.
Кая арыш!
Камылына кадәр якканнар!
Син килгәнсең беркөн,
ә ул җиргә
яткан булган инде ап-ак кар...

1974

●

Шөкер,
мин дә байтак бактым
якты дөньяның күзенә!

Әй, ул кышкы аяз төнге күкнең чуарлыгы, серлелеге!
Ужымнарның көзен яшькелт дулкын булып уйнаклавы,
көнбагыш кырларының сары утта ялкынлавы,
шәфәкъләрнең канлы моңсу кызыллыгы,
таң атканда Идел өсте алсулыгы...

Шөкер,
күрдем —
чәчәкләрнең таҗын,
бөек рәссамнарның мәңге тере буяуларын,
балкып янган асыл ташларны,
салават күпере астындагы яңгыр толымын,
төсле музыканы,
тулган айның салкын саф аклыгын
(сокланып туймадым
карап аңа,
әле мәшригына, әле мәгърибенә чыгып кыйтгаларның),
гәрәбә залларны,
шәрабларның нурда балкышын...

... Ә шулай да,
мин күргән могҗизаларның
иң олысы, илаһие —
эссе мунча ләүкәсендә
тонык утта,

таза тыгыз мускулларына һәм иңнәренә
борчак-борчак тирләр чыккан
яшь, сәламәт Кеше тәне!

1975

## Каршылык

Бала чакта үзем тапкан изге чишмәм —
синең өчен бер су. Гадәти су — $H_2O$.
Нәселемнең шәҗәрәсе — иске кәгазь сиңа.
Мине өзгәләгән җырлар сиңа ни...

Гаҗәп инде:
кырмыскалар дөньясыдай мыжлап торган
ыгы-зыгылы шушы тормышта,
шыр сәхрәдә калган ялгызак күк,
утыр инде икең бер булып! —
(Ай, бу язмыш холыксызлыгы!)
Бер учакка багып!
Янып...

...Йөрәкләр типсә дә бер булып,
бер-беребездән яшереп,
барыбер нидәндер (ахры, капыл аерылудан) куркабыз.
Ялкын шул бер булса да,
төрле уттан без...

1974

●

Сабыйлыктан килгән мирас — беркатлылык!
Сафлык белән тоташкан җеп — беркатлылык.
Җанымның бер юанычы, куанычы — беркатлылык...

Ах!
Куенымда йөрткән кешем
шул бер катны салдырмакчы,
болай да инде ачык җанны
шыр-шәрәгә калдырмакчы...

Җанны сарды меңкатлылык!

Җиңдем диеп юануы бер рәхәттер,
ә чынында,
бу — мең катлы җәрәхәттер...

1974

●

Л. истәлегенә

Афәрин!
Мең яшә!
Браво!!

Калмаган комедия дә,
калмаган водевиль дә!
Алкышка күмгәннәр аны,
күмгәннәр аны гөлгә!..

Афәрин!
Мең яшә!
Браво!!

...Картлар йорты сәхнә түгел икән!
Менә кайда көткән драма...

## Төш

Күрдем бер төш:
мин бәләкәй малай —
рәсем ясыйм, имеш.
Ясаганым —
нindидер кош.
Бара торгач,
каргага охшаш
шыксыз гына җан иясе килеп чыкты.
Бетереп аны, ният — ясау яңабаштан
берәр былбыл,
я булмаса, лачын-бөркет.
Тик... ничек тә бетереп булмый бер сызганны!
Яңа кәгазь сорамакчы үрелеп —
юк...

...Әни миңа,
гомер кебек,
ак кәгазьне
берне генә биргән булган.

1975

## Менә тагын... яки онытылмас мизгел-бәхет

Һаман күңелдә,
күңелдә һаман
таныш түгел берәүнең йөзе.

Аэропортта,
самолетка утырып, күк катына менәр алдыннан,
бәхетле бер якынлык тоеп,
теләп,
яратып
озак итеп бер карап торган иде ул!..

Рәхәтләнеп,
изерәп,
ләззәтләнеп,

апрель кояшындагы кар кебек,
эреп тордым мин дә
ул караштa...

...Менә тагын,
күпме ел үткәч,
Бөгелмәдән ерак-еракта,
таулы-ташлы диңгез ярында,
тагын бер йөз.
Инде бүтән йөз,
әмма шул ук күзләр,
нәкъ шул ук караш!
Күпме якынлык!

...Исемеңне дә синең сорамадым,
дулкын ерып үтеп барышлый,
«рәхмәт!» дидем.
Син дә,
бәхетле бер каушау белән,
сүзсез генә миңа баш кактың...

1975

## Иң биек тау

Кояшларга якын түбәләр бар!

Кешеләр
бәхетле җыр җырлый-җырлый
менеп-төшеп йөри алса —
кечкенә үр дә
иң биек тау минем өчен.

1975

## Назыйм Хикмәт Куктүбәдә

Аяз көнне
биектән —
Каратау башыннан карагач —
еракта-еракта,
күгелҗем офыкта,
әлҗе-мөлҗе булып күренә
Туган иле ярлары!

Ничәнче кат инде,
тораташтай катып,
багып тора диңгез ягына.
Алда — Кара диңгез.
Ә артта, ян-якта —
бәрәкәтле Кырым-йорт-җире.
Сихәтле җил. Күзге чуарлык.
Йөзем кырлары. Тәмле ис...
. . . . . . . . .

Диңгез өслəп кыр казлары очып бара каршы ярга.
Берəү — икəү... тугыз...
Бигрəк тиз очасыз шул! Отып калалмассыз бар сүземне...
Ичмасам, сез сəлам əйтегез —
тауларыма минем,
Мəмəдемə,
дусларыма...

Йөрəк борчыса да кайчак,
таза әле, исəн-сау диегез.
Йөгереп килер идем үзем дə,
арада шул... менə
диңгез!

Түбəсендə Каратауның — җиллəр.
Иркəли дə чəчне, йолкый да.
Зəңгəр күзле алтмыш яшьлек шагыйрь,
унсигездəге кебек алгысынып,
карап тора Кара диңгезгə.

Əй, дулкыннар!
Кара исем алган зəп-зəңгəр су!

Йөртмəдегез кайларга кагып!
Кыяларга килеп бəрелгəч,
киңəймəде ярлар ишелеп,
бер юаныч — яньчелсə дə,
йөрəк зурайды!
Сыйдырырлык булды
дөньяның шатлык-кайгысын.

...Кара диңгез алда.
Каратау.
Сагышының аның бар төсмерен
җыйган кебек
елтыр ташлар ята яр тулып...

1975

# Фатих Хөсни

## Язмыш

повесть

### Кереш

Беренче мәртәбә 1959 елда басылган һәм аннары татарча, русча, казакъча берничә кабат яңадан чыккан «Җәяүле кеше сукмагы» романы, укыган кешеләр бәлки хәтерли дә торганнардыр, түбәндәге пафослы юллар белән очлана:

«...Менә алар, бу юлы инде тар сукмактан түгел, көрәш белән, ялгышулар һәм икеләнүләр, сөртенеп егылулар һәм борын канатулар аша яулап алынган олы һәм иркен юлдан бердәй тигез адымнар белән алга китteләр.

Берсе — татар халкының мәңге тутыкмас көләчлеген һәм хәрәкәтчәнлеген чагылдырып, кыңгырау кебек, дала яңгыратып шаулап бара.

Икенчесе — хезмәт иясе хатын-кызларның мәңге сулмас җылы күңелен гәүдәләндереп, иптәше көлгәндә, аның шатлыгын уртаклаша, иптәше арып калса, аны назлый, иптәше ташка бәрелеп аягын җәрәхәтләсә, аның җәрәхәтен бәйли...»

Рус телендә чыккан вариантында тәрҗемәче Николай Богдановның йөгерек фантазиясе ярдәмендә һәм, әлбәттә, Фатихның да фатихасы белән:

«...Вот идут они вместе, широкоплечий мужчина и тоненькая женщина, под высоким небом, по широким полям, и звенит-звенит, как жаворонок, черноглазый мальчонка, юлой вертясь на плечах отца» кебек юллар да өстәлгән. Ямьсез тәмамланган дип кем дә әйтә алмас, хәтта беркадәр купшырак та түгелме икән әле! Әтисе иңбашына утырып, зәңгәр күк астында тургай кебек сайрап һәм бөтерелгәләп баручы малай, белеп тордык лабаса, Сәфәргалинең үзенеке түгел, бик тә шапшак яшьлек кичергән, беренче пулясын революция җилкәсенә җибәргән, җәзалау отрядлары составында совет активистларын, мөгаллиммөгаллимәләрне атып-асып йөргән һәм соңыннан революция тарафыннан тиешле җәзасын алган йөгәнсез байбәтчә Мидхәт Вильданов ма-

лае, дөресрәге, Мидхәтнең законлы кәләше Зәйтүнәгә калдырган бердәнбер «бүләге». Дөрес, ул бала Зәйтүнәнең Вильдановлар белән арасы өзелгәннән соң туды. Әмма шулай да, хәзергә аны ничаклы гына иңбашына утыртып, тургай итеп җырлатып йөртмәсеннәр, кайчандыр беркөнне, әлбәттә, үсә төшкәч, очы яшерелгән төеннең бер сүтелеп, көннәрнең берендә малайның «Минем үз әтием кем?», «Ул хәзер ник юк?» кебек бик хәтәр сорауларны куячагын көтәргә кирәк иде. Бу — яшеренеп яткан бер каршылык булса, икенчедән, Сәфәргалинең алда әле бик тә үзенчәлекле, күрер күзгә кызыклы, киң күңелле, ләкин шулай да, бармагы үзенә таба кәкре үз этисе Корбангали тегүче белән дә катлам-катлам очрашасы, бергә торасы бар. Бу бергә торулар да «күчәр башлары» бәрелмичә генә, әлбәттә, узмый.

Онытырга мөмкин булмаган өченче бер хәят: заманның үз каршылыклары сугыш узган, революция җиңгән, карашлар һәм юллар аерылган... Өстәвенә, егерме беренче елгы ачлык, кыскасы, яңасы килгән, искесе әлегә китеп бетмәгән һәм тиз генә китәргә дә ашыкмый... Болар соң безнең кешеләргә «зәңгәр күк» астыннан тургай кебек җырлап кына үтәргә мөмкинлек бирделәрме икән?

«Җәяүле...»нең нindидер рәвештә дәвамы булырга тиешлеге миңа башта ук ачык иде. Ләкин иҗат эше шундый «мәкерле» бер процесс ул, башта бик ачык булган хәл-әхвәлләр дә соңга таба томалана, оныта башлый. Арага икенче, өченче вакыйгалар керә, ә тегесенә — калган эшкә кар ява. Шул ук вакытта күңелгә бер төшкән орлык эзсез генә югалып та калмый. Минем «Җәяүле...»м белән дә шулай булды. Мин аны күрә-күрә йөрдем, ул әледән-әле миңа очрый, сәлам биреп уза, ләкин тукталмый, узып китә, күрәсең, минем башта бүтән уйлар кайнаганлыгын сизенә булгандыр. Ниһаять, менә без ныклап очрашырга карар кылдык. Соң булса да уң булсын!

Инде килеп, авылдашларым — Мәтәскә авылы кешеләре белән авызны-авызга куеп сөйләшәсе бер сүзем бар. Тегүче Корбангали һәм аның шук җанлы улы Сәфәргали, тегү машинасы һәм башка үлчәү-кисү әсбаплары төялгән бәләкәй чананы тартып, авылдан чыгып, урманны узганчы гына Мәтәскә кешеләре иделәр — онытмагыз, безнең ярты авыл диярлек тегүче иде элек. Аннан соң инде алар, бигрәк тә Сәфәргали, озын һәм мәшәкатьле юл үтте, башларыннан күп мәшәкатьләр кичте, алар тик Мәтәскә кешеләре булып кына калмадылар, халык эшенә кушылып киттеләр.

Шулай да язылачак бу китапта да мин Мәтәскә авылын еш кына телгә алганмын икән, зинһар дип әйтәм, «Кара, безнең Мәтәскәдә нинди эшләр булып узган!» дип, яки «Мондый тамашаларның, мондый кешеләрнең безнең Мәтәскәдә булганы да юк» дигән сүзләр белән мине хурлап та, хуплап та телгә алмагыз. Монда Мәтәскә дә, Бәрәскә дә, Мәчкәрә дә, Бәйрәкә дә бар, үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, монда, әлбәттә, мин үзем, минем фантазиям дә бар. Чөнки бу сәнгать әсәре итәргә тырышып, тормышны гомумиләштереп язылган әсәр, фото бугазы аркылы гына үткәзеп, шул бер урында катып калган салкын күчермә түгел.

**Фатих Хөсни.**

I

Егерме беренче елгы ачлыкның икенче елында җәй искиткеч матур башланды. Ачлыктан кырылганнарның каберләрен йомшак сәрдә үләне белән төреп, исән калганнарда яңа өмет чаткылары кабызып, табигать, сабан туена әзерләнгәндәй, купшыланды: урманнар күпереп яшәрделәр, өй түрләрендәге канәфер, шомырт агачлары атна-ун көн шау чәчәктә утырдылар да, инде чәчәкләрен коеп, тәрәзә пыялаларына куе яфраклары белән орына-орына, өйдәгеләрне тышка, тыштагыларны сахрага кыңлегенә дәшә башладылар. Кукәй сытып, уч белән генә кукуруз оны туглап пешерелгән кычыткан шулпасында гына яшәүче авыл кешеләре, киләккә-киләкмәскә сахрага чыгып, койрык чәнчеп чабып йөрергә бик җилкенеп тормасалар да, киртә-читән буйларында яшь кычытканны йолкыган саен урынына яңасы котырып үсеп торуына, бигрәк тә чәчелгән хәтле игеннәрнең соклангыч күренешенә карап, өметле сулап куялар: «Аллага шөкер, болай булса, яңага хәтле, шәт, сузарбыз!»

Ачлык елның кышында терлекләрнең күбесе ашалып беткән, хәтта эт, мәче дә сирәк, шунлыктан урамнарда, тыкрык, бакча башларында үлән, кычыткан котырып үсә, кыскасы, башы исән калган терлекләргә бөтен җирдә тәрханлык, алда үзләрен мул азыклы кыш көтә иде.

Гаҗәп-хәйран калырлык хәл: Корбангали тегүче хәтта шул ачлык ел кышында да Цепилов алпавытыннан алып кайткан айгырын исәнимин саклап калды. Әлбәттә, үз ишеге алдында түгел (хәер, аның үз ишегалды юк та иде), атланып өязгә чыгып китте, үз тамагы, ат тамагы хакына кулдан тегү тегеп йөрде — яңаны тектерүчеләр булмаса да, искене сипләтүчеләр табылгалый торды. Инде кайтса, Мәтәскәсендә әйтеп бетергесез тәрханлык: атны тышаулыйсы да юк, чыгар да җибәр. Асылбикә түти кычыткан шулпасы пешерергә тәмам остарып беткән. Өстәвенә, мөгаллимә киленнең аз-маз паегы да килә тора иде. Тик хәзергә килен үзе генә өйдә тормый, кышын күрше Янбулат авылында укытып, кайта-китә йөрүдән узмаса, уку елы беткәч, Мәтәскәдән сигез километрдагы Казаклар авылында шул төбәктәге мөгаллим-мөгаллимәләрнең белемен күтәрү буенча айлык курс ачтылар, атна арасын шунда үткәрә иде. Тик ничек кенә булмасын, акча һәм паек китерә торган укымышлы килен алдында куштанланырга Корбангали карт тәмам өйрәнеп җитте. Кайткан чакларында: «Килен! Фатирың ипләме? Булмаса, мин барып үзем сөйләшермен. Казакларда мине белмәгән кеше юк, гүрнәчә табып бирәм, әгәр теләсәң», дип, әледән-әле кабатлап тора иде. Ял көннәре алдыннан, кешедән сбруй җыеп (әлегә хәтле аның үз сбруена тиенгәне юк, йөрсә, атланып йөрү белән дә канәгать иде!), киленне Казаклардан үзе барып ала, кайтышына, һичшиксез, мунча яктыра, сугыш яраларыннан әле җунләп терелеп тә җитмәгән Сәфәргалине дулатып мунчага куа иде. Аның болай куштанлануы сәбәпсез дә булмаган, килененең һәр алган хезмәт хакына азлап-азлап көя булып төшкән икән. Әлбәттә, өйдәгеләргә сиздермәгән, «Менә камыт-иңгырчак алырга!», «Менә, тырышып булса, арба юнәтү турында сөйләшеп йөрим!» дип юмалап теләнгәч, Зәйтүнә дә таш күңел түгел, артыгын төпченеп тормаган. «Эчәргә сорамый, йорт кирәк-ярагы өчен ич!» дип, кадәре хәленчә, эндәшми-тынмый гына өлеш чыгара килгән.

Юмалап-тәмле телләнеп җыйган бу акчалары кесәне тишә башлаганнан түгел — Корбангали агай еш кына, «Һәй, бездә акча бер очыр-

ма!» дип шапырынса да, анда акча бервакытта да, революциягә хәтле дә, революциядән соң да, кесәне тишәрдәй дәрәҗәгә җиткәне булмады — җәйнең шулай күңелле торуыннан җаны ташып булса кирәк, көннәрдән бер көнне, иртәгә Теләче базары дигән көнне, кичтән үк базарга җыенырга тотынды карт.

— Иртәгә өлгермәс иең, ходаем, кичтән үк болай олыдан кутмасаң, — дип, авыз эченнән сөйләнгәләп алды Асылбикә түти.

— Әллә Цепилов айгырына хәер-фатиха бирергәме исәп, эти? — дип, ирониялә сорау куйды Сәфәргали. Аның тавышында ук атка бик алай исе китмәгәнлеге ишетелеп тора иде, — сбруең, җигәргә арбаң юк килеш авылда бер айгыр асрап ятканчы, дим.

— Тәлгатькә өр-яңа бәрхет кәләпүш алырга барам, — күренеп тора, малае Сәфәргали сүзенә бераз хәтере калган иде картның. Моны сиздермәскә тырышып, гадәтенчә, уен-көлкегә борасы итте, — базарга мал-туар сатасы-аласы булганда гына кичтән чыгарга дигәнмени? Менә мин кәләпүш алыр өчен дә кичтән чыгам.

Соңыннан карчыгына, малаена берьюлы курт кына әйтеп куйды:

— Нәрсә алырмын, нәрсә сатармын — кайткач күрерсез.

Хәер, Теләче базарына чабу Мәтәскә кешеләре өчен искитәрлек вакыйга түгел. Йомышы булса да, булмаса да чаба Мәтәскә Теләче базарына. Беришесе дөнья хәлләре ишетеп кайтыр өчен чаба, икенче берәүләре дөнья хәлләреннән туеп, азрак җилләнеп кайту өчен дип чаба. Берәү аягына чабата алырга дип китсә, әйтик, шуның ук күршесе чабатачы Бикназар атна арасында ясап өлгерткән яңа чабаталарын сатарга дип бара. Теләче базарыннан башка Мәтәскә тора алмый икән, ник әле без Корбангали агайга гына бәйләнеп маташырга тиешбез, ди? Җәяү түгел, айгырга атланып бара ич — хәерле юл телик үзенә!

Килененнән тарттырган, йомырка саткан һәм, гомумән, кайчандыр искәртмәстән генә «баеп» киткән чакларыннан кысып калдырган акчаларына базарга шулай чыккалый йөргәндә, Корбангали карт камытынэшлиясен, дугасын-дилбегәсен дигәндәй алып, белеше Максим келәтенә җыя барган, бу чыгуы зуррак максат белән: җигәргә тимер хут арба сатып алу өчен, әлегә тик алдан кычкырып куюны гына кирәк тапмаган иде булса кирәк. Чынлап та, көтмәгәндә айгырны үз тимер хутына, яңа каеш исе аңкып торган үз сбруйларың белән җигеп кайтып керү үзе ни тора, әкәмәт. Дусың сөенәчәк, дус түгелең эчен уачак.

Әмма безнең ул ярлы мактанчыгыбыз бер кызгач, хәтта тимер хут арба белән генә дә чикләнмәгән, Комаровка русларыннан әле яңарак кына үреп ясалган әрҗәле өр-яңа тарантас сатып алган иде. Эшкәйөккә җигәргә арбасы юк чагында кирәк-кирәкмәсә тарантас! — менә шунда да инде бу җильяк кешенең хөррияткә анлавы. Туктагыз әле, байлар гына җиккәндә түгел тарантасны, гомердә ат-тун күрмәгән Корбангали тегүче дә җигеп карасын бер, янәсе.

Ләкин һәр очракта нинди дә булса бер киртәгә тап булганы кебек, бу куанычына да шайтан таяк китереп тыкты. Базардагы алу-сату мөгәриченнән ярыйсы гына авыз итеп, тарантас түренә кырын төшебрәк, җырлый-шаулый кайтып килгәндә, Тәмте тавы башында, авылдан аерыла төшеп, күркә кебек җилгәрәк кунаклаган ялгыз өйдән итәген ыштан бөрмәсенә яртылаш кыстырган бер пумала баш килеп чыкмасынмы. Өсте элә-танаксыз, яулык читләреннән чәчләре тузгып чыккан, кулында шакшы су чиләге. Менә шул «эшем кешесен» әллә кайдан ук күреп, шомланып, колакларын шомартып килгән айгырга ул хатынның юл буендагы канауга, атның нәкъ борыны турысына чиләген ларык итеп түгүе җитә калды, куркынган хайван дәррәү алып-биреп чабып китте.

Биек текә таудан, бигрәк тә иярәшмәгән тарантас арттан көч-куәт өстәп, этеп торганда, дүрт аякны дүрт якка ташлап ыргылырга күп кирәкмени! Дилбегәне тартып карамады түгел Корбангали абзый, кулына урап тартып карады, кайда ул сәрхуш башны тыңлау. Китте ат, китте ат, мескен яңа тарантас тигезле-тигезсез юлда шырпы тартмасы урынына сикергәли, мескен тарантаста мескен Корбангали абзый сикерә. Болай да җәһәннәм чокырына олаккан хәлдә, кайдан, кайчан кем уйлап чыгаргандыр, юл читенә тәп-тәп тумбалар тезеп төшкәннәр, имеш. Хәтәрлекне алдан ук абайлаганнар, базардан кайтучы «салмыш башлар» юл читендәге канауга дөмекмәсеннәр диптер инде. Канауга ук дөмекмәде Корбангали, әмма кучәр башы тумбага эләгеп, тарантас күтәрелеп бәрелгәндә, чигәсе белән кузла тимеренә барып төште. Әлбәттә, күзеннән утлар чәчрәде, анысы бер хәл, күзләр урыннарында калганга шөкер итте. Инде тауны төшеп җиткәннәр, инде күперне дә үтеп чыкканнар, атның ярсуы басылган, ул сөзәк үргә сузылган Тәмте урамыннан җай гына атлап бара иде. Шунда гына сизде Корбангали абзый — яңа тарантасның тәже өзелгән, тәртә бушаган, айгыр кыеккыеграк атлаган кебек иде. Шул минутта тагы бер нәрсәне сизеп алды базар кайтучы Корбангали: чигәдән бит буйлап җылы кан агып төшеп бара. Капшап карады, кан, кып-кызыл кан. Бермәл кемне ничек әрләргә белми барды карт. Тау башында атны өркеткән пумала башнымы? Һич кенә дә юктан күзен акайтып чапкан алпавыт калдыгы менә бу айгырнымы? Юл читенә бер кирәкмәскә карсак баганалар тезеп төшкән мәнсез Тәмте кешеләренме?

Тәмте авылыннан Мәтәскәгә ерак түгел, аннары тагы җене дә кузгалып торган чак, юри үч итеп тарантастан төшмәде, чигәсендәге канлы җәрәхәтне бәйләмәде. Хәер, бәйләрлек яулык-мазары да юк, авыл кешесенә кесәдә борын яулыгы йөртү дигән аять, ачуым килмәгәе, хәтта Корьәннең үзендә дә язылмагандыр, ахры.

Сәфәргали ярлылар комитеты йомышлары белән каядыр чыгып киткән иде. Авыл буе өзелгән тәжен өстерәтеп, бит буйлап аккан канын ялтыратып, гаҗәпсенеп сәлам биргән кешеләрдән исе китмичә генә сәлам алып, җил капканы киң ачып, тарантас белән кайтып кергән Корбангали картны беренче булып:

— Нәрсә булды? Нишләп канадың? Сугыштыңмаллә? — кебек сораулар белән, әлбәттә, карчыгы Асылбикә түти каршы алды. Яңа тарантасны хәтта бөтенләй күрмәгән дә кебек, өтәләнә иде карчык. Ишегалдына яңа кергән малга мондый игътибарсызлыгы картның канын янә дә кыздырып җибәрде.

— Нәрсә булмас базар йөргәндә. Бәлкем без талчыбыктай нечкә билле берәр кыз өчен кыр талашып сугышканбыздыр. — Карчыгы бу җилле сүзне дә колак янынан гына уздыргач, кинәт ипкә килеп өстәде: — Менә син, әнисе, тарантасны күр дә исе борынны кытыклый торган менә бу каеш сбруйларга кара. Түлке ни... тәжене өздердем кайтышлый. Әй, өзелсә тагы, өзелгән әйберне ялгарга да була ич.

Кешедән ишетеп булса кирәк, атылып-бәрелеп ишегалдына Тәлгать кайтып керде. Яңа тарантасны күреп, малайның башы дәррәү җиденче кат күккә күтәрелгән иде.

— Үзебезгәме, бабай? Бөтенләй үзебезгәме? — Ул инде тарантасның кузласына ук менеп кунаклаган, бу сорауларны шуннан гына биреп утыра.

— Менә, ичмасам, бу мужикларча сөйләшү, — диде бабасы, ат-тун әйбере өчен куана белүче оныгы белән горурланып. Аннары атны тугара-тугара, авыз эченнән мыгырданды, — илла менә бу алпавыт калдыгы җенемне чыгарды бүген. Яңа тарантасның тәжен өздереп...

## 2

Якшәмбе арты Сәфәргали гадәттәгедән иртәрәк торып кырынды, юынды, «самаварның тизрәк кайнап чыгар исәбе бармы, әни?» дип, кече якта кыштырдаучы әнисен ашыктыра төште. Боларның барысын да бер читтән күзәтә йөргән Корбангали карт, әллә соңгы вакытларда бик тә эшем кешесенә әйләнеп, өйгә, йорт эшләренә күңел бирми башлаган малаена бәйләнәсе килүдән, әллә өйгә акча китерә торган уңган киленен яклап, тавышын күтәрмичә генә әйтеп куйды:

— Киленне таң тишегеннән кузгатып чәйсез-нисез озатсак та, үзебезнең чәйсез кузгаласыбыз килми, алайса, акыллы татар?

Сәфәргали әтисенең бу төртмә сүзләрен ишетмәмешкә салышты — ни сөйләнмәс иртүк кузгалып, кая барыр урын тапмыйча буталып йөрүче кыбырсык карт. Бәлки, чынлап та, Зәйтүнәне кызганып әйтүе булгандыр: тизрәк барып җитәргә дип чабуы булгандыр шул.

Чәйдән соң, ишегалдына чыккач, ата белән малай арасында сүз куртрак ялганып китте. Югыйсә, Сәфәргали бик җайлап, юк нәзакәтлелеген бар итәргә тырышып куйган иде мәсьәләне.

— Яңа тарантасыңны җигеп, бер урап кайтыймчы дисәм, каршы килмәссең бит, әти? — дип сораган иде. Карт коры гына:

— Тәже өзек тарантасның, — дип җавап кайтарды. Һәм шундый ук корылык белән үзе сорау куйды:

— Кая юл төшеп тора тагы? Өйдә эш беткән иде, ди. Бәрәңге бакчасының киртәләре авыш, казыклары берсе мәшрикъка, берсе мәгърипкә киткән.

— Киртәгә көне табылыр, бүген миңа кордонга барып кайтырга кирәк.

«Кордон» дигән сүз чыккач, картның күңеле шундук йомшап китте — малаеның урман артыннан йөргәнлеге колакка кереп калган иде һәм, әлбәттә, бу йөрүнең ярлылар комитеты исеменнән, барыннан да элек өйләре коелган берничә фронтовик семьясын өйле итәр өчен йөрү икәнлеген әлегә ул белеп җиткерми иде.

— Тәжене анысын яңадан тарттырырга да булыр,— ул тарантасны лапас астыннан тартып алгарак чыгарды. Картның йомшый төшкәнлеге әллә кайдан сизелеп тора иде,— илла мәгәр җәлләгәннән түгел, болай әйтәм: теге тинтәк хайван тарантас шыгырдаганга бер дә ияләшмәгән. Кенәген базардан кайтышлый Тәмте тавында чүт башымны ярмады.

— Кулына туры килмәгән. Минем кулда алай котырына алмас.

Шәп яңгырады бу сүз. Үзе дә мактанырга ярата торган җильяграк Корбангали абзый малаеның болай өздереп әйтә белүен ошатты. Хәтта «кулына туры килмәгән»е аның үзенә кагылса да, моны нжекләмәскә тырышты. Күп сөйләшмичә генә тарантасның тәжен ялгап, яңадан тарттырдылар. Малаеның сбруйга кулы ябышып торганлыгын күреп, Корбангали абзый эченнән генә куана, ләкин тышка чыгармый иде. Шулай да соңыннан әйтми булдыра алмады:

— Атланып кына барсаң соң? Иләшмәгән атның кытыгын китереп, тарантас шыгырдатып йөргәнче, дим.

— Кичә Тәлгатькә сүз бирдем. Яңа тарантаска утыртып, бер катать иттерәсем килә. Малай кеше бит.

Һәм, өй ягына карап, әнисенә аваз салды:

— Әни, уянмаган булса, уят Тәлгатьне, юлга әзерлә.

Кайда ул уянмаган булу! Шундый тантаналы бер көндә! Малай бар булганы белән купшы гына киенгән, бу иртәнге сәгатьләрдә ашыйсы бер дә килмәсә дә, өстә әбисе тукый торганга гына көчләп-көчләп сөт белән тары көлчәсе мүкләп азаплана иде. Әтисенең тавышын ишетүгә ялт чыгып басты. Бу өйдә малайны берсеннән-берсе көнләшеп яраталар.

Малай моны үзе дә сизенми түгел. Сизенмәсә, әле этисе дә, энисе дә, әбисе дә утырмаган өр-яңа тарантаска утырырга шулай җилкенеп торыр идеме соң? Юлның унуын яки уңмавын тикшереп тормастан, дүртесе дә бик шат иде. Хәтта әле яңарак кына көйсезләнеп торган Корбангали карт та ачылган, ат һәм тарантас тирәсендә нишләрен белми тыпырчынган Тәлгатьне бик иртә сикертмәскә тырышып, иңеннән учлап, ычкындырмыйчарак тора иде.

— Үзем утыртып йөртмәкче идем малайны иң әүвәл, кулымнан тартып аласыз бу бәхетне.

— Ничава, бабай... Ат та, тарантас та синең үзеңнеке, бер дә, ун да йөртерсең, Тәлгатьне синнән күпсенгән кеше юк,— моны Тәлгате өчен Сәфәргали әйтте.

Малай инде тарантас түренә менеп кунаклаган, җил капка төбенә хәтле ачык иде. Җитмәсә тагы, киртә арасыннан күрше малайлары — Тәлгатьнең иптәшләре күзләрен яндырып карап торалар. Иа хода, шундый минутларда ничек инде атны тыеп, йөрәкне тыеп, сөйләшкән булып тормак кирәк?! Әбисе белән бабасы нәрсәдер әйттеләр кебек, Тәлгать аларны ишетмәде, ишеткәнен дә аңлый алмады, малай өчен иң аңлашыла торганы хәзергә шул: аның янына — тарантаска этисенең сикереп утыруы, кулына дилбегәне алуы булды, алар зырылдап капкадан чыгып киттеләр. Малайның беренче мәртәбә тарантаска — үз тарантасларына — утыруы иде, бәхеттән теле бәйләнгән кебек, авылдан чыгып хәтсез җир киткәнче сүз әйтә алмыйча барды. Әле ярый, этисенең теле бар икән.

— Рәхәтме соң эти белән тарантаста утырып бару? — дип, мыек астыннан гына көлемсерәп сорап куйды ул берара. Шундук, ипләбрәк утырткан атлы күренергә тырышып, бер кулы белән аркасыннан кысып, малайны үзенә табарак тартты. Сугыш күргән, атышларда булган, революция ясашкан, ә беркатлылыгы һаман бетмәгән адәм баласының, малайдан «рәхәтме?» дип сорап торган була. Ерык авызыннан, тешәү чоры кичерә торган тигезле-тигезсез тешләреннән үк күренеп тора: малайның башы җиденче кат күктә иде. Ә барыннан да элек, Сәфәргалинең үзенә рәхәт иде бу минутларда.

Эти һәм малай — менә алар тарантас түренә, йомшак печәнгә янәшә утырып баралар. Баш очларында тургай сайрый, өстә зәңгәр күк, сулда һәм уңда — ерак та түгел, якын да түгел — күңелне алгысытып яшел урманнар күренеп кала — җәй башы урманнары. Яфракларга тут төшәргә өлгермәгән әле, алардан яшәү-яшьлек сулышы бөркелеп тора иде. Тишелеп, кәлшәләнә башлаган сабан ашлык басулары да яшел, еракларга-еракларга җәелгән киңлек һәм шул зөбәрҗәттәй җемелдәүче киңлекнең күк белән тоташкан җире дөньяның чиге кебек күренә иде малайга.

— Эти, бу дөньяда безнең авылдан башка тагы ничә авыл бар? — дип, кинәт кызыксынып сорап куйды Тәлгать. Аңарга офыкны — күк белән җирнең тоташкан чиген күреп бару, бер яктан, күңеленә шом сала: әгәр дөнья шуннан гына торса, бик бәләкәй чут икән, ничә генә авыл сыя торгандыр бу зәңгәр гөмбәз астына. Икенчедән, янында этисе утырып бару уйларын тынычландыра: этисе бөтенесен белә булыр. Сугышта булган, буржуйларны кырып йөргән, энисенең әйтүенә караганда, әллә ниткән зур-зур калалар күргән, аның этисеннән дә күбрәкне белгән кеше бу дөньяда бармы икән? Шуңа күрә андый этине яратырга, яратырга, андый этигә ышанырга, ышанырга кирәк. Икәү генә калган чакларында энисе Тәлгатькә гел шулай дип тукып килә иде.

Хәер, бер карасаң, Тәлгать белән этисен, аларны тартып бара торган атны чолгап алган һәм еракта-еракта камаланып чиге күренеп торган бу зәңгәр гөмбәз астында да әкәмәтләрнең бетәсе юк икән. Яңил авы-

лының тау башындагы манарасыз мәчете үзе генә дә ни тора! Манара урынында — түбә кыегындагы түгәрәк тишек. Мәзин шул тишектән генә башын чыгарып азан кычкыра, ди. Ә менә Тәлгатьләрнең Мәтәскәсендә ике мәчет, икесенең дә күккә ашкан ике манарасы бар. Аннары тагы Яңилне чыгып барганда, Югары очта болар юлын аркылы кичеп, дүрт тәгәрмәчле тәбәнәк арбага утырган, арбаны куллары белән үзе тәгәрәтеп баручы əкәмәт бер гарип узып китте. Тәлгатьнең әтисе, ул кеше тәмам узып киткәнче, атны тыя төшеп, дилбегәне ике куллап тартып торды. Әллә үзе өчен, әллә малайга аңлатасы килеп, авыз эченнән генә әйтеп куйды аннары: «Күрәсең, сугыш гарибе. Кыйбатка төште бу сугыш, бик кыйбатка төште!» Аңлап ук бетермәсә дә, Тәлгатьне дә уйландырып калдырды бу сүзләр.

Ә малайны уйландырган нәрсә аңа хәтле дә, әле бу сәфәргә чыкканчы ук бар иде. Әбисе аның колагына салып куйган иде теге көнне. «Бабаң базарга сиңа хәтфә кәләпүш алырга китте», дигән иде. Ә нишләптер базардан хәтфә кәләпүш кайтмады. Бераз дәшми-тынмый уйланып барганнан соң, кинәт һәм беркадәр сәер итеп сорап куйды малай:

— Бабай базардан миңа хәтфә кәләпүш апкайтмакчы булган, ә үзе апкайтмады. Син белмисеңме, әти, ник апкайтмады икән?

— Менә бит тарантас, ат сбруйлары алып кайткан, акчасы беткәндер, — дип өзеп кенә бетермәкче иде әтисе, әмма малайның моңсуланып калган матур күзләре бер генә минутка аны да уйландыргандай итте. Дөрес, тарантас һәм ат сбруйлары кирәклеккә кирәк инде, әмма малай көтеп торган хәтфә кәләпүш түгел шул алар! Һәм шунда кинәт Сәфәргалигә элекке җорлыгы әйләнеп кайтты.

— Бабаң алган булган ул хәтфә кәләпүшне, улым, бабайны ачуланмыйк, алган булган. Әнә бит каһәр суккан бу алпаут токымы (ул атка ымлап күрсәтте!) Тәмте тавында дулап, тарантасны аударып, бабаңның үзен канга батырып, пыр тузып чабып киткән. Хәтфә кәләпүш шунда тәгәрәп төшеп калган булса кирәк.

Әтисенең бу аңлатмасы малайны, әлбәттә, ышандыра: шулайдыр, шунда тәгәрәп төшеп калгандыр. Ләкин аңа карап малайга һич кенә җиңел түгел иде. Тәлгатьнең күңелсезләнүен, рухи халәтен сизеп алган Сәфәргали аны ничек тә тынычландырырга тырышып:

— Менә кордон кибетендә булмасмы, үзем алып бирермен,— дип әйтеп ташлавын үзе дә сизми калды.

Кордонда юллары уңды. Волплан биргән нарядны күрсәткәч, аңарга агач кисү делянкасын якын арада билгеләп куярга булдылар. Һәрхәлдә, лесничество пичәте кәгазьгә менеп кунды, койрыклы имза салынды. Ләкин, булмагач булмый икән, Тәлгать өметләнеп көткән хәтфә кәләпүш кордон кибетендә дә туры килмәде.

— Монда соң, кәләпүш кайдан килсен,— дип, үзенең дә хәтере кырылгандай, сөйләнә-сөйләнә чыкты әтисе.

Хәер, бик алай буш кул белән түгел иде. Бәйләгән җиреннән атны чишкәнче үк тарантаста утырып калган Тәлгате янына килеп басты. Кесәсеннән чыра башына кукуруз оны белән сахариннан катырып, алсу сиропка манылган өч этәч чыгарып тоттырды.

— Кара әле, этәч бит бу,— дип алгысып кычкырды гаҗәпләнүдән күзләре алышынган малай. Базар кайтышлый юлда тәгәрәп калган хәтфә кәләпүш хәсрәте минуты-секунды белән юкка чыкты, аның берүзенә берьюлы өч этәч бит! Шулай да комагайланып берьюлы яларга тотынмады, икесен кесәсенә салып куйды: үзе белә, кирәге чыгачак. Сахариннан катырган этәч бик бәрәкәтле булды, кайтышлый малайны дөньяның киңлеге яки тарлыгы һич кызыксындырмады, тузга язмаган сораулар биреп, әтисен дә йөдәтмәде, өйгә кайтып кергәнче җитте шул бер этәч.

### 3

Кайтып кергәнче эретмичә, шулай да кесәсендә әледән-әле кымтырыклап, саклап алып кайтты ике әтәчне. Берсен бабасына, берсен әбисенә бирде — янәсе, этисе белән тарантаска утырып барган җиреннән кучтәнәч. Дөньяны күп күргән карт тегүче озак чуарланып тормады, кучтәнәч икән кучтәнәч, татым күрмәгәнгә дә ни гомер, шундук әтәчне тоташы белән авызына озатты.

— Болай үзе бабаңның авызына үлчәп ясаганны сайлап алгансың, маладис,— дигән булды малайны үсендереп. Асылбикә түти генә кылчыкланып маташты:

— Һе, кара әле, нәкъ әтәч итеп килештереп ясауларын,— дип, әтәчне чырасыннан тотып, әйле-шәйлерәк күрә башлаган күз төпләренә үк китереп бераз гаҗәпсенеп карап торган булды да малайның үзенә кире бирде. — Рәхмәт төшсен, бәбкәм, минем авыз андый матур уенчыклар өчен бик иләмсез, үзең аша, игелек күргере.

Аннары, кинәт исенә төшереп, өстәде тагы:

— Алай юмартлыгың ташып торса, әнә иптәш малаең Гаптелләхәткә бир. Инде ике-өч трит кереп чыкты. «Тәлгать кайтмадымы?» дип.

Бу, чынлап та, колакка керә торган сүз иде. Малай, тәкәллефләнеп тормыйча, әбисенең кулыннан әтәчне кире алды, шундук урамга чапты. Чабуын шулай үтә сикереклэп чапкан иде, күпмедер вакыттан соң борынын бер дә харап салындырып кайтып керде. Бигрәк тә шунысы гаҗәп: өйдәгеләргә ләм-мим сүз кушмады, почмакка басып куырылып тынып калды. Тик әбисе кат-кат һәм бик йөдәтеп сораганнан соң гына, көтелмәгән тупаслык белән:

— Сорап тора. Малайлар арасында ни булмас,— дип кырт кисте дә, бүтән бер сүз дә әйтмичә, ишегалдына чабып чыгып китте. Тәлгать урамнан бөтенләй алышынып кайткан, аның гомердә болай әбисенә каты эндәшкәне юк иде. Үзенчә эченнән бермәл уйланып, ни дип юрарга да белмичә аптырап йөргәннән соң, ян сәкедә чабата ясап утыручы карты янына килеп:

— Нәрсә булган безнең ул Тәлгатькә? Берәрсе ярамаган сүз әйтмәгәндер ич?— дип, эчке пошаманын карты белән бүлешәсе итте.

— Әй, исең китмәсен иске чикмәнгә. Бала-чаганыкын белмәссең,— дип өздә дә куйды Корбангали карт. Ләкин Асылбикә түти бу очракта сизгеррәк күңелле булып чыкты, оныгы янында ул күбрәк була, шуңа күрә күбрәкне белә, малай әбисенә, эти-әнисенә караганда да, ныграк береккән, һәрхәлдә, болай керпедәй энәле торганы һич кенә дә юк иде. Бу гаиләдә, гомумән, Тәлгатьнең кайда туып, ничек бу якларга килеп чыкканлыгын, бигрәк тә этисенең кем булып, гомерен ничек очлаганлыгын малайга ничек тә белдермәскә тырышалар иде, Асылбикә түтинең борчылуы бигрәк тә «шуны тишмәделәрме икән?» дип шикләнүеннән иде.

«Бала-чаганыкын белмәссең!» имеш. Ай-һай ла, шулай гына булсачы! Хәлбуки, малайлар арасында да белмәстәйне белә торган, дөресрәге, белмәстәйне селкеп салырдай «төпсез кесә»ләр табыла икән шул.

Киткән чакта ул этисе янында тарантаста бик тә кукраеп утырып китүен күреп, көнләшеп калучылар булган булса кирәк. Тәлгать: «Без эти белән кордонда булдык!», «Мин апкайткан ул әтәчле конфетны бүтән бер җирдә дә ясый алмыйлар, кордон кибетендә генә ясыйлар икән. Эти шулай ди», «Минем эти кулына эләксәме? Иртә инде ул айгырны» кебек сүзләрне өсте-өстенә тәтелди башлагач, шул кәнче күбәләкләрдән берсе, бигрәк тә Гаптелләхәткә эләккән сахаринлы әтәчкә күзе явып калганы булса кирәк, дуамал гына ярып салмасынмы ярманы:

— Ул бит синең этиең түгел Сәфәргали абый.

Шуңа өстәп икенчесе:

— Син бит үзең дә безнең авылныкы түгел, әниеңә тагылып килгән килмешәк малай, әгәр беләсең килсә...

Бу сүзләрне ишетеп, Тәлгать кинәт аптырап калды, ул әлегә мәсьәләнең очына һич чыга алмый: әллә үртәүләре? Әллә... Ни дә булса әйтергә, кирәкле җавапны бирергә сүзен тапмый, теле әйләнми иде. Эндәшми торуны малайның масаюы дип кабул иткән иң белдеклесе, арада үзенең гәүдәлерәк булуы өчен дә борын күтәргәне, тотты да кинәт Тәлгатьнең башына китереп сукты.

— Ә үзең беләсеңме син кем малае икәнлегеңне? Син бит буржуй малае.

Һәм киттеләр, киттеләр өсте-өстенә өстәп... Аларга Тәлгатьнең телсез калуын, бөрешкәннән-бөрешә баруын күреп тору болай да кызык иде, ул да түгел, Гаптеләхәтнең арага кереп иптәшен якларга маташуы тегеләрнең каннарын тагын да кыздыра төште.

— Аның әтисе аклар яклы булган. Кызыллар атып үтергән аны. Әпсәләм абыйдан үзем ишеттем.

— Әйтмә ул хәтлесен: буржуйдан туган бәләкәй буржуйның ачуын китерерсең.

— Дабай, икенче вакытта аны уенга катнаштырмыйк.

— Тешләр дисең мәллә?

— Тешләр дә. Бүре баласы ич ул.

Инде моннан соң да эндәшми калыргамы? Бәләкәй булса да, Тәлгатьнең дә, әлегә үзе ышанып килгәнчә, әтисе бар, әнисе бар, әбисе-бабасы, атланып су эчәргә төшәргә атлары бар. Кечкенә генә булса да йөрәге, бу хурлык сүзләрне ишетеп дөп-дөп тибә башлаган йөрәге бар. Үзен-үзе тотып тора алмыйча, бар көченә, сырып алган малайларның барысына да — хурлаучыларына да, яклаучыларына да җен ачуы белән кычкырып җибәрде ул:

— Дөрес түгел... Алай түгел. Бүре баласы түгел мин, кеше баласы мин!..

Һәм елый-елый өйгә чапты. Әлбәттә, елаганны әбигә дә, бабайга да сиздерергә ярамый иде, арт урамнардан урап, малайларга хас булмаганча җитди уйланып, әле генә колак яныннан бер-бер артлы яңгырап үткән хурлыклы сүзләргә ышанырга да, ышанмаска да белмичә үртәнеп кайтты. Малай өчен бик авыр, күтәреп булмаслык авыр минутлар булды бу. Күңелендә иптәш малайларына карата үпкәле әрнү, шул ук вакытта кайдадыр тирәндә, тирәндә сүнәргә ашыкмый торган әрсез ышаныч та саклана иде: «Үрти генә торганнардыр. Үзләре кордонга бармаганга, баллы әтәч эләкмәгәнгә. Ник булмасын минем әти? Әни дә, әби дә, бабай да бар. Нишләп мин бүре баласы булыйм ди?»

Шундый сораулар белән тыгылып, сулышы кысылгандай кайтып керде ул. Аның берәү белән дә сөйләшәсе килми, ышанычы какшаган, юатулары кирәкми, малайлар әйткәнне кире кагарга да теләми, үйнатмасалар үйнатмаслар, үртәсәләр үртәрләр, ләкин ул үзе белә, ул бүре баласы түгел... түгел.

Әнә шундый, җаны котырган чакта, әби дисәң дә әби, сорау биреп, сүзгә кысылмакчы булып маташа. Кирәгең бар иде!

Сүзен тапты, каз бәбкәләре исенә төшкән әбинең.

— Бәбкәләреңне онытып бетермәдеңме, улым, уенга күзең-башың акаеп?

— Оныттым, — дип, тик бер сүз белән җавап кайтарды малай. Һәм ашарга да сорамыйча, башка вакыттагы кебек, артык сыланып та тормыйча, чабып чыгып китте.

Менә инде ул Таш чишмә болынында. Казларын тапты. Бәбкәләре, аллага шөкер, барлык сигезе дә исән-саулар. Инде ныгый башлаган томшыклары белән чирәм чүпләнеп йөргән булалар. Аларга ни... Эти-

эниләре яннарында. Бигрәк тә ата каз муенын гел югары тотып, «тирәюньдә берәр хәтәр юкмы?» дигәндәй, гел карангалап тора.

Тукта, чү! Бүген генә күрдемени Тәлгать бу ата казны? Язга чыкканнан бирле бәбкә саклау аңарга йөкләнгән төп эш ләбаса! Нишләп соң әле ул ата казның сакта болай уяу торуына бүген генә шулай игътибар итте? Юк, юк, колак яныннан гына узмады теге белдекле башларның үртәуләре. Нидер кузгалды Тәлгатьнең күңелендә. Нәрсә икәнен ул, әлбәттә, әйтә алмый, моңарга башы җитми, ә күңеле сизенә: кузгалды, кузгалды. Нәрсәдер балаларга хас булмаган, куркуга да, үпкәләүгә дә, билгесез өметкә дә охшаган әчке тынгысызлык кузгалды. Кич кенә житсен, әтисе генә кайтсын, ул аңардан урамда малайлар әйткән сүзне сораячак, ачыклаячак. Әтисеннән сорамаса, ял көне менә әнисе кайтыр. Әнисеннән сорар, һич шөбһәсез, сораячак. Ә хәзергә малайның иң ачык белгәне шул булды: ата каз ояны — бәбкәләрне иң уяу саклый торган каравылчы икән. Боларныкы гына түгел, бөтен ояларныкы шулай, имеш. Ничек соң әле бүгенгә хәтле Тәлгатьнең моңа башы җитмәде икән? Кыскасы, Тәлгать ул көнне кичәге Тәлгать түгел, ул, башына олы кеше бүреге киеп чыккан бәләкәй «зур кеше» кебек, чак-чак кына көлке, чакчак кына «күктән төшкән» бер малай иде.

— Әти! — дип, гадәттәгечә, кычкырып каршы чыкты ул, Сәфәргали атка атланып кайтып кергәч. Һәм кинәт, нәрсәнедер исенә төшергәндәй, туктап, тынып калды. Бу — әллә ничегрәк килеп чыкты, моңа Сәфәргали дә, әлбәттә, игътибар итмичә калмады.

— Иә, ни әйтмәкче иден? — Малайга якынлаша төште, гадәтенчә кочып алмакчы булды. Ләкин, малайның ничектер маңгай астынарак карап кан күзләрен күреп, кинәт кенә ул да аңга килгән кебек булды, — әллә берәрсе абижать иттеме үзеңне? Кәмитрәк карыйсың бүген.

— Атны эчереп кайтыйммы?— дип сорады малай, бу юлы инде «әти» дип кычкырып эндәшергә бик үк ашыкмыйча. Хәер, гел катып торып та булмый, нәрсәдер әйтергә кирәк иде ләбаса! Аннары тагы, Сәфәргалиме, Корбангали абзый үземе берәр җирдән кайтса, атланып ат эчерә төшү малайның көтеп ала торган эше иде.

— Кирәкми, Заһри бабай чишмәсендә эчерә кайттым, — диде Сәфәргали, аны-моны искәрмәстән. Кем белгән бу катлаулы дөньяның эт эчәгеседәй чорналып беткән әчке серләрен. Белгән булса, болай коры эндәшер идеме соң Сәфәргали! Эчерә кайткан булса да, бөтенләй кирәкмәсә дә, малайның күңелен кайтармас өчен, атландырып, капканы үзе ачып чыгарып җибәрер иде.

Ә малайга исә Сәфәргалинең шул коры эндәшүе җитә калды, иртәнге якта урам малайлары салган коткыга керосин сибү булды бу. Малай, гадәттәгечә, әтисенең итәгенә тагылып өйгә керергә ашыкмады, ишегалдында бер ялгызы басып калды.

4

Гел өйдә чуалган Асылбикә түти белән Корбангали абзый, аңлап ук житкермәсәләр дә, сизеп торалар: соңгы көннәрдә, кай якка икәнен дә белмәссең, әмма үзгәрде малай. Алагайланып чабу юк, ун сүзгә бер җавап, гел диярлек өйдә, өй тирәсендә чуала, каз бәбкәләрен саклауны да исенә төшертми, үзе белә, уйнарга чыкканда да гел күрше малай Гаптеләхәт белән генә. Һәрхәлдә, элекке кебек эт белән эзләргә урын калдырмый башлады. Баш ташлап чапканда да әбигә борчу иде, болай кинәт акыллыланып китүе Асылбикә түтине бигрәк тә аптырашта калдырды. Дөресен әйткәндә, алар бөтенесе, өй эчләре белән, малай алдында чын хакыйкатьнең кайчан да булса бер ачылачагын, Тәлгать бу йортка нярә генә килгән кеше икәнлеген беләчәген онытмыйлар, ләкин

моны ничек тә булса кичектерергә тырышалар — бөтенесенең уртак уе бар: үскәч, аң керә төшкәчрәк ачылса, малай моңа әллә ни әһәмият бирмәс, җинел уздырыр дип фараз кылалар. Син көтәсең берне, дөнья синең юлыңа икенчене чыгарып куя: әнә бит малай дигәнең кинәт малайлыктан чыгып, яше җитмәгән олы кеше булып бара.

Болай да сәерсенебрәк күзәтә йөргән Асылбикә түтигә бер көнне Тәлгать искәрмәстән генә:

— Әби, бүредән бүре баласы гына туа ич? — дип сорап куйды. Бигрәк тә шунысы сәер: сүзенә җавап та көтмичә, атылып өйдән чыгып китте. Башка килмәслек сүз һәм сискәндерә торган кинәтлек белән. Асылбикә түти моны үз эчендә генә, әлбәттә, саклап кала алмады, карты кайткач, аның белән дә уртаклашырга булды.

— Кара әле, сиңайтәм, — дип тотынды ул, сүзне мөмкин чаклы күпертмәскә тырышып, — күзеңә Тәлгать чалынмадымы шунда?

— Шул гына истә ие, — диде тегесе, нидәндер сырты кабарганлыгын сиздерә төшеп.

— Истән дә чыгарып ташлама, безнең өстәге ятим ич ул.

Һәм карчык, ничек тә картының җаеннан торырга тырышып, әкренләп-әкренләп Тәлгатьнең соңгы көннәрдәге үзгәрешен, кинәт олы сымак булып китүен, малайлар белән уйнаудан качуын, вакыты-вакыты белән әллә ниткән сәер сораулар биргәләп куюын сөйләп китте-китте дә, ниһаять, әле яңарак кына биргән башваткыч сораудан үзенең шөйлә аптырап калганлыгын әйтеп, аңлатуны сорагандай, картының күзләренә карап калды.

— Бүрек астына яшереп асрап булмый ич тере җанны, кемнән дә булса берәрсеннән колагына кергәндер: үзенең буржуй токымы икәнлеге.— «Буржуй» дигәнне әллә ни тирәнтен аңламаса да, картының тупас эндәшүе йомшак күңелле Асылбикә түтине аптырата куйды. Ул ни әйтергә дә белмичә сүзсез калгач, карт яңадан ялгап алып китте.— Бездән дә бигрәк әнә олыларына кагыла, берсе — тапкан анасы, икенчесе әзерне күтәреп алып, «Әти булдым!» дип кабарынып йөрүче. Чабалар бит икесе ике якта. Бүген кешедән ишетеп, җеннәрем чыкты: урман артыннан көн вә төн болай тырылдап чапкач, мин аны үзебез турында кайгыртуы дип йөрим, бактың исә, ирләре сугышта үлеп калган солдаткалар өстенә кояш чыгарырга йөрүе, имеш. Янәсе, зур түрә булган: ярлылар кәмитеты башлыгы. Ә үзенең төп нигезендә алабута, кычыткан үсеп утыра.

Хәер, картның тузынуы озакка бармады, малае Сәфәргали кайткач, хәзергә урман турыннан эндәшмичәрәк калуны хәерле санады. Җитмәсә, Сәфәргали дә сүзне куертырлык сәбәп бирмәде. Ул аеруча шат күңелле, ачык чырайлы иде бүген.

— Бер дә таба исе чыгарганыңны сизмим, әни җаным. Онытмагансыңдыр, кунак кайтасы көн ич бүген. Курсны бетереп, бер карышка үсеп кайтасы, әгәр беләсегез килсә.— Аннары сүзсез утырган әтисенә борылып, шундый ук күтәренкелек белән дәвам итте, — ә әти тарантасны җиктерергә, шәт, җәлләмәстер инде. Акча китерә торган сөекле киленен апкайтырга, дим.

Аннары ул тиз генә сакал-мыегын кырырга утырды, олыларның үзара мәгънәле ымлашуларына игътибар итмәде. Олыларның Сәфәргали алдында ымлашып кына сөйләшүләре шулай ук аңлашыла: алар сугышта йөреп, мактанчык Корбангалинең үз сүзләре белән әйткәндә, «камисар» булып кайткан, монда да әледән-әле волость юлын таптаучы, әгәр чын булса әгәр, крестком, кооператив дигән нәмәстәкәйләр оештырып, ирекле сәүдә чыккач, «Тагы иске заман кайта, ыштансыз гел ыштансыз булып калачак!» дип, түш киереп йөри башлаган кибетче Вәлиханныкыларның тез асларына сугарга йөрүче Сәфәргалидән, үз малайлары булса да, чак-чак кына шүрлиләр иде.

Кырынып беткәннән соң, Сәфәргали үзенең фронт истәлеге итеп саклый торган гимнастеркасын алды, солдат гадәте буенча, аңарга әчтән ак яка текте, сугыш значокларын алып такты. Әзерлек чараларын үзенчә күреп бетергәннән соң:

— Теге малай кайда шатаеття безнең? Әнисен каршы алырга аны да алып барырга ие исәп, — дип, кемгә әйткәнен үзе дә рәтләп төшенмәстән сөйләнеп куйды. Корбангали карт, көннең мондый тантаналы икәнлеген шундук абайлап, сүзсез-нисез чыгып киткән, тарантасны ишегалдына ук чыгарып, көпчәк майларга керешкән иде. Нидән сүз башларга белмичә, бераз икеле-микелерәк торганнан соң, Асылбикә түти шулай да хәзергә сүзне кузгатмаска булды булса кирәк.

— Әле генә шушы тирәдә чуала ие, кая олакты соң шул арада? — дип, юри чәпчегән булып, малайны эзли чыгарга әзерләнде. Ләкин чыгып өлгермәде, ишек тоткасына ябышкач, кире борылып, артык куертмыйча гына, малайның соңгы көннәрдәге үзен тотышын, бигрәк тә бүген, тора торгач, шундый әкәмәт сораулар биреп куюын әтисенә җиткерүне кирәк тапты.

— Ничива, туйга хәтле ярасы төзәлер. Руста шундый мәкаль бар, эни,— дигән булды тегесе. Ләкин бу аның үзенчә тыныч күренергә тырышуы гына. Күңеле буш түгел, малайның соңгы вакытларда үзен кыргыйрак тота башлаганын Сәфәргали үзе дә күрми түгел иде.

— Менә әнисе дә кайтса, без икәүләп аның тузанын кагарбыз, курыкма, әбисе, — дип өстәде аннары, үзеннән дә бигрәк «әбисен» тынычландырырга тырышып. Ләкин сизенә, бик тә яхшы сизенә: монда «тузан кагу» белән генә берни дә чыгарып булмаячак, киресенчә, нәкъ әнә шул «тузан кагып» уйнау малайны кирегә сикертүе дә мөмкин иде.

Еракта чуалмаган булса кирәк, әбисе Тәлгатьне тиз алып кайтты. Малайның күзе, барыннан да элек, киенеп-ясанып, күкрәгенә значокларын тагып куйган әтисенә төште. Ул әле аны мондый «гвардин» кыяфәтендә бер генә дә күргәне юк иде. «Әл-лә-лә! Күрегез әле минем әтине!» дип кычкырасы килде малайның. Болай киенгән әтине күрү, әлбәттә, уен түгел иде. Шулай да эндәшмичәрәк калуны кирәк тапты — ул инде үзен кулда тотып кала белә башлаган. Әтисе хәзер бергәләп әнисен алмага барырга әзерләнергә кушкач та, артык очынмыйча, түбән карап кына әйтте:

— Мин бармыйм, без Гаптеләхәт белән тегермән буасына балыкка барырга сүз куештык,— диде.

«Бармыйм!», «Балыкка барырга сүз куештык» — карасана бу карсакны! Ничек өздереп сөйләшә башлаган. Әле кем белән? Әтисе белән! Димәк, әбисе дә тикмә генә сөйләми торгандыр, Асылбикә түтине берәү дә бер вакытта да әләкче дип телгә алганы юк, югыйсә. Димәк, моңарчы малайдан сер итеп саклаган чынлыкны, авыр һәм котылгысыз чынлыкны кайдадыр, кемнәрдер «тишкәннәр». Хәлбуки, моңа артык әһәмият бирмәгән кебек күренергә тырышты Сәфәргали.

— Бармыйсың икән — бармыйсың, көчлек эше түгел, — диде ул, артык кыстау да, үтә исе киткәнлек тә күрсәтергә ашыкмыйча. Шулай да, шаярткан булып, малайның муенынннан кочып алмыйча кала алмады, — алайса, әниең белән без кайтышка табында кыздырылган балык булачак? Ишеттеңме, әбисе, майны жәлләмә, тәмле итеп кыздыр Тәлгать апкайткан балыкны.

Зәйтүнә эшләрен бетереп, җыештырасын җыештырып, курс администрациясеннән тиешле таныклыкны алып, әзерләнеп куйган иде, Казакларда озак юанмыйча юлга чыктылар. Көн кояшлы, күк зәңгәр, тирә-як еракларга-еракларга хәтле ачылып күренә, тирә-якта яшәреп калыккан сабан ашлык басулар җәелеп ята, кыскасы, сагынышып торган кешеләрне дә бермәлгә җиңеләйтеп, гамен оныттырып, сәбәпсез бәхет-сәгадәт-

кә күмә торган көн иде. Бәлки икесенең дә шул билгесез бәхеткә чумуларыннандыр, бер кавым вак-төяк сораштырулардан, өй хәлләре белән кызыксынудан уза алмыйча бардылар. Бактың исә, икесенең дә телен бәйләгән җепләр булган икән.

— Көне нинди матур, әгәр без туй итеп өйләнешкән булсак, безнең туебыз нәкъ менә шушындый кояшлы җәй башында булырга тиешле булгандыр, — дип, кинәт, яшь вакытындагы тел бистәсенә әйләнеп, сайрарга кереште Сәфәргали. Дилбегәне тарантас башына бәйләде, атны үз җаена куйды — атлый бирсен, бу минутта Сәфәргалидә сугышка хәтле, яшь чагындагы иләслеге кузгалып тора, Зәйтүнәсе «авызың белән кош тотып бир» дисә, авызы белән кош тотарга әзер иде. Зәйтүнә тарафыннан андый четерекле тәкъдим булмагач, ул солдатча тәкәллефсезлек белән:

— Сагындым, хатын, каршы килергә не смей,— диде дә, хатынын ирләрчә үзенә тарта төшеп, бит алмасын үбеп алды. Әйткәнебезчә, көн бик якты, төшлеккә җиткән кояш, нәкъ аларны гына күзләгән кебек, үтә туры карый, әле генә булып узган үбешүдән соң икесе дә уңайсызланып, тынып калганнар иде.

— Син, ичмасам, Зәйтүнәнең ничек укыганлыгы, характеристикасы белән кызыксынып идең, алай тилергәнче,— дип сүз башлады Зәйтүнә, тынлыкны бозып. Мактанасы килеп алдан ук әзерләп куйган иде булса кирәк, сумка кесәсеннән курс администрациясе биргән таныклык-характеристиканы чыгарып тоттырды.

— Мин аның шулай буласын әллә белмәдемме? Эш чыгарырдай икәнлегеңне алдан ук белмәгән булсам, ай буена сине Казакларда кадаклап тотарга әллә Сәфәргали абыең риза булыр идеме дисең? — Ул кәгазьдән күз йөртеп уздырган, эшнең нәрсәдә икәнен инде белеп алган, ләкин, бу сөенечне тагы бер уртаклашмыйча, таныклыкны кире кайтарып бирергә ашыкмый иде. — Только шуны белеп тор, аппагым, больше мин сине үз янымнан бер шак та җибәрмим.

— Наркомпростан приказ белән кушсалар дамы?

— Кушсалар да. Син Наркомпросныкы түгел, син минеке.

Сәфәргали үзе дә сизеп тора: бу минутта аның җанында артык хөр күңелле коры куаныч Корбангали тегүче каны кузгалды, Наркомпросның монда һичбер катнашы юк, телгә алынса да әлеге шул бәхетле тилелек аркасында гынадыр. Тарантас башыннан чишеп дилбегәне кулына алды, атка бер чөңгереп, дилбегә кагып җибәрде. Малкай да, шуны гына көткән диярсең, бермәл тарантас шыгырдатып юыртып барды, колакта тик тояк тавышлары гына тупырдашып торды.

— Йә, әйтәсе сүзләрең шуның белән беттеме? — дип, ничектер яшертен мәгънә салырга тырышкандай сорап куйды Зәйтүнә, ат юыртудан чак кына тыйлыга төшкәч.

— Минеке бетте, — диде Сәфәргали. Һәм кинәт, сискәнеп киткәндәй, тавышын күтәрә төшеп сорап куйды: — Нәрсә? Әллә берәр ярамаган сүз ычкындымы?

— Минеке бетмәде, — Зәйтүнәнең дә күңеле купшыган иде, Сәфәргалинең юк-бар соравына җавап биреп торуны хәтта кирәк дип тә тапмады, күңеле анда түгел иде. Иренә елыша төшебрәк утырды, ләкин йөзен аңардан ничек тә яшерергә тырыша иде.

— Әйе, минеке бетмәде... әйтәсе сүзем, Сәфәр,— тавышы кысыла төште хатынның, ләкин бер кузгалгач әйтәсе сүзен әйтмичә калыр исәбе сизелми иде,— ...минем буемда бар. Озакламыйча безнең балабыз булырга тиеш.

— Бәрәкәт, ник аны моңарчы әйтмәдең? — Бу юлы инде һичбер сайрашусыз Зәйтүнәсен кочып алды Сәфәр. — Әләгәчәк сиңа моның өчен, белеп тор.

Йа хода, бер көнгә нихәтле сөенеч: кояшы нинди жете, сабан тургайлары ничек сайраша, сагынышып торган ир белән хатын янәшә утырып кайталар, Зәйтүнәнең сумкасында мактап язылган таныклык. Хәлбуки, болары чүп тә түгел Сәфәргали өчен. Аның өчен иң зурысы, иң әһәмиятлесе: аларның баласы булачак. Бу юлы инде чып-чын әти, кешедән калган кыргый балага әти булып күренергә тырышу түгел.

Бу соңгы уе Сәфәргалине кинәт сискәндереп куйды. Бер үк вакытта ул моның телдән үк ычкынмаганлыгына сөенеп тә бетә алмый иде. Һәр икесе үз дөньясына чумып, беравык сүзсез бардылар. Кайтып житәргә күп калмаган, Зәйтүнәнең кәефен ничек кенә сакларга тырышмасын, бу аулак юлдан файдаланып, Сәфәргалинең Тәлгать һәм аның соңгы көннәрдәге үзен тотышы турында, әлбәттә, әйтеп каласы килә иде.

— Алайса, Зәйтүнә-жанаш, әйтелеп бетмәгән бер сүз миндә дә кала язган икән,— дип башлады ул, уңайсызланганын ничек тә сиздермәскә тырышып, — мәгәр сүз бирешеп керешик: үпкәләштән булмаслык булса гына.

— Нинди үпкәләш ди ул ир белән хатын арасында? — Шулай да Зәйтүнә сагая төште. Сәфәргали, бер башлагач сүзгә суынырга да, сузыларга да урын калдырмаска тырышып, Тәлгатьнең соңгы вакытта аңлашылмый торган якка таба үзгәрә башлавын, сүзсезләнүен, иптәш малайларыннан качуын, тора торгач әбисенә әкәмәт-әкәмәт сораулар биреп куйганлыгын, бергәләп әнине алмага барыйк, дигәч тә төрле сылтау табып бармыйча калганлыгын, дөреслектә моңа үзенең артык игътибар итмәгәнлеген Зәйтүнәгә ничек тә сиздерергә тырышып, иплән кенә сөйләп бирде.

— Сиңа чат ябышырга торуымның сәбәбе дә шунда, Зәйтүнә, — диде ул, сүзенә йомгак ясап һәм, уйланып калган Зәйтүнәсен ничек тә юатырга тырышып, өстәде: — баягынак Наркомпроска тел-теш тидерүем дә, ихтимал, шуннан булгандыр. Кыскасы, Зәйтүнә-жанаш, безнең эшләр катлаулана бара: безгә, кеше балаларын укыту-өйрәтү белән генә чикләнмичә, үз балабызны да өйрәтеп, кеше итү бурычы төшә бүгеннән соң. Син теләсәң нәрсә әйт, хатын, миңа Тәлгатьнең әбисенә әйткән сүзләре ошамады. Кайдан гына колагына кереп калган булмасын, «бүре баласы» турындагы фикерне аның башыннан чокып чыгарырга кирәк. Ничек итеп? Анысы синең эш, минем эш. Юк, бүре баласы түгел ул, безнең бала, малайны бүреләргә бирмик.

— Бәлки көзгә минем буемда барны искә алып... — нәрсә әйтергә теләгәнлеген әйтеп бетермәде Зәйтүнә, кирәкле генә сүзен таба алмады.

## 5

Шулай да Сәфәргалигә икенче көннән үк малай белән шөгыльләнә башларга туры килмәде. Кордоннан авыл Советына хәбәр иткәннәр: билгеләнгән делянканы килеп кабул итәргә һәм, озакка сузмыйча, кисүэшкәртү эшләренә керешергә. Димәк, Сәфәргалинең волостьтан кантонга, кантоннан янә волостька чабулары бушка китмәгән икән. Сәфәргали, авыл Советы председателе Мөхсинов белән сөйләшеп, шундук кордонга үзе китәргә булды.

— Мин кайтышка син монда үзең кирәк тапкан агайларга сүз салдыра тор, кичкә бер сөйләшеп алырбыз да иртәдән эшкә тотынырбыз.— Чыга башлагач кире борылып, өстисе итте:— Бармагы эрә дә үзенә кәкре кешеләрнең белмичәрәк калуы хәерле.

— Мужикның бармагы үзенә кәкре булмаганын кайдан табарбыз икән? — дип, иптәшләрчә шаяртып калды Мөхсинов.

Шулай да тапкан тагын. Кичен авыл Советы өендә егерме бишүтыз кеше — күбесе ярлылар комитеты членнары — башларын кашыш-

тыргалап утыралар иде инде. Башларын кашулары кычытканнан түгел, «Миңа элэгер микэн? Ай-һай ла, элэксэ генэ ярар ие» дип, нэфеслэрен сузудан иде булса кирэк. Сэфэргалинең авылдашлары белэн беренче мэртэбэ болай зурлап очрашуы иде бу, бераз сагая төшебрэк исэнлэште. Мэтэскэ кешелэрен ул яхшы белэ, элбэттэ, берэр кантор кешесе килгэн булса, алар ныграк кызыксына төшэрлэр иде, авыл тумасы — тегүче Корбангали малае гына баш эйлэндерэсе булгач, утырдың ни дэ утырмадың ни дигэн төслерэк караячаклар. Шушы шикне тиз генэ таратып ташларга телэгэндэй, солдатча кистереп сүз башлады.

— Менэ болай тора эш, җэмэгать.

— Протокол язасымы, юкмы? — дип бүлдерде Мөхсинов, үзеннэн элек Сэфэргалинең сүз башлавын бик үк өнэмичэ.

— Анысы сезнең эш, Фазылҗан абый,— җавабы шул булды Сэфэргалинең. Аны мэсьэлэнең рэсми ягы кызыксындырмый, сузмыйча гына эш турында эйтеп бирэсе килэ иде.

Лэкин сөйлэшэ башлагач сүз сузылды. Җэмэгать җыенына дип килеп тэ, туйганчы бер эчне бушатмыйча китэме соң Мэтэскэ кешелэре! Кисэргэ тамгаланган агачның дүрт йөз төп кенэ булуы нэфсесен сузып утыручыларның чирегенэ дэ житэрлек түгел иде. Моны белеп алгач, кырмыска оясына таяк тыгып болгаткан кебек булды. Төрле яктан:

— Булгач-булгач бутка булсын ие ул, өйрэ генэ пешэ икэн.

— Балта тотып урманга бер керсэм, тамгалысын-тамгасызын тикшереп тормыйм инде мин.

— Көтү кайтыр вакыт житэ, бик сузмаганда да ярый болай булгач.

— Миңа ни... Мунча сиплэтергэ өч-дүрт бүрэнэ кирэк, анлык кына фытыр сэдакасы, шэт, тияр эле.

— Хөрияте безнеке, урманы казнаныкы диген, алайса,— кебек репликалар яварга тотынды.

Беренче нэүбэттэ күздэ тотылган мохтаж хуҗалыкларның — өйлэре өслэренэ ишелергэ торган карт-коры, гарип-гораба, ирлэре сугышта үлеп калган фронтовик семьяларның исемлеге укылгач, «кырмыска оясы» бермэл таяк тыкмыйча ук тузгып китте. Эшнең уен түгел икэнлеген янэ дэ бер кат абайлап алды Сэфэргали. Монда эреп агып утырырга ярамый. Дилбегэне кулда тота белергэ кирэк иде.

— Шаулап туйдыкмы? — дип кырт кисте ул. Солдат гадэте буенча гимнастерка каешын бер сыпырып куйды, турая төште, өтеп ала торган житди бер караш белэн бөтенесе өстеннэн күз йөртеп чыкты. Гүяки эйтэ иде аның бу карашы: юк, мин сезгэ тегүче Корбангали малае гына түгел, мин утны-суны кичеп, окоп бете туйдырып, революция ясашып кайткан Сэфэргали Корбангалиев булам, минем белэн шаяру яхшыга алып бармаячак! — Мөмкинме миңа түгэрэк кенэ бер йомгак ясап куярга, Фазылҗан абый? — дип, кирэк табудан да бигрэк эдэп йөзеннэн, Мөхсиновтан сүз сораган булды һэм, үзен кызып китүдэн ничек тэ сакларга тырышып, ипле генэ ялгап китте:—Бүгенге кенебез, иртэге кенебез, и бөтен гомеребез, и бөтен килэчэгебез өчен бер хакыйкатьне мыекка урап китик, авылдашлар! Үз абзарыңнан арыны күрергэ телэмичэ, йомран кебек үз өнендэ генэ тынчып яшэү заманнары узды, без революция алып килгэн яңа заманда яшибез. Бутка өмет итеп килеп тэ, өйрэгэ генэ авызы пешүдэн зарланып алды берэүлэр. Икенчелэребезнең мунча сиплэтэсе бар икэн. Белмэссең, дөнья булгач, өйне Вэлихановларныкы кебек аслы-өсле итеп салдырырга хыялланучылар да юк түгелдер. Хыял эйбэт нэрсэ, илла-мэгэр өйлэре терэтсэң дэ аварга торган карт-коры, ирлэре сугышта үлеп калган фронтовик семьялары турында кайгырту эйбэтрэк. Беренче чиратта, шундыйлардан башлыйк. Экренлэп-экренлэп безгэ дэ күк капусы ачылыр. Озын сүзнең кыскасы, монда булган иптэшлэр — аларның исем-

леге Фазылҗан абыйда бар — билбауларыгызны бәйләп, учларыгызга төкереп, булган балта-пычкыларыгызны кыстырып, иртәгә сәгать алтыга сельсовет бусагасы төбенә килеп баскан булыгыз. Шуннан бер күмәк булып, солдатларча тигез атлап кузгалырбыз. Җырлыйсы килгәнгә җырлап җибәрү дә рөхсәт ителә, так что тамакларыгызны майлап-җайлап килегез. Өйрә икән өйрә — хәзинәдә бары хәзергә шул. Безнең сүз шуның белән вәссәләм. Шулай бит, Фазылҗан абый?

Олы җирләрдән мактау кәгазьләре алып, күкрәген бу тирәдәге адәм күрмәгән значоклар белән тутырып кайткан, кайтканнан соң да кантор юлларын байтак таптаган, теленнән авыл халкына бик үк аңлашылып та җитми торган китап-газета сүзләре ычкындыргалаучы бу «зимагор-солдат»ны бераз ятсыныбрак, аңардан чак кына өркебрәк йөрүче авыл агайлары — җор сүзгә җаннарын бирергә әзер Мәтәскә кешеләре — Сәфәргалинең кыска, үтемле, арада шук сүзләр дә кыстыргалап җибәргән соңгы «йомгаклау речennән» үтә дә ачылып киттеләр. Дөресрәге, нәкъ әнә шуннан соң аларның телләре ачылды, өйгә кайту юлын оныткан кебек булып калдылар. Чынлап та, кызык килеп чыгарга тора бит әле бу килештән: имештер, үз эшеңне бер якка куй да, дәррәү кубып, әллә кемнәр өчен урман кисәргә чап. Дөньяда булмаган-ишетелмәгән хәл бит бу, билләһи.

— Өмәгә дисәң, өмәнең дә соңыннан бәлеше-сые була, моның бит әле ул ягы да күренеп тормый, — дип, уенын-чынын бергә кушып, сүз кыстырып куйды берсе.

Икенчеләре шуңа ялгады:

— Минем балта бар барлыкка да, белмим, кешегә дигән агачка үтәр микән ул?

— Анда без куна-төнә эшләргә барабызмы? Әллә көнен эшләп, кичкә кайтачакбызмы?

— Я, я.. бер төн генә Камилән синнән башка да йоклар.

— Минем өйдә сәгать юк, әтәч кычкыруы белән генә йөрим. Сәвит өе бусагасына үтә иртә килеп, озак көттерерлек булмагыз, җәмәгать.

Кыскасы, хәзергә бөтенесе дә кәефле күренә, киреләнеп торучы булмады, төн чыкканчы карашларын үзгәртеп куймасалар гына инде. Ә моның нигезендә гади авыл кешесенең башы җитмәслек, тик төйгысын гына сискәндергән факт ята иде: кара әле, бу Корбангали малае, камисар егет, өйлек бүрәнәгә темтенүчеләр арасына үзен ник кертмәде соң? Ә үзләренең төп нигезләре урынында ничәмә еллар инде алабута да кычыткан үсеп утыра. Моңа башы җитмәгән бер агай, үтә сәерсенеп, юаш кына сорап куйды:

— Кара әле, кем, тавариш Корбангалиев дип әйтимме, «камисар» дип тә йөртәләр инде сине, чәйнәбрәк каптырчы без мокытларга: өйлек бүрәнәгә мохтаҗ байгышлар рәтенә нишләп әле син үзеңне кертмәдең? Нигезегездә котырып чүп үләне үсеп утыра, әтиең-әниең картаймыш көннәрендә кеше морҗасыннан төтен чыгарып азапланалар.

Соңга калып кузгатылган бу мәсьәлә бөтенесен бермәл аптыраштa калдырды. Чыгарга кузгалып, бусагага барып җиткәннәре дә чыкмыйча тукталып калдылар. Тагын бер ярыйсы гына гөрләшү булды.

— Мөгезеннән тотты үгезне Мөбарәкша, даром что Мүкләк Мөбарәкша булсын.

— Син, Фазылҗан энем, әйтү шушы, кенәгәңнең бер читенә камисарның үзен дә теркәп куй, җәме. Ничә еллар сугышта йөреп кайтты, җитмәсә, үзе ранный, кемдә бар аныкы кебек җиһазлы түш? Исүзсез аның үзенә кирәк башта.

— Таралышыгыз дигәндә генә сез, панимаешь, — Сәфәргали үзе дә аптыраган иде бу минутта.— Безгә соңыннан, тишек-тошыкларны ямап бетергәч.

— Соңыннанмы, баштамы, анысын күз күрер. Список миндә, хәзергә власть минем кулда,— дип, бераз күкрәк киереп нокта куясы итте Мөхсинов.

Мужиклар бит, ул арада берсенең башында тагын үз хәсрәте калкып чыкты.

— Кара әле, Фазылҗан кордаш, шуны беләсем килә: эшкә ат җигеп барсам әгәр, чыбык-чабык салгалап кайтырга мужны булыр микән?

— Булыр, әгәр чыбык-чабыклар арасына бүрәнәсе дә кереп ятмаса, — дип, председательдән элек тел чайкап калырга ашыкты икенче бер җилкенчәге. Председатель Мөхсиновка килгәндә, ул мондый мәсьәләдә таш кебек каты иде.

— Не смей шырпысына да кагылырга, — дип кычкырды ул, һичнинди тәкәллеф саклап тормастан, — кара син аны кулак койрыгын, шундый эштә дә үзенә тарттырмакчы. Крестьян!

Бу «Крестьян!» сүзен ул шундый бер ачыну һәм нәфрәтләнү белән әйтте ки, кешеләр таралып бетеп, совет өендә икәве генә калгач, Сәфәргали әлеге сүзгә яңадан әйләнеп кайтмыйча булдыра алмады.

— Ай-һай, Фазылҗан абый, бая Ярулла абзыйга «крестьян» дигәнне бик тә каты әйттең. Ярулла абый курыккандыр да курыккандыр, хәтта мин, ике сугыш күргән солдат, калтырап куйдым,— шундук үтә җитди тонга күчеп өстәде: — беләсеңме шуны, безгә бит алда әлеге шул крестьян белән эш итәргә туры киләчәк.

«Йомырка тавыкны өйрәтми. Беспартийный башың белән сиңамы Фазылҗан абыеңа сабак биреп торырга» дигән уй үтте Мөхсиновның башыннан. Ләкин ул моны әйтмәде.

— Крестьяннымы? Үзем крестьян, атам-анам крестьяннар булмасамы? Читтә-чатта чапкан кеше син, Сәпәр. Алпут җирләрен талап, нәфсесе котырган крестьянны белмисең, җаным.

Чын дөреслектә исә, ике сугышта да катнашып, мактау кәгазьләре алып кайткан бердәнбер кешене, җитмәсә тагы, кем тарафыннандыр «комиссар» кушаматы тагылып, авылда күпләр тарафыннан «Камисар Сәфәргали», «Тегүче Корбангали камисары» дип йөртелә торган, әйтсә — кем алдында да сүзен үткәрә белүче, әле менә урман табу эшен дә ахырына җиткезеп чыккан Сәфәргалине ул чын-чынлап хөрмәтли, аның түшендәге значокларыннан берсен, әлбәттә, орден дип кабул итә, күрше авыл кешеләре алдында «Кем бар орденлы сездә? Ә менә бездә бар!» дип күкрәк төяргә дә ярата, шул ук вакытта Сәфәргалидән чакчак кына шүрли дә. Үзе ул Татбригада составында Төркстан җирләрендә басмачыларга каршы аз-маз кылыч ялтыратып кайтудан узмаган, дәрәҗәле исемнәргә буе җитмәгән, шулай да туры килгәндә «за што боролись»ны әйтергә бик остарган, урынлы-урынсыз партизанлык галәмәтләре ычкындырудан да тайчанып тормый иде.

### 6

Иртәгесен көтү чыккан тузан да басылырга өлгермәде, совет өе янында балта-пычкы кыстырып кешеләр күренгәли башлады. Әлбәттә, Мөхсинов белән Сәфәргали дә шунда иде. Мөхсинов кешеләрнең болай, бау белән тарттырган кебек, эленке-салынкы җыелуыннан бер дә канәгать түгел, үткәндә-сүткәндә кичә Сәфәргалигә «нәфсесе азган» крестьян турында әйткән сүзенең туры килүен ничек тә сиздерергә тырышкандай, үпкәле-мыскыллы караш ташлый уза.

— Күрдеңме, җаным, авыл кешесен. Авызына калач каптырсаң гына сәвит яклы ул, белмәсәң бел,— дип төрттереп тә куйгалый иде. Көтеп-көтеп йөрәге түзмәгәч, совет өенә кереп китә, кичә бергәләп

төзегән, исемнәре теркәлгән кешеләрдән имза яки, анлык грамотасы юк икән, тамгаларын салдырган исемлекне күтәреп чыга. Кычкырып түгел, Сәфәргалинең үзенә генә ишетерлек итеп ачу белән пышылдый:

— Минем иректә булсамы? Авыл саен бер трибунал бастырып куяр идем мин. Әйткән эшне формасына җиткереп үтәмәдеме? Яткыр да сук! — Аннары кычкыра төшебрәк өсти:— Егерме биш кеше җиң сызганып, вакытында килеп басабыз, дип кул куйган, ә монда аяк өсли йөклап торучы нибары унбиш зат. Күтәргәме калганнарын, әллә кузгалыргамы?

Ботак-санак төяп кайту нияте барлыгын кичә үк белдергән агай ат җигеп килгән, ат белән килгән тагы берәү бар, калганнары кайсы аларның арба үрәчәсеннән аякларын салындырып утырган килеш, кайсысы болай гына тәмәке пыскыткан җирдән тегеләй дә, болай да сузарга мөмкин була торган итеп мыгырданыштылар:

— Кузгалырга икән — кузгалырга, кояш әнә кем белән дә сатулашып тормый, кузгалган, күтәрелә.

— Әйттегез сүз: кояшның эше ни... күтәрелү дә бату.

— Алай түгел ул, Сәгыттин, көн җаравында эшләп калган яхшы.

— Әй, урманда тәүлек буе җарау анда.

Сәфәргали сүзгә кушылмыйча гына кешеләр кулында булган балта, пычкыны барлап чыкты: алты пычкы; балта барысында да бар иде.

— Әйдә, Фазылҗан абзый, бир команданы, юл кешесенең юлда булганы яхшы,— диде аннары Мөхсиновка. Мөхсиновның үзеннән узып эш йөртергә яратмаганлыгын белеп алган инде ул. Атларның аркалыкларын күтәреп, чөңгергәләп, үзара гөрләшеп кузгалганнар гына иде, арттан Зәйтүнә чабып килеп җитте.

— Ашарыңа алырга да оныткансың, анда бит узган елдан коелып калган имән чикләвеге белән туйдырмаслар,— дип сөйләнә-сөйләнә, Сәфәргалинең кулына әбәтлек ризык төенчеге тоттырды.

— Рәхмәт, хатын. Тамак барлыгы гел истән чыккан.— Зәйтүнә китә башлагач, туктатып, аны да искәртәсе бер сере калган икән:— Теге малайны да алмакчы идем, йокысын җәлләдем. Шулай да син аны күздән бик ычкындырма, кемнәр белән уйнаганын күзәткәлә.

Урманчылар юл алдылар, инде алар әнә Арыяк басу капкасына якынлашып баралар, ә Зәйтүнә әле һаман кереп китмәгән, тыкрык башыннан юлчыларны күзәтеп тора һәм Сәфәренең соңгы сүзләре турында уйлана. Нимдидер яшертен хәвефләнү бар кебек ишетелде аның тавышында. «Кеше үз баласы турында да болай кайгыртмас, теленнән төшерми шул малайны» дигән уй үтте күңеленнән.

Тәлгатьне үзе торганчы уятмады — аңарчы өй эшләрен карый, кайнанасына булыша торды. Ә малай белән икәүдән-икәү генә калып бер сөйләшәсе барлыгы исеннән чыкмый иде. Чишмәдән су алып кайтканда, малай йокысыннан торган, битен юыпмы, юмыйча гына өлгерепме, әбисеннән сорап алган сөт белән ипи мүкләп утыра иде.

— Әле бу, эшем кешесе, өлгергән икән,— дигән булды әнисе, малайны назлы үчекләү белән,— битеңне-кулыңны юдыңмы? дип сораучы да булмагандыр инде.

Әнисенең, әле күптән түгел генә кайткан үз әнисенең, күтәренкекөр тавышы малайда да аваздашлык тапты булса кирәк, теленә һич көтмәгән сүз килде:

— Бит белән ашыйммыни мин, авыз белән ашыйм ич.

— Битен юды, анысына сүз тидермә, килен,— кече якта нидер кыштырдатып йөргән Асылбикә түти дә үз сүзен кыстырды,— тик менә бисмилласын әйткәнен генә ишетмәдем.

— Бу хәтле йокы чүлмәге булмасаң соң... Әтиең әнә арбага утыртып урманга алып бармакчы ие үзеңне.

Бу чаклысын ук әйтмәскә дә мөмкин иде, күреп тора: малайның

танау болай да бер дә харап күтәренке. Бу очракта педагоглык такты житеп бетмәде Зәйтүнәгә. Әллә ул киермә танауның әтисенә булган мөнәсәбәтен ачыкларга ашыгуы шуңа китердеме?

— Ә мин барыбер бармаган булыр идем. Торган булсам да бармас идем.

Кече якта Асылбикә түти, бу якта энисе Зәйтүнә бу кырку җаваптан аптырабрак калдылар. Асылбикә түтинең күңеленнән: «Карасана гына әле сүзен. Орчык башы хәтле нәмәрсә, әнисе белән ничек олыдан кубып сөйләшә. Бу шул шөйлә бисмилласыз утырудан инде» дигән уй узды. Зәйтүнә исә: «Тәлгатемме соң бу? Кагылмастан элек, керпедәй, әнәләрен кабартып тора», дип гаҗәпсенеп торды.

— Нинди сүз булды бу? — дип тавышын күтәрә төшеп сорап куйды аннары. Аның тимерне кызуында бөгәсе килә иде,— имештер, эти әйткән җиргә бармый калырга да ярый булып чыга. Кем өйрәтте сине болай сөйләшергә?

Ул арада малай-керпе энәләрен яшереп өлгергән иде инде — әни хәтле әнигә җавап кайтармыйча мөмкин түгел.

— Бәбкә саклыйсым бар ич минем,— дип мыгырданды, башын аска игән килеш кенә. Бер хакыйкать гел ачыла бара: малай белән аулакта ныгытып бер сөйләшергә, әлбәттә, кирәк иде. Зәйтүнәнең бу турыда шиге-шөбһәсе юк, ләкин кайда? Хәзергә шул чаклысын гына ачыклап житмәгән иде.

Ике сүз моны да ачыклап бирде.

— Нинди бәбкә саклау ди ул? Канат чыгарып, үзләре казга әйләнеп бара торган бәбкәләрне,— бусын кече яктан, бераз ачулана төшеп, Асылбикә түти әйтте.

— Барсаң, синең белән барам,— Тәлгать моны, берни дә уйламыйча, малайларча кодрәтләнеп һәм, шул ук вакытта, чак кына иркәләнергә дә теләгәндәй, ачылып-кычкырып әйтте.— Үзебезнең урманга, якын урманга. Җиләк җыярбыз, каки җыярбыз, мин сыбызгылык юкә...

Әтисе әйткән сүзгә энәләрен кабарткан иде, ә әнисенә, әйтмәгән килеш үк, үзе тагылырга әзер — юк, монда уйланырлык урын күренеп тора, иптәш мөгаллимә. Бар син малаең белән, сөйләш... сөйләш син.

Җиләк тә, каки да җыймадылар, баштарак ничектер сөйләшүнең дә рәте-җае чыкмады. Зәйтүнәнең, улы җаена ятарга тырышып, читләтеп-чатлатып сорашкалаган булуы Тәлгатьнең ачуын гына китерде. Теге вакытта иптәш малайларыннан беренче кабат ишеткән яңалык аның күңеленә тиз генә төзәлмәслек җәрәхәт салган һәм шул тетрәүдән соң ул акылы-уйлары белән берьюлы үсеп киткән, үзе белән малайсытып сөйләшкәнне күтәрә алмый иде.

Һич көтелмәгәндә, урманны яңгыратып кинәт сорау бирде малай:

— Ник сез аны миннән яшердегез?

— Кемне? Нәрсәне? — дип, нык кына аптырап, сорауга сорау белән җавап кайтарды әнисе. Ләкин монда «сорау-җавап кичәсе» уйнарга урын юк, малайның күңеле мөлдерәмә тулган, аңарга түгелеп китәргә кирәк һәм ул түгелмичә булдыра да алмаслык хәлдә иде:

— Бу эти бит минем чын эти түгел... мин эти дип йөргән кеше. Түгел, түгел. Син мине алдап маташма, җәме. Минем эти бүтән. Буржуй булган минем эти. Кызылларга каршы сугышкан. Аны атканнар. Шулай бит? Шулай бит? Бүре баласы бит мин. Малайлар миңа шулай диләр, «син бүре баласы», «син контр баласы» дип үртиләр — Тәлгать сүзләрен һәм сорауларын бергә бутап, сорауларына ничек җавап бирелгәнне көтмичә үк, дөресрәге, көтеп тора алмыйча, яшенә тыгылып, әнисенең итәгенә капланды. Аның бүтән сүзләре сулкылдау аша, күлмәк итәге аша, аңлашылыр-аңлашылмас өзек-өзек кенә чыга иде: — ә син шуны миңа әйтмичә йөргәнсең.

Бу үпкәле сүзне ишетми калу мөмкинме соң. Зәйтүнә мондый ачы

сүзнең яки моңа охшашлырагының кайчан булса да бер әйтеләчәген, әлбәттә, белә, ләкин болай иртә кузгалыр дип әлегә көтми иде. Малай гына, бөтенләй малай гына, югыйсә, ә ярсуы нинди көчле. Ялганны белми, ялганны күтәрә алмый торган сабый күңелләр генә болай тилереп ярсый ала торганнардыр. Йа хода, шөкер, үзең сакладың, тирә-юньдә чит-ят кешеләр юк, тирә-юньдә урман, агачлар да кошлар гына. Кошлар югарыда, агачлар кешеләр телен белмиләр. Тәлгать — ничек кенә ярсыган булмасын! — үзенеке, үз йөрәгеннән өзелеп төшкән валчык — аңарга ничек тә аңлатыр.

Беравыктан алар гүя икесе бер кешегә әверелгән, Зәйтүнә Тәлгатьне күкрәгенә кысып алган, инде әни дигәнебез ярсып елый, ә малай елап туктаган, ул әнисенә текәлгән, гаҗәпләнеп һәм чак-чак кына куркынгандай текәлгән иде.

— Җылама, әни,— ди ул, бүтәнчә ни әйтергә дә белмәгәч,— мин бит хәзер ул малайлар белән уйнамыйм. Мин Гаптеләхәт белән генә уйныйм.

Беравык сүзсез калдылар, күзгә-күз карашып тордылар, гүяки белергә телиләр: тагын ялган кушылмадымы? Тагын алдашу юкмы? Киләчәктә бер-берсенә хилафлык эшләмәсләрме? Аннары елап түгел, кисәтеп, чак кына орышкандай итеп, Зәйтүнә сүз башлый:

— Бер әйттең, миңа әйттең бу сүзләреңне,— ди ул, малайдан күзләрен алмыйча,— икенче тапкыр теш арасыннан чыгарасы булма. Малайлар сүзенә ышана китсәң, алар ни димәс. Ә син шуны бел: синең әтиең дә, әниең дә бар. Алар гына җитмәсә, синең әле әбиең белән бабаң да бар. Әйт малайларга: бер кешенең ике әтисе булмый, диген.

— Бер кешенең ике әтисе булмый шул менә,— дип, авыз эченнән мыгырданып куйды малай. Әнисе әйткәннәргә кушылуы булдымы бу, әллә аңарга каршы төшәргә маташуымы? — белмәссең. Ә әнисенең, бу аулак урында, болай ачыктан-ачык башлангач, бөтенесен дә ахырына кадәр төшенеп һәм кирегә сукалап торучы Тәлгатенә дә тәмам төшендереп, бушанып һәм тынычлап кайтасы килә иде.

— Ятыйк әле менә шушы үләнле төшкә башны башка куеп,— диде ул, урман эчендәге түгәрәк аланлыкка чыккач. Бөтен борчуларын җиргә коеп калдырырга теләгәндәй, иң элек үзе ауды, нәкъ үз каршыннан Тәлгатькә дә урын күрсәтте. Чынлап та, башны башка куеп яту булып чыкты бу.

— Сизәсеңме, җир нинди рәхәт,— дип сузып куйды аннары, малайга әйтүдән бигрәк, үз борчуларын җир куенына коеп калдырырга тырышкандай,— ә без шул рәхәт җирдә бер-беребезгә кычкырабыз, елашабыз, чак кына талашмыйча калдык.

Була шундый кешеләр: үз гомерендә ул бер юл шигырь язмас, бер купшы сүз әйтмәс, хәтта башкалар арасында аның чак-чак кына мокыт булып күренүе дә мөмкин, һәрхәлдә, бүтәннәрдән элек чәчрәп чыгарга һич ашыкмас. Тик алар табигать белән, урманнар һәм кырлар, йолдызлар һәм айлы төннәр белән ялгыздан-ялгыз калсыннар гына, андыйларның җаннары шундук шагыйрьгә әйләнә, башкалар алдында әйтелмичә яшеренеп килгән җылы сүзләре шундук тышка атылып чыгарга тора. Яшьтән үк ятим калып, үги ана талкысы астында үскән, аннан башка да күп кенә талкылар күргән, яшьлек омтылышлары, кабул булмаган гыйбадәт кебек, юлда тапталып калган Зәйтүнә дә бу минутларда, күңеле купшынган бу чарпалану минутларында, җаны белән чын шагыйрьгә әверелгән һәм аның хәзергә бердәнбере Тәлгать белән чынны, бары тик чынны гына сөйләшәсе килә. Малае аңлармы-юкмы, Зәйтүнә аңлатырлык итеп әйтә алырмы? — ул турыда уйлап тормастан, башыннан узган бөтен хәсрәтле тарихны, нәкъ булганынча, чын ихластан түгеп ташлыйсы килә иде.

Әлбәттә, ул үзе белгәннәрне генә, Тирәкле авылында, Сәлмән байлар өендә башыннан кичкән хәлләрне генә сөйләде, элекке ире Мидхәт Вильдановны яман итеп тә, яхшы итеп тә күрсәтергә тырышмады — үзе күрмәгәнне күрдем дип әйтергә базмый иде. Ә аның Вильдановларда күргәннәре җитәрлек иде. Һәрхәлдә, әнисе сөйләгәндә, малай аны бүлдереп, сораулар бирмәде.

— ...Көзге караңгы төндә, кантарланып каткан юлда, Тирәкле авылыннан — синең бай бабаларыңнан Тимәш авылына — фәкыйрьнең дә фәкыйре Тәтә-апаларга җәяүләп китеп барышлый карынымдагы җан иясе белән сөйләшкән бер сүзем искә төште, Тәлгать улым. Дөрес, ул чагында әле син тумаган идең, карынымда гына идең,— тумаган ук кеше белән болай сөйләшкән булуы малайны гаҗәпләнү катыш сискәндереп үк җибәрде.— Соңыннан да мин ул сүзләрне әледән-әле телгә ала килдем, син дөньяга туып, икәү генә калган чакларда да гел искә төшерә идем. Әйтсәм әйтим, соңыннан ул минем син ятим нарасыйга җырлый торган җырыма әверелде. Син хәзерге кебек әнәле сораулар бирми идең ул чагында. Син сабый идең. Инде алай күпне белә башлагач, син мөнә моны да белергә тиешсең, улым. Әлбәттә, белергә тиешсең. Бары тик бер үтенечем бар: мин сөйләгәндә син мине бүлдерәсе булма.

Зәйтүнә яткан җиреннән торып утырды, малаена елыша төште, аның башыннан сыйпый-сыйпый, сабак баласына шигырь өйрәткән кебек суза һәм чак кына моңгы төшеп:

— ...Без дөньяда синең белән икәү генә калдык, улым,— дип, инде күпме тапкырлар кабатлаган, ятлап бетергән сүзләрен һич үзгәртмичә башлап алып китте,— бер-беребезне ташламыйк, беребезне-беребез рәнҗетмик. Икәү бергә үсәрбез, икәү бергә еларбыз, икәү бергә сөйләшербез, икәү бергә дөнья көтәрбез...

Ләкин малай бу очракта нәкъ малай булып калды, бүлдермичә түзә алмады:

— Үзең бер әйтәсең: «Синең әтиең бар, әниең бар, әбиең бар, бабаң бар», дисең, шунда ук тагын үзең әйтәсең: «Без дөньяда синең белән икәү генә калдык», дисең. Ничек инде бу болай була ди?

Сүзне бүлдермәскә дип керешкән иде Зәйтүнә, ләкин Тәлгатьнең уйлапмы, уйлап тормастанмы әйткән бу сүзләре аның эченә җан кертте: димәк, малай әлегә «бүре баласы» түгел, ничек кенә гайбәт сатмасыннар, түгел, түгел!.. Һәм ана күңеленнән ант итеп куйды: «Үзем исән чакта бүре баласы булуына юл куймам, юк, куймам!»

## 7

Урман. Җәй башы урманы. Агач яфраклары әле кара-кучкылланып катарга өлгермәгәннәр, яшеллек, бөтен нәрсәдән — яфраклардан, үләннәрдән, хәтта җирнең үзеннән дә борынны кытыклый торган дымлы яшеллек исе аңкый. Урман юлындагы чокыр-чакырларда моннан өч көн элек яуган яңгыр сулары җыелып калган, аларга төбәлебрәк карасаң, агачлар ябалдашлары белән аска таба үскән кебек күренәләр һәм иң аста, урманчыларны каршылап җәеп куелган хәтфә палас кебек, күкнең суда чагылган фирүзә шәүләсе җәйрәп ята. Рәхәт, сулышка иркен, дөнья мәшәкатьләре урманның аргы ягында, авылда, кысан өйләрдә торып калды, монда гамьсез мужиклар да җырчан кошлар гына. Шулайдыр кебек, ләкин беренче карашка гына шулай күренгән икән. Итәрсең мужикны гамьсез.

Билгеләнгән делянка янына килеп туктаулары булды, берсенең уйный-көлә әйткәндәй яңгыратып салуы булды:

— Миңа да өлеш чыгасын ачык кына белсәмме? Өч көндә тамгалысын, тамгасызын тоташ урып салам мин бу урманның. Иманлы авызым белән әйтәм.

— Ә син миңа да булыр дигән өмет белән кереш, Гайнетдин абзый,— дип кыска гына әйтте Сәфәргали,— иртәме-соңмы безнең барыбызга да булачак. Революцияне без шуның өчен ясадык.

Сәфәргалинең бу юатуы Мөхсиновка ошамады, гомумән, эшкә керешкәндә үк ач күзле мужик белән болай сайрашып торуны егетнең булдыксызлыгы дип саный иде ул. Шулай да турыдан-туры Сәфәргалигә түгел, барыннан да элек «үзенә өлеш өмет итүче» Гайнетдингә кадады:

— Алма пеш, авызыма төш. Кайчанга хәтле авызыңа төшкәнне көтеп ятмакчы буласың син, ипи шүрлеге? Комбед абыең әйткәнне иң элек әйбәтләп эшләп күрсәт, учыңа ныграк төкерә төшеп...

Кояш күтәрелеп бара, озак әрепләшеп торырга вакыт юк иде. Бер пычкыга ике кеше, ботак-чатак чабарга бер балталы кул исәбеннән чыгып, өчәр кешелек биш төркемгә бүленеп, эшкә керештеләр. Төркемнәрнең һәрберсе бүгенгә егермешәр төп агач аударып эшкәртергә, бүрәнәсен бүрәнәчә, ботагын ботакча планга чыгарып өя барырга тиеш дип кисәтелде. Озак та үтмәде, әле тегендә, әле монда чаж-чож пычкы йөрткән, «Карабрак, карабрак! Ботагы белән ипи шүрлегенне җимермәсен!» кебек кисәтүләр, дөпелдәп ауган агач тавышлары ишетелә башлады. Керешкәндә шулай зурдан кубып, учларына төкереп керешсәләр дә, төкерекләре тиз кипте булса кирәк, бераздан җанлылык сизелеп кимеде. Каудар җанлы Мөхсинов колагы моны бөтенесеннән элеп тотып алды.

— Мин бер обход ясамыйча булдыра алмыйм,— диде ул, күршедә генә эшләүче Сәфәргалигә эчке тынгысызлыгын ачыктан-ачык сиздереп,— ышаныч юк безнең «алма пеш, авызыма төш!»ләргә. Тәмәке тартырга дип утырыр, утырган җирдән кырын авып төшәр и шуның белән шул: онытты революцияне, китте-барды нәвем базарына.

Авылда күбрәк кайнашкан, яше ягыннан да шактый өлкән картлачның борыны дөрес сизә икән. Бер «өчлек» җәелеп тәмәке тартып утырса, икенчесе тәмәкедән әкият сөйләшүгә күчкән, ә өченче «өчлек»нең берсе бөтенләй юкка чыккан, калган икесе кырын ятып, балталарының үткенлеге белән мактанышалар иде.

— Бик иртә аргансыз, егетләр,— дип кабынып эндәште Мөхсинов,— болай селкенсәгез, өлешегезгә төшкән көмешне җәй буена сузуыгыз бар...

— Бөтен бәла дә шунда, адаш: төшәр микән безнең өлешкә, шуны белгән юк.— Агайның кисәтүгә исе киткәнлеге бер дә сизелми, киресенчә, Мөхсиновны юри үртәгәндәй, җайлабрак ятты ул.— Бүрек белән киңәш итеп ятам да менә, бүрек әйтә миңа: син йөрерсең, тиле күркә, урман кыдырып, чабата туздырып, ди, ә яңа йортны син түгел, синең күршең салып керер, ди.

Икенчесе, үзе өчен дә, бергә эшләргә тиешле иптәше өчен дә уңайсызлангандай, шундук сикереп торып, өстеннән җир тузанын каккалады.

— Бездән ни... бездән эш тормый. Әнә ич Хаматша абзый. Олы йомышымны гына йомышлыйм дип киткән кеше, сәгать була торгандыр киткәненә, юк та юк.

Ул арада ипләбрәк ятканы үзенекен өстәде:

— Сәгать дигәннән, кем, адаш дус, вакытлыча гына булса да, берәр сәгать тоттырсагыз икән безгә. Казна эше точкага точка барырга тиеш. Эшләдең бер сәгать — курилка, унбиш минут анысына. Эшләдең ике сәгать — малый әбәт. Эшләдең өч сәгать — большой әбәт, анысына

круглый бер. Заводта эшләп кайткан кеше мин, пурәткә дигәнне беләм.

Ачулануны уен-көлке белән бергә бутап, чын дөреслектә Мөхсиновның канын яхшы ук кыздырып, шулай сөйләшеп-әрепләшеп торганда — кирәк бит тәкмә-тәк килергә — урман эченнән бер кочак яңа суйган юкә төяп Хаматша дигәне килеп чыкты. Борылып китә башлаган җиреннән кире әйләнде Мөхсинов һәм юкә карагын тантаналы рәвештә каршыларга булды. Зәһәре бик яман чыккан иде — эшне ташлап йөрүе өчен дә, рөхсәтсез юкә суюы өчен дә. «Тантана»сы мич төбендә пешкән майсыз көлчә кебек коры, надан кешенең амины кебек кыска булды:

— Ну, әйт, син дә булдыңмы инде кеше?

— Мин үземне кеше дип әйткәнем дә юк, мин чабатачы Хаматша! — Әллә үзеннән, әллә авыл Советы председателе Мөхсиновтан көлүе. Ачуы килгән Мөхсинов беравык шуны аера алмый торды. Аннары дуамал каты итеп кычкырмасынмы:

— Кайтышлый кордонның үзенә тотып бирәм мин сине! Юкәң-ниең белән каталашкага яптырып куйдырам.

— Мине яптырсаң, авыл кешеләрең чабатаны кемнән алыр? Бер кием чабата өчен дә Теләче базарына йөгертер иең мәллә?

И, каеш та соң бу Мәтәскә кешеләре! Авыл башлыгы аларны дукитереп тирги, әлбәттә, урынлы тирги — юкә суйганы, эштән качып йөрүе өчен. Ә теге ерык авызның гамендә дә юк. Хәтта әле үзен хаклыга, авыл башлыгын дуамалга саный. Янәсе, тапты бәйләнер сәбәп: Хаматша, адәм әүлиясы, чын ихластан авыл кешеләренең аяклары турында кайгыртып йөри, ә авыл башлыгы Мөхсинов — «Партизан» дигән данлы аты чыккан кеше — шуның өчен Хаматша мескенне каталашкага яптырасы.

— Син, Фазылҗан әкәмәт, үзең ук чамаларга тиешсең, күктән төшкән кеше түгел ләсә. Юкәнең хәзер агачтан чыжылдап куба торган чагы, үтсен тагы бер-ике ай, аннары ул кубарга зрә ашыкмый.

Аптыраудан сүзен әйтә алмас булды Мөхсинов — илла да пошмас җан да соң бу Хаматша дигәннәре. Үзе бит әле: «Мин ярлылар комитеты члены!» дип күкрәк кагып сөйләнергә ярата.

Чапсаң балта үтмәстәй бу гамьсезлекне ялгыз гына ерып чыга алмаслыгын сизеп, Мөхсинов ярдәмгә Сәфәргалине дә чакыртты — янәсе, «Камисар» исемен зрә генә тагып йөрмәсен, борып алсын бу «каешларны» якаларыннан.

Борып алу урынына уйланып калды Сәфәргали.

— Ә без мондый бер хикмәт эшләп карыйк, Фазылҗан абзый, — аның бу тынычлыгы Мөхсиновны да кинәт чак кына тынычландырды, — ничек дип әйтергә дә белмим, но сүзе бар, тел очымда гына тора сүзе. Словом, бераз кортларын котыртыйк.

— Аңлатыбрак сөйлә, минем баш бәрәңге бакчасында гына үскән. Прсидәтел дигәч тә...

— Аңлатуы шул: сүз белән, агитация белән кысуга караганда, еккан агачларының ботагын-очын үзләренә вәгъдә итик.

— Барыбер килеп җитмәде, энекәш. Мужикның болай да азып бара торган нәфсесенә юл куяргамы? Җир алды мужик, хөррият алды мужик, алпут талады мужик, инде хәзер үзебезне талатыргамы? Торып тор, мин аларны болай да иманга китерәчәкмен.

Бәхәснең тирәнгә китүеннән куркып, Сәфәргали алда торган практик мәсьәләгә якынрак сүзне әйтте:

— Ә монда коточырырлык бернинди контрреволюция дә юк. Ауdarган агачларыбызның очын-ботагын каргаларга калдыра алмыйбыз. Лесничество бездән чүп-чарыбызны җыеп, урыныбызны чистартып

китүне сорый. Рас шулай икән, ник безгә, әйтик, болай эшләп карамаска. Ботак-чатакны кая житте шунда ыргытмыйбыз, өеп, сажинга салып барабыз и шуннан килеп...

— ...И шуннан килеп, кайсыгыз элек төяп китә ала, төяп китегез, дип, аларның өелешеп сугышканын карап торабызмы?

— Карап тормыйбыз, әйтәбез: кайсы өчлек үзенә билгеләнгән агачларны элегрәк эшкәртеп бетерә — ботак-чатак шуныкы, дибез. Билләһи дип әйтәм...

— Куеп торсана «билләһи»еңне, коммунист белән сөйләшәсең ич син,— дип шаяртткан булып, Сәфәргалине тагын бүлдерде Мөхсинов. Ничек кенә булмасын, авыл башлыгының йөзенә кинәт нур йөгерә башлады, Сәфәргалинең сүзләрендә саф алтындай акыл яшеренеп ятканлыгын ул сизенә иде.

— Ну, ни дип ышандырырга соң сине, картлач? Ант та калмады рәтле,— үз нәүбәтендә Сәфәргали дә ачыла, ялтыра, шуклана бара иде,— ну, честное красноармейское инде, алайса... тешләре-тырнаклары белән ябышып ятачаклар синең ул «мужик» дип мыскыллап йөрткән кешеләрең.

Чынлап та, мавыктыргыч идея иде бу. Төшке әбәт вакытында аны урман кисүчеләргә дә житкерделәр. Әлбәттә, «ур-ра!» кычкырып каршы алучы булмады, крестьянның үз акылы үзе белән иде. Шул ук вакытта төштән соң, яшел үләнгә чалкан әйләнеп төшеп, күккә караган килеш «бүреге белән киңәш итеп» ятучылар да күренмәде. Барысы да тавышсыз-тынсыз гына эшли, план буена чыгарылып өелә барган ботак-чатак сажиннары барысының да күзен яндыра иде.

Бу, әлбәттә, тирән аңлылык нигезендә үткәрелгән хәзерге социалистик ярыш түгел, монда, якты акылдан бигрәк, крестьянның күбесенчә үзенә табарак кәкре булган бармагы уйный, ләкин шулай да монда инде ярышып эшләү орлыгы салынган иде. Кешеләрнең ябышып ятып эшләүләрен күреп шатланып бетә алмаучы Мөхсинов, берара Сәфәргалинең үзен генә туры китереп, мутларча күз кыса узды:

— Баш бар икән үзеңдә, Сәпәр, тәки кымырҗыттык бит халыкның кортын.

— И, алда әле ничек кенә кымырҗытучылар табылыр,— дип калды Сәфәргали, Мөхсиновка әйтүдән дә бигрәк, үзенә-үзе әйткән кебек.

Шулай да, көннең икенче яртысында никадәр тырышып эшләсәләр дә, егарга билгеләнгән ун агачны бер «өчлек» тә егып бетермәгән, эшкәртелгән бүрәнәләрне әле план буенча ташып куясы да бар иде. Шуннан «Кайтабызмы, әллә куна калабызмы?» мәсьәләсе кузгалды. Күбесе куна калу ягын яклады. Дәлилләре дә үзләре белән үк иде: янәсе, кичке салкында әвәсрәк эшләнә. Кайта-килә йөреп чиләнәсе юк. Урманда, йолдызлар астында йоклауга ни житкән. Берсе, әллә кызык өчен, әллә чынлап та хатынына ачуы чыкканлыктан, әйтеп тә куйды шунда:

— Узган төн Майтап җиңгәгез кочаклатмыйча теңкәмә тиде, имештер, Корбыеның кочагы зрә дә эссе. Унбиш ел бәргә торып, әйтерсең бүген генә күргән Корбыйны. Йоклап карасын әле ялгыз үзе генә.

— Һи, әйттең сүз, Корбый абый. Ялгыз йокларга курыкса, әллә күрше-күләннән иптәшкә керергә ахутниклар табылмасмы? — дип, арадан бер яшьрәге Корбыйның күңеленә шик үрләтмәк булды. Барысы да гөрләшеп көлеп алдылар. Ләкин бугаздан китереп торткан житди мәсьәлә дә бар: күбесенең ашарына беткән, һава белән генә туенып агач аударып, бүрәнә ташып булмаячагы ачык иде. Менә шунда ризык алып килү өчен иң кулай кеше итеп ат җигеп килгән Тәкыйга тукталдылар. Тәкый кайтып килергә каршы түгел, ләкин ул

үзенең бер шартын куя (хәер, ул моны килгән чакта ук бөтенесенең дә исенә төшерә килгән иде):

— Төягез миңа ат сыртыннан итеп менә бу чыбык-чабыкларны, кайтам!

Әмма Тәкыйның ничек тә игътибарсыз күренергә тырышып төртеп күрсәткән ул «чыбык-чабыклары» хәзер барысының да исәбендә, узганда-барганда һәркайсы ул якка күз атып уза иде. Зык кубып бер сатулашып алдылар:

— Илла гуж да син, Тәкый абзый. Булдыра алсаң, урманы белән күтәреп апкитәр иең.

— Гуҗлык түгел бу, эш хакы. Имештер, ат җиккән килеш урманнан буш арба белән кайт. Авылга кертмәсләр, дурак.

— Син бит үзең өчен түгел, җәмәгать өчен йөрисең.

— Ә җәмәгать минем атны туйдырырмы? Өемне җылытырмы соң?

— Сүзеңне әрәм итеп, тел талдырма. Кара сарык йонын агартып азаплану гына булачак.

— Үзеңнең дә ризыгың юк, үзең өчен дә кайтасың ич, Тәкый абзый.

— Чистый. Әллә гел безнең өчен генә йөри.

— Үзем ач булсам, аның караvы, атым тук. Күрәсең, монда нинди тәрханлык.

Сүз куерту, сатулашу булды, әмма Тәкыйне барыбер буш арба белән кайтырга күндерә алмадылар. Бермәл, ризасызлык белән этләмәчеле әйтешкәләп, җигүле ат тирәсендә кайнашып алдылар. Анда да мәзәксез генә булмады. Тәкый үзе арба өстендә: бер яктан китерәләр чыбык-чабыкның иң «карга оясы»н — вагын да төяген. Тәкый абзый дигәннәре аларны икенче якка атып бәрә бара — янәсе, котырдыгызмәллә, нишлим мин сезнең бу «карга оягыз» белән, төйисез икән, даешь күзгә күренердәйләрен. Авыл буе кайтасы бар ич, тиле бәрәннәр.

Шулай сатулаша-сатулаша, бер йөкне караңгы капканчы төяделәр. Аның караvы, йөк, чынлап та, ат сыртыннан булды һәм кешекара күрмәгәндә генә Тәкый арага бер нечкә бүрәнә кыстырырга да өлгерде.

## 8

Бер генә көнгә дип киткән кешеләр икенче-өченче көнне дә эшләделәр. Урманның шау чәчәккә, кошлар моңына күмелгән чагында күмәкләп башкарылган эш болай да күңелле: кайсы борын астыннан гына җырлап җибәрә, кайсы кошларга охшатырга тырышып сызгырырга маташкан була, кайсы өемгә бүрәнә илтеп килешли шундый ук бүрәнә күтәреп юлга чыгара барган иптәшләренә: «Чырайны бәк сыткансыз, әллә хатыннарыгыз ашарыгызга каты-коты гына җибәргәнме? Өч көн рәттән ялгыз түшәктә яталар мескеннәр, ачулары да килгәндер», дип тел шартлатып узалар. Ләкин урманыннан да, кошларыннан да, күңелле шау-шудан да, Тәкый «илче» артыннан хатыннары төйнәп җибәргән сый-хөрмәттән дә (янәсе, кеше арасында ким-хур күренмәсен) бигрәк, монда урманчыларны астыртын куа торган ике «чыбыркы» бар: беренчедән, вагъдә ителгән ботак-чатак өемнәре күзләрен яндыра, икенчедән, һәркайсы эченнән генә яшерен өмет белән яна: «Маңгай тирен җәлләмәгәнне күреп торалар ич, соңыннан биш-алты гына бүрәнә булса да миңа да ыргытсалар, бер дә харам булмас!» дип фикер йөртәләр иде.

Ләкин өченче көнне төштән соң, инде бетерәбез дип аеруча тырышып йөргәндә, аяк астыннан гына бәхетсезлек килеп чыкты. Бергә эшләүче иптәшенең саксызлыгы аркасында Сәфәргалинең аягына бүрәнә төште. Башта сиздермәскә тырышкан булып маташса да, мөм-

кинме соң бәхетсезлекне кисәгә салып асрарга. Бүрәнә бот буйлап сыдырып узган, шуның аркасында егетнең сугыш яралары ачылган... Шундук ак киндер ыштан аркылы берничә җирдән ургылып кан бәреп чыкты. Ул арада иреннәре дә күгәрә, төсе дә китә башлады. Бетерә торган эшләрен ташлап, Сәфәргали тирәсендә кайнашырга, төрлесе-төрле яктан киңәшләр яудырырга тотындылар. Ләкин үзе дә яу кичкән һәм сугыш инвалиды килеш, алдын-артын онытып, шушы хәлгә төшкән иптәшенә акыллы киңәш бирү белән генә чикләнеп кала алмаган Мөхсинов сүз яки киңәш белән вакыт уздырып торуны кирәк тапмады. Өстендәге ситсы күлмәген җәлт кенә салып, шатырдатып ерткалады һәм, каны акмасынга ярага черек агач гөмбәсе оны сипкәләп, аякны бала биләгәндәй бәйләп куйды.

— Живы атыңны җик, Тәкый! — дип боерды аннан. Мөхсиновның тавышы да каты, хәер, эшнең уен түгеллеген болай да күреп торалар иде. Бу юлы Тәкыйга сатулашып торырга туры килмәде, кайсы кайдан йолкып, «ә» дигәнче арба ящигын яшел үлән белән тутырдылар, Сәфәргалине шуның өстенә күтәреп салдылар.

— Авылга кереп тә торма, момент Теләче больницасына,— дип, сугыштагыча команда биреп калды Мөхсинов.

Команда болай яңгырауга нык яңгыраса да, ләкин бит ул урманда яңгырады. Кырга чыккач, Тәкыйның такыр башы үзенчәрәк фикер йөртә башлады: «Әйтергә ансат, «момент Теләче бүлнисенә», имеш. Теләче бит ул Мәтәскәдән сигез-ун чакрым. Ярый ла, анда кочак җәеп каршы алсалар, барып әлгәшкәнче кич җитәчәк, ул арада духтыр-ак якалар өйләренә таралып беткән булсалар... Фазылҗанга аңа, ат күрмәгән әтрәк-әләмгә, кычкырынырга ансат, ә Тәкыйга аты белән бүлнис капкасы төбендә төн уздырырга туры килсә...»

Аның бу уйларын чамалаган кебек, ул арада Сәфәргали үзе телгә килде. Күрәсең, кан агудан туктаган, авыру күзен ачкан, беравык вакыт сүзсез-нисез күккә карап барды.

— ...Теләченең кайда икәнен белмәгән кеше кебек, тиле... Күке Фазылҗанга аңа ансат кеше атына «на!» дип чөңгереп тору...

Тәкый моны авыз эченнән, үзенә-үзе генә мыгырданып әйткән иде, югыйсә. Сәфәргали, күрәсең, ишетеп алган. Хәер, туган авылын, әле Казаклардан курслардан гына кайтып, назлап туймаган сөекле Зәйтүнәсен читләтеп, Теләче больницасына барып егылырга Сәфәргали үзе дә бик ашкынып тормый иде.

— Юк, син мине авылга алып кайт, Тәкый абзый,— диде ул, йөзен Тәкыйга бора төшеп. Боерган да, үтенгән дә кебек әйтте,— бәлки больницасыз да үтәр. Күп иснәдем андагы марганцовка исен.

Ләкин ул моны кызулык белән, өлешчә Зәйтүнәсеннән аерыласы килмәгәнгә күрә генә әйтте,— хәер, аерыласы килмәсә дә гаеп түгел, башны башка куярга зар-интизар булып, аерым-турагай күпме яшәргә мөмкин кешегә: сугышы, революциясе, продотряды, соңыннан хатынының чит авылда укытып йөрүләре, курслары.

Ләкин, ничек кенә димә, тагын бераз чыдарга туры килердер. Моны иң элек аңарга Зәйтүнәсе әйтте.

— Больницасыз булмас, Сәфәр җаным,— диде ул, иренең ачылган яраларын чиста ак марля белән бәйли-бәйли. Ышандыра торган итеп, ихлас күңелдән әйтте,— монда синең эшләр байтак күренә, хәтта медицинадан ерак торган безнеңише кешегә дә.

Алар шыпырт кына сөйләшәләр кебек иде, канлы чүпрәкләрне дә мөмкин чаклы селкемәскә, өйдәгеләргә күрсәтмәскә тырыша иде Зәйтүнә, ләкин өйдәгеләр дә сукыр яки колаксыз түгелләр икән. Бу ышертен пышылдашуларны ишетеп, күрердәен күреп, бер читтә, күзгә чалынмыйчарак тетрәнеп-куркынып торган Тәлгать, бөтенесеннән

элек чәчрәп чыгып, әнисенең муенына сарылды. Беләкләре әнисенең муенында булса да, яшь белән тулган күзләре Сәфәргалидә, үзе бөтен саны белән дерелди иде.

— Үлмәсме... безнең бу эти дә? Син беләсеңме, үлмәсме?

Малай, ярсыганын үзе дә сизмәстән, Сәфәргалинең өстенә капланды — бу минутта ул әнисенә дә бик ышанмый, шул ук вакытта инде бу этисеннән дә... соңгы вакытта, бигрәк тә малайлар котыртып кайтаргач, «эти!» дип эндәшергә кыюсызланыбрак йөргән бу этисеннән дә аерылып калырга бер дә теләми иде.

— Сугышта үлмәгәнне... кайда ул монда үлеп, авылдашларга, өйдәгеләргә кирәкмәгән мәшәкать ясап торырга,— дигән булды Сәфәргали, өйдәгеләрнең барысын да берьюлы тынычландырырга тырышып. Үзе Тәлгатьне күкрәгенә кысып алган, яшьле күзләрен аңарга ничек тә күрсәтмәскә тырыша иде. Бераздан, чак кына суына төшкәч, малайны кулыннан җибәреп, тик Зәйтүнәсенә генә ишетелерлек итеп әйтте:

— Больницасыз булмас, син дөрес әйтәсең, Зәйтүн гөлем,— теленә мондый җыр сүзе, кызлар сүзе килгәне өчен уңайсызлангандай, аннары коры гына түгәрәкләп куйды:— Только Теләче больницасына түгел, Пановка больницасына. Анда минем тишек-тошыкны беләләр. Өч ай аунап яткан таныш урын.

Шуның белән бөтенесе дә хәл ителде, сүзгә һәм икеләнүләргә урын бетте бугай, дип уйлаган иде дә, юк, калган икән. Иртәгесен юлга әзерләнеп, ат җигеп кергәннән соң, утырып дога кылыр алдыннан, Корбангали абзый, уныып-уныып торып та әйтмичә уздыра алмагач, җайлап кына болай дип башлады сүзне:

— Минем дә бар ие сүз барлыкка да...— Әйтә башлагач әйтмичә сузып торуына караганда, аның сүзе үзе өчен бик тә әһәмиятле иде булса кирәк, һәм ул ашыгыч арада гына авыз ачып тору батмас дип икеләнебрәк тора иде кебек.— Хәер, без әле бара-бара да сөйләшергә өлгерербез. Бик алай сызланмыйсың ич хәзер.

Ләкин картның бу әйтелмәгән сүзе Зәйтүнәне әйтелгәннән дә бигрәк сискәндереп җибәрде.

— Әткәй, син дә бармакчымыни? — дип сорап куйды ул аптырабрак. Авыруны аның ялгыз үзе генә илтәсе килә, монда сөйләшенеп бетмәгән сүзләрен дә юлда — аулакта — икәүдән-икәү генә әйтмәкче иде бугай. Болай булгач кителде таба коймак пешердем дигәндә генә! Үз нәүбәтендә сүзсез килененең кинәт болай теле ачылуы картны да уйландырмый түгел иде.

— Арбага бишенче тәгәрмәч кирәкми, дип кенә әйтми килен дә,— дигән булды ул хәйләкәр төрттереп,— мәгәренки айгырны хатын-кыз кулына тоттырып җибәрә алмыйм, килен, бигайбә. Юктан гына да өркеп китә торган алама гадәте барлыгын беләбез.

Сәфәргали бу очракта сүзгә кысылуны кирәк тапмады, аның үз хәле хәл иде. Асылбикә түти, Зәйтүнә, этиләре карт өчәүләшеп тотып Сәфәргалине баскыч төбенә алып чыктылар. Корбангали абзый кешедән тимер хут арба сорап җиккән, арбага мул итеп печән салган иде — баш очына мендәр куеп, авыруны яткырмакчы булдылар.

— Сез тагы бигрәк, авыздан җан чыгарга тормый ич әлегә,— дип, мендәрне алып атты Сәфәргали. Кинәт шунда баскычка чыгып баскан Тәлгатькә күзе төште, малай сүзсез генә мөлдерәп карап тора иде,— ә син, улым, бармыйсыңмыни этиеңне озатырга?

— Алайса, карчык, әйдә син дә утыр, арбаның буш почмагы бар әле монда,— дип, урынлы-урынсыз җор сүз кыстырып ташлады шөребе какшаган карт тегүче. Моңа башкалар игътибар итмәсәләр дә, малай игътибар итте: «Бабайның алып барасы килми», дип уйлады ул боегып. Сүзсез генә басып тора бирде.

Җил капка ачылды, Корбангали карт дилбегә кагып атны кузгатты, китәселәр киттеләр, чыгып баскан урыныннан гел кузгалмыйча малай торып калды, яулык почмагы белән күзләрен сөрткәләп һәм авыз эченнән бетмәс-төкәнмәс догаларын пышылдап торган Асылбикә түти дә кузгалырга ашыкмый иде.

Сөйләшә башласалар, әлбәттә, мондагыларның да сүзләре табылыр иде — Асылбикә түти яше җитмәс борын акылы ташып барган оныгын тыңларга һәр вакыт әзер, хәтта малай белән сөйләшү аны чак кына очындыра да. Ләкин бу очракта малайның сөйләшәсе килмәде. Торды-торды да бер урында басып, капкадан уктай атылып чыгып китте. Һич югы, авылны чыкканчы гына утыртып барсалар соң! Әнә, бабасы ич.

Хәер, китеп баручылар арасында да сүз тиз генә ялганмады. Өчесе өч төрле уйланып бара иде.

Зәйтүнә уйлый: «Ник тыкшынды әле бу карт? Рәхәтләнеп, сөйләшер сүзләреңне сөйләшеп барасы урында барабыз менә авызга су кабып».

Сәфәргали уйлый: «Харап итте бу яралар ачылу. Мин кайтканчы киселгән агачларыбызны таратып, урлатып бетермәсәләр ярый. Врачлар кулына бер барып капсаң... тиз генә җибәрәләрме».

Корбангали абзый уйлый: «Әйтсәң, сүз башлар урын нәкъ үзе инде бу. Ят колак юк. Малайда бүрәнә кайгысыдыр дисеңме, аягына басып тора алмаган килеш. Килен үзебезнеке».

Гел сүзсез бару туйдырды булса кирәк, кинәт дуамал гына сүз кузгатып куйды Корбангали:

— Бу сугыш-кырылыш елларында каралты-кура зәп дә коелды, кара инде бу Урифкин авылын. Капка-койма юк, кругом тыкрык. Кайдан барасың килә — шуннан юырттыр арык алашаңны.

— Берьюлы булмый, Мәскәүне дә бер көндә генә бастырып куймаганнардыр, эти.

— Мәскәү моннан күренми, мин күргәнемне әйтәм,— дип, өнәрөнәмәс кенә җавап кайтарды Корбангали абзый.

Искерәк фикерле атай карт белән «Камисар малай» арасында кирәгендә дә, кирәк түгелендә дә күчәр башлары бәрелгәләп китүләрне электән үк белә-күзәтә йөргән Зәйтүнә бу очракта сүзне ничек тә олыга җибәрмәс өчен тизрәк арага керергә ашыкты:

— Больницаның ул шыксыз зур палаталарында унбишәр-егермешәр кешедән дә ким булмас. Гырлый торганы бардыр, саташа торганы... Болай да йокыңның рәте-җүне юк, Сәфәр...

Сәфәргали моны вак мәсьәлә итеп санады булса кирәк, җавап биреп торуны кирәк тапмады. Аның каравы, бу сүз картның тыгылып яткан җорлык буасын ерып җибәрде.

— Гырлый торган кешегә догасы үзе белән: ул гырлый икән, син аның колак төбенә барып җырлап җибәр: момент туктый.

— Пановкага да күп калмады,— дип куйды ул аннары, кинәт җитди тонга күчеп,— барып җиткәнче синең белән ваклап каласы туксаным бар иде дә...

— Мин сине тыңлыйм,— диде тегесе, кырын яткан җиреннән калка төшеп.

— Син тыңлавын тыңларсың, анысында шигем юк,— карт урабрак йөри, тел төбен берьюлы ачып күрсәтергә ашыкмый иде, — тыңлап бетергәч, сәкенеп ничек куярсың? Мине шул ягы кызыксындыра.

Малае сүзне сузарга бик ашыкмагач, тәвәккәл карт: «Әй, кем бар соң монда ят кеше. Барыбыз да бер алабута күмәче», дигәндәй, кинәт үгезне мөгезеннән борып алырга булды.

— Болай уйлыйм мин үземнең дурак башым белән, Сәпәр... — Бермәл мыек очларын боргалап торды, әйтерсең иң кирәкле сүзе

шунда — мыек очларында иде.— Үзең фронтовик, мәйтәм, эрбалуция өчен хәләл каныңны койган кеше, ул күкрәкләреңә дә медальне зрә генә такмаганнардыр. Нигезебездә кычыткан котырып утыра, кеше өендә торабыз. Кыскасы, мәйтәм, ул комбит кистергән бүрәнәләрегездән, шәт, безгә дә өлеш чыгардыр. Үзең бүлнистә ятканда, кайсынкая ташып бетермәгәйләре дип куркып әйтәм бу сүзләрне.

— Бетермәсләр. Мин булмасам, авылда совет власте бар,— диде Сәфәргали өзеп кенә. Әтисенең сүзе аны чак кына чыгырыннан чыгара язган иде. Моны, барыннан да элек, Зәйтүнә тотып алды — хатын кеше, мөгаллимә кеше, авыру ирен озата баручы кеше, арага кермичә булдыра алмады ул.

— Таптың сүз син дә, әткәй. Иң элек тизрәк терелеп кайтсын дип телисе урында...

Киленнеке дә дөрес, әллә белмиме Корбангали карт. Әмма аңарга үзенеке дөресрәк, беренче нәүбәттәгерәк булып күренә иде. Нишләмәк кирәк, ул кузгаткан темага сүз куермады, Сәфәргали сызланган атлы булып яңадан Зәйтүнәсе ягына кырын әйләнеп төште. Берсен дә ошатмады Корбангали карт: сүзнең ялганып китә алмыйча өзелеп калуын да, малаеның хатыны итәгенәрәк әйләнеп төшүен дә, бигрәк тә килененең арага кереп торуын ошатмады. «Кем колы торырсың? Хатын колы торырмын,— булып бара минеке дә. Баш юк, бүрек кенә бар. Камисар кушаматы таккан булганнар үзенә», дип уйланып барды ул.

Ә килененә әйтәсе сүзен кайтканда әйтте һәм үзенчә бик бирәгәйле итеп әйтте кебек:

— Кеше югында әйтим, килен, хәтереңә авыр алма, син әле безнең өйгә җил белән очып төшкән яфрак кына. Ирләр сүзенә, аннан килеп, ата белән малай арасына кысылырга сиңа әле иртәрәк, шуны белеп тор, җәме.

Һәм авылга кайтып җиткәнче бүтән бер сүз дә дәшмәде.

## 9

Сәфәргалине больницага салып кайтып, ике-өч көн уздымы икән,— Мөхсинов делянкадагы бүрәнәләрне кайтарту артыннан чаба иде,— бер көнне урамда аны Корбангали карт туктатты. Зурдан кубып сәлам бирде, ачык чырай белән хәл-әхвәл сорашты.

— Сезнең ише урындагы кешенең артына кыл сыймый торган вакытыдыр,— дигән булып, хәйләкәрләнеп, тегенең салпы ягына сәлам кыстырып маташты. Бүтән берәү булса, Мөхсинов ак җеп белән салынган мондый «ямау»ны шундук кубарып атар иде — кызу канлы эскадрон солдатын тиз генә таякка атландыра алмассың. Ләкин Корбангали карт белән ул алай коры сөйләшүне килештермәде — дөнья күргән бу карт тел бистәсен ул чын ихластан хөрмәт итә, шуның өстенә Корбангалинең данлыклы «камисар» этисе булганлыгын да онытмый иде.

— Ничек соң, безнең камисарны бик хуп күреп каршыладылармы анда, бүлнистә дигән сүзем? — Авыруның хәленнән дә бигрәк, үз хәлен белдерергә ашыгып, аннары өстәде:— Монда мин аннан башка перәме ике кулсыз.

— Кичкә миңа сугыл әле син, Фазылҗан. Барысы турында да шунда гәпләшербез,— дип, Мөхсиновны бүлдерде Корбангали абзый. Аннары, гадәтенчә тәкъдимен җор сүзенә төрергә ашыгып, өстәп куйды:— Асылбикә түтәң тавык суйдырмакчы ие бүген. Дөрес, тавыкның күкәй сала торган вакыты, ник әрәм итеп, җан кыясыз дип әйтәсең булыр. Илла бер нәфсесе төшсә, җан кыюны инәгә дә сана-

мый Корбангали тегүче. Үз гомерендә биш мең җиде йөз илле биш тавык башына җиткән кеше, әгәр алты мең үк булмаса.

Шундый җор телле атаклы тегүченең чакыруын игътибарсыз калдырырга мөмкинме соң! Җитмәсә, Мөхсиновның Сәфәргали һәм аның кайчанрак аякка басарга ниятләве турында ныклабрак сорашасы да килә иде. Яшерен-батырын түгел, болар өстенә тагын, әлбәттә, тавык ите дә эчне тишмәс.

Көтү кайтып, кичке ыгы-зыгы башланган арада, ләкин урамда кеше аягы басылганны һич көтеп тормастан, тып итеп килеп керүе булды авыл башлыгының. Корбангали карттан өрекми — үзе чакырды! — шулай да өйдәге хатын-кыздан бик үк яхшысынмый, бигрәк тә мөгаллимә киленнән уңайсызлана иде.

— Бер бәрәнебез көтүдән кайтмый калды, шуны эзләп йөрешем,— дигән булды ул, болай вакытсыз йөрүенең сәбәбен кер-ә-керешкә аңлаткан атлы күренергә тырышып.

— Алдан ук әйтеп куям, бездә юк бәрәнең,— дип шаулап каршы алды Корбангали абзый. Ул рәиснең иртәнчәк булган сүзне аяк астына салып таптамыйча килеп керүенә шатланып бетә алмый иде,— мәгәрәнки, олы башыңны кече итеп, Корбангали тегүченең бусагасын атлап кергәнсең икән, шундук борылып чыгарга рөхсәт итмәбез.

Аннары, өйдәге кыз-хатынга сиздермичә генә, Мөхсиновка дустанә күз кысып куйды:

— Кул җу дип кыстау юк, урындагы кешенең кулы һәр вакыт чиста булыр: тавык шулпасы әзер, этәч булып кычкырырга маташа башлаган игелексез бер җан бар ие, шуның башына җиттем.— Шундук, карчыгы ягына — кече якка борылып, өзеп кенә әйтте:— Кайда, энкәсе, безгә начас кына табын әзерләп бир әле. Мондый зур кунак бусагадан атлап кергән икән, ризыктан да олы түгелдер, табынга утыртмый чыгару килешмәс.

Мөхсинов бераз аптырабрак калды. Тавык шулпасы исе дә борынны кытыкламый түгел, шул ук вакытта кеше табынына утырып моңарчы локмә ризык капканы да юк. Андый эшне күңеле күтәрми. Кеше сүзеннән куркудан түгел, үзенә-үзе биргән шелтәдән — «әһә! Ил өстендә ашап йөри башладыңмы син дә. Микулай заманындагы канечкеч старосталар кебек» дигән шелтәдән курка иде.

Табынга ризык килүдән элек, чытлык карт Корбангали ашыгыч бер адым ясамаган булса, Мөхсинов бу мактанчык ярлы тәкәббернең табынына утырып, берәр кашык шулпасын кабудан да тартынмаган булыр иде. Үз гомерендә күп тапкыр башына бәла булып төшкән шул ашыгу-кабаланучанлыгы — асыл кошны аягыннан эләктерәм дип торганда — бу очракта янә дә харап итте чытлык картны. Кирәк бит, табынга әле тавык шулпасы килеп өлгермәгән, ә Корбангали инде кочаклап килә. Киндер алъяпкыч, шул киндер алъяпкычка кадерләп төрелгән шешә. Җитмәсә, теленә салынып маташкан булмаса икән!

— Менә бу «кунак»ның почмакта посып утыруына унбиш көн, җылый-җылый утырды бичаракаем, ә мин — карт тиле — җылый-җылый тирә-юнендә әйләнеп йөрдем. Илла вәгъдә көне җитмичә теңкәне корытты. Менә хәзер какрас шул көткән көн килде булса кирәк: казанда тавык пеште, түремдә кадерле кунагым — сәвит влачы. Әйдә, җаным, мәйтәм, якты дөнья чыраен күреп кара, синең дә көнең килде, мәйтәм.

Ләкин Корбангали абзый шешәне киндер алъяпкыч астыннан тик чыгарып кына өлгерде, хәтта бик дәртләнеп тотынган монологын да бетерә алмады, сикереп урыныннан купкан Мөхсинов шундук аның кулыннан шешәне тартып алды.

— Нәрсә бу? Кайдан алдың? Үзең кудырдыңмы?

Әле генә сайрап торган тел бистәсе картыбыз кинәт ык-мыкка калды, чөнки күреп тора: Мөхсиновның күзләре утлы кадак булып аңарга кадалган иде.

— Әйтмичә кала алмыйм, Корбангали абзый, малаең камисар булса да, әйтмичә кала алмыйм: менә шушы минутта ике җинаять өстендә тоттым мин сине. Беренчесе — көмешкә. Кешедән алган булсаң да җинаять — ил икмәккә туймаганда, кайсыдыр ки ач күзле спекулянтны узындыруга юл куйгансың. Үзең кудырган булсаң, тем паче — хәзер үк мин синең струментларыңны конфисковать итәргә, милиция идарәсенә тапшырырга тиешмен.

— Үзем түгел, билләһи, җир йотсын, үзем түгел,— дип шүрли төшеп кабатларга тотынды карт, аңа үзе өчен дә, бигрәк тә малае, укытучы килене өчен уңайсыз иде. Берничек тә аклана алмагач:

— Кара әле, кем, Фазылҗан энем, әтиең белән бергә гомер иткәнгә шулай әйтүем, гаепкә алма. Әле бит син дә, мин дә авыз итеп карамаган, бәлкем ул гупчи да икмәктән ясалмагандыр, бәлкем ул бәрәңгедәндер.

Ләкин Мөхсиновның йомшар исәбе күренми, ул «әтисе белән бергә гомер иткән» картны куыра бирә иде.

— Герой красноармеецның атасы, панимаешь, килинең мөгаллимә, ничек оят түгел сиңа, Корбангали абзый: көмешкә и шул көмешкә белән авыл властеның авызын томалауны план итеп куйгансың. Взятка белән бер бу — икесенә бер статья закон кенәгәсендә.

— Кара әле, кем, изге ата баласы, әле бит «әчик!» димәдем. Бәлкем бу күрсәтүем генә булгандыр. Икенде намазына дип алган тәһарәтем бар, тәһарәтле авызым белән сорыйм: күпертмик сүзне. Эчмибез икән, берәү дә авызыбызга коймый, алып куябыз. Алып куябыз да тавык шулпасын бисмилла белән генә кушабыз да ашыйбыз.

Тегесе дә кызу, бусы да кызу, әгәр тавышны зурга җибәрә калсалар, белгән юк, кем кемне җиңгән булыр иде, ә менә картның тәһарәтле килеш көмешкә чөмерергә җыйналып йөрүе кинәт Мөхсиновны йомшарткандай булды.

— Болай булгач ике генә түгел синең җинаять, Корбангали абзый,— башлык та кеше ич, әллә ул көлә белмиме? — тәһарәтле килеш көмешкә эчәргә җыйналгансың — бу булды өченче җинаять.

— Сер итеп кенә... синең үзеңә генә әйтәсе сүзем бар ие. Әллә, Фазылҗан, утырасыңмы? Тавык шулпасын гына авыз итеп карыйкмы дим? Ризыктан олы түгел бит беребез дә.

Сүзгә Асылбикә түти дә кушылып, икәүләп кыстап карадылар, ләкин Мөхсинов инде кузгалган, ишек төбенә килеп җиткән иде.

— Сүзең булса,— диде ул кистереп,— совет йортына кил. Өемнең дә кайсы урамда икәнен беләсең, тавык шулпасы ук вәгъдә итә алмыйм, но чәй эчәргә мөлким булыр.

— Синдә, түрә кешедә, ихтимал, такта чәйдер әле,— дип, кирәк түгел җирдә тагын шаярту кыстырып маташты Корбангали абзый. Председательнең эшне зурга җибәрмәвеннән ул бит шат иде.

— Такта чәйне коммунизмга чыккач эчәрбез,— актык сүзе шул булды авыл башлыгының. Әллә тагын ачулануы, әллә өметләндерергә тырышуы иде бу аның,— шуны ачык кына абайларга өлгерә алмый калды карт.

Калган эшкә кар яварга ирек бирмичә, иртәгесен үк Мөхсиновның өенә барып керде Корбангали. Хәер, сузып торыр вакытмы. Кызу канлы Мөхсинов эшне коры тота. «Мобилизация тәртибендә!» дип кычкырынып, авылның ике атлы хәллерәк кешеләреннән берәр атын озын арбага җиктереп, урмандагы бүрәнәләрне кайтарта башлаган, ат-сыер кермәгәнлектән ишегалдын үлән баскан ике фронтовик семья-

сына урман исе аңкып торган чи бүрәнәләр инде аударылган иде. Шуны искә алып, бу юлы карт кыска сүзле, ефәк телле булырга тырышты.

— Ачуланма, Фазылҗан, кенәгеи әйтә алмыйча калган серемне әйтергә дип килдем, эчкә җыелган сүз әйтелми калса, кату булучан,— Фазылҗанның хатыны, татар гадәте буенча самавар колагына ябыша башлагач, кулы белән кисеп ташлагандай, үзеп кенә әйтте:— ташла әле, килен, кирәк-кирәкмәскә самовар яндыруны. Иртә белән эчкәнем авыздан килә.

Һәм ул, ымлар белән генә ишарәләп, «килен»нең бу минутларда гомумән өйдән үк югалып торуы хәерлерәк булганны аңлатты. Мондый мәсьәләдә Мөхсиновка кат-кат аңлатуның хаҗәте юк, аның бер карашы җитә, бераздан алар өйдә икәве генә калган иде инде.

— Сүзем шул, иптәш-тавариш Мөхсинов,— дип башлады Корбангали карт, мөмкин хәтле «урындагы кешеләр»чә чыгарырга тырышып,— безнең хәлне үзең күреп торасың: төп нигезебездә алабутакычыткан үкереп утыра, ә үзебез кеше бусагасында йөрибез. Фактически алып әйткәндә, беренче чиратта, кемгә тиеш урман? Минем малайга — безгә тиеш урман. Фронтовиклыгы — бер. Тәне тишек белән тулган, җиде җиреннән ранный — бу булдымы ике. Кемнең әле шундый алтын белән язылган Мактау кәгазьләре алып кайтканы бар? Ә минем Сәпәр кайтты. Бу булдымы — өч. Хатыны мөгаллимә, панимаеш, урындагы кеше. Бу булдымы — дүрт.

Дүрт бармагын бөгеп чыккач, бишенчесен бөгәргә әзерләнеп, беравык уйланып торды ул, бөгәрдәй сәбәп таба алмагач, ачуланып кулын селкеп куйды һәм шул кызган шәпкә ярып салды:— Иә, әйт, законныймы минем сүз? Әллә контр сүзен сөйләп утыручымы мин?

— Малаең үзе өйрәтеп җибәрмәгәндер ич? Зрә дә законный сөйләп утыруыңнан әйтәм бу сүзне.

— Әй, сөйләмәсәнә ул төшеп калганны! — Корбангали абзый сулагай кулын селтәп куйды, малае Сәфәргалидән бөтен ризасызлыгы шушы бер селтәнүдә бәреп чыкты.— Анда сугыша белгән, ә монда, мин сиңайтим, арыш боламыгы булып йөри.

— Арыш боламыгы булып йөрсә, урманны юллап ала алмаган булыр ие, синең Сәпәрең юллап алган урманны бүләбез түгелме соң?

— Менә-менә, өстенә үк китереп бастың,— дип кодрәтләнеп куйды Корбангали карт һәм, сүзгә суынырга ирек бирмичә, тел төбен ачты да салды:— алла үзе язып, санап куйган безгә дигән бер өйлек бүрәнәне. Артыкны сорамыйм, кимгә риза түгел.

— Тукта әле, алланы куеп тор син, аллага аңа мәчете булгач до горла,— Мөхсинов, ачуланган кебек, ишекле-түрле бер йөренеп килде, кесәсеннән бөрмәле бәләкәй янчык тартып алды, янчыктан түгәрәк пичәт чыгарып, бермәл карап торды. Авызын зур ачып, пичәткә өргәләде, аннары янә янчыгына тыкты һәм янә кесәсенә салды. «Мин әйткәнгә пичәт басуы, ахры, моның» дип канат ярып көтеп торган Корбангали карт, пичәт яңадан үз урынына кереп югалгач, бермәл кара көеп сүзсез утырды: «Сүз әйтеп торган булам бу зимагорга, мин дә шул карт дурак!» дигән уй үтте аның күңеленнән. Инде борылып чыгып китәргә генә калган иде. Ләкин чыгып китәргә өлгермәде, Мөхсинов якты чырай белән аңарга якынрак елыша төште:

— Син дөресне сөйлисең, картлач,— дип, картның иңбашына кулын дустанә китереп салды ул.— Сәпәргә тиешлекне әллә мин белмимме? Сөйләштеңме соң үзе белән? Әгәр син дигәнчә эшләсәк, ул моңа ризалык бирерме?

— Ул ризалык пычагымамы миңа? — дип чәчрәп торды Корбангалинең, аның карт күзләренә комсыз чаялык чаткысы бәреп чыккан иде.— Өлеш кенә бир син миңа. Үзе бүлнистән кайтканчы бүрәнә-

ләрне ташып, өйне бастырып куям мин, алла боерган булса. Корбангали тегүчене белмисең икән әле син, кара кашым.

Болай «кара кашлап» ук җибәргәч, ничек кенә коры талкан булмасын, хәтта Мөхсинов та йомшармыйча булдыра алмады:

— Менә без болай итик, алайса,— диде ул, ниндидер юлын тапкандай кыяфәт белән,— мин монда кайбер сельсовет членнары белән сөйләшим дә... иртәгә хәтле көтәргә сабырың җитәр бит? Только сүз бер булсын: урманнан кайтартуын үзең кайтартасың, терелеп чыкканнан соң камисар малаең белән үзең аңлашасың. Булдымы шулай?

«Шулай булса, пичәт әзер!» дигәндәй, ул пичәт салып йөртә торган бөрмәле янчыгын янә кесәсеннән чыгарды.

И, моны да булмады дисәгез инде! Кыскасы, күпме еллар буена үзенең туган нигезенә яңа өй салдырып керү нияте белән хыялланып йөрүче Корбангали абзыйның башы күккә үк барып тимәсә дә, тәбәнәк авыл өенең түшәменә тия язган иде.

— Менә бит ул совит влачы. Бирәм дигән кешесенә бирә бит ул. Мәгәренки, аның көеннән тора белергә кирәк.

— Бик иртә төчеләнмә,— дип, картны кырт кисте Мөхсинов,— бирәм дигән кешесенә түгел, тиешле кешесенә. Шикәрне сахариннан, революцияне кода-кодагыйлыктан аера белергә вакыт.

## 10

Каты сукага төшәргә иртә, сабан туйлары — елына күрә җылы шулпа гына булса да — инде узган, авылның кунаклардан айнырайнымас иңке-миңкерәк торган бер чагы иде. Әлбәттә, үтә эшем кешеләре буш тормый, шушы ара — буш ара дип, кырга тирес чыгара, авыл өстенә аның әчкелтем исе тарала, такыр юлларга биялəй-биялəй тирес кисәкләре коелып кала. Әмма авыл шул ис белән генә туенып тормый. Тегe очта да, бу очта да, Үрдәк урамында да, Кушъелга башында да — иртәдән кичкә хәтле, күрше күршедән уздырырга тырышып — балта, пычкы тавышлары ишетелә. Ни хәерче кешеләр — фронтовик семьялары, малайлары сугышта үлеп калган сәлперәйгән карт-карчыклар — хәтта алар да терелгән. Китереп аударган бүрәнәләрне яңгыр астында черетеп яткырасылары килми, сыеры булганы сыерын сатып, осталар яллаган, өй кузгаткан — зарлану юк, берәр ел, сатылган сыерның бозавы үсеп җиткәнче, сөтсез яшәргә дә ризалар, күрше-күлән арасында өй генә өскә ишелергә тормасын. Ярлылар комитеты башлангычы ярдәмендә өмәгә урман кисү, Мөхсиновның «мобилизация»сеннән өркеп, «җыен хәерче»гә бушлай бүрәнә ташып бирүләр авыл халкында сирәк була торган «җенне» кузгаткан: «И, берничә көн кардәш-ыруга булышканнан гына дөньям җимерелмәс, кемнең дә кояш астында кеше шикелле яшисе килә!» дип карый. Оста ялларга көченнән килмәгәннәре өмәләр уздыралар, белеп киләләр андыйларга: бу корышкан мәчет карты, әлбәттә, самогон куймас, аның каравы, хәер-догасы белән коендырыр, аннары килеп, корырак булса да бәлеше булыр.

Бөтенесе кузгалган, бөтенесенең дә бөтәясе, ямалып-сипләнеп каласы килә. Ә шул бөтенесе арасында иң нык кузгалганы, әлбәттә, Корбангали карт иде. Комбед чутыннан өйлек бүрәнә кулга төшергәч, ул бөтенләй яшәреп китте, чабыпмы-чаба. Хәер, болай ашкынуы аңлашыла да. Өйләре ишелергә торганнар, әлегә шундые булган хәлдә, шулай зык купканнар икән, өстенә ишелерлек өе дә булмаган, кеше өендә яшәүче Корбангали тегүче ник авыз ачып торсын, ди? Икенче сәбәбе тагы шунда: малае Сәфәргали Пановка больницасыннан терелеп кайтканчы, Корбангали картның алты почмаклы яңа

өйгә кереп аласы килә. Югыйсә, «Камисар малай»ныкын белмәссең, кайдандыр дөньяда юк хөррият законнарын актарып чыгарыр: янәсе, имеш, иң элек кешегә, аннары күршегә, аннары гына үземә. Булдыра алган хәтлә мөгаллимә килененең запасларын да әрчеде, бурычка да керде, өйдә сыңар күкәй дә ваттырмыйча, Асылбикә тутинең күкәйләрен дә сата торды, кыскасы, ничек итсә дә итте, Комаровкадан махсус осталар китертеп, өйне рус өйләре кебек тәрәзә яңакларын киртләчләп, таш фундаментка салдырырга булды. Түбәсен яптыру өчен шул ук Комаровка якларыннан түбә тактасын да үзе ташыды — әлбәттә, буш түгел, тиешле хакын түләп, мөгәричен эчерттә. Калай белән яптыру нияте дә юк түгел иде — юк-бар шырлатан түгел, «Камисар малай»ның этисе торасы өй ич. Ләкин бу планы барып чыкмады, ник дисәң, сәбәбе булды: Корбангали картның өй салдырырга дип элек-электән җыя килгән яшерен «казнасы» — Николай акчалары да, шырпы тартмасындагы пичәт кебек шакмаклы керинкалар чүп булып чыкты. Андый чүпләр белән Комаровка яки Теләче осталарын алдарсың бар. Сүз арасында сер итеп кенә әйтү: алданырга әзер торучысы булса, Корбангали карт, шәп өй салдырырга дигәндә, гөнаһысыннан тамчы да курыкмыйча алдарга әзер иде.

Өй салдыру хәстәре белән шулай чапкан бер вакытында кайнатаңнан ничек ат сорап тормак кирәк! Хәер, сорый калганда да, җавабын тапкан булыр иде: «Атның холкы начар, хатын-кыз кулына тоттыра алмыйм!» гына дияр иде. Шуны искә алып, Зәйтүнә Сәфәргалинең хәлен белү өчен нәүбәттәге баруында ат турында ләм-мим сүз кузгатмады, улы Тәлгатьне җитәкләде дә җәяүләп китте.

Шулай да капка төбендә туктатып, карт аларны нык кына кисәтеп калды:

— Өй салдыру чутыннан Сәпәргә теш арасыннан сүз чыгарасы булма, терелеп кайтышына яңа өй бусагасын атлап күзләре шар булсын!

Чынлыкта исә, малаеның «күзләрен шар ясаудан» да бигрәк, ул моны шүрләүдән әйтә: янәсе, аның ул «шыр диванасы» кешедән элек үзләре турында кайгырткангa пыр туздырмагае. Ә дөресен әйткәндә, ник кешедән элек булсын, бөтен авыл — хәлле хәленчә дигәндәй — кагына, тезәтенә. Хәләл юл белән килгән агач та бар, казна делянкасы сылтавы белән, шактый өстәп кайтканнары да аллага шөкер — авыл кешесенә ни, бутка булса да ярый, өйрә белән генә калса да амины әзер!

Шулай да Корбангали картның капка төбендәге кисәтүе нәтиҗә бирмәде. Больница бакчасының эскәмиясендә — бакча бик ямьле, теге күздәге шыр көйгән клумбалар түгел, бөтен җир шау чәчәктә иде — этисе белән әнисенең чукердәшеп сөйләшүләрен бер читтән тыңлап утыру гына Тәлгатьне, әлбәттә, канәгатьләндерми, аның да этисенә нинди дә булса бер яңалык җиткерәсе килә иде.

— Эти, без яңа өй салдырабыз, үз өебезне,— дип, ишетми калмасын дигәндәй, җан-фәрман кычкырып салмасынмы!

Зәйтүнә сиздермәскә тырышып кына Тәлгатьнең янтыгына төртте, ләкин соң иде инде, яңа хәбәрне эти дигән кеше бик тиз ишетеп өлгерде.

— Шулаймыни, улым? — дип, малайны тезенә алды Сәфәргали, шатлангандай күренергә тырышып дәвам итте.— Ә әниең әйтмәгән иде. Күрәсең, бабаң белән икесе миннән яшереп эшләмәкчеләр.

— Бабаң нәрсә диде сиңа? — Зәйтүнә Тәлгать белән сөйләшкән атлы булып күренергә тырыша, Сәфәргалинең күзләренә бик карамый, шулай да күреп тора: теге уйланып калган иде.

— Тәки үз дигәнен иткән икән,— дип, авыз эченнән мыгырданып куйды Сәфәргали,— күз алдыма китерәм: мин юклыктан файдаланып,

Мөхсиновның бусагасын таптады бугай. «Үзем!» дигәндә авызы кыймылдый да инде.

— Әткәйне дә гаепләп булмый, Сәфәр. Картаймыш көнендә кеше нигезендә яшәү әллә җиңелдерме аңа?

— И, картлар яклы булып чыктың ла син, әнисе,— аера алмады Зәйтүнә: әллә чынлап әйтүе бу «әнисен», әллә мыскыл белән төрттерүе,— беләм мин ул картның нәфесен, синекен дә тарттыра торгандыр әле.

Җиңеләеп калгандай булды Зәйтүнә, ул яктан китереп әйтүе икән.

— Мүклисе дә, чутлыйсы гына түгел шул,— дип, иренә янтая төште. Күренеп тора: бу кысылудан аның сөяк-санакны ватмыйча чыгасы килә иде,— сиңа костюмлык, кышка пәлтәлек дип саклап торганым бар иде. Ахыры, картым, тагын бер-ике кыш шул иске шинелеңдә генә кышларсыңдыр.

— Сәгъди абзыйлар нихәл яталар? Әй кузгаталармы? — дип, кинәт сүзне икенчегә борып, авыл хәлләрен сорашырга тотынды Сәфәргали.

— Сыерларын саттылар. Күрше-күлән дә булыша. Инде түбә кайчыларын куялар.

— Итәк кисеп, җиң ялгау килеп чыккан икән.

— Бабай безгә ат бирмәде. Җәяү килдек. Урман аркылы чыкканда куян күрдек,— өзек-өзек сүзләре белән Тәлгать тә әңгәмәгә катышасы итте.

— Бабай белән мин үзем сөйләшермен. Менә кайтыйм гына,— дигән булып, малайны юатырга тырышып, битеннән үбеп куйды Сәфәргали.

— Сакалың кадый, үпмә мине.

— Менә терә вәт: мин дә ошамадым, бабай да ат бирмәгән.— Сәфәргали бу сүзләрне уйнап кына әйтте, ләкин уйлап әйткәннән болайрак чыкты: Тәлгатьнең шулай шырпылы торуы аны кинәт сискәндергән иде.

Авыруларны көндезге ашка чакырып звонок шалтырады, теләсәләр-теләмәсәләр дә аерылырга кирәк иде. Малай белән әнисе китәргә кузгалгач, Сәфәргали, нәрсәнедер исенә төшереп, тиз генә палатасына кереп китте. Анда аның авызыннан өзеп җыя килгән ун-унбиш шакмак шикәре булган икән, төргәкне хатынына түгел, Тәлгатькә тоттырды:

— Кайткач, әбиең белән икегез чәй эчәрсез,— диде. Малайга сиздермичә генә, Зәйтүнәсенә күз кысты,— бабайга бирмә, сезгә атын бирмәгән ич үзе.

Малай кучтәнәч шикәр белән әвәрә килгән арада, Сәфәргали Зәйтүнәсен бит очыннан гына үбеп алды. Малай күрмәде дип уйлаганнар иде, күргән икән, каһәр. Кайтыр юлга чыгып хәтсез генә сүзсез барганнан соң, Тәлгать дуамал гына итеп:

— Сине дә кададымы сакалы? — дип сорап куйды.

— Әллә тагы,— дигән булды Зәйтүнә, сорауны колак яныннан ничек тә уздырырга тырышып. Аулактан файдаланып, аның малайны кыздырып аласы да килгән иде, ләкин уйлый торгач, бу юлы да тыелып калырга булды — нишләмәк кирәк, чыккалардыр әле мондый «кадый торган сакаллар». Шулай да улы белән иплән кенә бер сөйләшергә кирәк һәм бу сөйләшү өчен иң уңайлы форсат менә хәзер иде. Тик сүзне нидән һәм ничек башларга? Орышырга тотынсаң, малайны берьюлы өркетүең, тагын да ныграк үз кабыгына яшеренергә сәбәп ясавың бар. Иркәләрлек сәбәп әлегә күренеп тормый. Шулай сүзсез-өнсез тотаклашып кайтып килгәндә, Тәлгать үзенең яшенә туры килми торган олы сымак кыяфәт белән:

— Эни, безнең бу эти кайткач та безнең белән, бабайлар белән бергә торыр микән? — дип сорап куйды. Зәйтүнәне бөтенләй сискәндереп җибәрде малайның бу соравы. Кинәтлеге белән — бердән. Эчтәлеге белән — икенчедән. Малайның кулыннан кысыбрак тотты энисе. Сизеп бара: бик күпне белә башлаган бу бәләкәй фетнә белән, ахры, ныклабрак сөйләшер минут нәкъ менә килеп җиткәндер.

— Каңдан башыңа килде мондый юк сорау? Безнең белән, бабаңнар белән тормыйча кая китсен ди ул?

— Безгә ат бирмәгәне өчен бабайга ачуланды ич эти. Күреп тордым ич мин.

— Күпне күрә башладың син, Тәлгать улым. Болай иртә алай күпне күрә башласаң, вакытыннан элек картаймагаең, дип куркып торам.

Әйтте һәм шундук уйлап та алды: юк, болай башланырга тиеш түгел иде сүз. Һәм бераз дәшми-тынмый барганнан соң, кинәт шелтәле тавыш белән, хәтта чак кына кычкыра төшеп, туп-туры сорау куйды:

— Кем уйлап чыгарды ул «безнең бу эти» дигән сүзне? — сораудан шундук кисәтүгә, хәтта өзеп әйтү тонына күчте,— теге вакытта бер әйттем инде мин сиңа, малай актыгы. Тагын бер кабатлыйм. Өченче кабатларга урын калдырма, ишетсен колагың: «Безнең теге эти», «Безнең бу эти» юк, безнең бер генә этиебез бар, безнең Сәфәргали атлы этиебез генә, «Камисар» этиебез генә бар!

Кыза барганын үзе дә сизмичә, малайның колагына ук ябышты энисе, ләкин кызартып, авырттырып борырга ашыкмады, чөнки белә: малайның колагы авыртса, үзенең йөрәге авыртачак.

Колакка ук барып җитеп әйтелгән бу кисәтү сүзе шулай да үтәрлек булды булса кирәк, малай шуннан соң шактый вакыт дәшмитынмый тыраклады, ул эндәшмәгәч, энисе дә сүз кузгатмады. Әмма җәй башының мондый якты, кояшлы көнендә, баш очында берөзлексез тургайлар сайрашып торганда, алдында шундый такыр юл сузылып ятканда, үзең тагын энисең белән икәү генә бул, малай кешегә шул хәтле озак сөйләшми бару мөмкинме соң! Бу эчпошыргыч тынлыкны җимерергә кирәк, нәрсәдер әйтергә кирәк иде, әлбәттә, аны-моны уйлап тормады, теленә килгән беренче сүзне әйтте малай:

— Эни, эти биргән бу шикәрне бабайга да бирербез, җәме?

— Бабаң ат бирмәде ич безгә,— дип, малайны ирештерәсе итте Зәйтүнә. Әле генә киреле-мырлырак сөйләнеп торган малаеның кинәт болай бабай яклы булып китүе аның күңелен ачкан һәм, җитмәсә тагын, һавадагы тургайлар, әлбәттә, аның өчен дә сайрыйлар, Сөекле ире белән дә очрашты, анысы тагы: «Сагындым. Духторларның ишек ачып озатып калуларын көтеп җиткерәсем юк, тәрәзә аша төшеп, җәяүләп качып кайтам!» дип тә теленә салынган булды. Кыскасы, Зәйтүнәгә генә гомер буена гел өзгәләнеп, тәрлесен уйлап яшәргә димәгәндер, һич югы, бер генә көн, бер генә сәгать булса да Зәйтүнәгә дә бәхетле булып карарга ярый торгандыр лабаса!

Ләкин бәхетле булырга ашыга төшкәнбез икән, дөньяның сораулары-борчулары бетмәгән икән. Сүзсез-өнсез энисе белән рәттән тыраклап кайтучы Тәлгать искәрмәстән генә тагын бер башка килмәслек сорау китереп куймасынмы!

— Алай булгач... ул минем эти булгач...— дип, әйтәсе сүзен төреп кенә әйтә алмыйча, балаларча буталып, өстәвенә, энисенең баягы шелтәсеннән соң чак-чак кына өркебрәк тә булса кирәк, сузгалап торды малай,— ник ул мине бер дә кыйнамый? Бүтән малайларның этиләре кыйный ич.

Йа хода! Әле мондый сорауның да куелуы мөмкин икән! Димәк, малайның эчке дөньясы әлегә карурман, ул тегеләй дә, болай да

уйлана һәм иң читене — аны тегеләй дә, болай да уйлаудан берәү дә, хәтта тапкан анасы да туктата алмый. И дөнья! Җырчы кошларың белән шатлык һәм моң алышып, шатланып һәм көлеп яшисе балаларың өчен ник шул хәтле гамь-хәсрәт тә яраттың син?

## 11

Сәфәргали Пановка больницасыннан көз җиткәч кенә кайтты — ак халатлылар кулына бер эләксәң, тиз генә ычкындыралармы соң! Ул кайтканда, Корбангали абзыйныкылар алты почмаклы яңа өйгә — үз өйләренә кергәннәр иде инде. Каршылыклы сәер хис эчендә калды Сәфәр. Бер яктан, бала чактан ук аунап үскән үз нигезенә салынган яңа өйгә кайтып керү, әлбәттә, күңелле иде. Икенче яктан, авылдашлары алдында ничектер уңайсызлану сизә: телдән үк әйтеп бетермәсәләр дә, эчләреннән уйлардыр кебек: «Әнә бит... йөрде, йөрде тегүче Корбангали камисары, ярлылар комитеты дип чапкан булды, гомердә булмаган бәлешсез өмәләр кузгатты... Ә чынлап карасаң, күбрәк үзе өчен чапкан икән. Сөйләгән булмасыннар «Хөррият тә хөррият... Тигезлибез дә тигезлибез! дип. Бар кешенең дә бармагы үзенә кәкре!»

Җитмәсә тагы, этисе «кәкре бармак» белән бер буразнадан тигез генә атлап барсалар икән, юк бит тигез генә атлау. Кайтып керү белән, кыз-хатынга ишеттермичә генә, ишегалдында бер «сөзешеп» алдылар.

— Морадыңа ирешкәнсең икән, эти, башка ни әйтим, — диде Сәфәргали, куанганлыгын яки төрттереп әйтүен сиздермәскә тырышып,— только миңа хәзер авылдашлар күзенә ничек күренергә булыр икән? Иң элек үзе өчен йөргән димәсләрме?

— Димәсләр! — Шушы бер сүз белән өзмәкче иде кызу канлы Корбангали, ләкин үзен тыеп кала алмады — хаклары юк алай әйтергә! Эрбалуцияне кем ясады? Син и синең кебек атаман егетләр ясады. Әллә синең үзең ясаган шул эрбалуциядән усак бүрәнәле өй генә алырга хакың юкмы?

Анысы шуның белән беткән иде, өйгә кергәч, «без очы» икенче яктан калкып чыкты.

— Алгы якка сәке җәйдергәнсез, анысы ярасын да ди, ә нигә түр якка сәке кирәк булды? — Бусын болай шаяртып кына, хатыны белән аңлашкандай гына башлады Сәфәргали.— Мөгаллимә кеше, бу чаклысын син чамаларга тиеш идең, Зәйтүнә. Кайчан без, башка халыклардагы кебек, культурный гына итеп өстәлдә ашый-эчә башларбыз икән?

Хәтта ярым пышылдау белән әйтелгән шушы уен-көлке сүз дә картның колагына барып җиткән бит. Ул, бусагадан атлар-атламас, киленен яклап арага керергә ашыкты:

— Син, агай-эне, чәй эчәргә иң элек шикәрен табып бир,— дип, Сәфәрнең авызын томалады ул,— тешләп эчәргә шикәре, салырга такта чәе булса, безгә аның культурасы ишек төбендәрәк торса да ярый. Шулай бит, килен?

Гомумән, үз сүзле картның яшьләргә буй бирер нияте күренми, малай анда — хөррият ясаса, инде кайтып монда — кунаклар колгасы юк ярлы-ябага арасында «камисар» атын күтәреп йөрсә, үз өемдә мин үзем камисар дигән төслерәк тота иде. Шушы үзсүзлелеге, дөньяны бары тик үз манарасыннан гына күрүе, ниһаять, ул тынгысыз картның әҗәлен якынайтуга да сәбәп булды.

Кирәк бит шундый үҗәт булырга. Малае, килене — бер яктан, гомер иткән Асылбикәсе һәм үлеп ярата торган оныгы Тәлгать —

икенче яктан, һәркайсы үзләре аңлаганча, әйтеп, үгетләп карадылар.

— Әти, йөрисе түгел, бу дөньяны син генә куып тота алмассың,— диде Сәфәргали ирләрчә җитди итеп.

— Үзең уйлап кара, карт. Кем сиңа анда җылы урын әзерләп куйган да, кем ертык-тишегеңнә ямар! — дип, үзенчә өзгәләнде Асылбикәсе.

Хәтта Тәлгать булып Тәлгатьнең дә әйтер сүзе табылды:

— Син атны апкитсәң, бабай, миңа калмый бит... эчерә төшәргә.

— Җылы өендә, кадер-хөрмәттә генә ятасы,— дип карады килен дә.

Бөтенесе әйтәсе сүзен әйтте, ләкин Корбангали карт үз сүзен бөтенесенекеннән дә өстенрәк чыгарасы итте.

— Барыбыз да җылы өйдә җыелып ята башласак...— диде ул, артыгын эчендә тыеп калдырып. Фикеренең дәвамын ишек төбенә чыккач, кадарга тырышып, Сәфәргалинең үзенә генә әйтте.— ...Җылы өең бар, ә өй тирәндә җил уйный. Бер торык каралты, тәрәт итәр өчен урын юк. Кем кайгыртсын алар өчен?

Һәм бүтән бер сүз дә өстәп мәшәкатьләнмичә, арба көпчәкләрен майларга тотынды. Хәер, болай җенләнеп керешүнең сәбәбе дә юк түгел, кайдандыр колагына кереп калган: имештер, Арчаның крахмал заводына күрше-тирә авыллардан бәрәңге чималы ташу өчен атлы йөкчеләр кирәк, йөри белеп йөргәндә, акча коеп ук булмаса да, һәрхәлдә, ат тамагын, үз тамагыңны туйдырырлык кына төшә, шуның өстенә, кесәгә чылтырап төшкәннәре дә була, имеш. Бер уйлаганда, картныкы да дөрес. Яңа өйдә чөкердәшеп торырга вакыты табылыр: алда әле озын көз, аның артыннан сузылып киләсе ак сакаллы кыш бар. Мөгаллимә килен көмәнле, менә-менә семьяга яңа кеше өстәлергә тора — ул «яңа кеше» белән утырганда акчасы килерме, юкмы? Корбангали карт моны ачык кына белми һәм килененең карынындагы туасы җан иясе китерәчәк акчаны күтәп ятуны ирлек абруе да «рөхсәт итми», ә үз малае Сәфәргалинең, гәрчә авылда аны зурлап «камисар» дип йөртсәләр дә, хәзергә чирдән арынганы юк. Ә яңа йорт янына яңа каралты-кура торгызырга кирәкме? Кирәк. Әллә уйланмыйммы Корбангали карт бу турыда? Әле ничек кенә уйлана!

Әйе шул, өйдәгеләр сүзенә колак салмыйча, җенләнеп сәфәр чыгарга йөрүенең сәбәбе бар иде. Ә бер җыенгач, аңарга инде сүз кушармын димә. Сәке йөзлегенә утырып, кылса догасын кылыр да, өйдә калганнарга һич үгет-нәсихәт укымыйча, торыр да китәр. Болай кырт кисүдә — аның тәвәккәллеге, акча яратуы, хыяллана белүе һәм шунда ук аның табылмаган тау чаклы мал өчен бугазга килеп тыгылган ачуы да кушылган булыр.

Сәфәргали белән мөгаллимә килен, картның үтә кырт кисеп әйткән сүзләрен дөрес аңлап, аңарга нә яхшысын, нә киңәш бирү рәвешендә бүтән бер сүз дә кушмадылар, ә карчыгы Асылбикә, тыйлыгу белмичә, гел карты тирәсендә чуала, җавап кайтарып алмаса да, сүз куша, үзенчә киңәшләр биргән була иде.

— Ах алла, шыгырдадың майсыз көпчәк кебек! — дип төрпә генә дәшеп куйды Корбангали карт арбага утырыр алдыннан. Ике кулын сузып, карчыгының кипкән, корышкан кулларын үзенә алды, бераз йомшый төшеп өстәде:— Арча җәһәннәм астында түгел, килгән-киткән артыннан хәбәремне сала торырмын.— Иң ахырда яшьрәк вакыттагы җорлыгы да кузгалып куйды булса кирәк, мыек астыннан гына көлемсерәгәндәй итте:— Акча салырмын дип ышандырып әйтә алмыйм, булса, анысын үзем белән апкайтырмын, ә хәбәргә, сәламгә, шәт, сусатмам.

— Мине дә утыртып бар,— дип, оныгы Тәлгать арага керергә маташты, кул астына кысылып, юлчы дилбегәне кулга алып, атны кузгатам дигәндә генә. Бер кешегә дә болай йомшамаганны оныгына карата йомшармыйча булдыра алмады Корбангали. Малайның беркатлы бу үтенечендә, күз сирпеп бабасына карап алуында тел белән аңлатып булмый торган ниндидер кисәтү ишеткән кебек булды. Күңелнең әллә кайчан булачакларны алдан яшеренеп сизенүедәй, үз чиратында, малай да бабасыннан аерылырга теләми, шау-шулы һәм юкка-барга бәйләнүчән шул бабай өйдән китkәч, кинәт өй бөтенләй бушап калыр кебек тоела иде.

— Утыр, басу капкасы төбендә төшеп калырсың,— дип малайны җилтерәтеп арбага тартып алды бабасы. Тавышы коры, кулы каты иде, югыйсә. Шулай да малайга бик рәхәт, күңеле бабасына карата рәхмәт хисе белән тулган иде. Шулай булмыйча соң! Әнә бит бүтәннәрнең берсен дә — әтисен дә, хәтта яулык почмагы белән күзләрен сөрткәләп, бер читтә елап торучы әбисен дә утыртмады, ә Тәлгатьне менә, кул сузып, арбага үзе тартып алды.

— Озак торма, берсекөнгә кайт, бабай, җәме? — дип калды малай, басу капкасы төбендә арбадан төшкәч. Ничектер аның «берсекөнне» тизрәк җиткерәсе килә, шуннан соң барысы да үз урынына утырыр иде кебек, бер уйлаганда, әллә кайда да түгел инде ул, «берсекөн» — ул инде иң якыны, аңардан да якынның булуы мөмкин дә түгел кебек күренә иде. Бабасы, оныгын арбадан төшерүгә, атына дилбегә кагып, чаптырып китеп барды. Хәтта борылып карауны да кирәк тапмады. Аның болай кинәт чаптырып китеп баруыннан бераз аптырап калды малай. Әлбәттә, ул күңеленә дә китермәде: бабайга да җиңел түгел иде аларны ташлап китү. Бер дә җиңел түгел иде, югыйсә. Әнә бит ләгънәт төшкән Арча ягында табылачак акча котырта. Җиңелчә элдереп чабып барган шәпкә вакыт-вакыт картның башында ике төшенчә бергә бутала: «Арча — акча», «Акча — Арча!»

Ләкин малайның «берсекөнгә кайт, җәме»се дә, бабай күңелендәге табылачак акчалар да буш хыял булып чыкты. Китүенә дүртбиш көн уздымы икән, Корбангали картның бүтән беркем кулына да тоттырмый торган сөекле айгырын Арчаның боларга җиде ят бер егете китерә килде. Арбасы да коры, сүзе аннан да корырак булып чыкты егетнең. Өзек-төтек әйткән сүзләреннән аңлашылганы шул булды: кайдадыр Арча тавында искәртмәстән килеп чыккан «Форзон» тракторыннан өркеп, котырып чабып киткән ат, Корбангали картны телеграмм баганасына китереп бәргән. Бабайның үзен аңсыз хәлдә Арча больницасына алып киткәннәр, фатир хуҗасының малае атны бушка туйдырып ятуны авырыксынып, Мәтәскәгә китерә килгән. Хәзергә мәгълүм кадәресе бары тик шул гына иде.

Күп мәшәкатьләр берьюлы аякка килеп уралган юеш көз булды бу. Зәйтүнәнең бала табасы бар, Тәлгатьнең укырга керер вакыты җиткән, Сәфәргали, элегә терелеп үк бетмәгән булуына да карамастан, кулына эш табу турында баш вата: «ярлылар комитеты дип юанып йөрер чаклар узган, вакытлыча килеп чыккан бу «комитет»ның вазифалары әкренләп авыл Советына — Мөхсинов җилкәсенә күчә бара, Мөхсиновның эш күплектән зарланыр исәбе һич сизелми, киресенчә, бурычлары арткан саен җегәрләнә, канатлана барган кебек күренә. Җитмәсә тагы, Сәфәргалинең колагыннан атасы төрттереп әйткән сүзләр дә китми. Әйтте бит Арчага — «акча эшләргә» китү алдыннан. Өйдә калганнарның барысына да яшертен үпкә белән әйтте: «Барыбыз да җылы өйдә җыелып ята башласак...» диде. Шуларның бөтенесен искә алып, барыннан да элек Тәлгатьне күздән ычкындырмау нияте белән, Сәфәргали Мәтәскә башлангыч мәктәбенә, һич югы, хатыны баладан котылып, яшь бала баккан арада булса да,

укытучылык эшенә урнашып булмасмы дип йөри иде. Аның бу тәкъдимен волонода кабул итәргә дә торалар, ләкин бер шарт белән; әлеге дә баягы, җаен хатыны укып чыккан Казаклар авылында бер айлык курс үтәргә тиеш булачак. Дөрес, моны ишетеп Зәйтүнә бер сызланып алмыйча булдырмады.

— Инде бергә тора башлыйбыз дигәндә генә...— диде ул сузып. Сүзен әйтеп бетермәде, ләкин шул әйтеп бетермәве белән үк, әйткәнгә караганда да, күбрәкне аңлатты: аның Сәфәргалине үз яныннан җибәрәсе килми иде.

Әй яңа, ә мәшәкатьләре аннан да яңарак, көтелмәгәнрәк: инде менә Арча юлын таптарга, картның хәлен белә йөрергә кирәк булачак.

Хәер, Корбангали — чуар йөрәк больница ятагында озак аунарга риза булмады, аны алты почмаклы яңа өе, күп вакытта эндәшми кала белүе белән үк җанны тынычландыра торган күндәм Асылбикәсе, акча китерә торган килене, аныңча «бераз кирегәрәк сукалый торган камисар» Сәфәргалие, барыннан да бигрәк, бабай җанлы оныгы Тәлгать өзлексез сагындыра иде. Өенә килеп, чак кына әл-хәл алуы белән үк, докторларга:

— Ник тозлап яткызасыз мине монда? Кайтарыгыз,— дип бәйләнә башлады. Өенә кайткач тизрәк тереләчәк икәнлегенә бөтен дәлилләр белән ышандырырга тырыша, әле генә без санап күрсәткән яңа салынган өе, Асылбикә «тутый кошы», «камисар малае», акча китерә торган тәүфыйклы килене һәм, ниһаять, «бабасының авызына гына карап тора торган» белдекле оныгы белән мактанып ала да ахырдан:

— Безнең Мәтәскәнең чишмәсе үзе ни тора! Суы сезнең бөтен даруларыгызны бәреп ега,— дип, артыграк ычкындырганын хәтта үзе дә сизми кала иде.

Әлбәттә, кызарга әлегә иртәрәк, әлегә сабыр гына дәваланырга кирәк иде аңарга. Әмма кайсыбыз гына белми соң тегүче Корбангалине? Дөньяда ике кыбырсык булса, берсе нәкъ менә шушы тегүче Корбангалидер, мөгаен. Җепне тешләгән җиреннән өзәргә өйрәнгән кеше. Күп сатулашулардан соң, ниһаять, чыгармыйча булдыра алмадылар. Ләкин кабат-кабат кисәттеләр: кызмаска, «ордым-бәрдем» белән кыланмаска, дөнья малына алай акаймаска. Ничаклы гына кисәтмәсеннәр, ләкин тегүче Корбангалинең «өянәкле башын» алыштырып куя алмадылар.

Кайтып керүе белән кесәдән «тапкан акчасын» бушата башларга, әлбәттә, ашыкмады. Бердән, акчаның әле кесәгә керәсе бар иде, икенчедән, акча мәсьәләсендә гомер буена ярлы тәкәббер булган, кесәдә нәрсә бар, нәрсә юклыгын кешегә селкеп йөрмәгән Корбангали башын телеграмм баганасына бәреп миңрәп калганнан соң да шулай кала бирде. Ә менә үзен ике мәртәбә баганага бәргән айгыры мәсьәләсенә килгәндә, ул инде әлекке Корбангали түгел иде.

— Кил әле, Сәфәр, сүзем бар сиңа,— дип, яткан җиреннән бармак изәп малаен чакырып алды ул бер көнне. Өйдә бүтән беркем дә юк иде, ниһаять, малае алдында ир кеше белән ир кеше буларак сөйләшәсе итте:

— Ул алпут аты — ләгыйнь безнең өчен игелекле мал булып чыкмады,— дип башлады үтә дә җитди, хәтта үзен-үзе нәфрәт аша үткәргәндәй итеп,— дөнья хәлен белгән юк, минем белән алай-болай була-нитә калса, васыятем шул: сат син ул игелексезне, аның урынына үзебезнең такыр басуда, болында уртлап үскән адәм рәтле ат ал.

Аталы-уллы икесе дә, кайгыга буй бирмичә, шау-шу белән дөнья гизгән кешеләр кинәт икесе дә уңайсызланып тынып калдылар. Ят һәм сискәндергеч тынлык булды бу.

Язын, җәен ярыйсы гына уңай торган елның көзе җайсызрак килде. Дөрес, атлы-тунлы, аяклы-куллы хуҗалыклар бирешмәделәр. Булганын көзге яңгырлар купканчы җыеп, сугасын сугып, бурага салып куйдылар. Авыл булгач төрлесе — бае, ярлысы бар, кайберәүләрнең ындырларында кояшны каплап торган куш кибәннәр калкып калды — бөтенесен берьюлы сугып, пыран-заран китерергә ашыкмый крестьян, артыгын бәя күтәрелгәчрәк сату өчен дип калдыра иде. Көзнең кырынлыгы бигрәк тә Корбангали тегүче семьясына төште. Нәкъ иген җыяр вакытта карт үзе урын өстендә аунап калды. Йөрәксеп, аякка калкырга омтылган минутлары булмады түгел, ләкин бусаганы атлап чыга алмады, башы әйләнеп, тагы урынына аварга мәҗбүр булды. Кыр, ындыр эшләренең иң кайнаган вакытында — август азакларына хәтле Сәфәргали укытучылар хәзерли торган кыска сроклы курсларда — Казаклар авылында үткәрде. Кеше булмагач, Асылбикә түтине дә, Тәлгатьне дә җиктеләр, әмма иң авыры Зәйтүнә җилкәсенә төште. Кайчандыр Сәфәргали курс үтү, укытучы булырга әзерләнү турында сүз кузгаткач, Зәйтүнәнең сыкранып:

— Тагы аерым-турагай торырга икән, ходаем. Безгә дә язган икән,— дип, ире алдында иркәләнергә маташканы исенә төшкәли. Аерым тору да, әлбәттә, җиңел түгел, ләкин бүтән мәшәкатьләр моның авырлыгын оныттырды. Урагын кеше рәтеннән урдылар, авыру картын ялгыз өйдә бикләп калдырып, анысына Асылбикә карчык та булышты, Тәлгатьне дә урак тотарга өйрәттеләр. Малайлыгына бирелеп, боргалана башласа, көлтә җыярга кушалар, бу да үзенә күрә кул арасына керү иде. Йөкле хатын Зәйтүнә өчен иң газаплысы арбага көлтә төяп, бастырык басу, юктан гына да күзләрен шарландырып, колакларын торгызып, әлдереп алып китәргә торган яман холыклы «алпут калдыгы» белән көлтә ташу булды.

Шуның өстенә, көтелмәгән яктан да китереп суккалыйлар иде. Бер көнне, әле кызу урак өстендә, әнисе белән икәүдән-икәү генә булудан файдаланып (ул көнне Асылбикә түти картын юындыру сылтавы белән өйдә калган иде), Тәлгать — этем иркәсе, бөгелергә дә, көлтә җыярга да иренеп, озак кына кәҗәләнеп торды-торды да искәрмәстән генә:

— Байлар болай азапланып урак урмый торганнардыр, син бит бай бабайларда торгансың элек, беләсеңдер...— дип әйтеп салды.

Малайның бу сүзләрен колак яныннан уздыргандай булды Зәйтүнә. Ләкин чынлыкта уздырып буламы, уздырырга мөмкинме соң андый сүзләрне! Әнә бит белмәгән, күрмәгән, асылда искә төшерергә хакы да юк, хәлбуки, орлыгы төшеп калган, шул орлыктан «чергәнбеткән» дигәнебез кабаттан баш калкытырга маташа. Ниләр генә булып бетмәде бу дөнья белән. Әле киләчәктә нинди хикмәтләр булмас!

Хәлбуки, бик киләчәккә дә калмады кайбер эшләр. Кайнаган чиллә көннәрен өйдән чыга алмыйча, барысын да йөрәгеннән кичереп яткан тынгысыз Корбангали, өстәвенә, юньләп врач ярдәме дә күрмәгән урын хастасы, төннәрдән бер төнне дөнья бетереп саташып уянды, бөтенесен аякка бастырды. Өйгә ашыгып ут алдылар. Күреп, барысы да эчтән генә тетрәнеп куйды: карт озын ак күлмәктән урынга торып баскан, тегү машинасы әйләндергән кебек кул хәрәкәтләре ясый, күзләре иләсләнгән, янындагыларның берсен дә күрми. Хәер, ул аларга карамый да иде кебек. Каядыр читкә, өйнең почмагына караган килеш, кузгалып, чыгып китәргә кабалангандай итенә, кузгалырга ирек бирмәгәч, бар көченә акырып өйдәгеләрне каһәрле, бер үк вакытта ялвару белән аларны каядыр чакыра да иде:

— Барыйк... Ник терәлеп каттыгыз бер урында? Безне анда чакырып торалар, безнең өчен анда җәннәт корып куйганнар: ат дисеңме, тарантас дисеңме, тимер хут арбамы кирәк... ә без, сукыр тычканнар кебек, гел шушы җир асты тишегендә сөрсеп ятабыз. Хурлык, адәм көлкесе, егыл да үл сезнең белән... сез сукыр тычканнар белән.

Әле ярый, ял көненә каршы булганлыктан, Сәфәргали кайткан кич иде. Ул да өйдә булмаса, хатын-кыз халкы бөтенләй каушап каласы икән. Сәфәргали әтисен ничек тә булса тынычландырырга, яткырырга маташканда, Асылбикә түти матчага кыстырган иске догалыкны алып килеп, үзе, аңарга күз дә төшермичә, белгән-хәтерендә сакланган догаларын укырга, картын өшкерергә керешә. Ә Зәйтүнә, кайнатасының кинәт болай катышланып китүеннән бер үк вакытта аптыраган һәм куркынган Зәйтүнә — үзенең совет укытучысы икәнлеген истән үк чыгарып — кем дә кушмастан, мулла алып килергә дип чапкан иде.

Ләкин Асылбикә түтинең ихлас күңелдән өшкерү-төкеренүләре дә, мулланың тыңкыш тавыш белән «изгам-мәгәлгөлләләп» корьән укуы да файда итмәде, башта йоклап киткәндәй генә күренгән Корбангали карт, барысы да беркадәр тынычланып, таң йокысына чумган бер мизгелдә, кемне дә борчымыйча, хәтта үзе дә тамчы да борчылмагандай, тавышсыз-тынсыз гына дөнья куйган иде.

— Авызына су да сала алмый калганмын, кирәк бит, ходаем,— дип өзгәләнде иртәгесен Асылбикә карчык,— әйтәсе сүзләре булгандыр бичарамның.

— Сабыр итик, әни. Әйтәсе сүзне кем генә әйтеп бетергән бу дөньяда,— дип, әнисен ничек тә тынычландырырга тырышты Сәфәргали. Ә үзен мена берничек тә тынычландыра алмый иде. Дөньяда гел баю нияте белән яшәгән, шул ният белән җәяүләп авыллар гизгән, ярлысының да, баеның да түрендә утырган, берсеннән дә җирәнмәгән, тегенең җырын да җырлаган, кызыклы җыр икән — моныкыннан да качмаган, чын асылда кешеләрнең бөтенесен тигез ярата белгән бу тынгысыз җан шулай тын, шулай тиз үлеп китәр дип кем уйласын. Мәрхүмнең авызы ачылып калган, иртәнчәк өйдәгеләр аякка калыкканчы шул ачык килеш катып кала язган иде. Көчкә-көчкә генә иягсн җыеп, яулык белән бәйләп куйдылар.

— Юк, Сәфәргали, яшьлегеңә барма, тикмәгә ачылмаган аның авызы,— дип, әледән-әле өзгәләнеп искә төшерә торды Асылбикә түти,— безгә әйтәсе сүзе булган бичаракаемның. Безнең кайсыбызгадыр үпкәсе дә булгандыр, ихтимал.

— Үпкәсе булган булса, миңадыр,— дип, бөтенесен үз өстенә алды Сәфәргали,— җүнле тегүче, эти көткән малай, йорт итәрдәй мужик була алмадым. Ярты гомер читтә-чатта йөреп уздым.

Нәрсә генә булмасын, «теге дөньяга» ашыккан чуар йөрәк тегүчене бу дөньяда артык бер көн дә тотмадылар. Татар гадәте буенча, шул көнне үк кабере казылды, шул көнне үк җирләделәр дә.

Кайткач, моңлы һәм күңелсез өйгә әйләнеп кайткач, бөтен ачыклыгы белән сизде Сәфәргали: юк, дөньяның артык кешесе булмаган икән тегүче Корбангали. Бетмәс-төкәнмәс хыялы, килешле-килешсез омтылышлары, гөнаһсыз ялганнары, җор табигате, акчага туймаган кесәсе белән дөньяны үзенчә нурлап, бизәп торган икән — менә хәзер тап инде андый әтине, андый кешене!

Табигать бушлыкны яратмый. Корбангали абзыйны җирләгән шул көздә, мәрхүм дөнья куйганнан соң ай да узмагандыр, Зәйтүнә ир бала тапты. Өйнең ятимлеген шатлык алыштырды, моның өчен барысы да куаныштылар, арада аеруча нык куанганы Асылбикә карчык булды. Күптән, бик күптән яшь бала тавышы ишеткәне булмагангамы, олан чак кына тавыш биреп куйса да, әбисе шундук очынып

килеп җитә, «Асты юешләнмәдеме икән, килен?», «Кая, үзем тотып торыйм, яңадан биләп сал» кебек сүзләр, киңәшләр белән килене тирәсендә өтәләнеп йөри, килене бала имезергә утырса, сиздермәскә тырышып кына аның күкрәкләренә күз төшереп үтә, аннары болай карангалап йөрүне яхшысынмыйчамы, күз тидермәгәем дип шикләнепме, кече якка кереп китә, шуннан торып кына «Берьюлы күп имезмә, эче китмәсен», «Төребрәк утыр, өебез салкынчарак бүген» кебек сүзләр белән әледән-әле кисәткәләп куя иде. Бала чүпрәкләрен юу, бигрәк тә баланы коендырышу аның өчен әйтеп бетергесез бер куанычка әйләнде. Үзе куану белән генә калмыйча, вакыт-вакыт Сәфәргалине дә битәрләп ташлый — янәсе, бала тәмен белмисең, кулыңа алганыңны да күргәнем юк... Сәфәргалигә әнисенең болай шашынуын күрү, бер яктаң, кызык тоелса, икенче яктан, ул аны кызганып та куя: күрәсең, картына биреп бетермәгән назы инде менә балага күчә барадыр, иртәрәк китте шул карты, менә бу яңа шатлыкны уртаклаша алмады.

Сабый энесенә мөнәсәбәттә тик Тәлгать кенә әлегә икеле-микелерәк йөри иде. Тулаем алганда, бу вакыйга, әлбәттә, аның өчен дә куаныч китерде. Һәм бер үк вакытта аны малайларга хас булмаганча уйландырып та калдырды. Кызык икән бу дөнья: бабай үлде, аның урынына менә бәби туды. Шулай да кайчандыр үзенең дә үлеп китү ихтималын күз алдына китерү аның котын ала, ул турыда ничек тә икенче уйламаска тырыша иде.

Тәлгатьнең башы җитмәслек кызык бер ягы бар икән бала туунын. Монысын аңа әбисе әйтте:

— Менә син хәзер абый кеше булдың инде, улым,— диде кытырşы кулы белән малайның башын сыйпап,— ул бәләкәч үсеп зур булгач сине «Абый!», «Тәлгать абый!» дип йөрер, җәме. Ни атлы куйыйк икән аны, улым? Исеме дә юк бит әле сабыйның, судан апкайттык кына.

Аннары аларга туган-тумачалары, күрше-күлән бәби ашы китерергә тотынды: бәлештер, кош теледер, майлы кабартмадыр, баллап катырган төштер — җыен тәмле әйбер, кыскасы, Тәлгать өчен бу чаклысы аеруча ярыйсы булып чыкты: бәби үзе, әлбәттә, ашамый, олылар да чеметеп-чеметеп кенә капкалыйлар да тагы төрләшүгә — сабыйга бәхет-тәүфыйк, озын гомер, әти-әнисенә саулык-сәламәтлек, йортка бәрәкәт теләргә тотыналар. Алар шулай гөрләшеп чәй эчкән арада Тәлгать малай, самавар артыннан гына килеп, сораса — сорап, сорамаса — әнине бөтенләй күрмәмешкә үк салышып, тәмле-томлы кисәкләрне тарттыргалый бирә иде. Яшь бала туунын бу ягы да ярыйсы гына була икән!

Әмма, дөресен әйтергә кирәк, тора-бара ярыйсы түгел яклары да чыккалый икән. Күреп, барысын да сендереп йөрде малай. Атналар, айлар үткәч, бәби ашы китерүләр инде беткәч, бөтен ашаганнары гадәттәге каты-котыга, катыклы умачка калгач, яшь бәби дигәннәре дә инде яхшы ук тере тавыш белән чырылдый башлагач, эшләр икенче ягы беләнрәк әйләнде. Һәрхәлдә, Тәлгатькә шулайрак тоела: олылар — әни дә, әти дә, әби дә — сизелер-сизелмәс кенә Тәлгатьтән суына баралар, яшь бәби әкренләп үзәккәрәк күчә бара кебек иде. Шулай итеп, кече-кечедән кирәкне-кирәкмәсне гел уйланып өйрәнгән малай күңелендә көнчелеккә охшаш кыргый инстинктның барлыкка килә башлаганлыгы үзен сиздерә иде.

Һәм бер көнне ул тышка ук бәреп чыкты. Асылбикә түти күрше авылдагы кыз туганына кунакка киткән, Зәйтүнә иренең — әлегә яшь укытучы исәпләнә торган Сәфәренең — дәресне ничек алып баруын күзәтү, кирәк булса — киңәшләр бирү өчен дип, бишек янында Тәлгатьне калдырып, мәктәпкә киткән иде. Имезеп салган бала башта

тавыш-тын чыгармады, йоклады. Әлбәттә, Тәлгатькә дә эш булмады ул йоклаганда. Бераздан бала уянды, елый башлады. Тирбәтеп карадә Тәлгать, имезлек каптырып бакты — ә баланың елавы елау. Тәмам аптырагач, чыгып качарга да уйлаган иде, әбисенең кисәтүе исенә төште — янәсе, яшь баланы ялгыз өйдә үзен генә калдырып китсән, жен-нәр алыштыруы мөмкин, имеш. Тәлгать, елак бала янында бер үзе утырып ничаклы гына ялыкмасын, шулай да энекәшен женнәргә биреп, үзе жен баласы тотып калырга һич кенә риза түгел иде. Юк, юк, малайларның үзен үртәүләре дә бик житкән, инде килеп жен баласын да энекәше итсенме? Димәк, баланы ташлап, чыгып киту турында хәтта уйларга да мөмкин түгел. Ә ул елакны туктату шулай ук әлегә мөмкин эш кебек күренми иде. Шулай да бер әмәле калган икән. Әнисе кайтып кергәндә алар — энесе дә, абыйсы үзе дә — парлашып елашалар иде. Тәлгатьнең бугаз төбенә килеп тыгылган ачуы берьюлы ташып чыкты:

— Калдырмагыз миңа бу жылагыгызны. Мин аның абыйсы түгел, абыйсы буласым килми,— дип, әнисенә ташланды ул. Баланы кулына алып тынычландырганнан соң гына, анда да Тәлгатьнең сүзен уенга борырга тырышып, бәләкәе белән сөйләшкән атлы булып сөйләнергә тотынды Зәйтүнә:

— Әнә абыең нәрсә, ди, нәнәм. «Мин аның абыйсы түгел», ди. Алайса, кем булыр икән соң безнең абыебыз?

Тәлгать әлегә өйдән чыгып китмәгән, ул өстенә киенгән килеш ишек төбендә таптанып тора, теленә бик тә хәтәр сүзләр килә: «Беркем дә булмас. Мин менә сезгә әйтмичә генә бабайларга китәрмен дә барырмын». Ләкин ул моны әйтми, күңелендә тыеп калдыра. Аны әйтәсе урында, бишмәтен-бүреген кигән килеш, кырын-кырын гына әнисенә табарак елыша иде. Зәйтүнә Тәлгатьнең бөтен хәрәкәтләрен кызыксынып күзәтә, аңарга хәтта малайның тел төбендә әйтелмичә калган сүзләренә хәтле килеп житте кебек, ләкин үзе башлап сүз дәшәргә ашыкмый. Әйтәсен әйтсен иде малай, шушы аулакта, бүтән беркем дә юк чагында, ай-һай ла, әйтәсен әйтеп бетерсен иде. Ләкин малай артык бер сүз дә эндәшми. Килеп баскан. Әле чапылдатып ими суыра торган бәләкәй энекәшенә, әле аңардан тилмереп нидер көтүче әнисенә карангалап ала һәм кинәт истә-осга юк сорау:

— Мин дә шулай имә идемме, әни... бәләкәй чагымда?

Күреп тора Зәйтүнә — газаплы тормыш күргән күзләре белән, азмы-күпме тупланырга өлгергән педагоглык тәжрибәсе аша күреп тора; юк, бу сорау түгел иде малайның күзләрендә, бу түгел иде. Күңелендәгесен әйтмәгән килеш эченә йотты. Күрәсең, ансат түгел малайга. Ә Зәйтүнәнең үзенә ансатмы? Кемгә генә ансат икән соң бу мәшәкатьле дөньяда? Белмим, телләрен оныткан идиотларга һәм жир астына китеп өлгергән исәпсез-сансыз Корбангали абзыйларга ансат булса инде!

## 13

«Тәлгать» дигән исемгә беркадәр яңгырашлы булганлыктан, анныры тагы яңачаракка да санап, сабыйга әтисе белән әнисе Марат исеме куштырдылар. Беренче карашка әллә ни әһәмияте булмаган бу факт бабай дөнья куйганнан соң әле дә булса тиешле тигезлеген тапмаган гаиләдә яңа-өстәмә наразыйлыклар китереп тудырды. Асылбикә түтинең, дөрес, «Марат»ка да каршылыгы юк, ләкин аның колагына «Морад» якынрак ишетелә һәм ул үз вакытында «Морад куйдырыйк» дип кыстап та караган иде. Яшьләр үзләренекен иттеләр һәм, үз дигәннәрен өстенгә чыгарырга тырышып, карчык һич аңламый торган әллә ни хәтле дәлилләр китерделәр. Марат — француз

революционерының исеме, бердән. Марат — авылда юк яңа исем — икенчедән. Картын җырлагәннән соң болай да канаты сыныбрак йөргән Асылбикә түтигә яшьләрнең ул әйткән сүзгә колак салмавы хәтер калдыргыч үзсүзлелек булып тоелды. «Карт исән булып, бергәләп тотынсак, ничек тә Морад иткән булыр иек, ялгыз калган карт каз каңгылдый да тына шул!» дип, кимсенеп уйланып йөрде ул. Һәм үз дигәнен дөреслеккә чыгарырга тырышып, сабый белән ялгыз гына калган чакларда, әти-әнисе өйдә булганда бигрәк тә ишеттерерлек итеп «Морад» дип эндәшә, «Зур үсә безнең Морад улыбыз, тиздән менә Тәлгать абыйсы хәтле булыр» дип иркәли-сөя иде. Үз нәүбәтендә Тәлгатькә әбисенең шул елакны болай назлавы ошамый. Шулай да әбисенең сабыйны «Марат» дип түгел, Морад дип атавын ошата — янәсе, бик очынмасыннар әле әти белән әни үзләренең «француз әллә кемнәре» белән!

Бер үк вакытта энекәш тууның малайга файдасы да тиде: мәктәптә быел әнисе укытмый, әтисе укыта. Ә Сәфәргали Тәлгатькә карата һәр вакыт кирәгеннән артык миһербанлы, малайның чатлы-ботлы якларын күрсә дә, күрмәмешкә салышып уздыра иде. Ә төрлесен уйлап, эчтән киреләнә, үҗәтләнә барган малайга шул гына кирәк тә. Ул көннән-көн чыгырыннан чыга, сабакташ малайлары белән урынлы-урынсыз сугышучы кем дисәң — Тәлгать. Алгы партада утырган кызларның әле чәчүргеченнән тартучы да, әле кәгазь карга төкереклэп очыртучы да, тәнәфестән соңга калып керүче дә ул. Тагы шул чаклысы да бар: Зәйтүнә Тәлгатенең киртәгә кермәстәй бу «егетлекләре» турында күп вакытта соңыннан кешедән ишетеп кенә белә, хәзергесе көндә малайның турыдан-туры мөгаллиме булып калган ире Сәфәргали малай өстеннән әләкләүне яратмый, күп хәлне эндәшми үткәрә иде.

Көннәрнең берендә, иренең кәефле, кайнанасының өйдә юк чагын туры китереп, сүз башлады Зәйтүнә — чак кына үпкәләү һәм күбрәк кисәтү тоны белән башлады.

— Син ул Тәлгатеңне үтәли сикертеп өйрәтмә, Сәфәр. Син эндәшмәгәч тә, әллә мин ишетмимме? Бу арада Гаптеләхәтенең сугып борынын канаткан — иң якын дусы санап йөргән иптәш малаеның.

— Беренче мәртәбә ишетүем,— дигән булды Сәфәр, башын белмәмешкә салырга тырышып. Һәм бермәл тынлыктан соң, бу юлы инде җитди тонга күчеп өстәде: — Сабагын яхшы белә, сүз тидерә алмыйм малайга. Ә инде... Кайбер вакытта кулы кычыта икән, малайлыгына бара торгандыр, без барыбыз да сугыша-сугыша үстек. Ярады тагын бу сугыш чукмары булып үсү... Кирәк урында... башкалардан калышмадык.

Әлеге сөйләшү дә нәтиҗә бирмәгәч, көннәрнең берендә Зәйтүнә, һич искәрмәстән, сабак вакытында мәктәпкә төшеп, сәгатьләр буена утырып калды. Дөрес, ул элек тә төшеп утыргалый, иренең — яшь мөгаллимнең дәресне ничек алып баруын күзәтә, кирәк тапса, соңыннан «алай түгел, менә болай кирәк!» рәвешендә иренә киңәшләр бирүдән дә тартынмый иде. Ә бу юлгысы озаккарак сузылды, тәнәфескә хәтлэ утырды. Авыз ачып сүз кузгатмады, классны тулаем күзәткән булды, ләкин тәгаен генә күзәткәне үзенең Тәлгате иде. Әмма малай кеше Тәлгать моны үз тилелегенчә аңлады: әти дә, әни дә үз янымда, өй ни, сабак ни, әләкләп карасыннар аның өстеннән. Гадәтләнгән тиктормас кул үзенекен итә — ары сузыла, бире тартыла, кәгазь каргалар да очкалый. Хәер, нишләсен, чыгарасы хисап мәсьәләсен бөтенесеннән элек чишкән...

Кырын күзен генә салып чамалап алды Зәйтүнә: класста икәнлеген оныткан шикелле малай. Менә ул дәфтәр битенең почмагын сиздермәскә тырышып кына ертып алды, тиз-тиз генә нәрсәдер язды; язылган кәгазьне дүрткә-бишкә бөкләде һәм алгы партадагы малайлар иң-

башы аркылы җелт кенә сузылып, тагын да алдарак утыручы кызның култыгына кыстырды. Төшеп югалмасын өчен, Тәлгать аны, әлбәттә, төкереге белән чылаткан иде, җибәрелгән «сәлам хат» нәкъ урынына ябышты. Ләкин хисап чыгару белән башы каткан кыз аны-моны абайлап өлгергәнче, парта алдына Зәйтүнә килеп басты, малаеның «сәлам хатын» ул «кабул итеп» өлгерде. Укучы балалар, алар белән бергә үк яшь «мөгаллим абый» Сәфәр дә, Зәйтүнәнең карчыгадай болай очып кунуына гаҗәпләнештеләр, ләкин алай-болай сүз кузгатучы булмады — апалары элеккеге укытучы, ни эшләгәнен үзе, шәт, белә торгандыр. Хәер, «кәгазь кисәгендә» сүз кузгатырлык әллә ни язылмаган. «Черек ми, мышкылдап утырасыңмы? Утыр дидем минем янга!» дигән сүзләр, тыныш галәмәтләре куелмыйча гына, рәттән тезелеп киткән иде.

Балалар тәнәфескә чыкканнан соң Зәйтүнә белән Сәфәр бергәләп укып, үзара елмаешып куйдылар.

— Ничева, кар өстенә таяк очы белән язылган хат түгел, онытмаган булсаң хәтерли торгансыңдыр, без синең белән карга таяк очы белән язып та бер-беребезне аңлыйдыр идек, — диеп, уенга борырга маташты Сәфәргали. Аннары, уенын-чынын бергә кушып, болай дип тә өстәде:— Минем дәресне ничек алып баруымны тикшерергә волоно җибәргән инспектор түгелдерсең ич? Бик озак, бик төпченеп утыруыңнан әйтәм.

— Бәлки үзем өйрәнеп утыра торганмындыр, — шулай да сүзне уенга әйләндерәсе килми иде Зәйтүнәнең,— тикшереп утырып, төзәтмәләр ясасам да хакым юк түгел. Ничек кенә димә, мин синнән элгәрәк укыта башлаган кеше.

Ләкин килешмәгән якларны «килештерергә» шулай да өлгерми калдылар. Звонок булды. Балалар керә башладылар. Барысы да үз урынына кайтты, тик шулай да бер урын әлегә буш иде. Утырганнар да сүз дәшмәде, шулай ук басып калган ирле-хатынлы «мөгаллимнәр» дә дәресне башлап җибәрергә ашыкмыйлар иде. Бу мәгънәсез бушлыкны ни беләндер тутырырга тырышкан Сәфәргали, кесә сәгатен чыгарып, аны бер ачып, бер ябып, вакытны күзәткән атлы булып торды. Хәлбуки, авыр минутлар булды бу. Звоноктан соң класска кермичә көттерүче бердәнбер буш урын Тәлгатьне көтә иде.

Биш минутка якын соңга калып, әлсерәп-чабып, ниһаять, Тәлгать атылып керде. Өсте-башы шау кар, үзе кызарган-бүртенгән, изүе чишелгән, сорамыйча гына этисенекен чәлдереп таккан кокардалы иске солдат каешы бляхалы ягы белән янга авышкан иде. Рәтләп тамаша кылырга да өлгермәделәр, хәтта укытучысы да авыз ача алмыйча калды, Зәйтүнә җилтерәтеп Тәлгатьне үзенә табарак тартып китерде, шап та шоп суккалады (әллә өстендәге карын коярга дип суккалавы, әллә чынлап торып шапылдатуы?), билендәге каешын борып алды һәм, бөтенесен гаҗәпкә калдырып, «мөгаллим абый»сының каршына китереп бастырды. Зәйтүнәгә каршы килергә яки нинди дә булса сорау бирергә мөмкин түгел иде бу минутта.

— Бу тәртипсез укучыңны шушы минутта ук класстан сөреп чыгар! — Зәйтүнә артык кызган иде бу минутта, «Ник?» дип сорарга урын калдырмады, «ник»кә җавапны үзе тезде:— Үзен мәктәп баласы итеп тота белмәгәнлеге өчен! Этисеннән сорамыйча, Николай патша солдатыннан калган каеш тагып сәвит мәктәбенә килгәне өчен. И аннары... Үзең беләсең ич аннарысын... — Зәйтүнәнең тавышы түбәнәйде, елап җибәрүдән үзен көчкә-көчкә генә тыеп торганлыгы әллә кайдан, хәтта балаларга да сизелә иде,— ...минем малаем булганы өчен.

Хәер, әнисе бу «өчен»нәрне тезгәнче малай чыгып сызган иде инде. Сөйләшеп торырга вакыт та юк, урыны да түгел, Зәйтүнә шун-

дук ишеккә борылды. Сәфәргали, бер нәрсә дә булмагандай, дәресне башлап җибәрде. Дөресен генә әйткәндә, укучылар бу тамашадан туеп җитмичәрәк калдылар, аптырап калдылар: әллә көләргә, әллә еларга Тәлгатьне жәлләп? Үз энисеннән бит... әнә ничек эләкте. Әле өйгә кайткач нишләтерләр?

Ләкин сабакташларының алдан юрап куюлары акланмады. Өйдә Тәлгатькә берни дә эләкмәде. Малай, кич җитеп карангы капканчы, өйгә кайтып күренмәде. Ул югында Зәйтүнә белән Сәфәргали, бергә сөйләшеп, тактик планны әзерләп куйганнар иде инде. Көндез булган сүз кич яңартылмады. Шул ук вакытта эзләргә дә чыкмадылар, кайткач, әбидән башка кызыксынучы да булмады.

— Кайда йөрдең болай бирчәеп катканчы? Ашарга да кайтмадың көнозын, — дип сөйләнә-сөйләнә, тик әбисе бөтерелде малай тирәсендә. Ә малай бик көткән иде. Һич югы энисенең «Иртәгә дигән дәресеңне хәзерләдеңме, Тәлгать?» дип, гадәттәгечә, ярым йомшак тавыш белән сорау бирүен көткән иде. «Юк, хәзерләмәдем. Хәзерләмим дә», дип җавап кайтармакчы иде. Башка көннәрдә гел искә төшерелеп торган ул сорау да куелмады. Шулай ук, башка көннәрдәге кебек, ашарга утыру алдыннан «Кулыңны юдыңмы?» дип сорау бирә калсалар, «Юк, юмадым. Ашарга да утырмыйм», дип киреләнеп җавап бирмәкче иде. Ул сорауны да бирмәделәр. Ә көнозын урамда, салкында йөреп, малайның ашыйсы килгән, түбән авыл көчекләре нык кына өрә иде. Нишләсен, әйтмәсәләр дә кулны юарга туры килде шул, ачудан булса да юарга туры килде.

## 14

Шул көннән соң малайда сизелерлек үзгәреш башланды. Укырга барасы көнне һич кыстатмыйча үзе сикереп тора, беркем искә төшермичә битен-кулын юа, табынга җәлт килеп утыра, ни куйган булсалар — шуны ашый, куелмаганны сорап йөдәтми, мәктәбендә дә хәттан ашып сикерми, сабагыннан элеккечә үк, хәтта элеккегә караганда да, өлгеррәк бара, кыскасы, анадан яңа тудымыни! Шул ук вакытта Зәйтүнә дә, Сәфәр дә күреп торалар: малайда аларга карата салкынаю сизелә иде. Күзгә бәрелеп тормый бу, ләкин Тәлгатьнең үзен тотышында, эндәшүләрендә, эндәшкән вакытларда тавышының малайларча чынлап тормавында, түбәнгә карап кына сүз кушуында — бөтенесендә, бөтенесендә сизелә: сабак алды бугай малай теге көнге шелтәдән. Ләкин ачык кына аңлау кыен: яхшы яккамы бу сабак, кирәгәме?

Ә малайның җанында уяныш ике якка да берьюлы туды. Бердән, шуны төшенде: ашамыйча, өскә искеме-яңамы бишмәт кимичә яшәп булмый икән бу дөньяда. Ә моның өчен олылардан кемнең дә булса берәр якының булу кирәк. Ә хәзергесе көндә аның якыннары — энисе дә, әлеге шул малай берничек тә үзенеке итә алмый торган, Тәлгатькә карата яхшылык эшләгән саен үз түгеллеген яшерер өчен генә эшли сыман күренүче этисе... Сәфәргали. Каты булсалар да шулар, йомшак булсалар да. Ә каты булсалар хәтта рәхәтрәк тә икән! Сизеп тора малай күңеле: ул чагында юмалау, юхалану кебек чит тойгыларга урын калмый.

Бер үк вакытта кирелеге дә сизелерлек баш калкытты. Әүвәл сорау рәвешендә: «Ник? Әллә минем болардан башка якын кешеләрем юкмы? Закама яклары?» Йөри-йөри, уйлана-уйлана торгач, ул сорау малайны кызыктырып, ерактан чакырып торучы йолдызга әверелде. «Китәрмен дә барырмын шул бабайларга. Эзләп йөрсеннәр болары елый-елый».

Күңелдә иң якын булып калганы хәзергә бу әби — Асылбикә әби иде. «Бу әби» белән Тәлгать малай арасында берничек тә боргаланмаган туп-туры юл бар. Тәлгать уеннан ачыгып кайтса, «бу әби» берни сорашып тормыйча, ипи белән сөт чыгарып бирә. Аннары тагы «бу әби» әнә ул бишектә астына җибәреп ятучы «француз әллә кемен» Марат дип түгел, Морад дип йөри — бу да ошый малайга. Тагын да кызыграгы шунда: ул әле «теге дөнья» турында да әллә нинди әкәмәтләр белә. Әйтә кайвакытта Тәлгатькә: «Үлдең дә беттең түгел, Тәлгать улым, әле теге дөньяда терелəчəгебез бар. Анда без бабаң белән очрашачакбыз, алла боерган булса. Ул безне, бәлəкәйдән этисеннән мәхрүм калган ятим бала итеп иң әүвәл сине, аннары гомер-бакый авызына гына карап торган хәләл-җәфете итеп мине кулыбыздан җитәкләп җәннәткә алып керәчәк, алла насыйп итсә».

— Нәрсә ул «җәннәт», әби?

— Нәрсә дип... кем белгән инде аның төгәлен генә. Бакча булса кирәк. Дөньяда безнеңише кара авызларга ирешмәгән төрле-төрле җимешләр дисеңме анда, кәүсәр чишмәләреме...

— Сабан туйлары буламы анда? Ат чабышлары?

— Көфер сөйлисең, бәбкәм. Кайдан килсен ди анда ат чабышлары? Гел изгеләр арасында.

Менә бу хәтлесе ошамый инде Тәлгатькә. Ул хәзергә ат чабышыннан да кызыклырак нәрсәнең дөньяда булганын күз алдына да китерә алмый иде. Ул да түгел, бишектә хәбәрсез йоклап яткан «француз Мараты», уянып, чырылдап елый башлады. Бүтән вакытта бишек тирбәтүне әллә ни өнәп җиткерми торган Тәлгать, әбисе кушмыйча ук, бишек янына утырып, зырылдатып тирбәтә башлады. Елакны тизрәк тынычландырасы, әбисе белән башланган кызыклы әңгәмәне дәвам иттерәсе килә иде аның.

Имезлек тә каптырып карадылар, озак кына тирбәтте дә Тәлгать, кыскасы, «кәүсәр чишмәләре»нә аппетиты тәмам шиңде малайның. Киресенчә, инде ул әбине дә яратмый башлаган, карчыкның ышаныл-бирелеп сөйләгәннәренә үч итеп нинди дә булса этлек эшлисе килә иде.

Күптән уйлап йөргәне дә, шушы минутта гына күңеленә килгәне дә кинәт бергә кушылып, тетрәткеч бер сорауга әверелде:

— Алай күп белгәч әйт: ник үлде безнең бабай?

Асылбикә түти малайдан кинәт ишетелгәли торган хәтәр-әкәмәт сорауларны колагына алгаласа да, бу хәтлесен үк һич көтмәгән иде. Аптыраудан да бигрәк хәтере калды Тәлгатькә. Шулай да кем белән сөйләшкәнен онытмады, очып-барып кунмады.

— Әрвахларны хөкем итү безнең эш түгел, улым,— диде ул, күңелендәге тетрәнүен ничек тә тавышына чыгармаска тырышып, — без барыбыз да ходай коллары, кайчан кирәк таба, шунда ала.

Болай гына аңлату малайны, әлбәттә, канәгатьләндермәде һәм ул моны чынлап торып аңлап та җитмәгән иде. Башлаган-башлаган, өйдә гел тәртип турында гына тукып торучы әти белән әни юк чакта, күңеленә җыелганның бөтенесен селкеп салырга булды:

— Ә мин бабайның ник үлгәнен беләм, — дип, үҗәтләнеп сүзен дәвам итте малай, чукрак кеше белән сөйләшкәндәгечә кычкырып,— мине яратканга күрә үлде бабай. Белмәсәгез, белегез: ул мине сезнең барыгызга караганда да күбрәк ярата иде.

Әби оныгына якынрак килмичә, чепи күзләрен ачыбрак карамыйча булдыра алмады.

— Тукта, кем өйрәтте сине мондый көфер сүзләр сөйләп торырга?

— Берәү дә өйрәтмәде, үзем беләм! — дип җан ачыгысы белән кычкырып җибәрде малай. Бу минутта ул малай түгел, бу минутта ул олы кеше дә түгел, бу минутта ул күзләрен чекерәйткән тере зәһәр-

лек иде.— Мин Махно калдыгы. Малайлар мине шулай дип үртиләр. Әти белән әни минешуңа күрә яратмый. Син дә шуңа күрә яратмыйсың. Ә бабай мена ярата иде. Ярата иде.

Соңгы сүзләрен ул елый-елый әйтте һәм, кинәт җиңеләеп калгандай, ишектән атылып чыгып китте.

Иске авыздан яңа сүзне ишеттекме менә? Әби үз колакларына үзе ышанмыйча катып калды. Яшьләргә дә үпкәсе чыкты. Ирле-хатынлы мөгаллим дә мөгаллимә аталып йөргән булалар, ә бот буе малайлары әнә нинди тузга язмаган сүзләр сөйли. Үзе сабак баласы, җитмәсә. «Сабакларын әйтер ием, үзләренә ходай бирмәгән акылны балаларга тагып азаплангач соң...» дип, күңеленнән рәнҗеп, уйланып куйды Асылбикә карчык. Шулай да оныгының мондый хәтәр сүзләрен киленне Зәйтүнәгә дә, Сәфәргалигә дә җиткермичәрәк торуны хәерле санады. Бу арада аларның малайга карата төксерәк йөрүләрен күреп тора, күңеленә болай да кирәк-кирәкмәс коткы кергән ятим баланы җәберләтәсе килми иде.

Бүген күңелдә кузгалган шомны үзендә яшереп калган булса, иртәгесен янә шомга урын чыгып куймасынмы! Сабакка дип әтисе белән әнисенә ияреп чыгып киткән Тәлгать, кайдан һәм ничек тайгандыр, сумкасын күтәреп искәрмәстән генә өйгә кайтып керде.

— Әйдә, әби, бабай янына зиратка барыйкмы? — дип, ишектән керә-керешкә үк ярып салды. Бу — әйтеп карау, тәкъдим яки үтенеч түгел, бу — боерык кебек яңгырады. Тагын шомлана калды Асылбикә түти, «Йоклаганда да саташып йоклады, бирәр нәрсә булдымы әллә безнең бу утыз тугызга?» дип уйлап куйды ул. Ләкин каты бәрелергә базмады.

— Син соң ни... сабакта түгелмени?

— Бабай каберенә барасым килә дигәч җибәрделәр. «Әбиең белән икәү барсагыз гына», диделәр. Барыйк инде, әби.

Үтә дә чекерәйгән күзләреннән күренеп тора: бу минутта малайда алдашу һәм изгелек хисе бергә буталган иде.

— Барсак та... миңа керергә ярамый бит зират эченә.

— Ник ярамый?

— Шулай. Йоласы кушмый мөселманның.

— Кушмаса, син коймa буенда калырсың, ә мин керермен. Минем бабай каберен күрәсем килә.

Болай да хорафатларга ышанучан карчыкны бусы инде бөтенләй телсез калдырды. Ышанудан түгел, дөресрәге, куркудан, ул чистарак өс-башларын алыштырырга тотынды.

— Әйт булмаса, укыйсы догам бар диген, шайтан баласы.

— Ашагач әпәр итә торган дога да ярыймы?

«Әпәр»дән башка тагы нинди дә булса дога белү ягыннан малайның эше әллә ни мактанырлык түгел иде. Бу белмәгәнлеге өчен хәтта бераз җәне дә кузгалып, бер үк вакытта әбисен үчекләргә дә теләп, колакка сак әбисенә үтә кычкырып әйтте ул:

— Мәктәптә анда «Туган тел» китабыннан шигырь ятла да, хисабыңны дөрес чыгар.

Шулай да ул бабасы кабере янына барып тезләнгәч кинәт телсез калды. Яшел үлән арасында калкып торган кызыл балчык өеме алдында шигырь сөйләп утырып булмый ич! Бер сүзсез шакаеп утыру да күңелне өркетә иде. Аптырагач, кинәт сикереп торды, тизрәк чыгу юлына борылды.

Кыскасы, бабай янына бару малай көткәнчә килеп чыкмады. Ә ул әтисе белән әнисе өстеннән бабайга әләкләргә дип барган иде. Аның каравы, мәктәптән качып, ашауны-эчүне онытып, көнозын эт куып йөргәнлеге өчен, кичен малайның үзенә җавап бирергә туры килде.

Хәер, төрләсен уйлап, төрлесен ишетеп күңеле каткан Тәлгать әллә ни калтырап төшмәде.

— Укыйсым килми минем сездән. Яратмыйсыз сез мине, берәү дә яратмый мине,— дип, гел түбәнгә карап, бер үк сүзләрне тәкрарлаудан узмады. Бу йортта малайның иң якын кешесе, әлбәттә, әнисе Зәйтүнә иде. Шулай ук аның язмышы өчен иң җаваплы кеше итеп тә Зәйтүнә үзен саный иде.

«Сез чыгып торыгыз, мин үзем сөйләшәм аның белән!» дигән ишарәне аңлатып кул изәде ул өйдәгеләргә. Ялгыз өйдә икәүдән-икәү генә калып та, малайдан рәтле сүз ала алмагач, түземлекнең дә актык чиге килде. Зәйтүнәдә этисе мәрхүм Бурсык Аптулланың каны кузгалды. Җитмәсә, җае туры килеп тора: стенадагы агач чөйдә чыбыркы эленгән иде. Олылар белән рәтләп сөйләшергә дә теләмәгән бу кире беткән сөеклесенә, ниһаять, чыбыркы телендә аңлатырга булды Зәйтүнә. Монда бүтән беркем дә юк, икесе дә сүз сайлап тормадылар, каһәрләү һәм шәп кеше булырга ант итешү бергә буталды, икесе дә елый, берсе — кыйналудан, икенчесе шушындый мәҗбүрияткә килеп житүенә гажизлектән елый иде.

Педагогия нормаларына сыйдымы, сыймадымы бу, ләкин «чыбыркы» телендә шушы сөйләшүдән соң малай сизелерлек ипкә утырды.

## 15

Әллә ипкә утыруы, әллә әкәм-төкәм кебек кабыгы эченәрәк яшеренә төшүе? Ачык кына әйтү читен иде. Ирле-хатынлы укытучылар, Зәйтүнә дә, Сәфәргали дә, әлбәттә, чамалыйлар. Чыбыркы белән генә баланы акылга утырту, ай-һай ла, мөмкин хәл микән? Бигрәк тә чатлы-ботлы яклары ачыктан-ачык күренеп торган Тәлгатьише баланы. Җитмәсә тагы, өстән — мәгариф бүлегеннән дә берөзлексез явып торган циркуляр-күрсәтмәләр дә тукыпмы-тукыйлар: каеш, чырагач белән балага белем «сеңдерә» торган иске мәдрәсә түгел совет мәктәбе, монда эш бик күпкә катлаулырак: баланың, һәр баланың үзенә аерым акылын-фигылен өйрәнергә, белергә, һәр балага карата үзенә хас ачкыч табарга кирәк.

Хәлбуки, соңгы вакытта Тәлгатьнең яхшы якка таба үзгәрә баруы сизелеп тора иде. Сабагын гел «яхшы», «бик яхшы» билгеләренә генә укып баруында түгел хикмәт — сабагын ул элек тә начар укымый иде — күзгә күренә һәм күренми торган якларда иде үзгәреш. Иптәш малайларына якыная төште, борын канатышулар бетте, искәрмәстән бирелә торган сәер сораулар да кимеде, өй, абзар-кура эшенә кушсалар да, һич карышмыйча, ялтыратып эшләп ташлый, кайчагында кушканны да көтмичә эшли, тик әлегә әбисенең Маратны «Морад» дип йөрүен генә берничек тә аңлый алмый иде. Кайчагында, бигрәк тә этисе белән әнисе өйдә юк чагында:

— Нишләп Морад булсын, Марат! — дип әбисенә кычкыргалап та җибәргәли. Нәкъ әнә шул этисе белән әнисе юкта теле ачылып әбисенә кычкырынулары малайның әлегә ачылып ук житмәгән бер ягын ача: ул эти белән әнигә керсез күңел белән ышанудан да бигрәк алардан чак-чак кына шүрли иде булса кирәк. Яхшы якка үзгәрешнең төбендә, беренчедән, әлеге шул шүрләү ятса, икенчедән — берәүнең дә башына килмәслек хәл, — энесенең аңарга, Тәлгатькә, бөтен яктан охшаганлыгы, көннән-көн ныграк охшый баруы күңеленә хуш килә иде. Малайлар икесе дә елдан-ел калка баралар, Марат инде тәпи китте генә түгел, әбисе күрмәгәндә урамга ук чыгып китә һәм соңыннан моның өчен нишләптер Тәлгатькә шелтә дә эләккәли иде. Шулай да абыйсы энесенең шулай шук-чая булып үсеп килүен ярата, бигрәк тә кулга ал-

дырмавын-күтәртмәвен ярата иде. Хәтта бервакытны ул урамда, иптәш малайлары арасында:

— Безнең Марат җиде айдан тәпи йөри башлады, — дип энесе белән мактанырга ук керешкән иде дә, малайлар шундук төрле яклап аны үчекләргә тотындылар:

— Кара әле, күргәнем юк ие, сезнең Марат бөтенләй синең төсле ике колаклы икән,— дип башлады берсе. Һәм абыйсы артыннан тагылып килгән бәләкәй Маратның колагына кагылып куйгандай итте.

— Кулың белән кагылмыйча гына,— дип кычкырды Тәлгать җене чыгып һәм энесен үзенә табарак тартты.

— Колагы колак, күзләрен әйт, тач абыйсыныкы.

Хәер, шуннан да артыкка китмәделәр. Тәлгатьләрдә генә иде ди җиде айдан тәпи киткән малай. Шулай да бу кыска үчекләшүдән бик тә күңеле булды Тәлгатьнең. Энесе Маратның да күзләре Тәлгать күзләренә охшаган, димәк. Моны малайлар әйтте, әйтмәсә, Тәлгатьнең бу турыда әле уйлаганы да юк иде.

Өйгә кайтса, әнисе ялгыз үзе генә утыра. Хакыйкатьне әнисеннән дә раслатасы килде малайның, дуамал гына сорау куйды:

— Маратның күзләре минем күзләр төслемени, әни? Малайлар шулай ди.

— Бетмәде синең ул малайларың! — Зәйтүнәнең үз мәшәкате көчле иде, булыр-булмас сүзне сузарга теләмәде. Әмма Тәлгать өчен бу «булыр-булмас» түгел, аның бу соравы артында әлегә бирелмәгән икенче — тагы да хәтәррәк соравы да бар иде. Әнисе болай коры торгач, мөмкинме соң андый сорауны биреп уйнарга? Сорау шулай бирелмәгән килеш күмелеп калды, ә һәрбер күмелеп калган сорау кайчан булса да икенче бервакытта, икенче бер яктан тагын да кискенрәк булып тишелеп чыгачак. Тормыш законы шулай. Ай-һай ла, күмеп калдырмаска иде ул хәтәр сорауны.

«Ә кызыллар аткан этинең күзләре нинди иде?» — бирелмичә калган сорау менә шушы иде. Димәк, малай ачылган гөл кебек булып күренә генә, әлегә ул бөтенләй үк ачылып җитмәгән, «теге эти», «бу эти» кебек бүленешләр аның күңелендә әле дә булса яшеренеп саклаға налар.

Малайларның үз дөньясы булса, олыларның үз дөньялары — үз мәшәкатьләре. Күптән инде авылда крестком сепараты булдыру турында сүз йөри, моның өчен бигрәк тә Мөхсинов көя, чөнки моңарчы авылга кайткан бердәнбер сепарат кулак Вәлихановларда гына иде. Мөхсинов фикеренчә, ул «канечкечләр» шул гөжелдәвек сөт аеру машинасы белән дәшми-тынмый гына авылның ярты маен имеп ятсалар, Мөхсинов оештырып җибәргән кресткомда пичәт бар, кәгазьләр-«дело»лар бар, сүз сөйлиләр, ә авыл халкына чын-чынлап файда китерердәй юньле-башлы бер эш тә юк — ачу китермәслекмени бу?! Файдасы — файда урынында, һич югы, Вәлихановларның тез асларына сугу өчен, әлбәттә, кирәк крестком сепараты. Мөхсиновка китереп җиткерә торалар, әйтә, ди, ул «канечкеч кулак», чын булса әгәр, битенә олтырак каплагандай ачыктан-ачык әйтә, ди: «Ул хөррият дигәннәре мылтык шартлату гына булып калды. Төтене чыкты да бетте, әлегә авылга Мөхсин Фазылҗаны да, зимагур Сәпәр дә хуҗа түгел, мин хуҗа — аларда пичәт булса, миндә акча бар, кибет бар, мал-туарым абзар тулы, сипаратыма бөтен авыл кыз-хатыны чират тора» дип әйтәдер, ди. Чынлыкта исә әйткәндерме Вәлиханов мондый шыр-ялангач контр сүзләрне, әллә совет властеннан дәшми-тынмый гына өркеп, елдан-ел җилкәгә ныграк өелә барган налогларны сукрана-сукрана булса да вакытында түләп килүче астыртын кулак эченнән генә шулай уйлагандырмы? Ничек кенә булмасын, обмотка чорнап, үзе революция ясашып йөргән, җитмәсә тагын, авылда бердәнбер коммунист саналган Мөхсиновка андый сүз-

ләр эрә дә каты ишетелә, дошман пулясы булып, туп-туры бәгыренә килеп кадала иде. Шуңа күрә ул югарыдан циркуляр килгәнне дә көтмәде, бүреге белән озын-озык киңәш итеп торуны да кирәк тапмады, теге сары капкалы Вәлиханнныкыларга үч итеп, барыннан да элек авылда крестком сепараты булдыруны максат итеп куйды һәм шул максатны җиренә җиткерү өчен әле волость үзәгенә, әле кантонга чапты.

— Җәй айларында әлегә синең мөгаллимлеген ял итеп торсын, син орденлы кәше, так бөтен җиһазларыңны күкрәгеңә, мәлҗеп торма, өстәл төеп сөйләш, — гадәттә әнә шундый «фатиха» сүзләре әйткәләп, зуррак йомыш белән ул Сәфәргалине җибәргәли иде.

Йөри торгач, ниһаять, алар үзләренекенә ирештеләр, сепараторга дигән язу хәзер кулда, тик, кадалып киткересе, җәһәннәм астына — Балык бистәсенә барып аласы булып чыкты. Сепарат алырга бару шулай ук Сәфәргали өстенә төште. Мөхсиновның әйтүенә караганда, олауга атның авылда бере булачак, тимер хут ди икән — тимер хуты табылыр, тарантаска утырып барырга тели икән, — тарантас көпчәкләре майланган булыр. Мондый юмартлыкка каршы торып кара, шуның өстенә, Сәфәргалинең үзенең дә авылны сепаратлы итәсе килә иде.

Әлегә хәтле читтә-чатта, совет өе тирәсендә йөргән шул хәбәр кичә кич «Тегүче Корбангалиләр» (аларны әле дә булса шулай атап йөртәләр иде!) өенә килеп керде. Ә Тәлгать өчен бу — башны күккә тидерерлек сөенеч булып чыкты. Чөнки Сәфәргали үзенә иптәшкә малайны да алып барырга ниятләгән иде.

— Пароход күреп кайтыр, әйдә, әзерлә малайны, — диде ул Зәйтүнәгә өзеп кенә.

Һич уйламаганда аяк астыннан килеп чыккан бәхет булды бу — икенче көнне китте малай тимер хутка утырып. Малай өчен бәхет өстенә бәхет: сепараторны бару белән арбага салып җибәрмәделәр. Бюрократизм дигән өстәл асты күсесе ярыктан борынын төртте: накладноена кемнеңдер имзасы салынмаган икән, ул имза сала торган кешене иртәгә хәтле көтәргә кирәк булды. Моңа чаклы ишле су күрмәгән Тәлгатьнең язгы ташкыннардан соң әле ярларына утырып җитмәгән киң Камага болай да һушы киткән иде, шуңа тизрәк пароход узганны көтү хиреслеге дә өстәлеп, бөтенләй тапырдавыкка әйләнде. Гүяки су һәм пароход карау өчен генә килгәннәр, сепарат мәсьәләсе, гүяки, бер якта торып торсын!

— Пароход килгәнне күрү кичен, караңгы төшкәч кызык, утлары кабынгач, — дип, малайны тынычландырырга тырышты әтисе. Өстәвенә, кырыс кына болай дип тә әйтеп куйды: — Көндезен монда сепарат мәшәкатьләре дә муеннан булып чыкты әле, әзерләп көтеп торганнар.

Кичкә икән — кичкә! Күрде малай. Кичке караңгылыкта зур дәрья өстеннән суны шаптыр-шоптыр айкап, бортларында, мачта башларында ак, кызыл, яшел утларын балкытып, пристань ягына борылыр алдыннан сузып гудок бирүче зур пароходны күрде. Беренче тетрәткеч тәэсире шул булды: ходаем, ничек су күтәреп тора икән мондый иләмсез зур әкәмәтне. Безнең авылның кибетче Вәлиханнарның ике катлы өйләре чүп кенә икән моның янында!

Тагын да әкәмәтрәкне ишетәсе көне иртәгесен булган икән. Ләкин иртәгә хәтле бүгенге кичне үткәрәсе бар иде. Ашханәдә хәзерләнгән «хәрам дуңгыз итен» өйдән төйнәп килгән хәлал солы күмәче белән кушып, тамак туйдырып, чәй эчеп чыкканнан соң, вакыт уздырып яр буе урамын таптап йөргәндә, Сәфәргали, уйлап җиткермичәрәк:

— Йә соң, ничек? Чучка ите шәпме? Туйдымы тамагың? — дигән ахмак сорау биреп куйды.

— Чучка ите идемени ул? — дип, гаҗәпләнүдән бигрәк куркынып, сорауга каршы сорау белән җавап кайтарды малай. Башка ни дә бул-

са әйтерлек сүзе калмаган, башында бер генә уй: димәк, «теге дөньяга» баргач яндырачаклар — әтисен дә, Тәлгатьне дә.

Йөри-йөри торгач, «теге дөнья» онытылды тагын. Чөнки «бу дөнья»дагы эшләр ерып чыккысыз катлаулырак бит.

— Бу Кама яклары таныш миңа, чәчне үрә торгызырлык таныш, — дип, әллә уфтанып, әллә сагынып, сузып куйды бераздан Сәфәргали. Малае белән сөйләшүдән бигрәк, ул үзе белән үзе сөйләшә иде бу минутта, — бигрәк тә Каманың әнә аргы ягы... каршы ягы таныш. Булды, малай, эшләр анда. Әйтергә дә була, әйтмәсәң дә ярый.

Нәкъ менә шушы «әйтмәсәң дә ярый» торган сүзләре малайда берьюлы шик һәм сагаю уятты. Димәк, «әйтмәсәң дә ярый» торган сүзләре дә бар икән әле «бу әти»нең! Аның колагына кермәгән түгел. Бөтенесе дә шунда: «Закамада», «Закамада» булган. Әнисе дә шуннан. «Теге әтисе» дә шунда булган. Бабалары да шунда... булырга тиеш.

Малай кинәт йомылып калды, сүз катсаң да урынлы-урынсыз җавап кайтара, кыскасы, тагын үзенең эчке кабыгына качкан иде.

Тик иртәгесен юлда кайтканда гына ул беркадәр җанлана төште. Әтисе пароход турында исенә төшергәч тәтелдәргә үк тотынды, сорау артыннан сорауны яудырып кына тора: нәрсә белән йөри? Кем ясый ул пароход дигән әкәмәтне? Кем йөртә? Ничек йөртә?

Сизелеп тора: малайның пароход белән кызыксынуы ясалмасыз иде. Форсаттан файдаланып әйтә куйды Сәфәргали. Үгетләп тә, ышандырырга тырышып та, малайда үзенә карата якынлык хисе кузгатырга теләп тә түгел, үз күңеле көрлектән, юлы уңганлыктан, дөньяга шиксез ышанганлыктан, хәтта үзе дә чак-чак кына малайга әйләнгәндәй, саф күңел белән әйтте:

— Яхшылап укы, улым, — дип башлады ул, җыр җырлагандагы кебек суза төшеп,— тырышып укы. Киләсе кыш син безнең Мәтәскә мәктәбен бетерерсең. Аннары русча өйрәнү өчен мин сине Теләче мәктәбенә бирермен. Аннары, русчаны да, татарчаны да белеп, шуның өстенә бүтән фәннәрне дә тутырып, башың тубал хәтле булгач, менә күр дә тор, үзем артыннан йөреп, мин сине әнә шул пароходлар йөртергә өйрәтә торган уку йортына урнаштырырмын. Миннән булмады, әйдә, син йөрт пароходларын.

Йа, хода! Яртысы гына чынга ашсын, шулай да башы күктә иде малайның, авызыңа бал да май, әти җаным!

Көн кояшлы, кояш күңелне иркәли, уйлыйсы, хыялланасы, пароход йөртәсе килә. Ә авылга сепарат кайткач, иң куанганы, хәтта киләчәктә «пароход йөртәчәк» Тәлгатькә караганда да ныграк куанганы, әлбәттә, крестком Мөхсинов булды.

— Моның өчен мин сине партиягә алам да алам,— дип сөйләнә-сөйләнә күтәрешеп керде ул сепаратны,— беренче рекомендацияне үзем бирәм, алла боерса.

Шундый шатлыклы минутта телгә килүен кара: «Алланың ни катнашы бар монда?» Әлбәттә, телдән ычкынган хатаны шундук төзәтергә ашыкты.

— Алланы катнаштырмыйк, ул үзенең җиденче кат күгендә аягын сузып утыра бирсен, ә сепаратны ходка җибәрәбез... Җибәрәбез булгач җибәрәбез!

## 16

Беренче тапкыр олы су, пароход күрү әлегә үз тирәләрендәге берничә кечкенә авылдан, кордоннан, капкач тишекләреннән бу пошкырып кайный торган яньчек самавардан бүтән нәрсә күрмәгән тәэсирчән малайда әйтеп-сөйләп бетергесез эз калдырды. Бигрәк тә пароход

һушын алды анын. Булса да булыр икән шундый тамаша, шуны бит кеше ясаган, ди.

— Моржасы гына да Хәмдияттәйләрнең мунчасы хәтле,— ди ул, пароходның зурлыгын ничек тә булса әбисенә аңлатырга тырышып. Монда малайның фантазиясен ике нәрсә бергә куша иде булса кирәк: мунча моржасыннан да ишелеп кара төтен чыга, пароход моржасыннан да ишелеп кара төтен чыга. Пароход моржасы да үзе тәбәнәкюан, үзе кара, Хәмдияттәйләрнең мунчасы да үзе җирдән бер карыш, үзенең эче, тышы кара корым. Әби кеше шул сүзләргә чын ихластан ышана тагы.

— Салам яга торганнардыр аңа, салам якканда ул төтен шулай кара болыттай ишелеп чыга.

— Салам ягалар, ди, прахутка. Берни белмисең син, әби.

— Син белгәч миңа ни... Син белгәч миңа шул җиткән инде, балакайгынам.

Рәхәт тә соң әби белән сөйләшү... Шул ук вакытта озак сөйләшеп тә булмый пароход күрмәгән әби белән. Рәхәт — чөнки бөтенесенә ышана. Озак сөйләшеп торасы килми — чөнки пароходның зурлыгына тамчы да исе китми. Әллә бар пароход дөньяда, әллә юк.

Икенче хәл, әйтик, иптәш малайлар арасында. Менә, ичмасам, алар иләпме-илиләр.

— Бер ягында кызыл ут, бер ягында яшел ут, дисең. Кәрәчине төрле микәнни соң анын? Бер кәрәчин ике төрле булып янмас.

— Йөздән артык кеше сыямы үзенә?

— Йөз генәме, мең диген.

— Прахуты суда, утырырга торучылары җирдә. Ә утырырга кирәк. Ни арада күпер сугып өлгерәләр соң прахут белән җир арасына?

Болары әле кердем-чыктым сораулар — малайларча кызыксынудан гына. Шундук бирә соравын, шундук онытa нәрсә әйткәнен. Хәлбуки, малайларның да төрлесе бар. Беришесе Тәлгатьнең пароход чаклы пароходны күреп тә, үзенең басу капкасы аръягына да чыкмаган булуыннан көнләшеп, юри тырнак астына шырпы булып кадалмакчы:

— Ә синең ул прахут дигәнең чалкан йөзә беләме? Алай бик шәп булса, чалкан йөзеп карасын ул менә.

Җавап табып кара син әнә шундый шыр тиле малайга. Шундук берәве бөтенләй сабыйларча сорау биреп куя:

— Зурлыгын әйттең, утларын әйттең, мең кеше сыйганлыгын әйттең, ә озынлыгын әйтмәдең. Озынлыгы нихәтле, озынлыгы?

— Озынлыгымы... озынлыгы нихәтле дип әйтим икән?

Сабыйларча гына куелган сорау булса да, Тәлгать бичараны бермәл аптырашта калдырды бу сорау. «Озынлыгы ни чамалы ие соң әле? Кадалып су астына төшеп киткере?» Ә җавап бирмичә калдырырга ярамый. Җавапсыз калдырдың, малайлар шундук эләктереп алачаклар. «Шартлата. Булмаган, прахутны гүпчи дә күрмәгән. Озынлыгы нихәтле икәнен дә әйтә алмый». Җене чыгып беравык җиргә карап калды Тәлгать һәм ачудан кинәт ярып салды:

— Озынлыгы нихәтле дип әйтим, үлчәп карамадым. Зыя муллалар тыкрыгы хәтле бардыр.

Кыскасы, батып калмады малай, бата башлаган җиреннән үрмәләп чыкты — авылында тыкрыклар күп булса да файдасы тия икән. Ләкин һәр очракта тыкрык кына коткарып та калмый, була шундый хәлләр, бигрәк тә малайлар арасында була, бигрәк тә кайчандыр безнең Мәтәскә малайлары арасында килеп чыккалый иде. Син күңелең яхшылык белән тулганлыктан чәчрәп чыгасың, шатлыгың эчеңә сыймый, олылар сиңа игътибар итми, үзеңнән көчлеләргә синең игътибар итәсең килми. Нишләмәк кирәк шундый чакта? Серне чишәсең үз ишеләреңә. «Әйтик, «безнекеләр бүген кабак бөккәне пешерә». Икенче

беренңнән икенче яңа хәбәр: «Безнең тайдан чабыш ат чыгачак. Әти әйтә: танавы парлы, танавы парлы булса, чабыш чыгачагын көт тә тор, ди». Өченче берәүдән тора торгач туры юл: «Безгә быел сабан туена каладан Гаделша абый кайта, скрипкәче Гаделша абыйны беләсезме безнең?» «Скрипкәче Гаделша абыйны», әлбәттә, берсе дә белми, хәер, белмәгәнгә карап исләре дә китми тагы. Әйтә бараләр, оныта баралар — шуның өчен дә малайлар, аларга ни... диңгез тубыктан.

Ә менә гел тубыктан гына да булып бетми икән шул. Мәсәлән, Тәлгать авылның басу капкасыннан да чыкмаган малайлар алдында Кама хәтле Каманы күрүе, аннары пароход күрүе белән мактанган иде. Анысын әле ярым кызыксынып, ярым көнләшеп булса да тыңладылар. Ай-һай, шуның белән генә калган булса соң! Юк шул, малайлыгы ахырына хәтле бәреп чыкты Тәлгатьнең. Бер кызып киткәч, мактанмый кала алмады.

— Әти әйтә, элек менә үз авылыбызның мәктәбен бетер, аннары Теләчегә җибәреп урысча укытам, аннары әнә шул прахут йөртүче капитанлыкка укытам, ди.

Бу хәтлесен үк ишетеп берьюлы чәчләре үрә басты малайларның. Үрә басмаслык та түгел, имештер, Мәтәскә тузанында аунап үскән малайдан пароход йөртүче чыксын. Чынлап торып әйтә калсаң, Мәтәскә малае да түгел әле. Китте буа ерылып, китте ерылып, тыеп кара хәзер. Малайлар үчләнүе дә ерылган буа икән.

— Кайсы этиең әйтте? Синең этиең икәү бит.

— Ирештермә Тәлгатьне. Кайчан булса да ул йөртә торган прахутка утырып барырга туры килмәсен. Суга төртте төшерде булыр.

— Ә мин менә әйтәм: чыгар Тәлгатьтән! Синең шикелле «ике җирдә икең ничә әле?» дип, күрше партадагы Фәниядән сорап утырмый.

— Башлы малай Тәлгать. Түлке ни... аяк кына бераз кәкре.

Иң элек башлаган усалы иң соңыннан һәм иң авырын әйтте:

— Аягына тимә. Әтисе белән әнисе икесе дә укытучылар — ничек булса да турайтырлар. Урысчасын да өйрәтерләр, прахут йөртүчең дә шушы Тәлгатең булыр.

Малайлар төрле, сүз төрле: бәлки арада кешечәрәк әйтүчеләр дә булгандыр? Ләкин Тәлгать артык чыдап тора алмады, мәлҗергә иртәрәк, сүз көрәштерергә инде соңга калган иде. Ыргылып кузгалды, унга-сулга карамыйча өенә чапты.

Ә өйдә кем бар? Әби бар да әлеге Марат дигән ыштансыз малай бар. Әти белән әни — эшем кешеләре, алар соң уникe яшьлек малайның күңелендә ниләр кайнаганны гел генә белеп торалармы? Ә малайның күңелен гел ярсытып кына торалар.

Әнә пароход күрсәтеп кайтты әтисе, күз алдыннан хәзер шул китми. Утлары, утлы тәрәзәләре, төрлечә ялык-йолык итә торган калайлары, җилдә уйнаклап торган флагы, иң өстә, пыяла бүлмә эчендә тәгәрмәче, ул тәгәрмәчне әле тегеләй, әле болай боргалап торучы кешесе... Малайлар теләсә ничек лыгырдасыннар, Тәлгатьнең күңелендә хәзер таш булып каткан бар уе шул: кайчан булса да Тәлгать тә иң өстә тәгәрмәч әйләндереп, кирәк булса, астагыларга команда биреп торучы кеше булачак. Хәзер аны «буржуй малае» дип котыртулары әллә ни өркетми. Китаптан да укыган, мәктәптән дә колагына керә, олылардан да ишетә, үз башы да гел эшләп тора. Әйе шул, булган шул андый заманнар. «Кызыллар» дигәне ажгырып чыккан, «аклар» дигәне дә посып ятмаган. Дөрес, аның бабасы, малайның уйлавынча, Тәлгатьне иң нык яраткан Корбангали бабасы, авыл кешеләречә әйтсәк, «Тегүче Корбангали» берсе ягыннан да катнашмаган. Ишетеп калганы бар Тәлгатьнең бабасы авызыннан: «Өелешеп сугышты халык ничәмә ел буена. Элек герман белән сугышты, аннары үзара

чәйнәшергә тотынды, бугаз гына тәтсен. Мин, аллага шөкер, кызыл да булмадым, ак та түгел, алар үзара әүмәкләшеп сугышкан арада, Цепилов алпавытының үзе атланып йөри торган сөлектәй айгырын җөгәнләп апкайттым да, ак бер якта, кызыл икенче якта калды, мин әллүр үз юлымнан», дип шаяртып әйтә торган иде. Бабай бабай инде ул, китап-газет укымаган, мәктәп күрмәгән. Ничек уйласа — шуны әйткән, ни әйтсә — шуны үзенчә дөрес дип тапкан. Үлгән бабай әйтмешли, юк белән башны катырып торырга ничу. Һәм ул бу чаклысына күнгән дә иде инде, юк өчен баш ватмый. Балык бистәсендә булып, пароход күреп кайткач, өстәвенә тагы, әтисе пароход йөртүче итәргә вәгъдә дә биргәч, «аклар» һәм «кызыллар» кебек бүленешләргә игътибар да итми башлаган иде.

Ә менә теге көнне малайлар моңарчы башка да килмәгән икенче бәла китереп тактылар. Имештер, Тәлгатьнең әтисе дә, әнисе дә укытучы, имештер, Тәлгать шуңа күрә яхшы укый, Тәлгать бөтенесеннән күбрәк белә, бөтенесеннән күбрәк уйлый. Имештер, әтисе белән әнисе аны артыннан этеп йөртәләр...

Малайның әлегә нытып өлгермәгән җилкәсе, урынына утырмаган мин-минлеге бу яңа тагылган гаепне алырлык хәлдә түгел иде. Әйтергә генә ансат, соңгы класста укыганда, алдынгы укучы саналып йөртелгәндә, хәзерге әтисенең әйтүе хак булса, киләсе көздән Теләчегә — русча укырга җыенасы бер вакытта, менә-менә язгы имтиханнар килеп терәлгәндә, кыскасы, әтисе-әнисе һич көтмәгәндә, әлеге хурлау сүзләрен ишетеп, малай энәләрен яңадан керпедәй калкытып куймасынмы! Урамга уйнарга чыкмый, энесе Маратка күтәрелеп тә карамый, әбисе кушкан йомышны тыңламый, мәктәбенә дә тик сәгатен үткәрү өчен, теләр-теләмәс кенә йөри, куелган сорауга җавап бирергә дип элекке кебек бөтен кешедән әүвәл кул күтәреп тормый башлады. Малайда сизелерлек эчке үзгәреш тууны һәм бу үзгәрешнең яхшы якка түгеллеген әти-әнисе, әлбәттә, сизеп торалар, хәвефләнәләр, эрактан-ерактан урап сорашкалап та карамыйлар түгел, ләкин малай энәле кабыгы аркылы берсен дә эчкә үткәрми иде.

Ниһаять, бер көнне ул, үртәп тел шартлатучы иптәш малайларына үч итеп, әле теге, әле бу яктан юмалап, эчкә үтәргә-сорашырга, кызыксынырга маташучы әти-әнисенә дә ачуы чыгып, хәтта Корбангали бабасы каберенә баргач нинди дога укырга белмәве өчен дә хурланып — «буржуй малае» икән — «буржуй малае!» — чыгарыш имтиханын аңлы рәвештә өзәргә, аңардан көтелгәннең нәкъ киресен эшләргә булды.

«Җәйне ничек уздырырга уйлыйм» дигән темага язма эш бирелгән иде. Басу капкасын үтеп чыкмаган авыл балаларыннан әллә ни фантастика көтелмәстән, шулай да алар дәрәҗәләренә күрә ярыйсы гына язып китергәндә, Тәлгать иншасын күреп үз күзләренә үзе ышанмады Сәфәргали. Җөмләләре киреле-мырлы, бер фикер белән икенчесе арасында бернинди бәйләнеш юк, хәреф хаталары тезеп куйган кебек, әндәш галәмәтләре берсе дә урынында түгел, иң ахырдан, укытучы әтисен юри үчекләргә тырышкан кебек, иншасын түбәндәге сүзләр белән очлап куйган иде: «Кыш кыра алмаганны җәй көне генә әллә ни кырырмын дип әйтә алмыйм. Ахыргы сүземне әби сөйләгән әкияттәге таз белән бетерәм: күлне күккә асарга тотынам җәй көне. Янә дә алдым биш баш куян тиресе, бәһасе булды керенский акчасы белән егерме сигез мең — аны да хәзерге акчага әйләндереп түләтергә кирәк булыр».

«Инша» дигәннең аңлы рәвештә мыскыл белән язылганлыгы әллә кайдан сизелеп тора иде. Дәрес сәгатьләре чыгып, башка укучыларны кайтарып җибәргәннән соң, Сәфәргали Тәлгатьне класста алып калды һәм, ачуланганын ничек тә чыгармаска тырышып, тыныч кына әйтте:

— Син нәрсә язганыңны уйлап, белеп язгансың, малай актыгы, — ул малайга күтәрелеп карамаска тырыша, күтәрелеп караса, ачулануы бәреп чыгар төсле сизә иде. Киресенчә, малай язган җайга ята төшеп, юри шаярткандай, аннары болай дип өстәде: — биш баш куян тиресе өчен түли алмабыз, хәзергә «бик начар» билгесе куйсак, шул җитеп торыр.

Малай ни дип тә җавап бирмичә, ишеккә атылмакчы иде дә, Сәфәргали аны туктатып — бу юлы күтәрелеп карамыйча булдыра алмады:

— Өйгә кайту белән, алган бәһаңне әниеңә күрсәт, мин соңыннан аңардан сорармын.

Моңа хәтле гел дип әйтерлек аркасыннан гына сыпырып торган, малайлар арасыннан әлегә берәү дә күрмәгән пароходны күрсәткән, алай гына да түгел, киләчәктә Тәлгатьне пароход капитаны итеп укытырга вәгъдә иткән киң күңелле «бу этисе»нең шул кадәр рәхимсез-каты булуын малай һич көтмәгән иде. «Бик начар» билгесен әнисенә, әлбәттә, күрсәтмәде һәм ул көнне кунарга да кайтмады.

## 17

Тын гына яткан авылны аякка бастырган вакыйга булды бу: малай икенче, өченче көннәрдә дә күренмәде, күреп калган кеше дә килеп чыкмады. (Чын дөреслектә күреп калган кешеләр булды — шул ук Мәтәскә кешеләре, Кама аръягына тегүгә китеп баручылар иде. Малай башта, урманны чыкканчы аларны арттан күрә-күрә барып та, урманны узып байтак киткәч кенә килеп тагылган, имештер, Кама аръягындагы бабаларына кунакка барырга эти-әнисеннән рөхсәт алып.) Ә монда исә төрлечә юраулар, фараз кылулар китте — авыл кешесенә сөйләр өчен азык кына бир, акылны ул базарга бармыйча да сата. Берәүләр малайны кызганган атлы күренергә тырышып сөйләделәр, бер уңайдан олыларын яманлап телгә алырга да онытмадылар. Икенчеләре олыларының кайгысын уртаклашкан булды, җилләре малайга кагылды: янәсе, күренеп тора иде астыртынлыгы, башында хәтәр уе булган икән!

Борчуның иң авыры, әлбәттә, Зәйтүнә белән Сәфәргали башына төшә иде. Малай язмышы өчен — бердән. Шул ук вакытта икенче ягын да уйлыйлар — авыл пышылдый булыр: «Күр инде син боларны, мөгаллим дә мөгаллимә үзләре, кеше балаларына сабак бирүчеләр, ә үзләренекен кулда тота алмадылар!»

Сәер хәл: эчтән иң нык өзгәләнгән кеше — Зәйтүнә, арада иң сабыры да шул ук Зәйтүнә булып чыкты. Сәфәргали милицияне, власть органнарын аякка бастырырга дип ярсып кузгалгач та, аны сабыррак булырга, уйлабрак эш итәргә өндәп урынына утыртучы Зәйтүнә булды.

— Тукта әле, Сәфәр, пошаман кагарга ашыкмыйк,— диде Зәйтүнә, үзенең эчке дулкынлануын ничек тә сиздермәскә тырышып, — күңелем сизә, теге бабалары ягына китмәдеме икән? Аларга хат язып карыйк башта.

— Бәлки Сәлмән кулак алдына барып тезләнергә дә кушарсың? — Сәфәргали кырыс иде бу минутта. Каты сүз ычкындырудан шикләнеп, читкә борылды.

— Сине катнаштырырга уйлаган кеше юк, — ниһаять, Зәйтүнә дә үзен тотып кала алмады, — мондый буталчык эшкә кайда инде ул сине катнаштыру, партиягә керергә йөргән кешене.

— Таптың әйтер сүз син дә.

Ишекне яхшы ук каты ябып чыгып китте Сәфәргали. Соңыннан, сабыр акыл белән уйлап, исенә килде Зәйтүнә: кирәкмәс сүз ычкынды бугай шул — нигә бу эштә партияне китереп кыстырырга кирәк бул-

гандыр? Партиягә керергә кирәклекне Сәфәргалинең исенә төшерә торучы кеше асылда Зәйтүнә үзе иде бит. Ире булганлыктан түгел, шулай ук нинди дә булса күтәрелү-карьера өмет итүдән дә түгел, кирәк булганын, шулай тиешлеген чын күңелдән сизенеп әйтә килде! Гражданнар сугышы герое, революция юлында кан койган, продотрядниклар сафында спекулянтларга — әлеге шул Сәлмән каруннарга каршы җаң талашып йөргән, бүгенгесе көндә дә авылда совет властен ныгыту өчен кулыннан килгәнчә тырышып-тырмашып йөрүче — партиягә аның Сәфәргалие ише кешеләрнең кермичә калуы мөмкинме соң! Ә ул — Зәйтүнә — әнә шундый кешене нәрсәгә этәрмәкче? Яңадан Сәлмәннекеләр каршына тезләндерергәме? Юк, юк, ачуланып чыгып китүендә Сәфәргали хаклы. Ә менә Зәйтүнә хатны барыбер язачак. Язып кына эш чыгара алмаса, барып, тартып алачак малайны. Болай эшләргә аның хакы да, таяныр көче дә бар: совет властена таяна.

Тәлгатьнең шул якка китүендә аның һич кенә дә шиге-шөбһәсе юк. Күзәтә, сыный килде: бүре баласы чалымнары юк түгел иде малайда. Күрәсең, «бу як» тиешле тәрбияне биреп җиткермәгән, «теге як» исә малайның иләс күңелен җилкетүдән туктамаган.

Ничек кенә булмасын, бу очракта төрлечә фәлсәфә корып, эшне озакка сузарга ярамый, Зәйтүнә моны яхшы аңлый иде. Хатны ул фәлсәфә сатмыйча, шулай ук кемне булса да өркетергә дә ашыкмыйча, сабыр тонда язды. Ләкин ничек кенә кыска язарга, кирәкле сүзләрне генә сайларга тырышмасын, хаты ул теләгәнгә караганда озынрак килеп чыкты.

Аның каравы, «теге як»ның җавабы ачу китергеч дәрәҗәдә кыска һәм дипломатларча төгәл иде. Хат язып җибәргәннән соң атна да узмады, Кама аръягындагы Тирәкле авылыннан болар адресына түбәндәге телеграмма килеп төште.

«Малай бездә. Без чакырып китермәдек, без куып та җибәрә алмыйбыз. Рифгать Вилданов».

Әлеге телеграмманы алганнан соң, капма-каршы тойгылар арасында күмелеп калды Зәйтүнә. Беренчедән, улының исәнлек хәбәрен ишетү аны сөендерде — димәк, исән. Калган ягын ничек тә рәтләячәгенә ул ышана, чөнки тәҗрибәсе бар, үз вакытында Сәлмәннекеләр тырнагыннан бер тартып алды инде ул аны. Ул вакытта әле ялгыз иде, хәзер әнә Сәфәргалие — малайның үз атасы бар. Шунлыктанмы, Зәйтүнәдә беренче хис — ана кичерешләреннән туган хис, түземсезләнеп кабыну, малайны ничек тә тегеләр кулыннан тизрәк тартып алу ярсуы булды. Сәфәргали белән бергәләп барып алып кайту, протест хаты җибәреп тегеләрнең үзләреннән китерттерү, инде алай да булмаса, озакка сузмыйча, Сәлмәннекеләрне судка бирү — беренче кабынудан соң туган беренче планнары әнә шулар иде. Әмма Сәфәргали уйланыбрак калган, коры ярсу белән генә әллә ни кырып булмаслыгын төшенә иде. Хәтта талашып-йолкып алып кайткан сурәттә дә мондый адымның малай өчен йогынтылы булмаячагын, киресенчә, аны котырту, тагын да усалландыру гына булып калу ихтималын алдан күрә, шуңа күрә Зәйтүнәне дә сабыррак булырга өнди иде.

— Монда, Зәйтүнә җаным, кабаланып эш итү бер якка да файда китермәячәк, — гомердә дипломат булмаган Сәфәргали бу очракта чак кына дипломатка әйләнмичә дә булдыра алмады, — ярый, синеңчә булды, ди. Бардык та — бирсәләр, яхшылык белән бирмәсәләр, әйтик, милиция, совет органнары ярдәмендә — малайны тартып алдык, ди. Бу бит әле, җан кисәгем, малайның кирелеген сындырдык яки аны үз йогынтыбызга аудардык дигән сүз түгел.

Бергә гомер итү дәверләрендә беренче кабат Зәйтүнә Сәфәргалигә ярсып каршы төште:

— Син миңа акыл сатма. Егет икәнсең, син миңа, озакка сузмыйча, малаемны алып кайтып бир, иптәш камисар.

— Алайса, син инде, туганкаем, «иптәш камисар»ны да тыңла,— Сәфәргали бер үк вакытта җитди, ләкин әни кешене ничек тә тынычландыру ягында иде,— Сәлмәннекеләр белән миңа үз вакытында күбрәк якалашырга туры килде — булды вакыт, мин аларныкын, алар мине утка аттылар. Тагын бер очрашудан һич курыкмыйм. Ләкин малайны алар кулыннан талашып тартып алуга караганда, малайның, аларны татып караганнан соң, үзенең акылга килүе, үз ихтыяры белән безнең якка борылып кайтуы зуррак җиңү булачак. Ә минем моңа ышанычым бар. Беренчедән, Сәлмәннекеләрнең хәзер болай да үзара тешкә теш бәрешкән чаклары булырга тиеш: яшь бай, Рифгатьне әйтәм, башсыз әфәнде түгел, НЭПның вакытлы чара икәнлеген, тиздән аларның койрыкларына басачакларын чамалый булыр. Шуннан чыгып, нишләр дип беләсең аны? Әлбәттә, итәкне-җиңне җыю, малны червонецларга әйләндерү ягын карар. Ә карт бай үз искелегендә катып калган. Шул үзара ызгыш вакытында, рәхим ит, көтелмәгән кунак, контрлыкта гаепләнеп кызыллар аткан ак офицер Мидхәтнең малае, боларга килеп төшсен әле. Бик исләре китәр дип уйлыйсыңмы бу «кунакка»? Бабай — карт кеше, Мидхәтен искә төшереп бераз балавыз сыгар, янтыгын селкер, прәннек-конфет белән әлбәләр. Ә Рифгатьне мин беләм, каты күңелле кеше, аңардан малайга якты чырай әләкмәячәк.

Икенчедән, әнисе җаным, никадәр генә керпеле булмасын, мин үз малаебызга — үз Тәлгатебезгә дә ышанам, бәлки сиңа караганда да күбрәк ышана торганмындыр: башлы малай ул. Сәлмәннекеләрдә үз оясы түгеллеген бик тиз төшенеп алачак,— әллә үзе фараз кылганнарга артык нык ышанганлыктан, хәтта пафоска бирелә төшеп әйтте ул бу соңгы сүзләрен,— аның үз оясы бездә, безнең яктан. Менә күр дә тор, тәңренең бирмеш бер көнендә бездәге оясына ул үзе, үз аягы белән кайтып егылачак, әйткән иде диярсең менә.

— «Оя» да «оя», син дә чистый бер бүре баласы иттең шул Тәлгатьне,— дип, бераз хәтере калгандай кысылып куйды Зәйтүнә. Ләкин бу иренә каршы килүдән түгел — иренең кайнарланып, дәлилләргә тырышып әйткән сүзләренә ул ышанган иде инде — бары тик әлеге ана хисләренең какшамас нык булуыннан, баласына ничек тә кырын сүз тидерәсе килмәгәнлектән генә тыпырчынуы иде. Кыскасы, алар сабыр итәргә, Сәлмәннекеләр белән якалашырга ашыкмаска булдылар.

Ә менә Сәфәргалигә Мөхсинов алдында үз дигәнен исбат итү читенрәк булды. Эш моннан гыйбарәт иде: Мөхсинов инде байтактан бирле Сәфәргалине партиягә керергә кыстап йөри, төрле яклап уйлый торгач, Сәфәргали үзе дә «тегүче Корбангали малае»ның, ниһаять, урыны партия сафында булырга тиешлеккә чын ихластан ышанган, моны тик рәсми яктан формалаштырасы гына калган иде. Ләкин Тәлгать белән әлеге күңелсез хәл килеп чыккач, Сәфәргали партиягә керү мәсьәләсен ул чаклы кумаска, һәрхәлдә, малай әйләнеп кайтканчы дәшмичәрәк тору ягын карарга булды. (Тәлгатьнең үзләреннән качып китүендә, хаклы рәвештә, ул үзен дә азмы-күпме гаепле саный — «димәк, тиешенчә тәрбияли алмаганбыз».)

Ә менә һәр эшне «үз вакытында кыздырырга, тимерне кызуында сугып калырга» ярата торган Мөхсиновка Сәфәргалинең болай тыелыбрак калуы көлке тоелды.

— Таптың иске авыздан яңа сүз,— дип әлеп алды Сәфәрне,— имештер, кайдагыдыр бер контр калдыгының көен көйләп, шундый зур эшне — партиягә керү эшен туктатып торырга. Ошамаган сүз бу. Ә минем сүз менә болай: җик атыңны иртәгә, икәү барабыз да йолкып алып кайтабыз малаеңны, бетте китте — вәссәләм. Ничу комнан аркан ишеп утырырга.

— Ә без, әнисе белән киңәшә торгач, шулай да малайның үзенең дөреслекнең безнең якта икәнлеген төшенгәннән соң, үзе әйләнеп кайтуын көтәргә булдык. Ул вакытта безнең якның җиңүе тагын да отышлырак булачак,— моны Сәфәргали өзеп, сүзне сузарга урын калдырмаслык итеп әйтте.



## 18

Хәер, бу юрауларында алар ялгышмадылар. Китеп югалуына озак та узмады, пичәнгә төшәр алдыннан, җәйге дымык һәм черкиле кичләрнең берендә, малай үзе кайтып төште. Өйдәгеләр йокыга ятканнар иде, өйалды ишеген эчтән терәтеп куйган бастырыкның дөбердәп төшүенә уянып киттеләр. Шундук чамалап алдылар — белгән кеше эше бу, өйалды ишеге буендагы кул гына сыярлык тишектән ыргаклы таяк сузып терәүне тартып төшерү аларда гадәткә кергән, тик моны олыраклары остарак эшли, йоклаганнарны уятмыйча керәләр иде.

Өйгә тиз генә ут алынды һәм күзләре шар булды: ишек төбендә, сүз дәшәргә куймыйча, Тәлгать басып тора иде. Өсте-башы теткәләнгән, үзе яланаяк, чалбар балаклары чукланып беткән, тузанда, кайда җитте шунда аунаганлыгы әллә кайдан күренеп тора иде. Бөтенесе бердән аякка калыктылар, барыннан элек кочагын җәеп малайга ташланучы, әлбәттә, Зәйтүнә булды — бу минутларда аны, акылдан да бигрәк, аналык инстинкты очындыра иде.

— Ник телеңне йоттың, син ич бу, Тәлгать? — беренче сүзләре шул булды. Һәм бу сүзләргә ул әллә ни мәгънә салырга да тырышмады. Нинди дә булса икенче сүз дә уйлап тормады, тузанга-балчыкка каткан, чалбар балакларына тигәнәкләр ябышкан ялан аяклы малаең бусагаңда кинәт пәйда булганда, ни генә уйлап өлгермәк кирәк.— Шул хәтле бетерешмәсәң! Чәчеңне алучы да булмадымыни соң?

Тәлгать үзе әле һаман сүзсез иде, беренче мәртәбә күргән кебек, өй эченә күзләрен йөртеп чыкты, әбисенә карады, әтисенә бермәл текәлебрәк карап торды, янәсе, «әти нәстә әйтер икән?» һәм кинәт балаларча беркатлылык белән:

— Ә Марат кайда? Марат йоклыймыни? — дип сорап куйды.

Шушы гап-гади сорауларны ишеткәннән соң, өненә килгән кебек булды Зәйтүнә, күрегезче: бу шул үзе, бу аның өйдән качып киткән Тәлгате әйләнеп кайткан лабаса! Әби кеше үзенең белгән эшенә — кече якта самавар белән кайнашырга тотынды, ә Зәйтүнә әле дә булса урынлы-урынсыз сораулар бирә-бирә малайны тинтерәтә иде:

— Язган идең лабаса, үз кулың белән язган идең: «Бабай яңа чалбар белән яңа тужурка тектереп бирде», дип. Кайда соң ул яңа чалбарың, яңа тужуркаң? Шушындый әрмәккә төренеп кеше күзенә күренеп йөрмәсәң.

— Калдырдым алар тектергәнне, — ниһаять, малай да телгә килде, ләкин ул әле һаман да «әти нәстә әйтер?» дигән кебек, сораулы һәм сынаулы караш белән әтисенә карап-карап ала иде,— яңа чалбар-тужуркадан кырда йоклап буламыни, мин бит кырда йоклый-йоклый кайттым.

— И дөрес эшләгәнсең калдырып, молодец,— беренче сүзе шушы булды Сәфәргалинең. Ләкин бу репликаның чын мәгънәсенә ул арада гына, әлбәттә, берсе дә төшенмәде: «алар тектергәнне калдырганы» өченме бу мактау, әллә бүредән-мазардан курыкмыйча «кырда йоклый-йоклый кайтканы» өченме? Әйе, хәзергә монда иң аек калган бердәнбер ир кеше — Сәфәргали иде.

— Килде-китте сорауларыгыз белән башын катырмагыз юл кайткан кешенең, — дип арага керде аннары Сәфәргали һәм шушында аның

«әйләнеп кайткан» качкын малайга бөтен мөнәсәбәте тоташы белән ачылып киткәндәй булды,— иртәгә дә көн бар, сорашырга өлгерерсез.

Аннары ул кече якта әле һаман самавар белән маташа торган әнисенә борылды.

— Нигә кирәк малай кешегә синең чәең, әни? Алып чык баздан салкын катык. Тешкә йомшаграк булсын дисәң, җәлләмичә генә сөт өсте сал. Ашасын да ятсын. Күрмисезмени, кеше арып кайткан, йоклыйсы килә торгандыр.

Болай да аптырабрак калган малайны берьюлы сораулар белән күмүдән, артык йөдәтүдән араларга тырышып әйтелгән бу сүзләр шулай да Тәлгатьне беркадәр сискәндергән иде булса кирәк, әтисе тәмәке тартырга чыгып киткән арада, ул әнисенә елыша төшебрәк сорады:

— Әллә әти ачуланды инде минем кайтканга? Минем болай карак малай кебек төнлә кайтып кергәнгә?

Мондый шик-шөбһәне, әлбәттә, минуты-секунды белән таратып ташларга иде дә бит, ләкин югалган улы белән кавышкан мондый дулкынландыргыч минутларда кирәкле сүзләрне генә кайдан табып бетермәк кирәк? Зәйтүнәдә хәзергә һушын җыеп бетерә алмау бар, сөенечле күз яше бар, тора торгач килеп малаен кочып алу бар һәм, ире ясаган кисәтүне онытып, бер-бер артлы телдән ычкына торган кирәкле-кирәксез сораулар бар.

— Ничек торалар соң, бабаңнарны әйтәм? Бай кешеләр, әйтәсе дә юк, шәп торалардыр инде?

Уйлап түгел, уйнап та әйтмәс иде берәү булса — пычагыма кирәкме Зәйтүнәгә «алар»ның ничек торулары. Шатлыктан үтә нык таркалган иде шул бичара ана, авызыннан ни ычкынганны абайламыйчарак калды. Ә бу сорау Тәлгатькә бер дә ошамады.

— Гел сугышып-талашып торалар, бер дә ничек тормыйлар,— дип, беркадәр кабалана төшеп, ачыктан-ачык ярып салды малай.— Рифгать абый: «Кибетне ябыйк, сату итүне туктатыйк», ди. Бабай: «Туктатмыйбыз», ди. Аннары Рифгать абый әйтә бабайга: «Ахмак син, ыштаныңны төшереп, эссе табага утыртканнан соң гына акылыңа килерсең», ди. Ә бер көнне, беләсеңме, нәстә булды? Рифгать абый белән бабай сугыштылар. Рифгать абый, бабай сүзенә каршы килеп, тегермәнне саткан. Бабай тегермән саткан акчаны яшереп куйган. Шул акчаны таптырып, Рифгать абый бабайның якасыннан борып алды, буа башлады, бабайның авызыннан-борыныннан кан килде. Аннары нишләгәннәрдер, «күзеңне терәп, сүз буры булып торма!» дип мине куып чыгардылар. Чынлап та, ник кирәктер җитмешкә җиткән ул бабайга тегермән?

Салкын катык белән генә чикләнеп калмыйча, әби чәйне дә өлгерткән иде дә, эчүче генә булмады. Кайнаган самавар әрәм сүнмәсен дип, почмак сәкегә кечкенә генә табын әзерләп, берүзе шапыр-шопыр чәй чөмереп утырды әби. Бу яктагылар мондагы хәлләр турында анысынмонысын малайга җиткергән булдылар, Гаптеләхәт тә телгә алынды, Маратның яңа һөнәрләре белән дә мактандылар. Эшләр ходка киткән монда Тәлгать юк чагында: Маратка әтисе Теләче базарыннан кызыл, яшел буяулар белән буяп ясалган ике көпчәкле арба сатып алып кайтып биргән. Чын булса әгәр, тагы бер һөнәре арткан Маратның, әбисе намаз укыганда ишекне ачык калдырып чыгып китә икән дә, өйгә тавыклар тула һәм әби сукрана-сукрана намазын бозарга, тавыклар куып иза чигәргә мәҗбүр була, имеш.

Шулай тату гына килде-китте сүзләр сөйләшеп, инде йокларга ятарга дип кенә торганда, Тәлгать әнисен бер читкә таба тартып китерде. Малайларга хас булмаганча, җитди иде ул бу минутта. Кисәктән генә пышылдады:

— Түлке ни, әни... теге як бабайлар турында миннән берни дә сорашма бүтән, җәме?

Бөтен кыланышыннан, «теге як» турында һич нәрсә әйтәсе килмичә генә сөйләнүеннән күреп тора: малайны ошатмаганнармы, малай үзе аларны ошатмаганмы, ничек кенә булмасын, бер факт ачык: борчаклары пешмәгән, көтмәгәндә-уйламаганда малайның буталып килеп чыгуын бигрәк тә яшь хуҗа Рифгать өнәп бетермәгән булса кирәк. Әмма кызык хәл: кайтып төшкән кичне үк әнисеннән «теге як» турында сорашмавын үтенеп, кисәтеп туйган Тәлгать — малай кеше малайлыгын итә — торып-торып искәрмәстән генә үзе үк шул турыда сүз кузгаткалап куя иде. Күрәсең, уалып һәм хурланып кайткан күңеленең ачыласы, бушанып каласы килә.

— Әни, син аларда чакта да Сәлмән бабай намазны шулай күп укый иеме? — дип, сәер генә сорап куйды малай әнисе белән ялгыз гына калган бермәлне,— хәзер күрсәң, гел намазлык өстеннән төшми. Үләм дип курка башлаган микән әллә?

— Дөньялыкта начар эшләре күп булгандыр, шуңа күрә куркадыр үлемнән,— Зәйтүнә йомшаграк бүтән сүз таба алмады,— күрәсең, иске җәрәхәтләре ачылып китте бугай. Ә малайның исә «теге як» бабасы турында ул хәтле үк начар әйттерәсе килми, ул аларда торганда гел яклап арага керүче шул бабай булды ич!

— Ә нишләп соң ул мин килгәнне яратты? Алай начар кеше булгач? — Бер сүз чыкканда Тәлгатьнең беләсе килә, ачыклыйсы килә, үз күңелендәгесен генә түгел, әнисе күңелендәгесен дә ачыклыйсы килә иде,— бер көнне Рифгать абый белән минем турыда, ай-яй, талашты. Мин ак өйалдында, чөйгә эленгән киемнәр арасына посып тыңлап тордым, юри тыңлап тордым. Рифгать абый әйтә: «Әнә ул буталып аяк астында йөрүче көчегеңне кая куябыз хәзер? Кызыллар атып үтергән ак әфисәр калдыгын, ди. Болай да астыбызга су йөгерергә торганда», ди. Бабай әйтә: «Ник көчек булсын, минем малаемның малае ул. Гомер-бакый җыйган мал-мөлкәтемне калдырсам да, берни кыра алмассың. Синең кысыр хатыныңнан көтеп файда чыкмады», ди.

Шундук тагы малайлыгы бәреп чыкты:

— «Кысыр» нәстә дигән сүз ул, әни?

Җитди башланган һәм тирәнгә алып китү ихтималы да булган сүз шуның белән очланып та калды диярлек. Уйлап куйды Зәйтүнә күңеленнән: «Малай булгач малай! Нәрсә сорыйсың аңардан?» Шулай да бу сөйләшү аның күңелендә төен калдырды. Башланган икән — башланган, ник күңелдә төен калдырырга? Һәм курт кына сорап куйды:

— Бабаңны алай яраткач, ник кайттың соң? Ник бөтенләйгә аларда гына торып калмадың?

— Әйе, калдым ди аларда. Бабай мине сатучы итмәкче, сәүдәгәр булырсың, ди. Ә минем сәүдәгәр буласым килми. Минем прахут йөртәсем килә.

Болай ачыктан-ачык сөйләшүләр, әлбәттә, гел кузгалып тормады, хәтта бүтән бер дә кузгалмады диярлек. «Бу әти», «теге әти» кебек сәер буташтырулар да бүтән кабатланмады, аңлы рәвештә сеңдереп үк бетермәсә дә, бер малайның ике әтисе булмаганлыгын, булырга тиеш түгеллеген малай инде төшенгән, әллә нидә бер иптәш малайлары арасында шундый ишарә-фәлән чыга калганда да, ишетмәмешкә салышып уздыра. Күрше малай Гаптеләхәт белән дә иске исәп-хисаплары онытылган, яңадан дуслашканнар, хәтта элеккегә караганда да ныграк дуслашканнар иде. Тик сирәк-сирәк кенә, анда да әнисе белән икәү генә калганда, һични уйламастан, телдән «теге бабай», «үлгән бабай» кебек сүзләр ычкынгалап куйгалый иде. Андый чакта да кирәкмәгән

сүз әйткәнне шундук абайлап ала, «безнең бу үлгән бабай» дип тизрәк төзәтеп куярга ашыга иде. Хәер, «төзәт» дип әйткән кеше булмый, әнисе моны ишетмәмешкә салышып уздыра. Ник дисәң, «безнең бу бабай» инде үлгән, җир астында ята, кем белсен, бәлки «теге бабай» да, «гомер-бакый җыйган мал-мөлкәтен калдырырга» варисы юклыкка пошына торгач, кайнатасы белән этле-мәчелерәк яшәүче кысыр килененә ачудан «теге дөнья»га киткәндер. Үлгәннәр белән карулашудан кемгә файда!

Шулай да исәннәре искә төшкәләми түгел икән.

— Әни! — дип шактый ук кычкыра төшеп эндәшеп куйды Тәлгать бер көнне. Алар өйдә икәү генә түгел, Марат та шунда аяк арасында чуалып йөри иде. Юк кына нәрсәдән ике малай арасында дау купкан иде булса кирәк, бәлки дуамал кычкырып эндәшүенең сәбәбе дә шуннан булгандыр,— давай, итек чистартучы итеп менә бу «француз Маратын» калдырыйк.

Аптырап калды Зәйтүнә Тәлгатьнең бу сүзләреннән. Кайдан чыккан сүз булды бу «итек чистартучы?» Ләкин Тәлгатьнең аңлатып торасы килмәде, кирәксез тапты, әнине тагын үпкәләтермен дип шүрләде — көн үткән, су аккан саен аңарга акыл күбрәк керә бара иде. Хәлбуки, бөтенләй үк нигезсез дә түгел иде «итек чистартучы». Кайчандыр, әле «теге якта» чагында Рифгать абыйсы әйтте аңарга бу сүзне. Күралмау, көнчелек һәм читләтү тулган күзләрен челәйтеп әйтте: «Кая ул сиңа, атасын кызыллар атып үтергән буржуй малаена пароход капитаны булырга дип хыяллану. Чыгышын яшереп кергән мулла малайларын да техникумнардан сөреп чыгара торган бервакытта. Син, энекәш, лучше итек чистартырга үрән. Казанга барырсың да, чатта камунисларның итекләрен чистартып утырырсың», диде. Тәлгатьнең бик тә җене чыккан иде бу сүзләргә, хәзергә хәтле оныта алмавы да бәлки, шуннандыр.

Ә болай бөтенесе үз урынында хәзер. Малайлар белән ике ара төзәлде. «Бүре баласы» дип үртәүләр бетте, Кама аръягыннан, бай бабаларыннан, уздырса бер кыш уздырып, үзенең иске сәләмәләренә төренеп әйләнеп кайткач, бөтенләй үз кеше хәзер — тегеләр сәләмә, Тәлгать сәләмә, кем кемне үртәргә тиеш икәнлекне дә белгән юк. Өй эшләренә дә карышмыйча йөри, дәреслекләрен дә караштыргалый — уен түгел, киләсе уку елында Теләчегә — рус школасына керәсе. Бүлешәсе уртак маллары юкта энесе Марат белән дә дус, аны үзе ише өлкәнрәк малайлар арасына алып йөри, әти-әни алдында әйтергә ярамый торган «сәкенле» сүзләргә өйрәтә.

Хәзергә тик бер нәрсәдән генә риза түгел Тәлгать: әнисе бүтән малайлар белән бергә төнгелеккә ат сакларга җибәрми. Дәлилләре ни диген, хурланып үләрсең: янәсе, болай да сөякләре генә шылтырап торган чандыр нәмәрсә — төнге салкынча һавада салкын тидерүе бар. Имештер, Тәлгатькә, «Закамадан» япа-ялгызы кырда куна-куна кайткан Тәлгатькә салкын тиде ди. Тимәгән кайда!

Әни әйткәннәрнең бөтенесенә дә колак сала китсәң! Әле ярый, әтисе Сәфәргали бар, тикмәгә генә аклар белән сугышып йөргән «камисар» түгел. Өзеп әйтте сүзен эти кеше:

— Барсын. Җирдә уйнап үссен. Бүтән малайларга тимәгән салкын нишләп ул минем Тәлгатьне генә эзләп йөрергә тиеш ди?

Ай, күңеле булды да соң Тәлгатьнең бу сүзләргә! Беренче мәртәбә төнгелеккә ат сакларга ышанып җибәрә. Кем? Әти! Шул үзе әйтте бит әнә нинди сүзләр! Малай өчен бу шундый бер изге минут булды ки, нәкъ шул минутта бугай аның күңеленнән бөтен шик-шөбһәләр коелды, башка бернинди эти дә юк, тик Сәфәргали эти генә торып калды.

Болары гына җитмәсә, бабасыннан калган иске тире тунны кигән, аякка зур киез итекләр элгән Тәлгать, бу хәлендә атка ничек атланырга белмичә аптырабрак торганда, атка менгезүче дә шул ник сүзле эти булды. Өстәп, менә тагы нәрсә диде, чынлап әйтте бусын да:

— Капитан мостигына үзең менәрсең, әйдә, хәзергә чак кына булышыйм.

Малай бөтенләй очынып китте соңыннан әйтелгән бу сүзләрдән — димәк, капитан итәм дигән сүзе шаярып кына әйтелгән сүз түгел икән! Исендә икән, исендә икән!

— Сугып та җибәр, әти, атка.— Әлеге шул очыну аркасында ычкынды малайдан бу кыю сүз.

Чынлыкта исә аларның бу аты тиле-тинтәк «алпут калдыгы» түгел, ачык капкадан ничек чыгасын, ничек кайтып керәсен белә торган, тиздән колхозга керәчәк акыллы мал иде, ыргылып чабып китәргә дә ашыкмады, арт санына сугып озатып калганны да көтмәде.

## Эпилог

Җырлар чыга, җырлана, әкренләп онытыла. Ерактан утлар җемелдәп күренә, килә-килә ныграк җемелди, нурлана төшә, узып китәсең, башта тоныгая, кичерәйгәннән-кичерәя бара, аннары бөтенләй күренми башлый — әллә утлар сүнә, әллә син үзең сүнәсең?

Кеше гомере дә шулай. Гомер юлын башлаганда алда бик күп утлар күрә кеше... Җемелдәшәләр, чакыралар, син алга омтылган саен алар күңелгә нур булып иңәләр, килеп җитәсең, күрәсең, ерактан синең хыялыңны кытыклап, уйнаклап елтыраган ут — буш амбарның почмагында, җилдә чайкалучы тоныкъ кына ялгыз фонарь булып чыга. Алданганлыгыңны үзең дә сизәсең, күңелне бер генә мизгелгә үкенеч хисе тырнап уза, ләкин туктап калмак юк, артка әйләнеп карамак юк, артка кире чабып китмәк шулай ук юк. Чөнки, тулаем алганда, тормыш үзе алга бара, тарих алга бара, алда тагын да яктырак булып икенче утлар кабыналар...

Бөтен кешеләр өчен дә тоташ шулай — язмыш бер генә төрле дип расларга ашыкмыйк, кешеләр күп — язмышлар күп. Кешеләр төрле — язмышлар да төрле. Әнә, Кама аръягындагы Тирәкле авылының атаклы бае — заманасында ажгырып яшәгән Сәлмән сәүдәгәр, тегермән хуҗасы, ике-өч җирдә кибет тотучы, өч малай атасы, бер үзенә ике хатын тоткан җегәрле ир бер урында туктатып тормакчы булды тормышны, «минемчә түгел!» дип тарихка кизәнеп тә карамакчы иде, чөеп атты үзен тарих. Ун еллар, егерме еллар узганнан соң, имеш-мимеш хәбәрләр колакка чалынып калгалады аның турында. Сәүдә-«эш»ен туктатырга теләмичә, үз малае, өчтән берәү калган Рифгате белән кискен бәрелешкә кергәч, ярсыган малае буып үтергән, дип сөйлиләр берәүләр. Икенче берәүләрдән, әлбәттә, шул як кешеләреннән, икенче сүзләр дә чыга: мал-мөлкәтне үзенә генә калдырырга теләгән комсыз яшь хатыны мунча мичен тавык тизәге белән кушып яккан да шул исле мунчада исертеп үтергән, имеш, дип тә җибәрәләр. Кайсы дөрес, кем ничек ялганлыйдыр, әмма чын дөресе шул: алып аткан тарих Сәлмән дигән кешене. Әтисенә караганда да комсызрак малае Рифгать, замананың кай юнәлешкә таба борылыш алганын алданрак сиземләүче астыртын-хәйләкәр Рифгать, бөтен «эш»не үз вакытында червонецларга әйләндереп, ялган паспорт белән чит илгә качмак булып түшендә шуышып барганда, чик сакчылары тарафыннан тотылып, тиешле хөкемен тапкан, диләр.

Ә менә көчләренә күрә гадел рәвештә тарихка хезмәт иткән Сәфәргали белән Зәйтүнә әле дә булса исәннәр, яшиләр, балалар үстерәләр. Яшәргәннән-яшәрә бармасалар да, картаерга да ашыкмыйлар. Дөрес, Мәтәскәдә түгел алар хәзер, урыннары кояш астында булгач, кайда булса да барыбер түгелмени!

Ә аларның үз вакытында «теге якка» да юргалаган, «бу якка» да сыймаска маташып караган чуар йөрәкле уллары Тәлгать, ниһаять, утырды — акылга да, пароходка да утырды. Пассажир булып кына түгел, капитан булып. Монда алар егетлекне әтисе Сәфәргали белән уртак бүлештеләр. Сәфәргали, биргән вәгъдәсендә торып, малайны иң элек әзерләде, нык булырга, алда җемелдәп янган хыял утына тайпылышсыз барырга өйрәтте. Артыннан йөреп, Нижний-Новгородтагы судоводительское училищега урнаштырды, ә калган ягында малай үзе сынатмады. Хәзер аның урыны — пароходта, капитан рубкасында.

Төннәрне көннәр, буыннарны буыннар алыштыра. Сулар ага, ярларыннан ташып чыга, яңадан ярларына кайта. Кама елгасында башка күп төрле су кәрваннары арасында, сигнал утларын балкытып, яшь капитан Тәлгать Корбангалиев йөрткән «Ян Юдин» пароходы да йөзә. Төнге вахтада, рубкада ялгыз гына калган чакларда, алдагы утлардан, маяклардан күзен алмастан, вакыт-вакыт узганнарга кайтып китә капитан. Әнә шунда, Каманың сул як ярында, элекке Спасс якларыннан башлана алар нәселенең юлы. Әнисе дә, әнисенең «тәти апасы» да, Сәлмән бабасы да шул яктан. Берәүләре тапталып кала, икенчеләре, яңа утларга карап, юлны дәвам итәләр — тарих шулай, тормыш шулай, язмыш шулай.

«Тапталып» калганнарга сәлам бирдең ни дә, бирмәдең ни... тик шулай да бу тирәдәге ярлар буеннан узганда яшь капитанның кулы, механик рәвештә диярлек, гудок тарткычына сузыла һәм, төнге тынлыкны ярып, болыннар аша моңсу гудок — узганнарга, «тапталып калганнарга» сәлам яңгырый. Акылы белән яхшы белә капитан, узганнар моны инде ишетмиләр, ләкин барыбер сәлам бирмичә уза алмый. Чөнки күпмедер дәрәҗәдә бу аның да узганы, ыргытып булмый аны күңелдән, булмый.

**1973—1975 еллар.**

Гали Халит

# ТУКАЙ. ЛИРИК ГЕРОЙ. «ҖАН ДИАЛЕКТИКАСЫ»

## I

XX йөз башындагы татар поэзиясен күзәткәндә, барыннан да элек, лириканың, лирик жанрның киң колач алуын күрербез. Лирик поэзия гадәттә милли һәм иҗтимагый күтәрелеш чорларында көчәя, диләр. Чыннан да, беренче рус революциясеннән башлап, татар әдәбиятында лириканың үсеше һәм яңаруы шәхес һәм шагыйрьнең эчке дөньясы активлашуны, аларның уй-кичерешләре киңәюен, баюын, чынбарлыкка мөнәсәбәтнең кискенләшүен күрсәтте.

Лирик поэзиянең үсеше өчен иң кирәкле беренче шарт — шәхеснең үз-үзен ачуы һәм үзенең җәмгыятьтәге ролен аңлавы татар лирикасының да яңа баскычка күтәрелүенә төп этәргеч булды.

XX йөз башындагы татар әдәбияты үзенә гаять катлаулы һәм каршылыклы иҗтимагый-политик шартларда юл ярды. Шуңа күрә аның эчтәлегендә искелектән яңага күчү өчен барган көрәш драматизмы һәм хәтта трагизмы киеренке төс алды. Ә бу көрәштә туган идеаллар, татар җәмгыятендәге кадимчелеккә, томаналыкка һәм караңгылыкка каршы баш күтәргән милли мәгърифәтчелек кысаларында гына калмыйча, самодержавие строен җимерү, демократик җәмгыять төзү һәм, ниһаять, социализмга юл ачу кебек максатларны да алга сөрде. Шуңа күрә татар җәмгыятендәге алдынгы шәхес өлеге идеалларны, максатларны алга куйган тарихи процесста үзенә юл эзләү һәм идеал табу газабын кичерми кала алмый иде. Югары идеаллар өчен көрәшкә чыккан алдынгы шәхес, үз милли кысаларында гына йомылып калмыйча, гомум Россия күләмендәге тарихи шартларга килеп керде. Һәм бу табигый, зарури бер күренеш иде. Татар җәмгыятендәге алдынгы шәхеснең тормышны аңлау офыгы һич булмаганча киңәеп китте. Татар җәмгыяте һәм культурасы үсешен зур тарихи перспектива яктылыгында аңларга теләгән әдәби геройның идеалы да әнә шул шәхес белән бәйләнгән иде. Тик шундый геройны күз алдында тотып кына әдәбиятның тормыш, тарих һәм халык белән бәйләнеше турында сөйләргә мөмкин.

Халык һәм шәхес проблемасы XX гасыр башында күпләгән татар язучыларының игътибарын биләде. «Татар әдәбиятында «шәхес тойгысы» рус әдәбиятындагыча кискен төстә гәүдәләнмәде,— дип яза Йолдыз Нигъмәтуллина. — һәм аның эчтәлеге дә берникадәр башкарак иде: бу тойгы күбрәк шәхес һәм милләт, шәхес һәм халык бердәмлеге тойгысы рәвешендә күренде» [1]. Һичшиксез, бу чорда инде «шәхес тойгысы»ның мөстәкыйльлеген милләткә һәм халыкка мөнәсәбәттән башка күз алдына ки-

[1] Ю. Г. Нигматуллина. Национальное своеобразие эстетического идеала. Рус телендә. Казан университеты нәшрияты, 1970 ел. 55 бит.

теру кыен булыр иде. Боларның кайсына аеруча игътибар итүгә карап, язучыларның гомумән иҗат позицияләре ничек булуын да билгеләргә мөмкин. Әгәр дә шәхес, үз ирекен, үз абруен гына идеал итеп, үзенең халык белән бәйләнешен аңламый икән, бу инде аның гадәттә индивидуализм позициясендә торуын яки халык азатлыгы идеясен аңлау дәрәҗәсенә күтәрелеп җитмәвен күрсәтә. Әгәр дә шәхес үз язмышының халык язмышы белән бәйләнешен аңласа, бу инде аның идея позициясендә дә халыкчанлыкның көчле булуы турында сөйли.

Татар поэзиясендәге лирик геройның яңаруы турында фикер йөрткәндә, ике гасыр арасындагы рус әдәбиятында кеше өчен көрәшнең аеруча кызып китүе кебек фактны истә тотмыйча булмый. Бигрәк тә М. Горькийның декадент язучылар иҗатында кешене түбәнсетеп, тарих һәм язмыш каршында көчсез итеп күрсәтүгә каршы көрәше һәм шул көрәш рухы белән тулы әсәрләре татар язучыларының да игътибарын җәлеп итте.

Мәгълүм ки, Беренче рус революциясеннән соң башланган реакция чорында һәртөрле декадентлар кешене мәсхәрә итүнең иң тупас үрнәкләрен бирделәр. Әмма алар М. Горькийның һәм фикердәшләренең кешене югары күтәреп, кыю итеп яклаган тавышын баса алмадылар. Әйткәнебезчә, ул тавыш татар әдәбиятында да яңгыраш алды. Бу фикерне раслау өчен, Шәһит Әхмәдиевнең «Кеше» (1913) дигән нәсереннән бер өзек китерү дә җитәр кебек: «Кеше... Аны биклиләр, бөтен кул-аягын чылбырлыйлар. Кылычлар, туплар, уклар аны урап алалар. Ул һәммәсен өзә, сындыра, вата, җимерә, барысын да изеп ташлый, тагын үзе генә кала. Алга китә ул. Аның теләге бар. Аңа һичбер нәрсә каршылык кыла алмый (...). Ул алга атлый, югары менә, күтәрелә, яңа нәрсәләр таба... Ул — кеше, аңа голувият (югары идеяләр) кирәк. Ул бер кешедән курыкмый, үзенең чиксез куәтенә ышана: көч ул!...»

Бу әсәрдә дөнья язмышын үз кулында тоткан һәм гайрәте белән барлык явыз көчләрне җиңә, үзенә буйсындыра торган кешенең шигъри, романтик образы сурәтләнә.

Беренче рус революциясе нәтиҗәсендә киң колач алган лирик поэзия, мәгърифәтчелек настроениеләре белән тагын да тирәнрәк сугарылып, азатлык идеяләрен ачыктан-ачык җырлау юлына басты. Әмма шулай да әле Беренче рус революциясе вакытында ук инде безнең поэзиянең лирик герое үз индивидуаль йөзен күрсәтеп өлгерде дип булмый. Поэзия стилендә дидактик, риторик һәм публицистик пафос өстенлек итте, ерак гасырлардан килә торган традицион элементлар, әдәби чаралар бик тотрыклы булды. Менә шул традицион элементлар теге я бу шагыйрь поэзиясендәге индивидуаль лирик башлангычны шактый тоткарлап торды. Әмма революциянең татар әдәбиятында азатлык идеяләрен сүнмәслек итеп дөрләтеп җибәрүе, әдәбиятны иҗтимагый изүгә каршы актив көрәш мәйданына чыгаруы безнең лириканың һәм лирик геройның да тирәннән үзгәрешенә, яңаруына җирлек бирде. Ниһаять, татар поэзиясе дә тарих ташкыннарына килеп керде, чын мәгънәсендә кеше һәм аның җаны, рухы өчен барган көрәшкә кушылып китте. Лирик герой тарих сәхнәсенә күтәрелде,- чорның зур сынаулары аша узарга тиеш булды. Бу сынаулар аның рухында тирән эз калдырды.

Бигрәк тә Беренче рус революциясеннән соң татар поэзиясендәге лирик герой катлаулы һәм каршылыклы төс алды. Аның явыз чынбарлыкка нәфрәт һәм ләгънәт белән тулы хисләре реалистик һәм романтик рухта гәүдәләнеп, ул хисләр бер-берсеннән ераклашып та, бер-берсе белән бик якынлашып та һәм хәтта кушылып та мәйданга чыкты. Монда инде «караңгылык патшалыгында» калган кеше һәм халык язмышына поэтик шәхеснең мөнәсәбәте төп критерий булып торды. Лирик герой, гади кеше язмышына актив теләктәшлек итеп, шәхесне изә торган чынбарлыкка үзенең мөнәсәбәтен белдергәндә, аның реалистик, кырыс кыяфәте ачыграк күренде. Г. Тукай һәм М. Гафури кебек шагыйрьләрнең лирик героенда бу бик тулы гәүдәләнде. Инде лирик герой шәхеснең үз абруен һәм тарихи процесска субъектив мөнәсәбәтен алгарак этәрсә, ул күбесенчә романтик кыяфәт ала иде. Без моның конкрет мисалларын С. Рәмиев һәм Дәрдмәнд поэзиясеннән табарбыз. Болардан башка тагын да реалистик һәм романтик тенденцияләрнең бер үк лирик геройда чагылышын, мәсәлән, Ш. Бабич һәм С. Сүнчәләй иҗатларында очратырбыз. Бу очракта бигрәк тә Тукай һәм С. Рәмиев традицияләренең йогынтысы көчле булганлыгы сизелә.

XX йөз башы татар поэзиясенең үзәген, һичшиксез, Г. Тукай лирик герое били. «Хөр кеше алдында җирләр һәм дә күкләр калтырар!» — диде шагыйрь («Гөнаһ», 1911). Ирек сөйгән кешенең кадерен һәм дәрәҗәсен югары күтәргән мондый сүзләрдән М. Горькийның «Кеше ул горур яңгырый!» дигән атаклы девизына аваздашлык ишетелә. Шундый хөр кешенең лирик образын Г. Тукай революционер Хөсәен Ямашев йөзендә күрде:

**Көч белән бергә гүзәллекне җыйган диңгез кеби,**
**Ул иде өстен вә кул җитмәс кеше, йолдыз кеби.**

**Әүлияларның барын бер-бер китерсәм каршыма,**
**Күрмәмен дип уйлыймын бер якты йөз ул йөз кеби.**

Әйе, бу — үзенең туган иле һәм халкы белән нык бәйләнештә яшәгән, аларның бәхете өчен көрәшкә күтәрелгән олы кешенең, заман героеның лирик образы иде. Ул — романтик рухта сурәтләнгән идеал герой. Әмма мондагы романтик ореол нурлары герой белән чынбарлык һәм халык арасындагы бәйләнешны капламый, тәссезләндерми, ә, киресенчә, аның чынбарлык һәм халык белән бәйләнешыннан туган матурлыгына, шундый матурлыкка ия булган рухи көченә һәм кешелегенә мәхәббәтне чагылдыра.

Шәхес азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен көрәш идеалының һәр нәрсәдән югары, илаһи икәнлеген өзлексез җырлап, шагыйрь бу идеалны хәтта алла белән тиңләштерүдән дә тартынмады:

**Күз карашыңда синең дөнья күренде мәңге төн.**
**Киттең эзләп син аны яктыртмага идеал утын...**

**Ялтырау күрдеңме артта! Ут түгел ул, алтын ул;**
**Юк мөкатдәс нур да анда, юк җылылык — салкын ул.**

**Артка бакма, даһием, идеал һаман да алда ул;**
**Алга барганнарга тик табла табылса: алла ул.**

**(«Даһига».)**

Әйткәнебезчә, татар әдәбиятында поэтик шәхеснең уянуы, лирик геройның формалашуы зур авырлык һәм каршылыклар аша барды. Демократик революциянең азатлык идеяләре белән рухланган шәхес реакция елларының мәрхәмәтсез изүеннән, тупаслыгыннан газапланып, хәтта элекке якты идеалларына ышанычын югалтып һәм киләчәкнең нидән гыйбарәт икәнлеген белмичә, абына-сөртенә барырга мәҗбүр иде. Г. Тукайның 1910 елда язылган «Яшьләр» шигырендәге:

**Бара милләт зәгыйфь, абныр-абынмас,**
**Сүнә яшьләрдә ут кабныр-кабынмас.**

**Кичә якты вә милли бер күңелдән**
**Бүген тычкан утыдай нур табылмас...**

**Ышанабыз халык көчсезлегенә,**
**Бабайлар шөһрәтен сагныр-сагынмас,**

— кебек юлларда «көмеш, алтын сәнамнарга табынган» яшьләрне хөкем итү генә түгел, ә бөтен бер буынның драматик портреты да тасвирланган иде.

Безнең яңа поэзиядә иҗтимагый тормыш һәм тарих чоңгылларыннан, сикәлтәләреннән үткән, идеологик кризисларны һәм кискен үзгәрешләрне кичергән шәхеснең киеренке рухи дөньясы чагылып калды. Бер шагыйрьдә азрак, ә икенчесендә күбрәк булып һәм төрле дәрәҗәдәге әдәби осталык белән шәхес психологиясенең төрле төсмерләре, сыйфатлары, тембрлары сурәтләнде.

Әдипләрнең, шагыйрьләрнең дөньяны сәнгатьчә танып-белү колачлары, диапазоннары төрле икәнлеге мәгълүм. Аларның бер өлеше кешенең эчке һәм тышкы дөнья-

сын киң итеп, төрле яклап сурәтләсә, икенчеләре исә аның аерым якларын, нокталарын, билгеле тема һәм мотивларны күрсәтү осталыгы белән танылалар. Шуның шикелле үк, XX йөз башы татар поэзиясендә дә талант колачлары, дөньяны шигъри күзаллау мөмкинлекләре, сәләтләре төрлечә булган шагыйрьләр байтак күренде. Шулар арасыннан, әйтик, Г. Тукай, Дәрдмәнд һәм С. Рәмиев кебек, үз чорында ук инде татар поэзиясенең бик үзенчәлекле талантлары булып саналган шагыйрьләр иҗатын чагыштырып карарга мөмкин.

Г. Тукай белән чагыштырганда, Дәрдмәнд һәм С. Рәмиевнең лирик геройлары идея-психологик яктан артык катлаулы түгел. Алар үзләренең характерлы берничә индивидуаль сызыклары белән генә күренәләр. Мәсәлән, Дәрдмәнднең тарихи процесска мөнәсәбәтендәге фатализм, язмыш фәлсәфәсе аның лирикасындагы төп трагик тонны, шагыйрьнең кешегә карашындагы төп лейтмотивны да билгели.

**Зәгыйфь кырмыскамын мин юлда яткан,**
**Түгел бал корты мин чагып елаткан.**

— дигән юлларда, әлбәттә, тормыш һәм тарих стихиясе алдында кешенең бик кызганыч бер хәлдә икәнлеген күрсәтү ярылып ята. Бу инде — мескен, мелодраматик герой.

С. Рәмиев исә:

**«Мин!» димен, «мин» дидисәм,**
**Миңа бер зур көч керә:**
**Аллалар, шаһлар, кануннар**
**Булалар бер чүп кенә,**

— дип, кешенең абсолют, чикләнмәгән ирекен, ихтыярын даулады һәм, шул позициядән торып, явыз чынбарлыкка каршы шәхес бунтын, аның ләгънәт һәм нәфрәтен белдерүгә басым ясады. «С. Рәмиевнең лирик герое — шашкан, ярсулы, барлык кануннарны ватып-кырып үтәргә омтылучы демоник шәхес» [2]. Ул герой явыз чынбарлык белән котылгысыз конфликтка кергән трагик, әмма шул ук вакытта үзенең шәхси горурлыгы, азатлыгы өчен көрәшкә чыккан актив романтик геройларның берсе иде.

Г. Тукай поэзиясендәге лирик геройга килсәк, без аның идея-психологик дөньясы шактый киң һәм катлаулы, тарихка, чынбарлыкка һәм халыкка мөнәсәбәте объектив булуын күрербез. Бу лирик герой кешенең һәм шәхеснең җәмгыять, тарих һәм халык каршындагы җаваплылыгын драматик тирәнлеге, зурлыгы белән хис итәргә, аңларга омтылды.

**Кузгатмакчы булсаң халык күңелләрен,**
**Тибрәтмәкче булсаң иң нечкә кылларын,**
**Көйләү тиеш, әлбәт, ачы хәсрәт көен,**
**Кирәк түгел мәгънәсе юк көлке, уен,**

**(«Сәрләүхәсез».)**

— кебек юлларда гына да Г. Тукай героеның кыйбласы шактый ачык билгеләнгән дияргә мөмкин. Әсәрнең мәгънәсе шигъри шәхес халык кичергән тарихи авырлыктан, газаптан һич тә читтә торырга тиеш түгел диюдән гыйбарәт. Шушы яктан ул Дәрдмәнд һәм С. Рәмиев поэзиясендәге субъективизмны кире какты.

Г. Тукай лирик героенда халык азатлык хәрәкәтләре белән нык бәйләнгән алдынгы яшь буынның интеллектуаль һәм мораль йөзе, гражданлык характеры ничек формалашуы бик ачык гәүдәләнде. Аның герое — үзенең якты теләк-максатларына ирешү өчен көрәш юлында корбан булган яшь кешенең трагик образы ул. Шушы ягы белән ул реалистик та, романтик та. Тулаем алганда, бу сыйфатлар Г. Тукай героеның тирән психологик каршылыклар аша заман чынбарлыгы белән аеруча катлаулы һәм каршылыклы мөнәсәбәткә керүе турында сөйли.

Романтизмга һәм реализмга кадәрге лирикада шагыйрь аерым шәхес булып түгел, иң әүвәл акыл, әхлак кагыйдәләренә һәм жанр канун-нормаларына буйсындырылган

---

[2] И. Нуруллин. XX йөз башы татар әдәбияты. Казан университеты нәшрияты, 1966 ел, 64 бит.

фикер системасын яклаучы буларак күренә. Лирик субъектның шәхеснең роле көчәю лирикадагы индивидуальлекне тагын да югарырак дәрәҗәгә күтәрә. Лирикага шәхеснең үз тормыш тәҗрибәсе, үз уй-кичерешләренең стихиясе ыргылып керә. Поэзиядә бу стихия никадәр көчәйсә, лирик геройның роле дә шул чаклы тулырак ачыла. Романтик һәм реалистик лирикада кеше образы алдан хәзерләп куелган нормалардан чыгып ясалмый, ә кешенең үз образына тапкыр формада иҗат ителә. Кеше лирикадагы үз образының чыганагы һәм нормасы булып китә.

Лирикада аерым тойгы, кичереш кенә түгел, ә кеше индивидуальлегенең бөтенләнгән чагылдырган эчке дөнья гәүдәләнә. Бу инде психологик бөтенлек — характер дигән сүз. А. Пушкин яки Г. Тукай лирикасы һәм лирик герое турында сөйлибез икән, без иң элек бу шагыйрьләр индивидуальлегенең бөтенлеген, ягъни характерын күз алдына бастырырга тиешбез. Әмма ул бөтенлекне шагыйрьнең үз тормыш тәҗрибәсе белән заман чынбарлыгы арасындагы мөнәсәбәттән башка аңлау мөмкин түгел. Шагыйрьнең үз шәхесен үз заманы белән никадәр тыгыз, нык һәм тулы итеп бәйли алуы реалистик лирикада кеше индивидуальлегенең бөтенлеген, лирик характерның мөстәкыйльлеген, оригинальлеген һәм типиклыгын билгели торган төп критерий булып тора.

Г. Тукай лирикасында да шагыйрьнең үз эчке дөньясына һәм шәхси тормышына караган, ягъни субъектив мотив һәм темаларны күпләп табарга мөмкин. Хәтта алар безнең башка шагыйрьләр иҗатындагыга караганда да күбрәктер әле. Әмма моңа карап, Г. Тукай лирикасында субъективизм өстенлек итте дияргә һичбер нигез юк. Үзенең шәхси, субъектив тормыш тәҗрибәсе җирлегендә лирик геройны заманга лаек биеклеккә күтәреп, аны тарихи объективлык белән типиклаштырган шагыйрьләр күп түгел. Рус поэзиясендә А. Пушкин, бездә исә Г. Тукай — үз чорының алдынгы идеалларын һәм замандашларының уй-кичерешләрен үз тормыш тәҗрибәсе, үз шәхси образы җирлегендә чагылдырган талантларның иң күренеклеләре. Г. Тукай үзен һәм замандашларын борчыган, дулкынландырган, шатландырган, өметләндергән уй-кичерешләрнең иң әһәмиятлеләрен поэзия хәзинәсенә әверелдерде. Нәкъ шушы момент аның лирикасындагы поэтик характерны да билгели. Бу характер — үзенең нигезе, асыл сыйфаты, тормышчан бөтенлеге һәм автобиографик төгәллеге белән реалистик. Аның бөтенлеге, бер яктан, лирик геройның шагыйрь шәхесенә тәңгәллегендә, якынлыгында, ягъни автобиографик чыганаклары конкрет булуда һәм, икенче яктан, шул чор кешесенә хас тарихи каршылыклары белән гәүдәләнүендә, ягъни югары идеаллар, шәхси теләкләр һәм тарихи чынбарлык арасындагы мөнәсәбәт-бәйләнешләрнең тормышчанлыгында.

Шигъри фикерләүнең башка төрләре шикелле үк, лирик фикер дә яңа гасырда синтетик форма ала бара. Әмма бу форманы ике арада торган ниндидер билгесез күренеш итеп түгел, ә ирекле һәм чикләнмәгән күренеш итеп аңларга кирәк. Шуңа күрә ул яңа бер форма да, яңа бер сәнгатьчә күренеш тә иде. Монда инде элекке чорлардагы поэзиягә хас һәртөрле канун һәм нормалар кысасыннан ирекле булырга омтылыш алга чыкты. Бу иреклелек бигрәк тә реалистик әдәбиятның кеше психологиясен, «җан диалектикасы»н ачуыннан аерылгысыз иде. «Җан диалектикасы»н ачу — кеше кичерешләре белән сәнгатьчә тасвир аралыгын, ягъни эстетик чикләрне тагын да якынайту һәм моңарчы яшәп килгән әдәби канун һәм нормаларны җимерү дигән сүз дә ул. Бу җимерүнең асыл максаты кеше рухының, аның психологиясенең сәнгатьчә кыйммәтен бөтен нечкәлекләре, катлаулы, яшерен һәм каршылыклы яклары белән сурәтләүдән гыйбарәт.

Г. Тукай лирикасы да рус һәм Европа классик поэзиясе салган шундый олы юлга килеп чыкты; ул кешенең рухи дөньясына үтеп керә алды, ягъни шул дөньяны психологик анализлау җирлегендә индивидуаль кичерешләрнең диалектикасын ачу югарылыгына күтәрелде. Шагыйрь реалистик поэзиянең иң зур казанышына — кешенең рухи дөньясын, аның уй-кичерешләре бердәмлеген, тормышчан төрлелек һәм каршылыклар гармониясен сурәтләү, шәхес белән иҗтимагый тирәлек, чынбарлык арасындагы зарури бәйләнешнең психологик тирәнлеген чагылдыру традициясенә турылыклы булды. Бу инде — әдәбиятта «җан диалектикасы»н ачуның иң беренче әһәмиятле шарты. Шундый шарт булганда гына лирикада уй-кичерешләрне хәрәкәтчел итеп, психологик процесс итеп бирә торган шигъри стиль туарга мөмкин.

## 2

XIX йөз дәвамында тәмам җитлеккән критик реализм методын һәм аның стильләрен психологизмнан башка күз алдына китерү читен. Әлбәттә, психологизм бер критик реализмга гына хас күренеш түгел. Аңа кадәрге иҗат методларында да кешенең эчке дөньясын тасвирлау кире кагылмады. Кеше җанын анализлауда бигрәк тә романтизм кыю адымнар ясады. Ул ирекккә омтылган шәхеснең рухи дөньясындагы эмоциональ киеренкелекне, кичерешләр бәрелешен сурәтләүгә игътибар итте. Романтик психологизмны реализм шулай ук читкә этәрмәде. Ләкин ул, романтик психологизмның кеше характерын ачудагы гомуми, абстракт берьяклылыгын кире кагып, иҗтимагый тирәлек белән тыгыз элемтәдәге кешенең эчке дөньясын бөтен катлаулыгы белән ачуны максат итеп куйды. Моның гаять көчле мисалларын рус классиклары тудырды. Инде татар әдәбиятындагы психологизмга килсәк, безгә берничә үзенчәлекле моментны күздә тотып фикер йөртергә туры киләчәк. Шулардан берсе — Көнчыгыш поэзиясендә чәчәк аткан хирыс[3] психологизмы мәсьәләсе. Аның иң характерлы ягы кешенең башлыча интим-мәхәббәт кичерешләре ташкынын, шуларга бәйле хәсрәт һәм шатлык тойгыларын югары пафос белән нечкәләп сурәтләүдә чагыла. Аеруча Г. Кандалый поэзиясендә кабынып киткән һәм җир кешесенә хас хисләр белән җылытылган бу традицион психологизм, безнең XIX йөз азагындагы мәгърифәтчелек прозасы аша үтеп[4], XX йөз башындагы әдәбиятыбызны да тулаем сугарган стиль факторларыннан берсе булып калды. Бу төр психологизм үзенең асылы белән поэзия чорына[5] карый иде һәм, поэзия белән бергә туганлыктан, ул күбесенчә романтик әдәбиятка хасрак булды. Хирыс психологизмы яңа чорның реалистик прозасындагы психологизмнан үзенең сентименталь һәм ритрик сыйфатлары белән аерылып торды. Моңа мисал итеп, шул чордагы прозабызның иң зур үрнәкләре саналган әсәрләрдән Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» һәм «Безнең көннәр» (беренче редакция) романнарын искә алу да җитәр. Әлеге әсәрләр татар романтик прозасында хирыс психологизмының гәүдәләнеше көчле генә булуын күрсәтәләр. Бу төр психологизм татар язучыларының күпчелегенә тегеяки бу күләмдә характерлы булып, барлык жанрларда да чагылды.

Тулаем алганда, XX йөз башы татар әдәбиятындагы психологизмга эмоциональлек һәм лиризм хас булып, бу сыйфатлар аңарда романтик настроениеләрнең көчле булуыннан килде. Рус әдәбиятындагы психологик стильләр белән чагыштырып караганда аның башлыча И. Тургенев стилендәге психологизмга якын торганлыгы күренә. Рус классикасында психологик анализның ике формасы еш очрый. Аеруча Л. Толстой һәм И. Тургенев иҗатларында урын алган ул формаларның татар язучыларына да мәгълүм булуы турында әйтелде инде[6]. Әмма татар әдәбиятының үсешен бөтен көенчә күз алдына бастырганда, аның рус әдәбиятында зур колач алган әнә шул ике төрле психологик анализга юнәлеш тотуын яки якынаюын йогынты планында гына карау берьяклырак булыр иде. Бу хәл аның бөтен идея-эстетик эчтәлеге нинди юнәлеш алудан килә. Әнә шул эчтәлектә аеруча И. Тургенев лирик психологизмына якынлыкның көчлерәк булуын да татар әдәбияты кичергән тарихи шартларның үзенчәлекле булуы белән генә аңлатырга мөмкин. Бу үзенчәлекнең әһәмиятле бер моменты татар әдәбиятында романтик һәм реалистик башлангычларның бик тыгыз, аерылмас мөнәсәбәтендә, бәйләнешендә булса кирәк. Ә И. Тургенев әнә шул башлангычларның икесен дә үз иҗатында тулы, гармоник чагылдыруы белән аерылып тора. Л. Толстой, И. Тургенев иҗатының төп мотивлары арасында «матурлыкка (хатын-кыз мәхәббәтенә, сәнгатькә) ышаныч»ның беренче булып торуын әйткән. Бу момент, билгеле, романтик тематикада гына түгел, ә геройга мөнәсәбәттә, әсәр структурасында, стильдә чагылган караш, сәнгатьле фикерләү ноктасы. Безнең фикеребезчә, нәкъ шушы поэтик

---

[3] Хирыс сүзенең берничә мәгънәсе бар. Монда аның «көчле дәрт, теләк» мәгънәсе күздә тотыла.

[4] А. Сайганов. Эстетика Фатиха Амирхана и эстетические идеи в татарской реалистической литературе конца XIX — начала XX века. Автореферат доктор. диссертации, рус телендә. Баку, 1972 ел, 32—33 битләр.

[5] Бу хакта тулырак мәгълүмат авторның «Иҗат методы һәм стиль мәсьәләләре» («Казан утлары» журналы. 1975 ел, 3—4 саннар) дигән мәкаләсендә бирелә.

[6] Ю. Г. Нигматуллина. И. С. Тургенев и татарская литература начала XX века. Рус телендә, Казан университеты нәшрияты, 1961 ел, 47 бит.

үзенчәлеге белән И. Тургенев иҗатының татар әдәбиятында барган эстетик процесска аеруча якын булуы аңлашыла. С. Сүнчәләйгә хатларының берсендә Г. Тукай И. Тургенев романнарын поэзия дип атый[7]. Бу — очраклы әйтелгән сүз генә түгел, ә И. Тургенев прозасында туры мәгънәсендәге лирик поэзия рухының көчле булуын тирәннән тоеп әйтелгән хакыйкать.

XX йөз башы татар әдәбиятындагы психологизмны өйрәнү көн тәртибенә куелса да, аның төп үзенчәлеген һәм аерым язучылар иҗатында чагылышын аңлау башлангыч хәлендә генә әле. Бер үк татар язучысындагы психологизмга мөнәсәбәтнең шактый төрле булуы да шуның белән аңлатыла. Ф. Әмирхан һәм И. Тургенев иҗатлары арасындагы якын, охшаш якларны күрсәтеп, Й. Нигъмәтуллина түбәндәге нәтиҗәгә килгән иде: «Шул рәвешчә, И. Тургеневтагы шикелле үк, Ф. Әмирханда да тәрбия шартларының тормыш белән бәрелеше герой психологиясендәге һәм характерындагы эчке каршылыкларның килеп чыгуында иң әһәмиятле факторларның берсе булып тора»[8]. А. Сайганов исә Ф. Әмирхан психологизмында Л. Толстойга якынлык барлыгын дәгъвалый[9].

Ф. Әмирхан иҗатындагы психологизмның тууын А. Сайганов татар җәмгыятендәге шәхси башлангычның нигездә рус җәмгыятенә хас иҗтимагый-тарихи тенденцияләргә бәйләнештә мәйданга чыгуы белән аңлата һәм, шуның бик үзенчәлекле бер моменты итеп, XIX—XX гасыр аралыгындагы татар тормышына да урта гасырчылык калдыклары белән яңа буржуаз мөнәсәбәтләрнең кискен көрәше характерлы булуын әйтә. «Тарихи чынбарлыкның тотрыксызлыгы, каршылыклылыгы кеше аңы, психикасы торышында да үзен күрсәтте»[10], — ди. Гомумән алганда, мондый мотивировка урынлы һәм ышандырырлык. Әмма конкрет килгәндә, кайсы татар язучысы иҗатында һәм стилендә Л. Толстойдагы «җан диалектикасы»на якын торырлык психологизм булу-булмау мәсьәләсе ныклап тикшерүне таләп итә әле.

Л. Толстой, татар язучыларының бөек замандашы буларак, һичшиксез, алар иҗатына тирәнтен тәэсир иткән. Ләкин татар әдәбиятындагы прозадан, аерым алганда Ф. Әмирханнан, аның психологизмына туры мәгънәсендә тәңгәл яки якын стиль эзләү бик үк урынлы түгел шикелле.

Шуңа да карамастан, безнең әдәбиятта «җан диалектикасы» дип аталырга лаек психологизм турында сүз алып барырга мөмкинме? Мондый психологизм булса — ничек булган?

«Җан диалектикасы» төшенчәсен фәкать Л. Толстой стиленең индивидуаль үзенчәлеге итеп кенә карарга кирәк, аны башка язучыларга күчерү ярамый, диләр кайбер белгечләр[11]. Һәм шунда ук, Л. Толстой иҗатында мондый стиль барлыкка килүнең төп сәбәбе итеп, Россиядә капиталистик мөнәсәбәтләр көчәю нәтиҗәсендә тирән каршылыклар кичергән шәхеснең эчке дөньясын ачуга сәнгатьчә ихтыяҗ җитлегүне күрсәтәләр. Димәк, бу стиль Л. Толстой талантының зур иҗтимагый-тарихи шартлар белән бәйләнешеннән, шул шартлар таләбенә җавап бирерлек көчкә ия булуыннан туган икән. Әмма күрсәтелгән шартлар бер Л. Толстой стилен, аның психологизмын тудырган фактор булып кына тормаганлыгы да мәгълүм. Чөнки Россиядә капитализм үсеше белән кискен каршылыкларга кергән шәхес, кеше абруе өчен көрәш күпләгән башка язучылардагы психологизмга да рух бирде, аны тудырган бер төп фактор булды. Бу яктан килгәндә инде, башка әдипләр психологизмында да «җан диалектикасы»ның теге я бу төстә чагылышын инкарь итү кыен шикелле. Шуңа күрә булса кирәк, икенче төркем белгечләр арасында «җан диалектикасы» төшенчәсен гомумән рус критик реализмындагы психологизмга хас бер тенденция итеп аңларга теләү дә бар. «Җан диалектикасы»н әдәбият мәйданына чыгарган иҗтимагый-тарихи шартларны истә тотканда, бу фикер белән исәпләшмәү шулай ук урынсыз булыр иде. XX йөз башындагы безнең әдәбиятка әнә шундый шартларның йогынтысы булдымы һәм алар «җан диалектикасы» дип аталырлык психологизмны тудырдымы? Һичшиксез, XX йөз башы та-

---

[7] «Совет әдәбияты» журналы. 1960 ел, 4 сан, 139 бит.
[8] Ю. Г. Нигматуллина. Күрсәтелгән хезмәт, 46 бит.
[9] А. Сайганов. Күрсәтелгән хезмәт, 36 бит.
[10] А. Сайганов. Проблема типического в татарской реалистической литературе. — «Вопросы татарской литературы». Сборник 5. Учен. записки Казанского пединститута, рус телендә, 1972 ел, 28—29 битләр.
[11] Павел Громов. О стиле Льва Толстого. Становление «диалектики души», Ленинград, рус телендә, 1971 ел, 150—151 битләр.

тар әдәбиятындагы психологизмда патриорхаль-феодаль, ягъни иске, кадими генә түгел, яңа буржуаз мөнәсәбәтләр белән дә каршылыкка кергән кеше, шәхес драматизмы сизелерлек булды. Бу моментта иске тормыш кысасыннан котылырга ашкынган шәхеснең яңа мөнәсәбәтләрне, яңа идеалларны ничек аңлавы һәм хис итүе кебек рухи киеренкелекнең каршылыклы, катлаулы яклары белән чагылмый калуы мөмкин түгел иде. Моның гаять көчле шигъри гәүдәләнешен, һичшиксез, беренче нәүбәттә Г. Тукай психологизмында табып булыр.

Ф. Әмирхан сүзләрен искә төшереп әйткәндә, «бөтен тормыш рәвеше белән буржуаз җәмгыятьтән читтә яшәгән, табигате белән капитализм дөньясына җайланырга теләп, җайлана белүдән камил азат»[12] халык баласы буларак та һәм, икенче яктан, Л. Толстойның һәртөрле битлекләрне ерткан, әмма гаять каршылыклы гуманизмына кайнар теләктәшлек иткән художник буларак та, Г. Тукай ирек даулаган шәхесне, гади кешене һәм халыкны изгән чынбарлык белән килешмәс конфликтның киеренкелеген сурәтләгән психологик лирика югарылыгына күтәрелде. Безнең әдәбиятның бер жанрында да күренмәгәнчә, аның лирикасында заманның алдынгы кешесе кичергән рухи драма үзенең күп төсмерләре, нюанслары белән гәүдәләнеп калды. Бер татар язучысы иҗатына да хас булмаганча, Г. Тукай лирикасында шагыйрьнең һәм лирик геройның чынбарлык белән тирән бәйләнешле уй-кичерешләре күп төрле каршылыклы яклары белән сурәтләнде. Ул уй-кичерешләр хакыйкать эзләү юлына чыккан шәхес психологиясендә шатлык һәм газап, өмет һәм өметсезлек, гомумән рухи күтәрелеш һәм төшүләрне бик җанлы итеп күз алдына бастыралар. Алар шагыйрьнең һәм аның лирик героеның явызлык белән көрәштә формалашкан эчке дөньясын тулы ачалар. Әгәр дә «җан диалектикасы»н кеше рухи дөньясындагы төрле кичерешләрнең яралуын, үсүен, бетүен яки икенче төсмерләргә керүен сурәтләү дип аңласак, Г. Тукай лирикасында да нәкъ шундый психологизм өстенлек итүен очратырбыз. Һичшиксез, «җан диалектикасы» Г. Тукай лирикасында уй-кичерешләрне хәрәкәт итеп, психологик процесс итеп чагылдыра торган стильне тудырды. Шагыйрь лирикасын үтәдән-үтә сугарган контраст, антитеза һәм күңел монологы алымнары да аның психологик стиленә бик характерлы. Бу алымнар Л. Толстой әсәрләрендәге «җан диалектикасы»на билгеле якынлык, охшашлык барлыгына дәлил була ала.

Мәгълүм ки, Л. Толстой «җан диалектикасы»ның мораль-этик һәм философик пафосы кеше рухының хакыйкать, хаклык һәм яхшылык эзләү юлында яңаруы, яңадан тууы, камилләшүе кебек идеалдан аерылгысыз. Г. Тукай лирикасындагы психологизмның асылында да шундый ук идеал этәргеч булып ятканлыгын күрү читен булмас. Без моның белән һич тә Л. Толстой һәм Г. Тукай иҗатларындагы «җан диалектикасы»ның тулы тәңгәллеген дәгъва итмибез. Әмма билгеле иҗтимагый идеаллар, тарихи шартлар һәм сәбәпләр якынлыгы, уртаклыгы күпмедер күләмдә алардагы охшашлык һәм яңашәлекне дә котылгысыз тудырырга тиеш була. Әлеге ике язучының индивидуаль стильләре сүз сәнгатенең бер-берсеннән бик аермалы һәм үзенчәлекле жанрларында гәүдәләнде, бу факт үзе генә дә күп нәрсә турында сөйли. Моннан инде Л. Толстой эпик герое белән Г. Тукай лирик герое арасындагы аерманың да никадәр зур булырга тиешлеге аңлашылыр. Ахыр килеп, Л. Толстой һәм Г. Тукай шәхесләренең художниклык дәрәҗәләре ягыннан да, иҗтимагый-тарихи яктан да төрле милли шартларда җитлегүенә шулай ук игътибар итәргә кирәк. Ләкин боларның һәммәсен истә тоткан тәкъдирдә дә, «җан диалектикасы» мәсьәләсенең Г. Тукай психологизмында үзенчәлекле урын алуын дәгъва итү һич тә урынсыз һәм хаксыз түгел дип уйлыйбыз.

## 3

Г. Тукай Көнчыгышка хас бизәкле, орнаменталь, метафорик, рационалистик һәм дидактик поэзия традицияләре аша Көнбатышка хас эмоциональ-логик поэзия юлына чыкты. Аның шигъри сүзе шагыйрьнең фикер-хисләрен тегәл һәм туры итеп ачу чарасына әйләнде. Ләкин бу әле һич тә аның Көнчыгыш лирикасындагы психологик сурәт традицияләреннән ваз кичүе турында сөйләми. Г. Тукай лирикасында эмоциональ бизәк һәм детальләр көчле. Бусы инде Көнчыгыштан килә торган шигъри традицияләр-

[12] Ф. Әмирхан. Сайланма әсәрләр. 2 том, 573 бит.

нең дәвамы булып, шагыйрьнең шигъри әсәрдәге сурәт детальләрен сәнгатьчә тулы, конкрет күрсәтү максаты белән бәйле иде. Монда инде кеше рухын сурәтләүдә Г. Тукай лирикасының эмоциональ-тасвири көче бик тирәннән килә торган традицияләрне яңарту осталыгына ия булуы да ачык күренә. Бәлки шушы моментта «Көнбатыш-Көнчыгыш синтезы»ның бик әһәмиятле бер эстетик элементы да гәүдәләнә торгандыр. Моны Көнбатыш лирикасына хас психологизмның Көнчыгыш поэзиясендәге эмоциональ-экспрессив детальләр белән керешүе, синтезы дип атарга мөмкин булыр иде.

Рационалистик-дидактик поэзиядән эмоциональ-психологик поэзиягә күчү әле ул гомумән акыл культына каршы килү дигән сүз түгел. Билгеле булганча, күп гасырлар дәвамында үсә килгән акыл культы мәгърифәтчелек әдәбиятының һәм философиясенең нигез ташына әверелде. Көнбатышта да, Көнчыгышта да һәм бездә дә ул шулай булды.

Әгәр дә рус әдәбиятында А. Пушкин классицизм һәм мәгърифәтчелек аша килә торган акыл культын үзенең романтик һәм реалистик идеяләреннән аерылгысыз итеп үстерсә, татар әдәбиятында Г. Тукай һәм аның күпләгән замандаш әдипләре Көнчыгыш, Көнбатыш классикларына һәм мәгърифәтчелеккә хас акыл культын шулай ук югары күтәрделәр. Алар акыл культын романтизм һәм реализм әдәбияты ирешкән эмоциональлек, психологизм белән органик гәүдәләндерү юлына алып чыктылар. Шуңа күрә бу чордагы романтик яки реалистик татар поэзиясенең эмоциональ-психологик җирлегендә акыл культы, рационализм үрентеләренең күзгә бәрелерлек дәрәҗәдә шытып, үсеп утыруы да гаҗәп саналмаска тиеш. Акыл культы, рационализм исә дидактикадан, үгет-нәсихәттән азат була алмый. Тизләтелгән үсеш процессын кичергән әдәбиятларда мондый хәл аеруча еш очрый. Шуңа күрә безнең әдәбиятта һәм аеруча поэзиядә бик ачык рәвештә яки эчкә яшеренгән төстә дидактиканың әледән-әле үзен сиздереп торуын да яман бер традициянең дәвамы дип кенә карарга кирәкми. Ул безнең тарихи-әдәби үсешебездәге катлаулы күренешләрнең язучыларыбыз эстетик карашында үзенчәлекле бер чагылышы иде. Акыл культын, рационализмны һәр очракта да дидактик әдәбиятка хас яссы бер күренеш, ягъни үгет-нәсихәт эстетикасы белән янәшә куярга ярамый. Г. Ибраһимов, мәсәлән, башта романтизмны һәм соңра реализмны яклап, безнең әдәбияттагы дидактик эстетикага каршы чыкса да, үзе мәгърифәтчелек әдәбияты байрагына язылган акыл культыннан һич тә баш тартмады. Аның әдәбияттагы эмоциональлекне, психологизмны яклавы акыл культына каршы куелмады. Реакцион романтизмга гадәттә нәкъ акыл культына каршы куелган «җан культы» характерлы булып, күп очракта ул мистикага барып тоташа иде. Бигрәк тә беренче империализм сугышы елларындагы безнең әдәбиятта шундый романтизм үрнәкләре байтак күренде.

Г. Тукайга метафизик рационализм, ягъни алдан хәзерләнгән һәм катып калган идеяләр, догмалар чит булган шикелле, аңа дөньяны субъектив, индивидуалистик аңлау да характерлы түгел. Киресенчә, ул үзенең башлангыч иҗатындагы дидактик, мәгърифәтчел рационализмны ташлый барып, чынбарлыкны һәм кешенең эчке дөньясын тарихи һәм психологик аңлау юлына нык басты. Бу инде тормышны, кеше уй-кичерешләрен үзгәрештә, үсештә, уңай һәм кире яклары, ягъни эчке каршылыклы бөтенлеге белән аңлау һәм сурәтләү дигән сүз. Бу инде поэзиядә «җан диалектикасы»ның иң әһәмиятле гәүдәләнеше. Г. Тукай үзенең иң җитлеккән шигырь җыентыкларын юкка гына «Күңел җимешләре» яки «Җан азыклары» дип атамаган. Шагыйрь моның белән үз поэзиясенең кеше җанын, күңел дөньясын ача торган, ягъни психологик сыйфатларга ия булуын әйтергә теләгән. Чыннан да, бу җыентыклардагы шигырьләр — Г. Тукайның дидактизм традицияләреннән принципиаль рәвештә читләшеп, лириканың эмоциональ-психологик тирәнлеген яулап алуын күрсәткән үрнәкләр. Аларда шагыйрьнең, лирик геройның «җан диалектикасы» ярылып ята. Тормышка лирик мөнәсәбәтнең һәм үз-үзен анализлауның психологик ачыклыгы, кискенлеге әнә шул диалектиканың характерлы бер сыйфаты булып тора.

«Җан диалектикасы»н антитеза алымыннан башка күз алдына китерү читен. Аның ярәлгылары борынгы поэзиядә үк урын алган [13]. Әмма тик реализм әдәбиятында

[13] Х. Госман. Антитезалы тасвир кайдан килә? «Казан утлары» журналы, 1968 ел, 5 сан, 136 бит.

гына антитеза чынбарлыкны иҗтимагый каршылык-контрастлар һәм драматик хәлләр нигезендә тасвирлау дәрәҗәсенә күтәрелде. Рус критик реализмында «җан диалектикасы»ның иң көчле һәм тулы үрнәкләрен тудыруга ирешкән Л. Толстой иҗатында антитеза алымы искиткеч зур иҗтимагый мәгънә һәм тирән психологик бөтенлек, система алды. Бу язучының, әйтик, «Яңадан туу» кебек романында шундый алым әйдәүче идея-художество принцибына әверелеп, көчле реалистик максат белән кулланыла һәм романның хәтта барлык детальләренә кадәр хәлиткеч сәнгатьле бер чара булып китә.

Л. Толстой иҗатындагы реалистик антитезаның иҗтимагый эчтәлеге В. И. Ленин мәкаләләрендә ачылды. Бу антитеза Л. Толстой психологизмының нигезендә ята. Аның иҗаты чынбарлык каршылыкларыннан үсеп чыккан антитезаның эстетик идеал яктылыгында бик көчле сәнгатьле, художестволы алымга әйләнүен исбатлый.

XX йөз башындагы татар әдәбиятында да социаль һәм психологик антитезалар шактый зур урын алды. Г. Тукай һәм М. Гафури поэзиясе аша үткән антитеза бу алымның татар әдәбиятында да тирән итеп тамыр җибәргәнлеген һәм безнең поэзиягә аның белән бергә киң гражданлык пафосы килеп кергәнлеген күрсәтә иде. Г. Тукайның «Дөньяда торыймммы? дип киңәшләшкән дустыма», «Китмибез!», «Сайфия», «Көзге җилләр» кебек шигырьләрен искә төшергәндә генә дә, безнең лирикадагы антитезаның иҗтимагый мәгънәсе һәм гражданлык пафосы нинди колач алуын күз алдына бастыру кыен булмас. Күп кенә очракларда антитеза сюжет төзүче башлангыч булып әверелә. Мондый мисаллар Г. Тукай һәм М. Гафури поэзиясеннән күпләп табылыр. Х. Госман үзенең искә алынган мәкаләсендә Г. Тукай поэзиясендә антитезаның югары дәрәҗә алуына игътибар итә. Аның традицияләре борынгы төрки лирикага һәм халык иҗатыннан башлыча мәкальләрдәге афоризмнарга барып тоташканлыгын әйтә. XX йөз башы татар лирикасындагы антитезаның психологик һәм иҗтимагый эчтәлеген баетуга, үстерүгә Г. Тукайның замандашлары да зур өлеш керткәнлеген шулай ук истә тотарга кирәк. Дөрес, бу алым аларның талантларына нисбәтән төрле дәрәҗәдә кулланылды. Әмма заманның кискен иҗтимагый һәм рухи борылышлары, ситуацияләре һәм каршылыклары антитеза алымын бөтен татар әдәбиятында көчәйтеп җибәрде.

Антитеза көчәю лирикадагы эмоциональ-психологик градациянең дә тирән үзгәрешенә китерде. XIX йөз азагындагы һәм бигрәк тә XX йөз башындагы төрки поэзиядә, мәсәлән, газәл кебек лирик жанрның үзгәрешен, трансформациясен дә шул моментка бәйләп аңлатырга мөмкин. Аерата соңгырак гасырларда газәлдәге канунлык һәм бәетләр мөнәсәбәтендәге шартлылык сизелеп үзгәрә башлаган. Мондый үзгәреш нигезендә иҗтимагый чынбарлыкка һаман якыная барган лирик герой эволюциясе ята. Лирик герой интересларының киңәюе, үсүе шигырьнең дә бәет структурасын, кысаларын үзгәртергә, киңәйтергә тиеш булды. Үзенең формаль билгеләре белән традицион нормаларга бик якын торса да яки шулай булып күренсә дә, газәл инде лирик герой характерын, аның психологик традициясен чагылдырган лирик монолог булып әверелә барды. Ә «лирик монолог» — жанр канунында котылып, жанр синкретизмына бару юлында кирәкле бер баскыч»[14] икәнлеге мәгълүм. Лирик характерның дөньяга карашын һәм рухи хәлен билгели торган төп сюжет элементы булган логик һәм эмоциональ градацияне лирик геройның киеренке һәм каршылыклы уй-кичерешләре үсеше дип кенә аңларга мөмкин. Бу төр градация поэзиядә романтизм һәм реализм юнәлешләре көчәйгәч киң колач алды, чөнки шул методлар өстенлек итә башлагач, поэзиядә лирик характер, индивидуаль шигъри тип алга чыкты. Ләкин болай дию белән без һичтә Көнчыгыш классик поэзиясендә, шул җөмләдән газәл традицияләрендә дә эмоциональ-психологик традиция яралгылары булуын инкарь итмибез. Суфичылык лирикасында, мәсәлән, «хәл» моменты гаять көчле экстаз буларак сурәтләрендә дә эмоциональ-психологик градация яралгылары булуын инкарь итмибез. нүенә аеруча игътибар ителгән һәм шуның белән кеше тойгысына турыдан-туры тәэсир итү күздә тотылган. «Моннан соң хәл суфичылык лирикасының иң яраткан темаларыннан берсе булып китә. Моны тасвирлауда ул ачык, якты буяулар таба алды, бу буяулар аңа бөтен алгы Көнчыгышта дан тудырдылар һәм психология өчен фәнни җир-

[14] В. И. Коровин. Жанры лирики.— «Литература в школе», 1963 ел, 6 сан, 19 бит.

[15] Илаһи көч белән кавышырга омтылганда, бик кыска бервакыт эчендә кешенең мистик яктыруы (мистическое озарение) мәгънәсендә онытылуы, экстазы «хәл» дип аталган.

лек табарга омтылган барлык кешеләргә аны бик кызыклы өлкәләрдән берсе итеп таныттылар»[16]. Суфичылык идеясе белән бәйләнештә туган «хәл» моменты, лирикадагы эстетик күренеш буларак, гомумән Көнчыгыш поэзиясенең зур сәнгать казанышына әйләнгән, шигъри шәхеснең кичерешләрен киеренке итеп тасвирлау алымы булып өверелгән һәм кешенең реаль психологиясен шигъри ачу максатына да хезмәт иткән. Моны исбатлау өчен, мәсәлән, Сәгъди, Хәйям, Хафиз һәм Низами кебек шагыйрьләр лирикасын искә алу да җитә. Шул рәвешчә, Урта гасыр поэзиясенең үз җирлегендә үк инде «хәл» моментының дини-мистик кысадан чыга баруын, кешенең чынбарлык, дөньяви уй-тойгылары белән бәйле эмоциональ-психологик халәтен ачу функциясен дә алуын күздә тотарга кирәк. Икеләнмичә әйтергә мөмкин, бигрәк тә Г. Тукай, С. Рәмиев кебек шагыйрьләр лирикасындагы эмоциональ-психологик градациянең әлеге «хәл» алымы традицияләренә тирән бәйләнеше барлыгы сизелә. Безнең шагыйрьләр лирикасындагы бу момент, азатлык һәм бәхет идеалын яклап, иҗтимагый изүгә каршы баш күтәргән шәхеснең трагик кичерешләрен шигъри тасвирлау киеренкелегендә, эмоциональ-психологик градациясендә гәүдәләнә дип уйлыйбыз. Поэтик шәхеснең караңгылык дөньясыннан яктылык идеалына омтылуы кебек символикада нәкъ менә шул «хәл» моменты белән бәйләнгән традициянең эстетик бер орлыгы ятмыймы икән?

Әмма, шуның белән бергә, реакцион романтизм позициясенә баскан кайбер шагыйрьләр суфичылыкның дини-мистик рухтагы «хәл» моментын кабартырга омтылдылар. Мондый тенденцияне безнең поэзиядә, мәсәлән, Н. Думави, Вакыйф Җәлал кебек шагыйрьләр яклады. Алар шәхеснең, кешенең «дини яктыруы» кебек мотивка аеруча нык басым ясадылар. Бу — илаһи, мистик интуиция концепциясе иде. Аның төп мәгънәсе — кеше үзен газаплаган уй-тойгылар караңгылыгын үз акыл көче һәм рухи ихтыяры белән түгел, ә илаһи көчкә, аллага табыну белән яктыртырга тиеш дигәннән гыйбарәт. Нәкъ шул ноктада реакцион романтизм суфичылыкның дини-мистик рухтагы «хәл» моментын тулысынча уртаклашты.

## 4

Поэзиядә «җан диалектикасы» үсеше күңел монологының һәм күңел образының ролен дә киңәйтеп җибәрде.

Шагыйрь шәхесе белән лирик герой арасындагы якынлыкның, уртаклыкның аеруча киеренке, кабарынкы гәүдәләнеше беренче тапкыр романтик поэзиядә күренде. Монда инде шәхес чын мәгънәсендә яңа иҗтимагый шартлар белән кискен конфликтка керде. Шагыйрьнең үз шәхесе, үз илһамы, үз поэзиясе белән сөйләшүе кебек күңел монологының һәм аның белән бәйләнештә саз образының киң таралган шигъри алымнар булып китүе дә шагыйрь рухи дөньясын һәм иҗат илһамын тулысынча ирекле, мөстәкыйль итеп аңлаудан аерылгысыз иде. Лирик монолог принцибы исә үз нәүбәтендә шигырь композициясендәге, аның структурасындагы иреклелекне дә таләп итте. XX йөз башы татар лирикасында да шуңа охшаш, якын процесс барды. Лирик алым буларак, күңел монологы зур урын алды. Аның да тирән лиризм һәм психологизм белән сугарылган үрнәкләрен Г. Тукай бирде. Шагыйрь лирикасындагы күңел монологы, иҗтимагый һәм рухи трагедия кичергән шәхес дөньясының төрле төсмерләрен чагылдыру белән бергә, гасырлар тирәнлегеннән килгән традицион-шигъри образны яңартуы белән дә аерылып торды.

Күңел монологы — Көнчыгыш лирикасының бай сыйфатларыннан берсе. Аңарда бик борынгыдан килә торган ике лирик дөньяның, ике лирик геройның капма-каршы тенденцияләре гәүдәләнгән. Шуларга нисбәтән күңел образы тудырылган. Аның берсендә суфичылык аскетизмы һәм мистицизмы белән сугарылган шәхеснең, җир тормышыннан ваз кичеп, илаһи биеклеккә ашкан романтикасы чагылса, икенчесендә исә, барыннан да элек, үз иргенә гашыйк шәхеснең җир өстендәге матурлыкны мактау

[16] Э. Бертельс. Избранные труды. Суфизм и суфийская литература. Рус телендә, 1965 ел, 60—61 битләр.

һәм ямьсезлекне нәфрәтләү шигърияте җырланган. Бу тенденция һәм образлар арасындагы аерма-ермаклар торган саен тирәнәя барган. Суфичылык фәлсәфәсе белән бәйле күңел образының дини-мистик кыяфәте тоныклана башлап, аның дөньяви портреты ачык төс алган, кеше җанының, рухының реалистик һәм романтик символикасына әйләнгән. Күңел монологында лирик образның, шигъри геройның чынбарлык белән турыдан-туры бәйле үз дөньясы алга чыккан.

Г. Тукай лирикасындагы күңел образы да, әнә шул традициянең татар поэзиясендә тәмам өстенлек алып, «җан диалектикасы»н чагылдырган шигъри образ булып ныгуын раслады. «Күңел» (1909) шигырендә җырланган күңел образы үзе генә дә шагыйрь лирикасында бу мотивның никадәр зур драматик эчтәлек, иҗтимагый мәгънә һәм психологик киеренкелек алганлыгын бик тулы исбатлый. Монда күңелнең бөтен бер образы тудырылып, аның лирик герой кичерешләреннән аерылгысыз катлаулы һәм каршылыклы психологик сыйфатлары тәгәл күрсәтелгән. Бу сыйфатлар башлыча рифмаларда тәмам ачыкланып, традицион «күңел» рәдифе белән тәмамлана барулары да бик характерлы. Болар һәммәсе күңел образында искиткеч газаплы, драматик лирик геройның портретын тудыра. Г. Тукай лирикасындагы күңел образының тагын да «җан, өмет, фикер» кебек төшенчә-сурәтләр белән гәүдәләндерелгән очраклары да аз түгел. Күңел образының шигъри төсмер игезләре аңарда шактый төрле һәм бай. Үз нәүбәтендә алар башка шагыйрьләр лирикасында да киң кулланыш алды.

1905—07 елгы революция кабызган азатлык идеалы югары һәм илһамлы булып, татар поэзиясендә тамырлана һәм үз шигъри сурәтен яңа сыйфатлар белән баета барды. Бигрәк тә ул сыйфатларның лирик-психологик төсмер, аһәңнәре көчәйде. Бу сыйфатлардан аерата да күңелнең, өметнең караңгылыкка — реакциягә каршы куелган яктылык сурәтләре: кояш, йолдыз, ай, таң, нур кебек шигъри юлдашлары киң урын алып, шулар аша лирик геройның ирек даулавы, иреккә сусавы билгеләнде. Башлыча Г. Тукай поэзиясендә югары сәнгатьчә дәрәҗә алган күңел һәм өмет лирикасының яктылык, ирек идеаллары белән бәйле иҗтимагый һәм психологик эчтәлеге көчле булып, ул бүтән күп кенә шагыйрьләргә дә йогынты ясады.

Г. Тукай поэзиясендәге өмет мотивының реакция караңгылыгына протест булып яңгыравы һәм лирик-психологик тирәнлек белән ачылып китүе беренче тапкыр «Өмит» (1908) шигырендә булды дияргә мөмкин. Монда шагыйрь ил һәм халык өстенә килгән иҗтимагый-политик изүгә каршы торуның үз эчке дөньясында искиткеч рухи киеренкелек белән гәүдәләнешен күрсәтә алды:

**Чыкчы, и фикрем кояшы! Китсен өстеңнән болыт,**
**Бу үлек вөҗданны җанландыр, җылың берлән җылыт,**

— дигән беренче юллардан ук караңгылык һәм яктылык, өмет һәм өметсезлек каршылык-контрастларының лирик-психологик кискенлеге бәрә башлый. Шул каршылыкларны газаплы кичерү аша лирик герой явыз чынбарлык белән килешмәс конфликтка, бәрелешкә кергән изге идеалына ышанычын белдерә. Әнә шундый авыр юлда аның туры кыйбласын билгеләүче акыл кояшы, өмет кояшы балкый:

**И минем яктыртучым! Тик син миңа һәр җирдә шәм;**
**Нәрсә ул дөнья кояшы, син миңа нур бирмәсәң!..**
**Юк, кояшым, мин беләм, син батмагансың мәңгегә;**
**Син дә, вөҗдан, бер торырсың, ятмагансың мәңгегә.**

Шул рәвешчә, лирик геройның тормышка, яшәүгә һәм иреккә ышанычы, өмете, кояш образы белән тыгыз бәйләнешкә керәп, үзенең зур иҗтимагый мәгънәгә ия булган конкрет психологик сурәтен тапты. Г. Тукайның моннан соңгы «Күңел», «Күңел йолдызы» һәм «Өмитсезлек» кебек шигырьләрендә дә күңел һәм өмет образлары шул яктылык һәм караңгылык, яну һәм сүнү контрастлары аша гаять киеренке булып ачылдылар. Шул образларга рух, җан биргән идеал шагыйрьнең нинди генә авыр

шартларда да, нинди генә газаплы ситуацияләрдә дә азатлыкка мәхәббәте, ышанычы булды. Бу идеалның атрибутлары, аерылгысыз сурәтләре, хәтта символлары итеп дөньяга, кешегә һәм яшәүгә мәңгелек көч биреп торган нур чыганаклары алынды. Болар арасында бигрәк тә кояш һәм йолдыз образлары бик актив кулланылды.

Г. Тукай иҗатында, әйткәнебезчә, классик поэзиядән килә торган күңел образы шулай ук лирик герой эчке дөньясының шигъри-фәлсәфи сыны буларак гәүдәләнде. Аның өметкә һәм ирекка ашкынуы яктылык дөньясына чыгу рәвешендә күз алдына китерелде. Шулай итеп, традицион күңел образының иҗтимагый-психологик җирлеге баеды, аның тарих һәм чынбарлык белән бәйләнеш даирәсе күпкә киңәйде, гомумән ул образ азатлык идеалы яктылыгында чын мәгънәсендә яңарды. Бу яктан да Г. Тукай лирик героеның роле искиткеч зур булды. Кыю итеп расларга мөмкин ки, караңгылык, өметсезлек һәм коллык дөньясын ләгънәтләп, өмет һәм ирек патшалыгына ашкынучы лирик герой татар поэзиясенең үзегенә кереп утырды. Г. Тукай белән чагыштырганда, С. Рәмиев иҗаты күпме генә каршылыклы тоелмасын, аның да лирик герое өмет һәм өметсезлек, яктылык һәм караңгылык, ирек һәм ирексезлек, хаклык һәм хаксызлык арасында барган зур көрәшнең эчке, рухи драмасын, аның кискен психологик конфликт һәм контрастларын газапланып кичерде:

**Тик азаккы тамчы яшьнең**
**Җиргә тамганын көтәм.**

**Ул тамар бер, мин бетәрмен,**
**Тик шуны белсен үзе:**
**Бу азаккы яшь булыр, бу —**
**Идеалымның йолдызы!..**

(«Д ө н ь я г а».)

Әлбәттә, Г. Тукай һәм С. Рәмиев лирик геройларының дөньяга, чынбарлыкка мөнәсәбәтләрен бер-берсеннән аерган идея-эстетик ермаклар, үзәннәр аз түгел, әмма аларның билгеле бер нокталарда якынлашулары, аваздашлыклары һәм кушылулары да сизелеп тора. Бу ике шагыйрь җырлаган геройларның бер-берсе белән тыгыз мөнәсәбәткә керүләрен, беренче нәүбәттә, изүче чынбарлык белән конфликтларының активлыгы көчле булуыннан килеп аңлатырга кирәк.

Бигрәк тә унынчы еллар башында күтәрелеп чыккан бер төркем шагыйрьләр иҗатында өмет һәм ирек идеалларының Г. Тукай һәм С. Рәмиев традицияләреннән азыклануы нык сизелде. Шундыйлардан, мәсәлән, С. Сүнчәләй белән Ш. Бабичны күрсәтергә мөмкин. Әлеге ике шагыйрь поэзиясенең үзегеннән шулай ук караңгылыктан яктылыкка омтылу психологик лейтмотив булып үтә. Моның да эчтәлеге — коллыктан ирекка чыгарга ашкыну, тормышта шатлык, бәхет булырга тиешлегенә әметләнү:

**... Төн үтә.**
**Вәхшилек, золмәт вә коллык тиз бетәр чаклар җитә...**
**Син теләә: чыксын кояш, чыксын! Халык күптән көтә.**

(С. Сүнчәләй. «Каһарманга». 1911.)

«Караңгы һәм газаплы төн. Бер очкын-чаткы юк алда. И таң, тиз ат! Кояш чыксын!» кебек символик метафоралар С. Сүнчәләй поэзиясендә еш кабатланды. Аларның иҗтимагый-психологик мәгънәләре ачык һәм һәркемгә аңлашыла:

**Күп көтелгән чак җитәр, шиксез җитәр,**
**Артка чикмәс милләтем — алга китәр.**
**Таң атар, нурлы кояш балкып чыгар,**
**Яхшы тормыш җилләре илдә исәр.**

(«Өмит». 1912.)

Шушы лирик традицияләрнең көчле бер үзенчәлекле гәүдәләнеше, психологик катлаулылык белән үстерелеше тагын Ш. Бабич иҗатында ачык күренде. Аның поэзиясе, ди Х. Госман, «әйтергә яраса, якты нур белән караңгылык көрәшеннән гыйбарәт. Шуңар да аның күп әсәрләре кешенең шатлык хәленнән кайгыга төшүен яки, киресенчә, әле генә күңелен биләгән зур хәсрәтне җиңеп, шатлык нурлары арасына килеп керүен һәм «күз яше аша елмаюын» сурәтлиләр» [17]. Ш. Бабич поэзиясендә лирик геройның караңгылык, коллык дөньясыннан ирек идеалына, өметкә ашкынуы күбесенчә ай образы белән бәйләнештә гәүдәләнде. Дөрес, аңарда да кояш, йолдыз һәм нур сурәтләренең роле аз түгел. Шулай да Ш. Бабич романтик героеның күңеленә, психологиясенә ай культы якынрак, аның якты киләчәккә омтылышының поэтик ассоциациясе күбрәк ай образы аша бирелә. («Кем өчен?» 1916.)

1905 елдан соңгы татар лирик поэзиясенең стилендә, сурәтләр системасында кояш, ай, йолдыз һәм таң белән бәйле символика гомумән яктылыкны гына түгел, ә лирик геройның ирек һәм бәхет идеалын белдерде. Ниһаять, анда инде зур иҗтимагый үзгәрешләрне көтеп каршы алырга торган лирик геройның тарихи оптимизмы да сизелә башлады:

**Төн үтә, гомрем күгенең көнчыгышы яктыра,**
**Анда ал таңның туасын белдереп чулпан тора.** [18]

Шул рәвешчә, XX йөз башындагы татар поэзиясендә формалашкан лирик геройның кыяфәтендә һәм психологиясендә заманның тарихи-иҗтимагый рухы белән сугарылган сыйфатлар өстенлек алды. Бу процесста Г. Тукай иҗатының роле гаять зур һәм хәтта хәлиткеч булды. Аның лирикасы ирек өчен көрәшкән шәхеснең һәм замандашның катлаулы эчке дөньясын, драматизмын һәм гражданлык горурлыгын сәнгатьчә бөтенлек һәм психологик тирәнлек белән ачу юлына басты. Гомумән бу дәвердәге татар лирикасын һәм аның героен әнә шул олы юлдан читтә тулы итеп күз алдына китереп булмас та. Бу лирик геройның байрагына шәхес һәм халык азатлыгы өчен көрәш идеалы язылганга, ул социалистик революцияне чын күңелдән үз итеп, шатлык белән каршылады һәм азат ителгән гади кешенең бәхет өчен көрәше белән рухланып алга атлады.

---

[17] Х. Госман. Татар поэзиясе антологиясе. 1956 ел, 12 бит.
[18] Г. Харис. «Кыйтгалар», «Аң» журналы. 1907 ел, 11—12 саннар.

## Илдар Юзеев

### Шагыйрь җаны типкән җырлы дөнья

Тырышса да дошман,
шагыйрьләрне
Аералмый җырдан, халыктан.
Тукай киткән...
Дошман сөенсә дә,
«Мин исән!» дип Җәлил калыккан.

Уйласа да балта тоткан җәллад:
«Җәлил китте...»
Җырчы китмәгән!
Шигъри җаны
Ярсу бер көч белән
Тибеп чыга тау-таш, чишмәдән.

Тән үстергән, «филдәй» җәллад күрә:
Җырлар исән...
«Нинди көч анда?!»
Шагыйрь җаны типкән җырлы дөнья
Гел тарая бара дошманга...

## Кадыр Мырзалиев,

казакъ шагыйре

### Җыр йөрәге

Кирәк илгә сүзнең ләгыль-якуты,
Безнең заман — асыл җырлар вакыты.
Шагыйрь булып Тукай килгән дөньяга,
Ул гынамы?! Тукай — татар бәхете!

Ватан күрке була алмый һәр кеше, —
Кара башын уйный адәм байгышы...
Җәбер-золым күреп Тукай кайгырса,
Тукай гынамы ул — татар кайгысы!

Ир-егетнең кирәк илен сөюе,
Һәркемнең дә кирәк моны белүе.
Яманлыкны мыскыл итеп җырында
Көлсә Тукай, ул — татарның көлүе.

Һәр дәм шатлык белән бергә атлар моң.
Көләч атып, моңсу гына батар көн.
Азап чигеп чирле Тукай еласа,—
Ялгыз түгел, ул — күз яше татарның.

Җырны гөлдәй тагарга дип түшенә
Халык өчен шагыйрь хисләр кичерә!
Тукай дисәң — татар баса алдыңа,
Татар дисәң — Тукай төшә исеңә.

## Сырбай Мәуленов,

казакъ шагыйре

### Тукай кабере янында

Кан бозланды,
Тән сызланды,
Йөзләрдә сагыш саргылт, —
Шалт ябылды
Хыял капка,
Уй — сандык...
Киттең, Тукай,
Үттең, Тукай,
Йөрәкләрне яндырып.
Иңрәде ил,
Тетрәде җир
Кара яңгыр яудырып.
Иртә киттең,
Кыска иттең
Яшь гомереңне азаплы.
Аптыратып,
Кан елатып,
Ташлап киттең Казанны.
Очты еллар,
Үсте җырлар —
Озарды яшь гомерең.
Кабат тордың,
Кабат кундың
Биегенә тогырның [1].
Шагыйрь Тукай,
Акын Абай,
Үлмәс җаннар идегез.
Берең анда,—
Берең монда,—
Йөрәкләрдә икегез.

Казакъчадан НУРИ АРСЛАНОВ тәрҗемәләре.

[1] Тогыр — ау кошларын кундыра торган биек урын.

## Рәдиф Гатауллин

### Кырлай юлында Сәгъди абзый белән сөйләшү

Авыл исеме — Түбән, Югары Аты...
Кайда — аның аты?
Тояк тавышын ишетәм еллар аша,—
тыңлыйм җиргә ятып...

Кырлай, сиңа юлым. Авыллардан,
кырдан — җәяү атлыйм.
Артка карыйм: куып җитәр кебек
бик таныш бер атлың.
Мин кычкырам аңа:
— Сәгъди абзый,
алып кайт Кырлайга!..
Мин дә нәни Апуш кебек гаҗиз
бу якты кырларда —
ал мине дә уллыкка син, күрсәт
сихри Казан артын.
...Арбаң инде татар шагыйрьләренең
сыйдырса да барсын —
иркен әле анда, күңелең киң,
арымаган атың.

Утырт мине, алып бар... Кырлайда
алтын бер кыңгырау
чыңлый, чакыра мине. Шунда — бәхетем,
булса да юл урау.
(Әй, тынма, кыңгырау!)

Сәгъди абзый, күрен... Көтәм
күкрәп
арыш үскән кырда;
еламамын — биткә тисен шартлап
сүс чыбыркың кулда.
(Миңа тансык ул да!)

...Арбаңа ал мине. Синең белән
ятим булмам — халкым җанына-моңга
Тукай килгән юлда.

Сәгъди абзый! Арбаңа ал, көтәм...

## Зиннур Насыйбуллин

### «Тәфтиләү»

Җаның аша сызылып үтә бу моң,
Күкрәгеңнән сагыш сыгыла...
Газап сеңгән, салмак әрнү сеңгән
Пластинканың һәрбер сырына.

Башың иеп гүя баскансың син
Өметеңнең кабере кырына.
Бу — «Тәфтиләү» шулай шагыйрь зарын
Бәян итә бүген чорыма.

«Тәфтиләү»нең тансык җәзасыннан
Туймас күңел, туймас, ахрысы.
Бу җиһанга «шат яраткан» икән,
«Ят яраткан» нигә «раббысы?»

Халык булып халык иңрәгәндә
Аның җаны — шагыйрь нишләсен?
Ә кара көч күңел кылларының
Иң нечкәсен суыра, нечкәсен!

...Бу моң белән биек күтәрелеп,
Чордан-чорга хыял сикерде.
Ә пластинка һаман әйләнештә...
Җир шарының үзе шикелле.

## Фәннур Сафин

### Тукай ягы

Күргәнем бар шундый кешеләрне
(Башкаларны болай сагынмам);
егетләрчә җитди горурланып:
— Без бит, диләр, Тукай ягыннан!

Паспортларга түгел, күңелләргә,
йөрәкләргә уеп язылган:
Минзәләдән булыйк, я Чаллыдан —
без барыбер Тукай ягыннан!

Якташларың, Тукай, сине укый...
Бәләкәйдән, бала чагыннан
күңелләрдә — синең якты җырлар,
синең моңнар күздә чагылган!..

Күпләр әйтер шуны,
сорап кара
Идел буе халыкларыннан.
Башын горур чөеп әйтер алар:
— Без, диярләр, Тукай ягыннан!

## Мөхәррәм Каюмов

•

Шагыйрьләрне бергә җый икән дә,
Еллар буйлап чәчмә, таратма.

Күпме җырчы, күпме җырчы бүген
Күңелем мәйданында парадта.
Саф башында килә Кол Галиләр,
Тукай бара әнә пар атта.
Такташ белән Кутуй бергә атлый, —
Нур артыннан сафта нур арта.
Җәлил килә, Кәрим, Алиш килә,
Төркем-төркем яшьләр — күр, сафта...
Күпме җырчы, күпме җырчы бүген
Күңелем мәйданында парадта!

Шагыйрьләрне бергә җый икән дә,
Еллар, илләр буйлап таратма!

## Ибраһим Нуруллин

# ТУКАЙ

Тукай 1906 елның урталарыннан башлап 1907 елның көзенә кадәр, ягъни бер елдан артыграк вакыт эчендә, иллеләп шигъри әсәр, шулар эчендә бер поэма иҗат иткән. Барлыгы — меңнән артык шигырь юлы. Шулар өстенә, иллегә якын мәкалә һәм фельетон язган.

Әмма хикмәт санда түгел — хикмәт Тукайның шагыйрь һәм публицист буларак гаять тиз үсүендә. Хикмәт — сыйфатта. Корама телдәге шигырьләре күренгәләсә дә, татарчаларында, гәрәбәдәй бодай бөртекләре арасындагы бакра кебек, гарәп-фарсы тәгъбирләре очраса да, Тукай хәзер нигездә саф татар телендә яза. Аның теле, халыкның үзеннән алынган булып, халыкның сурәтле фикерләү рәвешен чагылдыра.

Үгет-нәсихәтчелек, дидактизм да инде бу чорда юкка чыга бара. Моңарчы күбрәк «без» исеменнән риторик шигырьләр сөйләгән, берсендә хәтта «бән димәгел, бән димәктә күп бәла», дип белдергән Тукай хәзер инде «мин» исеменнән язылган, ягъни индивидуаль кичереш ярдәмендә иҗтимагый мәсьәләләр күтәргән чын мәгънәсендәге лирик шигырьләр иҗат итә башлый.

Тукайның бу чорда ук нинди югарылыкка күтәрелүен күз алдына китерү өчен атаклы «Шүрәле» әкият-поэмасының шушы чорда язылуын искә алу да җитсә кирәк. Пушкинның «Руслан һәм Людмила»сы рус поэзиясендә нинди роль уйнаган булса, татар поэзиясендә «Шүрәле» дә шундый зур эш башкарды. Шагыйрьнең әсәргә үзе биргән искәрмәсе дә кызыклы: «...мин бу «Шүрәле» хикәясен Пушкин вә Лермонтовның шундый авыл җырләрендә сөйләнгән хыялый хикәяләрне язуларына истинадән (нигезләнеп — Н. И.) яздым». Тукай да, Пушкин белән берлектә, остазы сүзләрен үзгәртә төшеп, поэмада тасвир ителгән дөньяга карата әйтә алыр иде: «биредә татар рухы... биредә татар җире исе аңкый».

«Шүрәле» поэмасы бүген дә тулы канлы тормыш белән яши. «Шүрәле» балетының, илебез сәхнәләреннән йөреп чыгып, ил тышында да шөһрәт казануы, поэманың бүтән төр сәхнә әсәрләре, җыр-симфонияләрнең, сынлы сәнгать һәм скульптура әсәрләренең туууна сәбәп булуы әнә шул турыда сөйли.

Тукай Уральскидан читтә, татарлар яши торган төбәкләрдә, нәкъ менә 1906 елның икенче яртысыннан башлап язылган шигырьләре

Ахыры. Башы 2—3 саннарда.

белән танылa. Дөрес, киң халык массасы тарафыннан танылу түгел әле бу. Чөнки аның «Су анасы» һәм «Кәҗә белән сарык» кебек әкиятләре, «Печән базары яхут яңа Кисекбаш» исемле поэмасы, балаларга багышланган шигырьләре әле язылмаган. Бер генә китабы да укучы кулына барып кермәгән. Сүз хәзергә әле Тукай шигырьләренең һәм шигырьләре аркылы исеменең каләм тибрәтүчеләр, газета-журнал чыгаручылар һәм китап нәширләре күзенә ташлануы турында гына бара.

Менә кайбер замандашларының Казанга яңа гына әйләнеп кайткан Тукай белән беренче танышуларына бәйләп әйткән сүзләре.

Атаклы драматург Галиәсгар Камал: «Мин шул килгән газеталардан Тукайның язган шигырьләрен эзәрләп барып, укый башладым».

1906 елда «Таң йолдызы» редакторы булган шагыйрь Сәгыйть Рәмиев: «...ул безгә шигырьләр дә яза, шигырьләрен газетабызга бик яратып баса идек».

Талантлы прозаик, драматург һәм тәнкыйтьче Фатих Әмирхан: «Бу фамилия миңа «Әлгасрел-җәдит» журналында чыккан кайбер шигырьләре аркылы таныш иде». «Әлислах» исемле газета чыгарырга рөхсәт алынгач, газетаның рәсми редакторы (чыны—Ф. Әмирхан) В. Бәхтияров 1907 елның 25 апрелендә Тукайга язышырга чакырып хат язган. Ф. Әмирхан кушуы буенча язганлыгы турында шик булырга мөмкин түгел.

Язучы, тарихчы һәм журналист Риза Фәхретдинов 1906 елда, Тукайның вакытлы матбугатта басылган шигырьләре белән танышып бара торгач, «татарның Мәгаррие булачак егет бу» мәгънәсендә бер сүз әйткән. Дөрес, 1914 елда аның бу фикере матбугатта телгә алынгач, могтәбәр зат каләмгә ябыша: бу сүзне әйттемме, язып чыктыммы, хәтерләмим, әмма Тукайны Мәгарригә тиңләү дөрес түгел, ди. Биредә мәсләк аерымлыгы да, Тукайның Р. Фәхретдиновка Казаннан сатира уклары җибәргән булуы да күпмедер роль уйнаган, әлбәттә. Әмма бу урында безнең өчен әһәмиятлесе шул: 1906—1907 елларда Тукайны Оренбургтан да күреп алганнар. Уральскида чагында язышырга, ә Казанга киткәч, «Вакыт»та эшләргә чакырып хат язулары да шуны күрсәтә.

Гыйльметдин Шәрәф җитәкчелегендәге китап нәшрияты «Шигырьләр китапханәсе» сериясеннән җыентыклар чыгарырга керешкәч, Габдулла 1907 елның мае тирәсендә Казанга хат язып җибәрә, минем дә шигырьләремне мәҗмуга итеп чыгара алмассызмы, ди. Г. Шәрәфтән уңай җавап килгәч, җыентыгын әзерләп бетереп, Казанга юллый. Хатында мондый юллар бар: «Үзеңез дикъкатьләп карап чыгыңыз да, нәшер итәргә рази булсаңыз, миңа тизлек берлә 50 тәңкә акча җибәреңез... Әгәр рази булмасаңыз, китапны кире үземә кайтарыңыз».

Тукайның шушы хаты игълан ителгәнчегә кадәр Г. Кариев версиясе яшәп килде: янәсе, Шәрәфләр «...Тукаевның шуңа кадәр «Фикер»дә, «Әлгасрел-җәдит»тә басылган шигырьләрен мәҗмуга рәвешендә бастырырга сорап, условиеләр язып җибәргәннәр». Габдулла, күрәмсең, риза булган, һәм Г. Шәрәф ул шигырьләрне утыз сумга сатып алган. «Тукаев, — дип яза Г. Кариев, — басылган шигырьне нигә алалар, аннан ни файда чыга дип, Шәрәфләрне, бер тарафтан, кызганган кебек, икенче яктан, утырттым бит дип, миңа көлеп сөйләгән иде». Яшь Тукайның дәрәҗәсен тагын да күтәрә төшсә дә, егетнең ягымлы беркатлылыгы безне елмайтса да, бу версиядән, күренә ки, баш тартырга туры килә. Дөрес, Тукайның бу вакытта практик тормыш тәҗрибәсе артык ташып тормый. Шулай да газета-журнал бит-

ләрендә басылган шигырьләрне аерым китап итеп чыгарганда гоно-рар түләнүне белмәслек дәрәҗәдә үк беркатлы булмагандыр ул.

Ахыр чиктә, Г. Кариев версиясен кире кагу артык зур югалту түгел. Чын «версия» дә Тукайның дәрәҗәсен һич тә киметми. Г. Шә-рәф әллә кайдагы бер яшь шагыйрьнең шигырьләр тупламын кабул итә дә бер генә түгел, бәлки ике китапчык итеп, тиз арада бастырып чыгара. Бу җыентыкларга «3 дәфтәр» һәм «4 дәфтәр» дип куелуына игътибар итсәк, «Шигырьләр китапханәсе» сериясендә моңарчы ике генә китап чыкканлыгын аңларбыз.

Безнең Габдулла моңарчы да талантына һәм шагыйрьлегенә ны-ышана иде. Хәзер исә китабы күренекле һәм зәвыклы нәшир тара-фыннан кабул ителгәч, газеталардан үтенеч хатлары да килгәч, Риза казый кебек могтәбәр затның җылы сүзе дә ишетелгәч, болай да кечкенә Җаек Габдуллага тагын да таррак булып тоела башлый. Ка-натлары ныгыган бөркет баласының, тар оядан чыгып, киң дөньяга очасы килә. Кая? Билгеле инде, Казанга! Кечкенә Апуш хәзер зур-зур Тукай булды. Ул шагыйрь. Аның халкына, милләтенә биргән олы вәгъдәсе бар.

Бала чагы никадәр генә ямьсез үтмәсен, туган туфрак — гази-бит ул. Кимсетелүләр һәм ачлык-ялангачлык инде онытылган. Сирәк була торган кечкенә шатлык һәм куанычлар исә, вакытның зәңгәр томанына өртелеп, матур булып күренәләр, дулкынландыралар. Кыр-лай урманы, чәчәкле болыннар, тар инеш һәм чишмә буйлары Габ-дулланың йөрәген сыкратып, туктаусыз чакырып торалар. Казанның үзен инде әйтәсе дә юк. Бала чагында гаять мәһабәт булып күренгән таш кала унике елдан соң аның хыялында, һичшиксез, нур эчендә йөзә торган әкият шәһәре булып калыккан.

Казанга ашкынуының соңгы вакытта ни дәрәҗәгә җиткәнлеген күз алдына китерү өчен «Пар ат» исемле шигыренең язылу тарихы-на күз ташлыйк.

Менә шагыйрь, пар атка утырып, «гомер иткән» шәһәр белән сау-буллаша да Казанга юл тота. Сагыш, каршылыклы уй-тойгылар, ка-лыгу. Менә бер вакыт кучерның: «Тор, шәкерт, җиттек Казанга, ал-дыбызда бит Казан!» — дигән тавышы яңгырап китә.

> Бу тавыш бик ачты күңлем, шатлыгымнан җан яна,
> «Әйдә, чап, кучер, Казанга! Атларың ку: на! на! на!»
> Әйтә иртәнге намазга бик матур, моңлы азан;
> И Казан! Дәртле Казан! Моңлы Казан! Нурлы Казан!

Әдәбият сөючеләр генә түгел, бәлки белгечләр дә күп еллар буе Тукай бу шигырен Казанга кайткач язган дип уйлап килделәр.

Менә без «Фикер» төпләмен актара башлыйбыз. 1907 ел. Январь, февраль, март, апрель, май... Чү! «Пар ат» шигыре! 17 сан, 6 май... Димәк, шигырь Тукайның Казанга чыгып китәреннән 5 ай элек язылган. Димәк, шагыйрьнең «пар ат» дигәне хыял канатлары икән. Димәк, бу шигырь — өзелеп сагынып та, Казанга кайта алмый йөдә-гән, әмма күңеле белән мең мәртәбә шунда кайткан шагыйрь тойгы-ларының кәгазьдәге гәүдәләнеше. Г. Кариевка язган хатында мон-дый сүзләр бар: «Мин хәзер Казанда инде. Уральскида вакыт шуны сөйли-сөйли авыз суларым кибеп бетдеге вә шунда бару хакында шигырьләр яздыгым Казанда инде!» Кем белә, бәлки: «Аерылып китсәм дә синнән, гомремнең таңында мин, и Казан арты! Сиңа кайт-тым сөеп тагын да мин», дип башланган «Туган җиремә» шигыре дә Җаекта язылгандыр...

Соң эш нәрсәдә? Җыенырга да юлга чыгарга! Бит Тукайны хәзер Уральскида бернәрсә дә тотмый. Газета һәм журналлар тукталды,

үзе эшсез калды. Ә Казаннан чакырып торалар. Җитмәсә, көзен солдатка караласы бар. Нигә һаман суза, нигә җәен Уральскида уздыра? Бәлки акчасы юктыр?

Түбәндәге документ исә безне бөтенләй аптырашта калдыра.

«Домашнее условие.

Мы, ниже подписавшиеся, решили издавать в г. Уральске газету на татарском языке под названием Яна Турмуш (Новая жизнь) на паях...» Алга таба бер пайның 100 сум торганлыгы, җитәкчелек эше К. Мотыйгый кулында булачагы әйтелә. Аннары имзалар китә һәм пайның суммасы күрсәтелә: К. Мотыйгый Төхфәтуллин — 500 сум. Мөхәммәтгали Мусин — 100 сум, Г. Тукаев — 100 сум.

«Город Уральск. Июля 20 дня 1907 года».

Димәк, 1907 елның июль ахырында да әле Тукайда Казанга бөтенләйгә күчену (дөресрәге, әйләнеп кайту) фикере урнашып җитмәгән. Ул гына да түгел, «Яңа тормыш» газетасы чыга башласа, солдатка каралгач (әгәр алынмаса), яңадан әйләнеп кайтырга да нияте булган.

Тукайның бу сәер карары ике сәбәп белән аңлатылса кирәк. Беренчесе — Габдулланың үз шәхси тормышын үзгәртү мәсьәләсендә илтифатсызлыгы дип әйтергәме, әллә иренчәклек яисә карарсызлыкмы, һәрхәлдә, авыр кузгалучанлыгы. Чынлап та бит, Уральскида инде аның тормышы көйләнгән, яхшымы-яманмы, гостиницада номеры бар, өс-башы бөтен, ач яшәмәде, янында — дус-иптәшләре, туган-тумачасы. Ә Казанда ничек булыр? Кайда урнашыр, нинди киләргә яшәр?

Бәлки Габдулла үзе дә хисап биреп бетермәгән, һәрхәлдә, телдән әйтү ихтимал булмаган икенче сәбәп — шикләнү, сагаю, үзенең «мин»е, хөсне заны өчен хәвефләнү булырга мөмкин. Ачыграк итеп әйтсәк, болай булыр: Уральскида хәзер Тукай һәрьяктан караганда да беренче скрипканы уйный. Казанда югалып калмасмы? Габдулла бирeдә томаланып яткан бер вакытта Казан яшьләре бик нык үскәннәрдер, алга киткәннәрдер. Аңа авыл малаена караган кебек карамаслармы?

Әнә шундый икеләнү эчендә көн артыннан көн уза, призыв көннәре һаман якынлаша. Бу вакыт Тукай үзенең Казанда чыгачак ике җыентыгы белән мәшгуль. Яңа шигырьләр язып, өстәр өчен Г. Шәрәфкә җибәрә, нашир белән хат аша хәбәрләшеп тора.

Призывка кайту өчен акча юнәтү мәсьәләсе белән дә шөгыльләнгән. Атасыннан калган йорт бу вакытта әле нигезендә тора икән. Габдулланы бердәнбер варис дисәң дә ярый. Чөнки абыйсы Мөхәммәтшәриф күптән вафат, ә апасы Газизә дәгъва итмәгән булса кирәк. Габдулланың үтенече буенча, опекун йортны сата да шуннан килгән 100 сум акчаны Уральскига җибәрә («Яңа тормыш»ка вәгъдә ителгән йөз сумның шушы акча булуы мөмкин).

Менә сентябрь керә, ул да үтеп бара. Ниһаять, 12 ел гомер иткән шәһәрне калдырып китү көне җитә. Сентябрь ахырымы бу? Октябрь башымы? Ничәсе? Хәзергә без көнен атап әйтә алмыйбыз.

Эшлисе эш эшләнеп беткән, күрәсе кешеләр күрелгән, әйтәсе сүзләр әйтелгән. Җыенырга да юлга чыгарга гына калды. Җыену да озак түгел. Камыштан үрелгән булып, кечкенә сандыкка охшаган кәрзингә күлмәк-ыштан кебек нәрсәләр, көндәлек тормыш өчен кирәкле бүтән ыбыр-чыбыр саласы да буш калган өлешенә дыңгычлап китап тутырасы. Китаплар арасында, әлбәттә, Пушкин һәм Лермонтовның калын томнары да бар.

Менә барысы да тәмам. Вокзалга чыгып китәргә вакыт җитә, атлар килеп туктый. Озатырга килүчеләр, гадәт буенча, утырып дога кылалар да станциягә юнәләләр.

Габдулланы кемнәр озатып калган соң? Олы Газизә апасы белән ул өйләренә барып саубуллашкан дип уйларга кирәк. Кече Газизә апасы исә Габдрахман белән (бае җибәргән булса) станциягә килгән булыр.

Кайбер озатучыларны тәгаенләп әйтергә мөмкин. Биредә безгә Тукайның иптәшләре белән төшкән фоторәсеме ярдәмгә килә. Анда без «Казан» гостиницасының буфетчысы Нәҗип Зариповны, Мортаза Гобәйдуллинның конторщигы Курушкинны, шуның ук приказчигы Рәхмәтулла Хәйруллинны, Тукайның үзен һәм аның белән бергә мәдрәсәне ташлап чыккан Сираҗетдин Белюковны күрәбез. Фотода Кариев юк. Димәк, рәсем булачак артист Уральскидан киткәннән соң алынган. Фотога төшүнең нинди уңай белән булганын да чамаларга мөмкин. Габдулла белән Җаекта үткәргән елларның истәлеге булсын дип, мөгаен, моны иптәшләреннән берсе оештырган. Тукайның өстендә җилән дип тә, казаки дип тә атарлык кием, аягында итек белән читек арасындагы бер нәрсә. Кара күзлек. Чәче җиту. Казанда Тукайны беренче башлап күргән замандашлары да аның тышкы кыяфәтен нәкъ шулай тасвир итәләр. Димәк, бу рәсем, шул көнне үк булмаса да, Тукай китәр алдыннан алынган.

...Ниһаять, соңгы звонок. Поезд акрын гына кузгала. Озатучылар, хәерле юл теләп, кул изиләр.

Поезд, йөрешен шәбәйтә барып, шагыйрьне сөекле Казанына таба алып китә. Аны нәрсә көтә? Хәзергә әле бу аңа караңгы. Күңелендә өмет һәм шөбһә, сагыш һәм куаныч — барысы бергә укмашкан...

1907 елның октябрь башлары. «Йолдыз» газетасының секретаре Галиәсгар Камал ялгыз гына эшләп утырганда, ишек шакып, редакция бүлмәсенә яшүсмер кыяфәтле бер егет килеп керә. Тәбәнәк, чандыр, өстендәге киеме әлеге фоторәсемдәгечә. Чалбарын итегенең йөзенә төшергән. Ялан баш, җиту чәчле.

Шәкерт-мәкертләрнең редакциягә килгәләп йөрүләре гадәти хәл булганга күрә, Г. Камал артык илтифат итмичә, яңадан өстәленә иелә. Әмма гаҗәеп хәл: кунак тәкәллефсез-нисез генә редактор өстәле янына уза да, бер урындыкка утырып, өстәлдәге газеталарны караштыра башлый. «Малай»ның болай үзсенеп китүе Галиәсгаргә бик үк ошап җитмәгән, күрәсең, ул тегеңәр кырыс кына карап куя. Озак үзенең Уральскидан икәнлеген әйтеп, Камил Мотыйгыйдан сәлам

— Һади әфәнде тиз килер микән?

Әһә, бу, мөгаен, редакторга атасы хәзрәтнең сәламен тапшырырга дип килгән мәхдүм. Галиәсгарнең мыгырданып кына әйткән җавабыннан соң, шактый вакытка тынлык урнаша. Ниһаять, «мәхдүм» тагын сүз башлый:

— Безнең газета-журналлар сезгә килгәндер бит?

— Нинди газета-журналлар?

— «Фикер», «Әлгасрел-җәдит», «Уклар».

— Сез Уральскиданмыни?

— Ие...

— Алай булгач, сез анда шигырьләр яза торган Габдулла Тукаевны да беләторгансыздыр?

«Малай» чак кына елмая да:

— Ул «Апуш» мин булам, — дип куя.

Атаклы драматург булып китәчәк Галиәсгар Камал белән Тукай өнә шулай танышкан.

Аның шагыйрь Сәгыйть Рәмиев белән танышуы да кызыклы. Фикердәш иптәшләре арасында булып үткән кулга алулар сәбәпле якты дөньяга күтәрелеп карыйсы килмәгән бер көнне Сәгыйтьнең

«Болгар»дагы номерына әлеге «малай», ягъни Тукай, килеп керә дә, үзенең Уральскидан икәнлеген әйтеп, Камил Мотыйгыйдан сәлам тапшыра. Хуҗа, чакырылмаган кунакка өнәми генә бер карап куйгач, тәрәзә янына барып, төн караңгылыгына текәлә. Нигә кирәк аңа Уральские да Мотыйгые! Аннары ул, кунакның, чакырганны да көтмичә, буш урындыкка килеп утыруын абайлап, һаман аркан торган килеш, сүз булсын дигән кебек кенә сорау бирә:

— Сез анда шәкерт идегезме?

— Шәкерт тә идем, хәлфә дә идем.

Хуҗа үртәнеп уйлап куя: «Булырсың инде, хәлфә булырга кыяфәтең бик килгән!» Озак паузадан соң Тукай тагын сүз башлый:

— Сәгыйть әфәнде, мин сезгә «Царь-голод»ның тәрҗемәсен җибәргән идем. Сез аны басмадыгыз да һәм җавап та бирмәдегез...

Хуҗа ялт итеп кунакка таба борыла:

— Соң сез кем буласыз?

— Габдулла Тукаев мин...

— Соң, кергәч үк шулай дип әйтсәгез ни була? Мин сезне икенче төрлерәк каршы алган булыр идем! Әй, Тукаев, Тукаев!

Менә бу — Тукайча танышу. Билгеле инде, «Йолдыз» редакторын сорашуы да, «Царь-голод»ның тәрҗемәсе турында сүз кузгатуы да — сылтау гына. Югыйсә, нигә кирәк аңа Максуди һәм «Әлгасрелҗәдит»тә әллә кайчан басылып чыккан мәкаләнең кульязмасы? Төп теләге, әлбәттә, Г. Камал һәм С. Рәмиев белән танышу, аралашу. Тик менә ничек кабул итәрләр? Авыл малае итеп карамаслармы? Габдулланың исә үз горурлыгы бар. Менә ни өчен ул, исем-фамилиясен әйтеп кул сузарга ашыкмаган кебек, бу шәхесләр янына килүенең төп сәбәбен яшерә, юк-бар сылтау таба, сыный, күзәтә, ура-тып кына максатка якыная.

...Тукайның Казанга кайсы көнне килеп төшкәнен белмәгәнебез кебек, аның башлап «Болгар»ның ничәнче номерына урнашканлыгын да төгәл генә әйтүе кыен. Шулай да иң элек аның 30 нчы номерга кергәнлеге турында мәгълүмат бар. Ә инде «Болгар»да үткәргән гомеренең күбрәк өлешен шагыйрь атаклы 40 нчы номерда яшәгән. «Атаклы» дибез, чөнки Тукай турында язылган фәнни хезмәтләрдә һәм әдәби әсәрләрдә шушы бүлмә телгә алына.

Хәрби хезмәткә каралып кайтканнан соң, Габдулла нәкъ менә шушы номерга урнашачак. Хәзергә исә ул Г. Камал, С. Рәмиев, Ф. Әмирхан һәм башка Казан яшьләре белән таныша, шәһәрнең төрле урыннарында була, бала чак хатирәләрен яңарта. «Тәнкыйть — кирәкле шәйдер» исемле мәкалә язып, «Әлислах» газетасына тапшырырга да өлгерә.

Берочтан ул туган якларына кайтырга әзерләнә. Өс-башын яңарта, туганнарына һәм якыннарына күчтәнәч ала. Унике ел югалып торганнан соң, әтрәк-әләм булып кайтырга ярамый ич инде. Җитмәсә, ул хәзер Гариф мулла мәхдүме генә түгел, бәлки танылып килә торган татар шагыйре. Кушлавычта һәм Кырлайда бала чак дуслары бар. Каенсар авылында аның күңеленә «ак фәрештә» булып кереп калган Саҗидә апасы яши. Кырлайда — Зөһрә апасын һәм энесе Садрины күреп чыгарга кирәк.

Тукайның солдатка каралу уңае белән Казан артына кайтуы турында архивта сакланган һәм бу юлларның авторы тарафыннан җыелган истәлекләрдән чыгып фикер йөрткәндә, ул анда ай-ай ярым чамасы яшәгән булып чыга. Чынлыкта исә туган якларында шагыйрь ун-унике көннән артык тора алмаган.

Октябрьның 15—16 ларында әле ул Казанда. Чөнки «Әлислах»-ның 17 октябрь санында чыгачак «Тәнкыйть — кирәкле шәйдер»

мәкаләсенең корректурасын карыйсы бар. Бәлки әле шул газетаны кулына алгач кына юлга чыккандыр. Каралу исә 27 октябрьда инде тәмам булган. Габдулла, туган ягында артык юанмыйча, «Казанда мине эш көтә» дип, ашыгып кайтып киткән. Ничек исәпләсәң дә, һаман шул ун-унике көн.

...Менә безнең Габдулла, ямщик яллап, Казаннан чыгып китә. Билгеле инде, иң элек ул Каенсарга юл тота. Саҗидә апасы «приемга кадәр Габдулла бездә ун көнләп торды» дисә дә, бу раслау — хәтер алдавы нәтиҗәсе. Шулай да шагыйрь якын күргән апасы йортыннан ашык-пошык кына китеп тә бара алмаган.

Каенсардан Кушлавычка барышлый Тукайның Кырлайга тукталганлыгы, остазы Фәтхерахман мулла өендә чәй эчеп чыкканлыгы һәм кордашы Ахун Сабирҗановларга сугылганлыгы билгеле. Хәзрәтнең улы Хәлилрахманны да, Ахунны да ул күрә алмый: болар Арчага каралырга китеп өлгергән булалар. Габдулланың мәрхүм Сәгъди карт йортында булып чыкканлыгына да шикләнмәскә мөмкин.

Кушлавычка Габдулланың кайчан — каралудан бер көнме, ике көнме элек — килеп төшкәнен белмибез. Анда аның двор төшерүче Ситдикъка тукталганлыгы гына билгеле. 24 октябрьда иртүк Кушлавычның каралачак егетләре кырпак белән капланган туң юлдан Олы Әтнәгә юл тоталар. Никрутлар бит — атларны каезлап, бик тиз барып җитәләр.

Волость управасы янында — мәхшәр! Шулай булмый хәле юк: дүрт волость егетләре карала бит бирерә. Үзләре генә биш йөздән артык. Шуңа тагын һәркайсының атасын яисә берәр туганын өстик. Бу әкәмәтне карарга җыелган Әтнә кешеләрен дә кушыйк.

Бер якта вак сәүдәгәрләрнең арбалары тезелеп киткән. Арба тәртәсенә асып куелган көянтә үлчәүдә конфет, прәннек, чикләвек, көнбагыш кебек нәрсәләр сатыла.

Мәйдан гөж килә.

Бүгенгә әле каралырга килүчеләрне исемлек буенча барлау һәм җирәбә алу булачак.

Менә бервакыт старосталар үз егетләрен управа баскычы янына җыеп китерәләр. Хәрби писарь чыгып баса.

— Фәлән Фәләнов! — Эздич! Фәлән Фәләнов. — Монда!

Барлау беткәннән соң, җирәбә башлана, җирәбә дигәне — номер язып бөтерелгән кәгазь. Шуларны кечкенә кисмәк сыман түгәрәк савытка тутырып болгаталар. Каралучы егет калтыраган куллары белән (бәхетле номермы, бәхетсезме булыр!) «кисмәккә» тыгылып кәгазьне ала да писарьга күрсәтә. Тегесе номерын язып алгач кайтарып бирә. Билгеле инде, Габдулланың да исем-фамилиясе яңгыраган, ул да «здесь» дип җавап биргән. Ул да кисмәккә тыгылып җирәбә кәгазен алган. Чират номерын гына белмибез...

Җирәбә алгач, өйләргә таралалар: шушы авылныкылар — үз өйләренә, ерактан килгәннәр — фатирларга. Төркем-төркем булып оешалар да, мәчет картларыннан һәм мулладан качынган булып, хәмердән авыз итә башлыйлар. Бер кызып алгач, урамга чыгалар, гармунга кушылып очтан-очка җырлап йөри башлыйлар. Мулла да, тәкъва картлар да эчтән тыналар, патша хезмәтенә китүчеләр бит ни әйтсәң дә.

Җирәбәдән соң, Габдулла Әтнәдән сигез чакрымдагы Олы Мәңгәргә барып, Габделвәли исемле кеше өенә төшә.

Замандашларының «Габдулла Тукай Мәңгәрдә 5—6 көн торды» дип раслауларыннан без аңа өч сан язылган җирәбә чыкканлыгын чамалый алабыз. Мәңгәрдә ул 5—6 көн тора алмаган, әлбәттә, күп булса, 2—3 кич кунган (ягъни каралуның соңгы көненә кадәр).

Әнә шул ике-өч көн эчендә Габдулла өйдә генә ятмаган. Аның мәдрәсәдә булганы, мәчеткә барып та, эчкә үтмичә, сөннәт бүлмәсенең тәрәзә төбендә генә утырып торганы билгеле. Көн саен дип әйтерлек Әтнәгә барып кайткан.

Билгеле инде, Тукай — Әтнәдә булсын, Мәңгәрдә булсын — никрутларның да, авыл кешеләренең дә бик тиз күзенә ташланган. Өстендә яңа җәйге пальто, салкын булуга карамастан, аягында шиблит, башында кепка. Өсләренә бишмәт яки чикмән, аякларына тула оек белән чабата (итекләре бик сирәк) кигән никрутлар Габдулла кебек ыспай киемле бай малайларына матур күз белән карамаганнар. Мондыйларны үзләре котылып калып та, китәчәкләрне һәйбәтләп сыйламаса, тукмап ташлаудан да тартынмаганнар.

Габдулла хакында, әлбәттә, чыш-пыш сүз киткән:

— Кем бу? — Кушлавыч хәзрәтенең мәхдүме, ди. — Кит әле, аның солдатка китәрлек малае бармыни? — Юк, бу үлгән хәзрәтнеке, хәзер Уральскида тора, ди. Бик гыйлем егет икән.

Әнә шул килеш, Габдулланың мәрхүм хәзрәт мәхдүме булуы, галимлеге, үзен гади һәм табигый тотуы, акыллы күзләренең үткен карашы иң бәйләнчек һәм усал егетләрне дә коралсызландырган. Эчү мәҗлесенә дә аны кыстамаганнар. Килеп-китеп йөрүләре дә аңа хөрмәт күрсәтү, акыллы киңәш ишетү, ара-тирә зарлану, эч бушату өчен булган.

Сизгер күңелле Габдулла шушы 2—3 көн эчендә аз нәрсә күрмәгәндер дип уйларга кирәк. Әнә бит, кызып алгач: «Без барсакмы, күрсәтербез без фәлән җирнең патшасына» дип күкрәк каккан арысландай егетләр управа ишегеннән йөзеннән каны качкан хәлдә килеп чыгалар. Солдатка алынмаганнарының исә авызлары колакларына җиткән була. Падиша хәзрәтләренә хезмәт итү теләгенең ничаклы булганлыгын бу ачык күрсәтсә кирәк.

Бигрәк тә никрутларның җырлары!

Аклы ситса күлмәгемнең
Якалары тар икән.
Җан алучы Газраил
Периумда бар икән.

Әнкәй, мине ник таптың,
Ник таптың да ник бактың?
Үсеп буйга җиткәченнән,
Падишага ник саттың?

Дүрт волостьның яше җиткән егетләре, аларның аталары һәм туган-тумачалары җыелган Әтнәдә авылдагы социаль каршылыклар да Тукайга бөтен ялангачлыгында, бөтен кискенлегендә ачылып киткән.

Бүген без архивның хәрби чакыруга кагылышлы фондын актара башласак, сау-сәламәт булып та, котылып калганнар, яисә алынырга тиешле булмаса да, алынганнар турындагы дистәләгән шикаять кәгазьләренә тап булырбыз. Боларның барысын да нигезле дип санарга ярамый, билгеле. Шулай да тиешле кешеләрне, аерым алганда, комиссия членнарын майлап-җайлап, акча түгеп, гаскәри хезмәттән йолып калу очраклары аз булмаган. 1907 елда исә мондый гаделсезлекләр халыкның аеруча ачуын кабарткан. Чөнки, беренчедән, крестьян хәзер элеккеге крестьян түгел инде. 1905 елдан соңгы крестьян. Икенчедән, Столыпин реформасын тормышка ашырган вакыт бу: кулакка тагын да ныгырга ирек бирелә, хутор байлары барлыкка килә. Ягъни күпчелек белән азчылык үзара пычакка-пычак килгән вакыт. Кызып алган никрутларның үзләреннән яки, улы китеп барса, ике кулсыз калачак картлардан әнә шуңа кагылышлы гыйбрәтле сүзләрне Тукай Әтнә һәм Мәңгәрдә аз ишетмәгән, билгеле. Дусты Г. Кариевка «Мин дә менә Казанны вә туган җирем булган Казан

арты авылларын күреп, күп гыйбрәтләр вә хиссиятләр алдым» дип язганда ул, ихтимал, әнә шуларны да күздә тоткандыр.

Никрутлар тагын болай дип җырлыйлар:

Периумның ишекләре
Эче-тышы пыяла,
Периумга кергән чакта
Бөтен тәнем ояла.

Артык нечкәләп тормый торган крестьян егетләре дә шундый тойгы кичергәч, юка тиреле, гарьчел Тукайга ни кала?! 26 яисә 27 октябрьда ул, салкыннан һәм дистәләгән күз карашларыннан җыерылып, докторларның, терлек-туар алгандагыча, капшау, төрткәләүләреннән кимсенеп, каралу булмәсендә күпмедер ямьсез минутлар кичергәч, «ак билет» алып чыга. Шулай булмыйни: бер замандашы әйткәнчә, «иң җитми, буй җитми», бер күзе бик үк сау түгел.

Габдулла шулай котылгач, Сәҗидә апасын шатландырырга теләп, Каенсарга юнәлә. Тагын берничә көнгә калырга кыстасалар да, күндерә алмыйлар. Апасы аның кулына йон бияләй, аягына киез итек кидереп озата. Әмма соңгысының гомере озын булып чыкмаган: күпмедер вакыттан соң, Казаннан хат килә: сүз арасында Габдулла әлеге киез итекне ничектер яндырганын әйткән.

«Болгар» номерлары урнашкан йортның парадный ишегеннән (хәзерге Татарстан урамы ягындагы) керәсең дә, укалы картуз кигән швейцар Закирга сәлам биреп, тимер баскычтан өченче катка күтәреләсең. Озын коридор буйлап уңга, ашханә залына таба атла. Өске ягы пыялалы ишегенә барып төртелерсең. Сулга борылып кара. Иң кырый ишек. Өстендә «40» дип язылган дүрткел калай. Шакы. Җавап бирмиләр? Димәк, хуҗасы чыгып киткән. Зарар юк, ач та кер. Чөнки теләсә кем шулай итә. Хуҗаның үз номерын бикләп йөргәне юк диярлек.

Иң элек, уң якта, соры одеал ябылган тар гына каты тимер карават күзеңә ташланыр. Кабан күленә карый торган бердәнбер тәрәзә янында кечерәк кенә өстәл булыр. Тәрәзә төбе, өстәл өсте, өстәл асты китап-журнал һәм төрле кәгазьләр белән тулган. Өстәлнең бер кырыенда яртылаш янган шәм тора (электр тогы кайвакыт бетеп тора, күрәсең). Гади генә ике урындык. Тагын нәрсә? Кергәч тә ишекнең уң ягында элгеч бар икән әле. Анда кепка, төймә тишегеннән генә эленгән пальто күрерсең. Бүлмә тар, кечкенә: хәзерге хисап белән әйткәндә, күп булса 8—10 квадрат метр.

Атаклы 40 нчы номерның Тукай яшәгән чагындагы эчке күренеше якынча әнә шундый.

Шагыйрьнең Казанда төпләнеп калу фикере инде өстенлек алган. Әмма моның өчен ни беләндер шөгыльләнергә, ай саен күпмедер вазифа (хезмәт хакы) китерә торган эшкә урнашырга кирәк. Дөрес, Габдулла Казанга килеп төшүгә үзенә шөгыль дә тапкан. Дөрес булса, ул килгән көнендә үк «Әлислах»ның рәсми редакторы В. Бәхтияровтан газетаның хәле турында сорашып торган. Редакторның «Хәзергә Фатих Әмирхан белән икәү генә алып барабыз, язышырга сүз бирүчеләр бар» дигән сүзенә җавап итеп ул: «Алай булганда, мин сезнең өченчегез булам» дип әйткән. 1907 ел, 30 декабрь тарихлы хатында Тукай болай ди: «Үзем теләп кенә «Әлислах»ка хезмәт итәм. Жалованье башка җирдән алам». Бу сүзләрне Габдулла җитди тонда язса да, без биредә ачы юмор ишетәбез: «Әлислах»ка хезмәт итә, жалованьены башка җирдән ала!

Тукайның «Әлислах»ка хезмәт итүе шигырь яисә мәкалә биреп бастыру белән генә чикләнмәгән. Ул редакциягә даими хезмәткәр кебек үк килеп йөргән, киңәш-табыш итүдә, материалларны эшкәр-

түдә катнашкан. Аңа газетаның әдәбият бүлеген алып бару эше тапшырылган. Ләкин... вазифасыз, ягъни хезмәт хакы түләмичә генә.

Нишләмәк кирәк, «Әлислах»ның артында калын кесәле байлар тормый. Газетаны аякка бастырыр өчен кирәкле сумма Ф. Әмирхан белән В. Бәхтияровның үзара салышулары, Фатихның шәхси дусларыннан кайбер хәллерәк яшьләрнең ярдәме һәм шәкертләрдән җыелган тиеннәр хисабына тупланган.

Әмирханның бер хатыннан күренгәнчә, редакциядә бердәнбер кеше, ул да булса газетаның редакторы В. Бәхтияров, 15 сум эш хакы алган. Секретариатка дип билгеләнгән 20 сумны Фатихның эш хакы итеп карап булмый. «Мөхәррирләренә (ягъни язышучыларга) бер дә түләнми диярлек» дигән сүзләрдән без бик сирәк очракта, аерым материалларга гына гонорар бирелгәнлекне аңлыйбыз. Нинди хисаптан? Секретариатка дип тәгаенләгән әнә шул 20 сумнан.

Шул ук вакытта чыгып килгән «Әхбар» газетасының хәле исә — бөтенләй башка. Бу газета Сөләйман Аитов, Садыйк Галикеев, Әхмәтгәрәй Әҗемов, Габделвәли Юнусов, Габделхәмит Казаков кебек Казанның зур байларыннан торган компания акчасына чыгарылган.

Әнә шул «Әхбар»ның җитәкчеләре, яхшы гына эш хакы тәкъдим итеп, Тукайны даими язышучы һәм хезмәткәр итеп эшкә чакыралар. Тукай, башта риза булган кебегрәк күренсә дә, бераздан яңа оешып килә торган «Китап» исемле нәшрият кисәгенә 25 сум айлык белән экспедитор булып урнаша.

Танылган шагыйрьнең, «Әхбар» чакыруын кире кагып, мәдрәсә сабагы алган һәм адрес язарлык русча белгән теләсә кем башкарырлык эшкә керешүенә замандашлары нинди мәгънә бирергә белми аптырыйлар. Габдулла исә, берни булмагандай, дәшми-тынмый эшләп йөри: корректура карый, борын очын тирләтә-тирләтә посылка тегә, тартынмый-нитми шуларны почтага күтәреп китә.

Еллар үткәч кенә бу мәсьәлә ачыклангандай була. Иптәшләренннән берсенә ул болай дип сөйләгән: «Мине «Әхбар»га чакыралар. Мин анда нәрсә бирсәләр, шуны тәрҗемә итәргә һәм һәр номерга 2—3 йөз юл нәрсә язарга тиешле. Минем русчам Уральскидан килгәндә зәгыйфь иде... Бу фәкать минем үз күңелемдә сакланган, ул вакыт беркемгә дә белдерү ихтималым булмаган бер сер... «Әхбар»га кереп, мин үземне сынатырга бер дә теләми идем».

«Уральскидан килгәндә русчам зәгыйфь иде» дигән сүзләрендә вәсвәсәгә бирелеп арттыру бар. Дөрес, русчаны ана сөте белән биргә үзләштерүчеләрдән ул калыша. Әмма татарчаға тәрҗемә итү өчен, рус телен генә түгел, бигрәк тә татар телен яхшы белү кирәк ләбаса. «Әхбар»га урнашса, үз бурычын менә дигән итеп башкару гына түгел, бәлки газетаның да күтәрелә, яхшыра төшүенә ул, һичшиксез, сәбәпче булачак иде. Ләкин бар син, сөйләшеп кара аның белән.

Бу кадәресен без истәлектән белдек. Мемуарчы Тукай сүзләрен арттырмыйча һәм киметмичә, ничек булган шулай китереп җиткергән тәкъдирдә дә Тукайның сынатудан куркып һәм русча җитәрлек белмәвен сәбәп итеп кенә, «Әхбар»га бармый калуына ышанасы килми. Эчке дөньясын теләсә кемгә ачып салырга яратмый торган Тукайның, тирәнгә керергә теләмичә, теленә килгән беренче җавапны әйтеп ташлау гадәте дә «ниндидер бүтән сәбәп булырга тиеш» дигән фикергә китерә. Нинди сәбәп?

«Әхбар» белән бер үк вакытта Тукайга икенче бер тәкъдим дә була. «Әле Оренбургтан да мине чакырып хат килде, — дип яза ул апасы Газизәгә. — «Вакыт» газетасында, «Шура» журналларында эшләргә; 40 тәңкә айга жалованье бирәләр. Ләкин мин хәзергә анда бара алмыйм. Оренбург язучылары илә газета аркылы бераз чәкәләшеп алган идек».

Күрәсең, монда да шундый ук җиңелчә сылтау табылган. Чынлыкта исә Тукай андый чакыруларны кабул иткән Борһан Шәрәф һәм Кәбир Бәкер кебекләрне:

Безнең урам аркылы ага суның салкыны;
Тарта Казанның яшьләрен Рәмиевләр алтыны,

— дигән сатирик куплет белән тамгалады. Һәм ул китә дә алмый иде. Сәбәбе Фатих Әмирханга язган хатыннан ук күренә: «Монда «Әлислах» ходка китсә, көлке журналы да чыкса, үземнең кальбән сөйгән газета вә идеямә хезмәт итәр идем». Димәк, Тукайны Оренбургка китүдән, барыннан да элек, «Вакыт» белән «Шура»ның политик юнәлешләре тыеп калган. Әнә бит ул, «Әлислах» газетасының программасына туры килә торган үз идеясенә хезмәт итәргә мөмкинлек булса, Оренбургны телгә алып сөйләп тә тормас иде.

«Әхбар»га килгәндә, аның «Вакыт»тан уңдарак торганы бәхәссез. Шулай булгач, Тукай ни өчен әле «Әхбар»да эшләргә атлыгып торырга тиеш? Иң яхшысы — «жалованьены бүтән төштән», ягъни экспедиторлыгы өчен Габдрахман Дәүләтшиннан алып булса да «Әлислах»та эшләү.

Бар иде беренче татар большевигы Хөсәен Ямашев җитәкчелегендә чыгып килгән «Урал» газетасы. Хөкүмәт аның яшәве белән килешә алмады. Бар иде Галиәсгар Камал чыгарган «Азат халык» газетасы. Әмма ул да кыска гомерле булды. Бар иде татар эсерларының иске дөньяны җимерергә чакырып шау-шу күтәргән «Таң йолдызы» һәм «Тавыш» газеталары. Алар да җан тәслим кылдылар. Бар иде дилбегәсе Тукайның үз кулында булган «Фикер» газетасы. Ул да тегеләр артыннан китеп барды.

Килде бер заман, болар кулыннан төшкән революцион-демократик байракны күтәреп алган бердәнбер газета булып «Әлислах» калды. Әмма аның хәле шәптән түгел. Финанс ягын инде беләбез. Жандарм идарәсе һәм цензура җентекләп күзәтә. Милләтнең үз эчендәге реакцион көчләр төрлечә һөҗүм итәләр. Казан шәһәре ахуны һәм тугыз мулланың имзасы куелып, губернаторга кергән прошениедән, стилен үзгәртмичә, бер генә өзек китерик: «В г. Казани издается с не давных времен татарская газета «Эль-ислах», сотрудниками каковой является из разных наших училищ, в г. Казани, не прилежные к учению ученики, не удовлетворяющими поведениями; цель которых не есть прогрессивность, а напротив возмущающая».

«Әлислах»ның программ мәкаләсеннән без мондый юлларны укыйбыз: «...гыйлем юлларын һәрбер сыйныфка бертигез, ачык итә торган сәяси вә икътисади сәбәпләрне үзләренә максут иткән сәяси хизепләр (ягъни сул партияләр, башлыча социал-демократлар — И. Н.) безнең дусларыбыздыр». Дума эшчәнлегенә күзәтү рәвешендә язылган мәкаләләр циклында Ф. Әмирханның, октябристларны һәм кадетларны тәнкыйть итү белән бергә, меньшевикларга да тел озайтып, большевикларга теләктәшлек белдерүе дә газетаның революцион-демократик юл тотуы турында сөйли иде.

Карагруһчыл һәм либераль-буржуаз юнәлешле газета-журналларның «Әлислах»ны яманлауларына тукталып тормастан, идея дошманнарыннан берсенең «Бәянелхак» «трибунасыннан» торып әйткән сүзләрен китерик. Ул болай ди: «Әлислах», бәнем хосуси фикеремчә, утлары сачрап чыгып тора торган бер янар дагка — тауга охшыйдыр».

Әнә шул рәвешчә, шагыйребезнең «Әхбар»га бармыйча, «Китап» ширкәтенә эшкә керүе, ә төп эш урыны итеп «Әлислах»ны санавы, каләм көчен һәм хезмәтен аңа багышлавы Тукай өчен табигый һәм зарури адым була.

## Әхмәт Фәйзи

# ТУКАЙ

КИНОСЦЕНАРИЙ

* * *

*Күпкырлы талант иясе Әхмәт Фәйзи Г. Тукайның тормышын, иҗатын, иҗтимагый эшчәнлеген тирәнтен өйрәнде. Бөек шагыйрьнең биографиясе, аның әсәрләре әдип өчен иҗат чыганагы да булды. Ул «Тукай» драмасын, «Тукай» романын, шагыйрьнең иҗаты турында күп кенә мәкаләләр, хезмәтләр язды.*

*Бөек Ватан сугышына кадәр үк, Әхмәт Фәйзи халкыбызның бөек шагыйре турында кинофильм чыгаруны оештыру эшләрен башлап йөри. Әмма сценарий либреттосы язылса да, бу матур идеяне тормышка ашырырга сугыш комачаулады.*

*Укучыларыбызга шушы киносценарий либреттосының һәм азакта аны экранлаштыру мәсьәләсенә караган ике рәсми кәгазьнең татарча тексты Рәшит Гәрәй тәрҗемәсендә тәкъдим ителә.*

## Пролог

1891 ел... Кытлыктан җәфа чиккән авыллардан шәһәргә кешеләр, олаулар агыла. Һавадан җиргә түзә алмаслык эсселек бөркелә...



Юлда яңа чыпталар төялгән арба күренә. Анда, олаучының аркасына сыенып, дүрт-биш яшьлек малай утыра. Ул эсселектән хәлсезләнгән һәм ач...

Олау шәһәргә килеп керә.

Казандагы базар мәйданы. Арба өстенә менеп баскан олаучы тирә-якка ишетелерлек итеп кычкырып хәбәр сала:

— Асрамага бала бирәм! Кем ала?

Олау янына өлкән яшьләрдәге бер агай килеп туктый. Ул малайның башыннан сыйпый һәм, кулындагы төргәген чишеп, аңа клиндер бирә. Малай комсызланып ашый. Олылар сөйләшкән арада ул мыжлап торган халык эченә кереп югала...

Менә ул карусель янында. Бөтен дөньясын онытып, балаларның карусель әйләнгәннәрен күзәтә. Әйбәт өс-башлы малайлар аның киеменең күп ямаулы булуыннан көләләр, карусельдә әйләнергә бер тиен дә акчасы булмавын белеп мәсхәрәлиләр. Аларның берсе бик нык тотлыга. Үксез малай, кызык итеп, нәкъ ул булып тотлыга-тотлыга аны үрти һәм шуның белән халыкны көлдерә. Бу исә тотлыгып сөйләүче малайның бик нык ачуын китерә, ул йодрыкларын төйнәп, үксез малайга ташлана. Ул арада малайны эзләүчеләр килеп җитә. Өлкән яшьтәге әлеге агай аны үзләренә, Яңа бистәгә алып кайтып китә...

1

Уналты ел вакыт уза...

1907 елның көзе. Уральскидан Казанга яшь егет Габдулла Тукай килә. Аның өстендә авылча тегелгән һәм шактый искергән пальто. Кулында шәкерт сандыгы. Бөтен багажы: бер пар күлмәк-ыштан, язып тутырылган дәфтәрләр һәм Пушкинның таушалып беткән томы. Күзләренең елмаюлы, дәртле карашы прологта без карусель янында күргән үксез малайны хәтерләтә.

Ни гомерләрдән бирле күрергә хыялланган Казанга килү шатлыгыннан ул тирән дулкынлану кичерә. Монда ул яраткан язучыларын, ниһаять, үз күзләре белән күрәчәк, алар белән якыннан танышачак. Кем белә, бәлки алар аны да үз араларына алырлар. Әгәр шулай булса, алар белән ул кулга-кул тотынып эшләячәк, туган халкының бәхете хакына бөтен көчен биреп бергә көрәшәчәк.

Кечкенә Уральск шәһәренә күнеккән Тукай, зур Казан каласына килеп кергәч, кинәт бөтенләй каушап кала. Аның өчен монда — Казанның буржуаз яшьләре җәмгыятендә — бөтенесе дә кирәгеннән артык купшы һәм ясалма. Ул үзенең провинциаль шәкерт хәлендә булуыннан чиктән тыш уңайсызлана.

Укучы яшьләрнең алдынгы карашлы газетасы «Әлислах» редакциясенә беренче тапкыр килеп кергәч, ул хәтта үзенең кем икәнлеген әйтергә дә батырчылык итми. Менә ул — редакторның кабул итү бүлмәсендә. Тукайның Казанга китүе турында Уральскидан хәбәр алырга өлгергән яшьләр, аның инде монда утыруын уйларына да китермичә, талантлы шагыйрьне ничегрәк итеп тантаналы төстә каршылау турында киңәшәләр.

Халык арасында исеме киң таралган булуын уена да китермәгән Тукай башта үз колакларына үзе ышанмый. Башкалар сүзенә кушыларга теләп каравы да уңай нәтиҗә бирми. Эш эзләргә килгән берәр шәкерттер дип уйлап, аңа һичкем игътибар итми.

Тукай бәлки аларга үзенең кем икәнлеген дә ачып салган булыр иде. Ләкин биредәге курсисткаларның берсе — сөйкемле кыз Әминәнең Тукайны күрергә хыяллануы, башка курсисткаларның да аның шигырьләрен яттан белүләре, Тукайны зур, көчле, дәртле һәм ялкынлы карашлы кеше итеп күзалдына китерүләре турында сөйләве шагыйрьне бөтенләй кыен хәлдә калдыра. Ябык йөзле шәкерткә редакторның кабул итү бүлмәсеннән тизрәк чыгып китүдән башка чара калмый.

Тукайның килүе турындагы хәбәр тиз арада барлык редакцияләргә һәм нәшриятларга таралып өлгерә. Номерында Тукайны беренче булып өлгер нәшир-конкурентлар: бай либерал Шәриф һәм миллио-

нер Хәсән байның ышанычлы кешесе Шәмсетдин эзләп таба. Елгыр Шәриф, ничек итсә итә, әмма Уральск газеталарында һәм журналларында басылган шигырьләрен аерым җыентык итеп чыгару хокукыннан файдалану өчен Тукайга алдан ук 30 сум акча биреп куя.

Утыз сум! Тукайның мондый күп акчаны әле гомерендә дә күргәне юк.

Бу «уңыш»тан башы әйләнгән шагыйрь кибеттән-кибеткә чаба һәм үзенә эшләпә, галстук, ак якалар, манжетлар сатып ала... Бу әйберләр аңа, әгәр йөзгә-йөз очрашырга туры килсә, Казанның «алтын яшьләре» алдында оятка калмас өчен кирәк. Әмма бу әйберләргә ничек иялэшергә? Аның бит моның ише нәрсәләрне беркайчан да киеп яки тагып йөргәне юк. Шунда Тукайга гостиница официанты ярдәмгә килә. Чиксез куануыннан әле һаман тынычланып җитә алмаган беркатлы һәм эчкерсез шагыйрь үзен киендереп азапланучы официантка, әллә кайчан басылган шигырьләрен сатып, капиталистны ярык тагаракка утыртуы турында сөйли.

Киенү-ясану тәмам. Үз үлчәвенә якын да килмәгән зур эшләпә, яка һәм аның өчен ят булган башка шундый нәрсәләр кигәч, Тукай көлке булып күренә. Ләкин шагыйрьнең моңа бер дә исе китми. Үзен Казан кешеседәй хис итеп, зур тәкәллефлек белән урам буйлап атлый.

Әмма аның бу нәзакәтлелеге артык озакка бармый: карашы якында гына кузна уйнап мәш килгән балалар төркеменә төшә. Барган җиреннән туктап, ул шуларны күзәтеп тора башлый: бала чагында ул үзе дә кузнаны бик оста уйный иде бит!

Бу мавыктыргыч уен аны тагын үзенә тарта. Ул, пинжәген салып, күлмәк җиңнәрен сызгана да кузна уйнарга тотына.

Менә ул балалар белән бергә урам буйлап бара һәм аларга уенчыклар, тәм-томнар сатып ала. Ниһаять, алар карусель янына килеп җитәләр.

Тукай карусель өчен бөтен бер сеанска акча түли, аннан барлык урыннарга малайларны утырта. Ә үзе карап торуга иң ямьсез һәм шәфкатьсез булып күренгән атка менеп атлана.

Тукайның Казанга килүен ишеткән яшьләр дөнья бетереп аны эзлиләр.

Базар яныннан, пролеткага утырып, драматург Камал һәм беренче татар большевигы, социал-демократларның татар телендә чыга торган «Урал» газетасы редакторы Ямашев узып бара. Аларның да Тукайны эзләүләре.

Урамнан безгә таныш официантның килгәне күренә. Камал, атны туктатып, официанттан Тукай турында сорый. Официант Тукайны инде иртәдән бирле сорауларын, ләкин аның кайда икәнлеген белмәвен әйтә. Бераздан ул, карусель яныннан узып барышлый, анда Тукайны күреп ала. Базар эченнән йөгереп чыга да кузгалып киткән пролетка артыннан кычкыра. Пролетка кире борыла.

Камал белән Ямашев Тукайның карусельдә әйләнеп бетерүен көтәләр.

Очрашу. Камал кинәт каушап калган Тукайны кочаклап ала һәм үбә.

— Кысанлыкта үткән бала чагымның үчен кайтардым, — ди Тукай уңайсызланып кына.

Яшьләр арасында «философ» дип йөртелүче доктор Хәнәфи дусты эстет-шагыйрь Бикчәнтәйгә Тукайны «таңчылар» (татар эсерлары) ягына тартырга тәкъдим итә. Югыйсә, аның карашынча, Тукайны «уралчылар» (татар социал-демократлары) кулга төшерәчәкләр һәм аны «таңчылар»га каршы файдаланачаклар. Бикчәнтәй Хәнәфинең шикләнүен һаваланып кире кага. Аның фикеренчә, Тукай — көчсез һәм ярдәмчесез авыл шәкерте — шөһрәтле, атаклы кеше санап, аның каршына үзе киләчәк.

Курсисткалар, шул нәүбәттән Әминә дә, Бикчәнтәй һәм Хәнәфидән үзләрен Тукай белән таныштыруларын үтенәләр.

Яраткан кызларының сорауларын кире кагарга теләмичә һәм Хәнәфинең катгый таләбенә буйсынып, Бикчәнтәй аларны Тукай янына озата барырга ризалык бирә.

Тукай бүлмәсе. Өч кешенең: Тукай, Ямашев һәм Камалның эчкерсез әңгәмәсе. Тукай, искиткеч бер матур кыз алдында үзен танытырга теләмичә, редакциядән ничек качып чыгып китүе турында сөйли.

Официант керә һәм Тукайга визит карточкалары бирә. Бу карточкаларның мәгънәсен аңламаган Тукай аларны Камалга суза. Камал алып укый да Тукайга кунаклар килгәнлеген, алар арасында Әминәнең дә булуын әйтә. Әминә исемен ишетүгә, Тукай куркынып урыныннан сикереп тора:

— Әминә? Моның булуы мөмкин түгел. Бар, чыгып әйт: Тукай беркемне дә кабул итә алмый, ул... чишенеп яткан, диген.

Камал шаркылдап көлеп ала, юрганга инде төренеп тә өлгергән Тукайны урыннан өстерәп төшерә һәм кунакларга ишекне киереп ача.

Гимназистка Хәят Тукайга чәчәкләр бүләк итә. Әминәнең чәчәкләре юк.

— Мин сезгә чәчәкләр алып килмәдем, чөнки алар көзге чәчәкләр, — ди Әминә елмаеп.

— Мин сездән язгыларын көтәчәкмен,—дип җавап кайтара каушап калган Тукай.

Талантлы шагыйрь, индивидуалист Сәгыйть Рәмиев, Дәүләт думасы члены, буржуаз милләтче Мәхмүди һәм журналист Рәшиди керәләр.

Тәбрикләүләр. Тостлар. Тукайдан үзенең шигырьләрен укуны сорыйлар. Тукай шигыренең:

> Шикләнмибез дошманнарның көченнән без,
> Бүгенге көн Гали, Рөстәмнәргә тиң без;
> Шагыйрь гомере хәсрәт, кайгы күрсә күрер —
> Дулкынланмый тормый ич соң өлкән диңгез,

— дигән соңгы юлларын бөтенесе дә күтәреп алалар һәм көйләп җырлыйлар. (Бу җыр төрле уңай белән киноповестьның буеннан-буена кабатланып бара.)

Самими, дусларча бу очрашудан канәгать калган Тукай һәммәсенә ишетелерлек итеп сорый: «Арабызда Әмирхан гына юк. Кайда ул? (Әмирхан соңыннан Тукайның дусты, татар әдәбияты классигы, прогрессив яшьләр хәрәкәтен оештыручыларның берсе.) Кемдер Әмирханның авырып ятуын әйтә.

Тукайның гомумән һәм аерым алганда Әминә алдында шундый уңыш казануы Бикчәнтәйне көнләштерә. Бу башта аның Тукайдан

дусларча, шаярган булып көлүендә, соңыннан ул көлүнең зәһәрләнә баруында күренә. Ниһаять, Тукай аңа тапкыр сүзләр белән җавап кайтара. Бүлмәдәгеләр, Тукайның җавабын хуплап, рәхәтләнеп көләләр. Бикчәнтәй Тукайга кайсы яктан суктырырга кирәклеген чамалап, ярлы һәм кызганыч шәкерт буе җитмәслек ширкәткә һәм малмөлкәте ягыннан үзенә тиң булмаган кызга үрелә, дип төрттерә. Шулчак ул, ачуына чыдаша алмыйча, бик нык тотлыгып, ниндидер сүздә төртелеп кала. Чагыштырып уйланулар шунда ук Тукайны еракта калган бала чагына — карусель янында бай малайларының берсе нәкъ менә хәзерге шикелле тотлыга-тотлыга аны кимсетергә теләгән көннәргә алып китә. Бу шул малай үзе түгелме соң?

Кинәт шагыйрьнең күзаллары караңгыланып киткәндәй була. Яшьләрнең, шул җөмләдән ул инде чын-чынлап яратып өлгергән Әминәнең, аңа булган бу игътибары шагыйрьгә алдан ук, уйлап хәзерләнгән мыскыллау, мәсхәрә итү булып тоела.

Бикчәнтәйнең кыланышы өчен гафу үтенеп, Әминә үзенең дус кызы белән Тукай янына килә. Ләкин шагыйрь инде аны тыңларга теләми.

— Кирәкми. Юатмагыз мине. Ярлы шәкерт булуымны да, Казан обществосына лаек түгеллегемне дә мин белә идем... Нинди шайтан котыртты соң мине монда, Казанга килергә... Ярый, калсын... Ярлы шәкерткә сабак бирүегез өчен сезгә зур рәхмәт... Хушыгыз!

Кул да биреп тормыйча, кызлар яныннан китә...

Камал Бикчәнтәйнең кылануында бернинди дә гаебе булмаган кызны шулай чыгарып җибәрүе өчен Тукайны әрли.

— Мин ярлы, әмма горур, — дип җавап кайтара Тукай һәм әйберләрен кәрзиненә тутыра башлый.

— Нишләмәкче буласың? — дип сорый аннан Камал.

— Китәм.

— Кая?

— Мин бары тик Казаннан китәчәгемне генә беләм.

Шул вакыт, таякка таянып, авыру Әмирхан килеп керә.

— Нишләп син урыныңнан тордың? Синең яныңа без бит үзебез барырга җыенган идек.

— Авырып ятар чакмыни? — Әмирхан барысына да күз йөртеп чыга. — Сез әллә бер нәрсә дә ишетмәдегезме?

Әмирхан революциянең тулысынча тар-мар ителүе, полиция тарафыннан күп кенә газеталарның, мәктәпләрнең, китапханәләрнең ябылуы, халыкның иң яхшы улларының кулга алынуы турында сөйли.

Ул үзе әзерләгән протест текстына кул куярга тәкъдим ясый.

Куркуга төшкән милләтчеләр сиздермичә генә чыгып сызалар. Социалист-революционерлар партиясендә булуы белән һәр вакыт мактанып йөргән Бикчәнтәй дә шүрләп кала — ул, үзенең куркаклыгын «кәгазьдәге» протестта катнашырга теләмәве белән аңлатып һәм үзен мондый юк-бар эштән өстен санап, протестка кул куймыйча чыгып китә.

Рәмиев икеләнә.

— Безнең бунтарь һәм тумыштан ук протестант каушап калдымы әллә? Моны ничек аңларга? — ди Әмирхан.

Рәмиев кул куя.

Хәнәфи барысының да имзалары куелган протест текстын кулына ала һәм күперенке тирада сөйли:

— Гаделлек тантана итәчәк көн килеп җитәр! — ди ул. Ләкин текстка кул куймый, аны кесәсенә яшерә һәм протестны үзе илтеп тапшырачагын әйтә.

Бүлмәдә — Тукай, Камал, Ямашев һәм Әмирхан. Сырхавы бик каты көчәйгән Әмирханны җайлап кына урынга яткыралар.

— Нәрсә, китәсеңме? — дип сорый Камал Тукайдан.

Әмирхан алып килгән хәбәр, кинәт кабынган магний уты шикелле, моңарчы шагыйрь күзенә чалынмаган бик күп нәрсәне яктырта. Шушы яктылыкта ул әлеге яшьләрнең чын йөзен күрә. Алар арасында нык характерлы, куркусыз һәм чыдам кешеләр бик-бик аз икән! Тукай менә шушы азчылык сафында калырга карар кыла. Чөнки ул бүтән теләсә нинди җирдәгегә караганда да кирәгрәк.

— Китмим, — дип җавап бирә Тукай Камалның соравына.

...Шушы ук вакытта эсер Бикчәнтәй китапханә заллары буйлап йөренә. Менә ул бер төргәк газеталар сорап ала һәм, шуларны укып утырганга салынып, як-ягына каракларча карана-карана, патша хөкүмәте алдында тегеләйме-болаймы үзен яманатлы итәчәк мәкаләләрне сиздермичә генә кисеп ала.

3

Печән базары (иске Казанның атаклы толчугы шулай дип йөртелгән). Төрле исемнәр белән аталган татар реакционерларының «клубы», дөресрәге, «штабы» шунда урнашкан. Монда алдынгы карашлы яшьләр турында гайбәт һәм ялган хәбәрләр таратыла, дуамал холыклы унтер Җамалый аша донослар җыела. Европача киенгән татар яшьләрен бу базар янынннан мәсхәрәләп, ә кайчагында һичбер сәбәпсез кыйнап озаталар.

«Печән базары патшасы» аксак Хафиз янына Ишми ишан килә. (Ул — Түнтәр авылы мулласы, татар карагруһчыларының рухи атасы, революциядән соң, совет властеның явыз дошманы буларак, атып үтерелә.)

Ишми, шәригать өйрәтүләренә таянып, болай дип тәкърарлый:

— Тар балакларны үтергән мөселман алла каршында бернинди дә гөнаһ кылмый...

Урамнан, изгеләр рәсеме төшерелгән байраклар һәм иконалар күтәреп, динчеләр төркеме уза. Болар — контрреволюциянең җиңүен бәйрәм итәргә, патша саулыгы хөрмәтенә гыйбадәт кылырга баручы рус карагруһчылары.

Ишми тәкъдиме белән, Печән базары әһелләре аларны аягүрә басып, тәкбир әйтеп каршылыйлар, аннан соң куана-куана Хафиз кибете янына киләләр. Хафиз аларны үзе итәк астыннан гына сата торган опиум белән сыйлый. Карагруһчылар революцияне бастырганда, яшьләрдән үч алганда күрсәткән «батырлыклары» белән мактаналар. Аларның фикеренчә, тар балаклыларның кояшы кабат мәңге чыкмаска батты. Ләкин нәкъ шушы минутта базар буйлап газета сатучылар кычкырып үтә:

— Яшен! Яшен!

Аптырашта калган әлеге базар әһелләре, башларын югары күтәреп, күккә карый:

— Нинди яшен? Күктә бернинди болыт әсәре дә күренми ләбаса.

Ниһаять, ачыклана: Камал белән Тукай оештырган сатирик журналның беренче саны басылып чыккан икән.

«Яшен»нең үткен уклары барлык реакционерларга, карагруһчыларга, шулай ук революциягә хыянәт итүчеләргә, прогрессив яшьләр лагерендагы куркакларга каты кадала.

Бу уклар хәтта Мөфти (Россия мөселманнарының рухани идарәсе башлыгы) һәм Гаспринский (Россия мөселманнары союзы җитәкчесе) һәм башка шундый дәрәҗәле кешеләрне дә аямый.

Тукайның сатирик шигырьләре революция җиңелгәннән соң тынычланып калган «Печән базарына» чыннан да аяз көндә суккан куркынычлы яшен кебек тәэсир итә.

Ярсыган базар, сайлаучыларның танышларын сатып алу юлы белән, Дәүләт думасына узган депутат Мәхмүди утырган тарантасны туктатып, аны төрле яктан урап алалар.

— Ни өчен син тар балакларның мөселманнардан көлүенә юл куясың?

— Шарларны кире бир! (Сүз тавыш биргәндә аның өчен тәгәрәткән шарлар хакында бара.)

— Син узындыргансың аларны!

— Бәлки син аларның журналында үзең дә катнашасыңдыр әле?

Мәхмүди, тиресеннән чыгардай булып, үзенең бөтен гомерен милләтне берләштерү, картлар белән яшьләрне, байлар белән ярлыларны татулаштыру идеясенә хезмәт итүгә багышлавын исбатларга тели.

— Менә шуңа күрә дә, — ди ул, — Дәүләт думасына үзенең депутаты итеп милләт нәкъ мине сайлауны мәгъкуль күрде.

— Ә менә мин сине сайламадым,—дип кычкыра Мәхмүдине тыңларга бер генә минутка туктаган эшче Гафур. Аның янында иптәше Васильев басып тора.

— Аны без, мөселманнар, сайладык, — дип җавап кайтара Гафурга базардагыларның берсе.

— Паспортымда минем дә «мөселман» дип язылган. Алайса, аны мин дә сайлаган булып чыгаммыни? — дип сорый Гафур.

— Әйе, сез дә, — ди Мәхмүди.

— Әгәр шулай икән, ни өчен син Думада, бездә Гафур Гайнетдинов юк, дип сөйләдең?

— Туганым минем... — Аңа кулын сузып, Мәхмүди нидер әйтмәкче була. Ләкин Гафур аны бүлдерә:

— Ялгышасың, мин синең туганың түгел. Ә менә Андрюша (янында басып торган иптәшенә күрсәтә), иптәш Васильев, минем чын туганым. Аның да, минеке шикелле үк, сукыр бер тиен дә акчасы юк. Аның каравы, кулындагы сөялләр сезнең кебекләргә әҗәткә өләшсәң дә бетәрлек түгел.

Бу сүзләрне ишетүгә, базар тагын шаулаша башлый:

— Кяфер, кяфер!

— Юк, туктагыз! — дип кычкыра Гафур аларга, йодрыгы белән прилавкага сугып. Сатар өчен тезеп куелган түбәтәйләр пирамидасы идәнгә ава. — Без инде сезне бик күп тыңладык, хәзер сез дә безне тыңлагыз... Ярый, анысы калып торсын, — дип дәвам итә ул Мәхмүдигә карап. — Гафурның үзе турында син анда бер сүз дә әйтмәдең дип фараз итик... Берлек санда Гафур нәрсә ул? Бер бөртек тузан! Өрдең исә Гафур юк дигән сүз. Ләкин бит син зуррагын әйттең. Бездә гомумән эшчеләр юк, дидең син. Шулай дип әйттең бит?

— Әйе, әйттем: бездә капиталистларга һәм эшчеләргә, ярлыларга һәм байларга гомумән бүленү юк, бездә бердәм милләт кенә бар, дидем... Бәлки сез шул хактадыр?

— Менә, менә, менә! Ниһаять, үзе икърар итте. Димәк, болай килеп чыга: милләт бар, ә Гафур Гайнетдинов юк. Шулай килеп чыга түгелме соң, ә?

Кычкырып көлүләр, шау-шу... Начар өс-башлы кешеләрнең—эшчеләр, һөнәрчеләр, шәкертләрнең хуплавы... Печән базары әһелләре, йодрыкларын төйнәп, яшьләр өстенә киләләр. Мәхмүди аларны туктатмакчы була.

— Милли туганнар, мөселманнар, — дип акыра ул. — Исламның яшел байрагы тирәсенә тупланыйк, кяферләргә үрнәк күрсәтик!

Ике арада якалашу, көрмәкләшү башлангач, халык арасыннан төрткәләп чыгарылган Мәхмүди, кемдер йодрык кундырган чигәсен ышкый-ышкый, нишләргә белмичә, бер як читтә басып тора һәм үзалдына сөйләнә:

— Милләт бердәмлеген яклап утыз ел буе көрәштем... Менә кирәк булса шуның өчен сиңа бүләк...

«Яшен» журналы битләре. Чигәсендәге шешне ышкып, аптыраштa басып торган Мәхмүди карикатурасы. Аның астында түбәндәге сүзләр:

«Милләт бердәмлеген яклап утыз ел буе көрәштем... Менә кирәк булса шуның өчен сиңа бүләк»...

Мәхмүди журналны бер читкә атып бәрә.

Мәдрәсәдә шәкертләр муллага һәм коры фәлсәфә белән мавыгучы иске карашлы мөгаллимнәргә каршы баш күтәрәләр. Алар шәкертләр гимнын җырлый.

Мәдрәсә башлыгы чакыруы буенча килгән полиция приставы кулга алынган шәкерткә алар җырлаган җырны кабатларга куша. Шәкерт гимнны җырлый.

— Кем язды моны? — дип сорый полицейский.

— Тукай! — дип, шәкерт өчен мулла җавап бирә. — Фетнәче...

4

Әминә Тукайның «...гә» дип аталган шигырен укый һәм:

— Сөя ул мине, сөя, — ди, яшерен шатлык белән.

Ул чиксез бәхетле.

Сәхнәдән Тукай шигырьләре укыла (яки җырлана). Аларны йотлыгып тыңлыйлар, кешеләрнең күзләре яшьләнә.

Тукайның даны иң югары ноктага күтәрелгән чак. Аның янына башка шәһәрләрдән бай нәширләр килә. Аларның берсе — миллионер Кәбир бай. Тукайга ул яңа зур газетага редактор урынын тәкъдим итә. Аңа материаль яктан тулы бәйсезлек вәгъдәли.

— Ә рухи бәйсезлек? — дип сорый аннан Тукай. Аның искелекне фаш итүче бәйсез каләмен алтын чылбыр белән богауларга теләүләрен ул яхшы аңлый.

Миллионерның тәкъдимен шагыйрь кире кага һәм алар оештырган яңа эшнең асылын: милли бердәмлек турында ялган сүзләр сөйләп хезмәт халкының уртак ватаны булган Россиягә мәхәббәтен сүндереп, милли дошманлык хисләре тудырырга омтылу икәнлеген фаш итә.

Реакционерлар Тукайга каршы имза җыялар. Протест кәгазенә аксөякләр, аристократлар, муллалар, Печән базары әһелләре һәм Тукай тәнкыйтьләгән яшьләр, шул җөмләдән Мәхмүди, Бикчәнтәй, Рәшиди һәм башкалар кул куя. Протестка кул куярга үзенә чират җиткәч, Хәнәфи аны, революцион яшьләр төркеменең алкышлавы астында, демонстратив рәвештә вак кына кисәкләргә ерткалап ташлый.

Ләкин бу — Хәнәфинең хәйләкәр маневры гына. Болай эшләп ул Тукайны сөюче революцион карашлы яшьләрдә яклау табарга ты-

рыша. Бу исә аларның яшьләргә һәм Тукайга каршы корган мәкерле ниятләрен тормышка ашыруны җиңеләйтәчәк. Бикчәнтәйнең: «Ни өчен протестны ертып ташладың?» — дигән соравына ул тыныч кына болай дип җавап бирә:

— Беренчедән, Тукайга каршы язылган мондый протестны басып чыгарырга бер генә газета да батырчылык итә алмаячак. Аны басып чыгару халыкны Тукайга түгел, ә бәлки хат авторларының үзләренә каршы аякка бастырачак. Икенчедән, югары дәрәҗәдәге шәхесләрне мыскыллап әйткән сүзләрен матбугат аша Тукайның үзе кире алуына ирешкәндә күп тапкыр эффектлырак булачак.

— Дөрес әйтәсең, — ди Бикчәнтәй, аның белән килешеп.

Җитәкчесе Мәхмүди булган «рәнҗетелгәннәр делегациясе» Тукайга килә. Мәхмүди, бик нәзакәтле генә итеп, Тукайдан милләткә һәм исламга хезмәт итүчеләргә карата әйткән мыскыллау сүзләрен кире алуын, шуның белән ике арадагы аңлашылмаучылыкны бетерүне сорый.

— Без сезнең белән милләт арасында аерымлык булуын теләмибез, чөнки без сезне үзебезнең милли талантыбыз буларак бәялибез һәм яратабыз, — ди Мәхмүди.

Бераз уйланып торганнан соң, Тукай Мәхмүдидән сорый:

— Ә сез курай уйный беләсезме?

Мәхмүди аңа курайда уйный белмәвен һәм мондый сорауларның урынсыз икәнлеген әйтә. Шаярып сөйләшүне бер читкә куеп торыйк, ди ул.

— Минем шаярырга вакытым юк, — ди Тукай. — Мин бу сорауны шуңа бирдем: Уральскида чагымда милләт турында нәкъ сезнең кебек кайгырткан булып йөрүче ифрат та эшлексез бер шәкертне белә идем мин. Минем аны җенем сөймәде. Әмма бервакыт ул курайда шундый итеп уйнап җибәрде ки, мин аның моңыннан таңга калдым һәм ул шәкертнең томаналыгын гафу иттем. Ә менә сез курайда да уйный белмисез икән.

Тукайның килешмәүчәнлеген күреп ярсыган милләтчеләр шагыйрьне туктаусыз әзәрлекли башлыйлар.

Ресторан. Искиткеч мул итеп әзерләнгән өстәл янында Бикчәнтәй, Хәнәфи һәм Рәмиев утыра.

Бикчәнтәй белән Хәнәфи Рәмиевне Тукайга каршы котырталар.

— Кара әле, — ди Бикчәнтәй Рәмиевкә, — безнең әдәби күгебездә дә йолдыз булып син түгел, Тукай калка. Бу ничек булып чыга соң инде? Син бит безнең чаңыбыз, ә Тукай нибары бер шалтыравык кына.

— Ул — талант! — дип, ихлас күңелдән каршы төшә Рәмиев.

— Ә син — даһи.

Йомшак ихтыярлы Рәмиев ялагайланып, икейөзлеләнеп әйтелгән бу мактауны кире кага алмый. Ул дәшми.

Эстрадада балерина Чарская чыгыш ясый.

— Күренекле меценат Стахеевның сәяркәсе! — дип белдерә Хәнәфи.

— Менә! — дип кычкырып җибәрә Бикчәнтәй, Хәнәфи авызыннан «меценат» сүзен ишетеп. — Безгә бай меценат кирәк, шул чагында синең җырың яңадан бөтен көченә яңгыраячак, Сәгыйть!

— Нинди меценат?

— Әйтик, миллионер Кәбир бай... Тукайлар, Камаллар һәм Әмирханнардан башка чыгарыла торган бай журнал... Аларның ярлы журналларына һәм газеталарына каршы тора алырлык журнал... Ул чагында каюк аларга!

— Сез минем миллионер Кәбирнең сөяркәсе булуымны күздә тотасызмы? Ә-ә, менә ни өчен мин даһи, ә Тукай шалтыравык икән. Минем алдымда Тукай турында мондый сүзләр әйтергә юл куймам!

Кызмача Рәмиев җәнҗал куптарырга әзер. Ләкин Хәнәфи, аңа таба иелеп, пышылдап кына әйтә:

— Тукай, Әмирхан, Камал һәм башкалар кул куйган протесттагы имзаң синең тормышыңда бөтенләй көтелмәгән нәтиҗәләр китереп чыгаруы мөмкин. Өстәвенә, кайбер урыннарда һәм кайбер кешеләрдә синең өстеңнән язылган донесениеләр дә бар.

— Боларның бөтенесе сиңа каян билгеле? — дип сорый Рәмиев, аптыраудан кинәт айный төшеп.

— Каян икәнлеген белүнең сиңа кирәге юк. Син белмәгән кайбер нәрсәләрнең синең юрист дустыңа билгеле булуы бер дә гаҗәп түгел. Ләкин син тынычлан. Барысын да үзем җайга салырмын. Ә сиңа хәзергә үзеңнең бунтарь, тормышка ашуы мөмкин булмаган хыялларыңнан арынып торырга туры киләчәк.

Тукайны эзәрлекләү әнә шулай оештырыла, Рәмиевне охранкага «эшкә» тарту әнә шулай тормышка ашырыла башлый.

5

Тукай белән Камал редакциядә эшләп утыралар. Тәрәзәдән караган Тукай, урамда нәрсәдер күреп, урыныннан сикереп тора һәм, үзен баштанаяк күздән кичереп, чәчен, галстугын төзәтергә тотына.

— Бөтенләй агарынып киттең, нәрсә булды сиңа? — дип сорый Камал.

— Нишләп агарыныйм ди мин?.. Каян уйлап чыгардың әле моны?

Иптәш кызы гимназистка Хәят белән Әминә килеп керә. Икесе дә пөхтә итеп киенгәннәр.

— Тукай биредә юкмы әллә?

Камал як-ягына каранып ала да, берни дә аңламыйча, кулларын шулай ук як-якка җәеп җибәрә:

— Кай арада юкка чыккан... Әле генә менә шушында иде бит...

Әминә үз өйләрендә. Аның күзләренә яшь тулган, елап җибәрмәс өчен иреннәрен тешли:

— Ул минем белән хәтта очрашырга да теләми.

Хәят аны тынычландырырга тырыша.

Редакция бүлмәсе... Тукай Әминә калдырып киткән перчаткаларны үбә...

Кабан күле буе — Тукайның ял итәргә яраткан урыны.

Кич. Күл өстендә беренче йолдызның шәүләсе тирбәлә.

Камал Тукайны Әминә белән очрашудан качып йөрүе өчен шелтәли. Тукай үзенең чиксез көчле, әмма горур сөю белән янганлыгын әйтә. Бу хакта ул Әминәгә белдерергә тартына, ул мине аңламас һәм

иң изге хисләрем мәсхәрәләнер, аяк астына салынып тапталыр дип курка.

Камал аңа шулай һавада очып йөрмәскә, җиргәрәк төшәргә киңәш итә.

— Мин — җирнеке, хәтта кирәгеннән артык җирнеке мин, — ди Тукай. — Җиргә мин бөтен барлыгым белән береккән. Мин аны әлеге салкыннары, фәкыйрьлеге һәм бөтен шыксызлыгы белән яратам. Нәкъ менә шуның өчен дә минем кебек бер йолкыш шәкертнең аңа ни кирәге бар, дип уйлыйм... Аның миннән өстенрәк, баерак һәм көчлерәк табынучылары аздыр дисеңмени? Тик мин аны шулай да яратачакмын... Без күзебезнең явын алырлык булып балкыган йолдызга карап сокланабыз. Ләкин ул үзе безне күрәме-юкмы, бу хакта уйламыйбыз.



Редакция булмәсе. Бикчәнтәй килеп керә һәм, анда беркем дә булмагач, эч пошудан почтаны актара башлый. Аның күзе таныш кул белән язылган конвертка төшә. Бикчәнтәй хатны кесәсенә яшерә.

Һәм менә ул аны Хәнәфигә укый:

«Миңа Казаннан китәргәме, әллә анда калыргамы — моны мин үземнең бөтен тормышымны багышлаган кеше генә — бары тик сез генә хәл итә аласыз».

Бу — Әминәнең Тукайга язган хаты.

— Тукай хакында минем сиңа кисәтүем хәтереңдәме?— ди Хәнәфи Бикчәнтәйгә. — Ул вакытта син аның көченә бәя биреп җиткермәдең. Ә ул, йолкыш шәкерт, башта синең даныңа ия булды, хәзер менә сөйгән кызыңны кулыңнан тартып ала.

Хәнәфи, Бикчәнтәй һәм аларның иярчене Рәшиди, Әминә алдында гүя ялгышып кына, Тукайның сөюе турында сүз кузгаталар. Үзен Тукайның мәхәббәт турындагы барлык шигырьләрен яхшы белүче дип санаган Рәшиди, шагыйрьнең «...гә» дип исемләнгән шигырьләре Хәят исемле гимназисткага багышланган дип әйтеп куя.

Әминә сискәнеп китә, ләкин үзенең дулкынлануын сиздермәскә тырыша.

Әминәнең әти-әнисе Казанда кунакта. Алар янына Бикчәнтәй килә һәм, сер итеп кенә, Әминәнең Тукайга кияүгә чыгарга ниятләгәнен хәбәр итә.

Бу хәбәр муллалардан һәм Казан байларыннан Тукайның «начарлыклары» турында ишетеп белгән ата-ананы хәвефкә төшерә.

— Сиңа кызыгып йөрүче мал-мөлкәтле менә дигән егетләрнең исәбе-хисабы юк, ә син шул фәкыйрьнең нәрсәсенә кызыгасың? — диләр алар Әминәгә.

Алар Әминәне кичекмәстән Казаннан алып китәргә карар итәләр.

6

Тукай нәшриятта иртәдән алып кичкә кадәр экспедитор булып эшли, посылкалар тегә, хәтта аларны почтага үзе илтә, ә төннәрен шигырьләр яза.

Хәлсезләнеп, ул һушын югалта.

Куркып калган Камал, әрле-бирле сугылып, аны аңына китерергә тырыша.

Тукай күзләрен ача һәм, үзенең йомшаклыгыннан уңайсызланып, моңсу гына елмая. Сәламәтлеге турында кайгыртмавы өчен Камал аны бик каты әрли.

— Үзеңне халык өчен корбан итү аз, үзеңне аның өчен саклый да белергә кирәк, — ди ул.

— Һичбер төрле мохтаҗлыклар, дошманнарның һичбер төрле көлүләре минем өчен берни түгел. Бары тик халкым минем хезмәтемне кабул итсен, бары тик аны үзенә кирәк санасын.

Тукай почта актара. Аның күзләре яңа гына килгән газеталарның берсендә басылган имзасыз мәкаләгә төшә.

Бу мәкалә шагыйрь буларак Тукайны түбәнсетә, аны бары тик башкаларны кабатлаучы һәм такмакчы дип атый. Имеш, халык мондый шагыйрьгә мохтаҗ түгел. Имеш, Тукай чын поэзиянең үсеш юлында хәтта киртә булып тора.

Нәрсә бу, дошманнарның Тукай инде күнегә башлаган чираттагы әзәрлекләвеме, әллә риясыз бер кешенең хакыйкатьне ачып салуымы?

Тукайны күңелсез, шомлы уйлар билән алган:

— Кем булуына да карамастан, мәкаләнең авторы бәлки хаклыдыр, Тукайның бәлки халыкка чыннан да кирәге юктыр? Ләкин моның ничек алай булуы мөмкин? Ул бит үзенең бөтен яшьлеген халыкка хезмәт итүгә багышлады, ул бит шуның хакына ничаклы мохтаҗлыклар, авырлыклар кичерде?!

Шул сорау белән ул үзенең дусларына — Камалга, Әмирханга һәм башкаларга мөрәҗәгать итә. Әмма аларның җаваплары Тукайны канәгатьләндерми, чөнки ул, кәефен китәрмәс өчен, дуслары аннан чын дөреслекне яшерәләр дип уйлый.

Кичен Тукай фатирына Хәнәфи килә. Тукай аңа да үзен борчыган шул ук сорауны бирә. «Ул — философ, һәрхәлдә, теләсә нинди дуслык яисә дошманлык карашларыннан өстен тора», — дип уйлый ул Хәнәфи турында. Хәнәфи Тукайны ресторанга чакыра. Тукай риза була, чөнки ул Хәнәфинең сүзен ишетергә, Кара Малайның (ул чорда танылган бер скрипачны шулай дип атаганнар) уйнавын тыңлый-тыңлый, «шешәләрнең тыгыз рәте артында» бушанып алырга тели.

— Минем үз халкыма кирәк түгеллегем чыннан да дөресме? Философ буларак, яшермичә генә шуны әйт әле миңа.

— Әйе, бу дөрес, — ди Хәнәфи. — Юк ул, халыкка хезмәт итү дигән нәрсә юк. Боларның бөтенесе дә бернинди таянычлары булмаган социалистларның саташулары гына. Дон-Кихот заманнары күптән үтте, хәзер бары тик үз-үзеңә генә хезмәт итәргә кирәк. Томана халык төркеменең җитәкчесе булу турында хыяллану буш нәрсә ул. Халык эчендә эреп югалырга, юкка чыгарга, әгәр тәвәккәллегең һәм ихтыяр көчең җитә икән, тормыш белән бөтенләй хушлашырга кирәк. Менә безнең чорның фәлсәфәсе шул. Тагын икенче төрле юл да бар...

— Нинди юл? — дип сорап куя Тукай.

— Синең поэзияңне халык чын-чынлап бәяли торган җиргә китү.

— Нинди җиргә соң ул?

— Төркиягә, Әмин Бюленд, Әхмәт Һашим шикелле поэзия сандугачлары ватанына...

— Төркиягә? Сез Пушкин һәм Лермонтов җырлаган илдә, Белинский һәм Чернышевский ватанында Бюлендны һәм Һашимны сан-

дугач дип атыйсызмы? Төркия хакына Россияне ташлап китәргә кушасызмы? Сез, ахры, минем «Китмибез!» дигән шигырьне укымагансыз.

Ул үзенең шигырен башта утырган килеш Хәнәфигә, аннары халык күп җыелган зур залда аягүрә басып һәм аның соңгы строфасын шушы шигырь уңае белән аны чакырткан жандарм полковнигы бүлмәсендә укый.

Кара йөзләр безне булмас эшкә тәклиф иттеләр:
— Сезгә монда юк ирек, солтан җиренә кит!— диләр.

Китмибез без, безгә анда мондагыдан эш кыен:
Мондагы ун урнына ул җирдә унбиш шпион.

Мондагы төслүктер анда һәм казаклар гаскәре;
Камчылар — шул иске камчы, башкалык — тик фәсләре!

Анда бит бардыр хәзинәне талаучылар, шөкер;
Ач мужиктан соң кисәкне тарткалаучы бар, шөкер!

Без юләрме, үзебезне утка илтеп ник терик?
Бу кызу җирдән чыгып, тагын сәкарьгә ник керик?

Без күчәрбез, иң элек күчсен безем әмсарыбыз,
Һәм дә кайтсын монда үткәргән безем әгъсарыбыз.

Монда тудык, монда үстек, мондадыр безнең әҗәл;
Бәйләмеш бу җиргә безне таңребез (гыйззе вә җәл).

Иң бөек максат безем: — хәр мәмләкәт, хәр Русия!
Тиз генә кузгалмыйбыз без, и гөруһе ру сияһ!

Ап-ачык бу бер җаваптыр, сүздә түгел, басмада:
Если лучше вам, туда сами пожалте, господа!

Жандарм полковнигы кырт кисә:
— Сез... статья буенча суд җаваплылыгына тартыласыз.

## 7

Тукай Ямашев квартирасына бара, ләкин ул, гадәттәгечә, өйдә юк...

Тукай — үз бүлмәсендә. Камал килмәгән.

Тукайны күңелсез, төшенке уйлар биләп алган. Ул үзен шагыйрь буларак халыкка кирәкми икән дигән фикергә килгән. Ә ул халыкка хезмәт итүдән башка яшәүне күз алдына да китерә алмый. Шулай булгач...

Тукайның күзләре кемдер язып өстәлдә калдырган кәгазьгә төшә.

«Бүген унбердә бөтенләй китәм. Әгәр пристаньга төшәргә кирәк дип санамасагыз, хушыгыз! Әминә».

Тукай, вакытның соң булуына һәм юлның ераклыгына да карамастан, караңгыда абына-сөртенә пристаньга йөгерә. Ләкин... пристаньга килеп җитә алмый кала, пароход кузгалып китә.

Идел ярында таң ата. Биек кыя тау өстендә хәрәкәтсез басып торган кешенең силуэты. Шәүлә яктырганнан-яктыра бара. Ул пароход китеп күмелгән якка күзләрен текәгән Тукай булып чыга. Аннан соң ул күз карашын кыя астындагы шаулы йөгерек дулкыннарга күчерә.

Шул урыннан ерак та түгел большевиклар оешмасының яшерен җыелышы бара.

Ямашев берничә татар эшчесе белән бергә килә. Алар арасында Печән базарында булып узган вакыйга буенча безгә таныш эшче Гафур да бар. Ямашев җыелышны оештыручы Михайловны үзе белән бергә килгән татар эшчеләре белән таныштыра.

Михайлов Лена приискаларындагы канлы вакыйгаларга бәйле рәвештә бөтен Россия буенча күтәрелгән стачка һәм забастовка дулкыннары турында сөйли.

— Чигенү чоры бетте, һөҗүм башларга кирәк, — ди ул.

Михайлов Казан заводлары һәм фабрикалары вәкилләренең яшерен җыелышын Кабан күлендә көймәләрдә үткәрергә тәкъдим итә.

...Тукайның күз алдыннан (дулкыннар фонында) үткән тормышның өзек-өзек истәлекләре: Казанга беренче тапкыр аяк баскач туган шатлыклы минутлар, яшьләр белән беренче танышу, Әминә белән очрашу күренешләре бер-бер артлы йөгереп уза.

Тукай ниндидер карарга килгән. Менә ул, упкын читенә басып, өстеннән пальтосын салырга җыена. Ләкин шул вакыт үзенә кемдер дәшкәнне ишетә:

— Шәкерт! Нишлисең син анда? Балтасы суга төшкән кеше шикелле, нигә борыныңны салындырдың?

Һәм бу сүзләрне әйтүче Тукай шигыреннән бер өзек китерә:

Авырлык төшсә, түз, сер бирми-нитми;
Ни хәлләр яшь егеткә килми-китми.

Тукай бөтенләй таныш булмаган кешедән үз шигырен ишетеп, гаҗәпләнеп артына борылып карый. Якында гына безгә таныш эшче Гафур белән Васильев басып тора. Алар, җыелыштан кайтып килешли туктап, яр буенда көймә көтәләр.

— Нишләп син миңа шулай гаҗәпләнеп карыйсың? Әллә бу сүзләрне кем әйткәнлеген белмисеңме? Алайса, мин сиңа аңлатып бирим: безнең Тукай әйткән бу сүзләрне!

— Ә кем соң ул Тукай? — дип сорый кызыксынуы артканнанарта барган шагыйрь.

— О! — ди Гафур, мәгънәле итеп, — Тукай — Тукай ул. Сиңа иш кеше түгел ул, туган!

Тагын берничә эшче һәм Гафурлар янына утырып бер үк янчыктан тәмәке төрүче Тукайны монда күреп гаҗәпләнгән Ямашев килеп туктый.

Ямашев эшчеләрне Тукай белән таныштыра. Эшчеләрдә гаҗәпләнү. Тукай шунда ук эшчеләрнең игътибар үзәгендә кала.

Ул үзен белгән һәм яраткан эшчеләрнең көр күңелле, шат булуларын күреп, кинәт җанланып китә.

Һәм менә ул газетада басылган төрле коткылар, Хәнәфинең җавабы, Әминәнең китүе, үз-үзенә кул салырга җыенуы — барысы-барысы турында да Ямашевка сөйли.

— Шагыйрьнең олылыгы да нәкъ әнә шунда — аның халык белән бергәлеген күреп шашынган милләтчеләрнең аны туктаусыз котыртуларында. Алар — халыкның иң әшәке дошманнары, — ди Ямашев. — Әгәр алар сине мактасалар, бу бик начар булган булыр иде.

Ямашев Тукайны кочаклап ала да, карашын еракка төбәп, хискә бирелә. Азат халык аны үз улы итеп искә алачак, хезмәт иялəре дәүләте матур биналарда шагыйрьләрнең съездларын уздырачак якты киләчәк өчен янып яшәргә, эшләргә һәм көрәшергә кирәклеге, ул биналарның стеналарына Тукайның исемен дә алтын хәрефләр белән уеп язачаклары турында сөйли.

— Без хәзер «Давыл һәм һөҗүм» чоры кичерәбез, — ди Ямашев. — Ләкин без элеккеге чор яшьләренә караганда бәхетлерәк.

Чигенү моментларында аларны оештыручы һәм үз артыннан ияртүче партия булмаган. Хәзер бездә андый партия бар!
Тукай Ямашевтан күңеле күтәрелгән, куанган, халык эше өчен көрәшче булуына чиксез горурланган хәлдә аерыла.



8

Хәнәфи жандарм идарәсенә якшәмбе көнне сәгать алтыда Кабан күлендә көймәләрдә эшчеләрнең яшерен җыелышы билгеләнүен хәбәр итә.

Кабан күле көймәдә йөрүче мещаннар, яшьләр белән мыжгып тора... Музыка, җырлар.

Көймәләрдә шулай ук гармун һәм балалайкалар тоткан эшчеләр. Алар арасында — Михайлов, Ямашев, Гафур, Васильев.

Михайлов тәкъдиме белән заводларда стачка оештыручылар билгеләнә.

Гражданский киемнәр кигән полицейскийлар көймәсе...

Ике арада бәрелеш. Эшчеләр ярга таба ашыга. Полицейскийлар аларның артыннан куа.

Столыпин законнары нәтиҗәсендә газап чигүче татар авылы. Иң әйбәт җирләр хутор байлары кулына күчкән.
Бөлгенлеккә төшкән ярлы Сәйфетдин үзе шикелле үк мал-мөлкәтсез күршесе янында утыра. Күрше малае Тукайның изелгән, фәкыйрь авыл турындагы шигырьләрен кычкырып укый.
Сәйфетдин аларны бирәр кәгазь кисәгенә күчереп бирүне сорый. Аннары ул кәгазьне кесәсенә яшерә.

Укучылар мәктәптә Тукай шигырьләрен хор белән укыйлар.

Урамнан пристав белән бергә Ишми ишан узып бара. Ишми җыр тавышына колак сала һәм приставка нәрсәдер әйтә. Алар мәктәпкә керәләр.

Укытучы — Әминә.
Ишми ишан, яңача укытуның дошманы, мәктәпнең астын өскә китерә: китапларны таратып ташлый, карталарны ерта, глобусларны идәнгә бәреп вата, балаларны таяк белән куып чыгара. Әминә, аларны якларга тырышмакчы булып, приставка мөрәҗәгать итә.
— Ә сезгә кем революцион җырлар җырларга рөхсәт бирде? — дип җавап кайтара аңа пристав.

Мохтаҗлык, ачыктан-ачык һәм яшертен эзәрлекләүләр Тукайны хәлдән тайдырган. Шуңа да карамастан ул, бөтен көчен җигеп, төннәр буе эшләп утыра. Аны эшчеләр белән очрашудан һәм Ямашев белән сөйләшүдән соң үзенең халыкка кирәклеген тою рухландыра.

Иптәшләре, сәламәтлеген сакламаган өчен, Тукайны орышалар. Камал аны көчләп йокларга яткыра.

Тукайны йокы алмый. Аның янына бераз сәрхүш Рәмиев килеп керә. Ул елый. Тукай аны тынычландырмакчы, күңелен күтәрмәкче. Рәмиев аңа үзенең ничек итеп охранка корбаны булуы турында сөйли. Тукайга ул Хәнәфинең провокатор икәнлеген ачып сала, полициянең террор оештырырга, Хәнәфи һәм аның ялчыларының Ямашевны почмактан торып үтерергә әзерләнүләрен хәбәр итә.

Тукай, үзенең хәлсез, авыру икәнлеген онытып, урыныннан сикереп тора һәм алда булачак куркыныч явызлыкны кисәтү өчен ишеккә ташлана. Шул вакыт Камал килеп керә һәм әле билгеле булмаган сәбәпләр нәтиҗәсендә Ямашевның кинәттән үлеп китүен әйтә.

— Әйтерсең үз үлеме белән үлмәгән, ә үтергәннәр...

Тукай — түшәктә. Камал аңа врач алып килә. Врач шагыйрьдә үпкә авыруы икәнлеген әйтә. «Кырымның көньяк ярында дәвалануның гына нинди дә булса уңай нәтиҗә бирүе мөмкин», — ди ул.

Хәсән бай конторасы. Бай, өстәл артына утырып, Тукай китапларын бастырудан килгән табышны саный. Аның янына икенче бер нәшир килә, өченчесе... Тукайның шигырьләрен бастырып чыгару хокукы өчен бәхәс башлана.

Камал керә һәм, Тукайның кан төкереп ятуы турында әйтеп, дәваланырга аны көньякка җибәрү өчен акча бирүләрен сорый.

Сүзгә Хәсән байда хезмәт итүче Хәнәфи кушыла:

— Нигә аны көньякка җибәреп торырга. Ул бит инде күптән үлде.

— Сезнең шикелле мәетләргә тереләрне күмәргә хокук бирелмәгән, — ди Камал һәм Хәнәфигә борылып өсти:

— Менә дигән үзгәрү... Кичәге социалист-революционер — бүген Хәсән байның ялагае һәм тәлинкә тотучысы булып өлгергән.

Камал, нәширләр тарафыннан тәкъдим ителгән сәдака акчасын кире кагып, кәефе кырылып чыгып китә.

Камал Тукайның иптәшләре янында. Ләкин аларның һәммәсе дә акчасыз һәм эшсезләр. Әмирхан паралич суккан хәлдә ята. Шулай да ул, урында гына дәвалап булса да, шагыйрь дустының гомерен бераз озынайту өчен кесәсеннән соңгы тиеннәрен чыгара.

Ябыккан, алҗыган Тукай Кабан күле буенда утыра. Көзге сүрән кояш... Төссез, сирәк яшеллек.

Кырымның көньяк яры урынына менә шул!

Камалның: «Больницага кереп, бераз дәвалану зарар итмәс иде», — дигән тәкъдименә Тукай, елмаеп, болай дип җавап бирә:

— Больницаны үлемнең беренче станциясе, диләр. Мин әле тагын бераз яшәп калырга телим. Эшләнеп бетмәгән эшләрем бер кочак...

Гостиница рестораны. Өстә Тукай бүлмәсе. Ресторанда, өстәл артында — Печән базары әһелләре, интеллигенция вәкилләре... Бер почмакта, аерым өстәл янында — Бикчәнтәй һәм Хәнәфи.

Аркасына биштәр аскан крестьян Сәйфетдин күренә. Ул Тукай-

ны эзли, ләкин аның адресын белми. Аның кулында бары тик Тукай шигырьләре язылган кәгазь генә.

— Шушы кәгазьләрне укырлар һәм Тукайны ничек табарга икәнлеген өйрәтерләр, дидем. Һәм менә шул кәгазь мине бирегә алып килде, — дип сөйләнә Сәйфетдин.

Тукайга ул үзенең кайгысын сөйләргә килгән һәм аны бары тик ул гына аңлар дип ышана.

Полиция килеп керә. Ресторанда тентү башлана. Полицейский Тукай ишеге ягына карап күз кыскан Хәнәфидә «үз кеше»не таный.

Менә ул Тукай бүлмәсенә күтәрелә, ишекне шакый. Ишек ачыла. Аннан врач чыга һәм полицейскийның сырхау кеше бүлмәсенә керүен тыя.

Бүлмәдән Камал, коляскага утырган Әмирхан һәм Тукайны култыклап башкалар чыга. Болар — Тукайны больницага озатучылар.

Тукайга, ахры, суык: ул бөрешкән. Сәйфетдин үзенең шарфын аның муенына сала.

Баскычтан төшкәндә Тукай Гафур белән очраша. Гафур, куркынып, аның хәлен сораша.

— Зарарсыз, — дип җавап бирә Тукай, аның алдында көр күңелле булырга тырышып.

Авырлык төшсә, түз, сер бирми-нитми;
Ни хәлләр яшь егеткә килми-китми?

Хәтерендәме: Идел буенда... Менә бер-ике атна больницада ял итәрмен дә... терелеп чыккач, күрерсез... Мин бик күп нәрсәне яңадан уйладым. Терелү белән якын дустым Ямашев шикелле яши һәм эшли башлаячакмын. Үзең ничек эшлисең, Гафур абзый?

Тукай соңгы сүзләрен әйткәндә хатын-кызлардан кемдер түзми, елап җибәрә.

Тукай борылып карый:

— Еларга ярамый! Җырларга кирәк! Исегездәме: шикләнмибез...

Акрын гына җырлый башлый. Беренче сүзләрендә үк аны ютәле буып ала. Ул, ашыгып, кесәсеннән яулык чыгара. Иптәшләре һәм яшьләр аның җырын күтәреп алалар:

Шикләнмибез дошманнарның көченнән без,
Бүгенге көн Гали, Рөстәмнәргә тиң без.
Шагыйрь гомере хәсрәт, кайгы күрсә күрер —
Дулкынланмый тормый ич соң өлкән диңгез.

Тукайны больницага озаталар.

Шагыйрьнең ишеге төбендә шау-шу куба! Бу — нәширләрнең аның бүлмәсен бикләп куярга килүләре.

## 9

Казандагы Клячкин больницасы. Тукай үзенең соңгы көннәрен кичерә. Ләкин ул аңында. Камалдан үзенә язгы беренче чәчәкләрне алып килергә вәгъдә биргән Әминә турында сораша.

Урамда больница каршына һөнәрчеләрнең, эшчеләрнең, интеллегентлар һәм укучыларның зур төркеме җыелган...

Һәркемнең йөзендә — хәвефләнү. Ишектән Камал чыга. Төркемдәгеләр аңа ябырылалар.

— Я, хәле ничек?

Вокзал. Поездан кулына кечкенә саквояж һәм язгы чәчәкләр бәйләме тоткан Әминә төшә. Ул шәһәргә ашыга.

Тукай өстәлендә — Уральскидан бирле үз янында йөрткән Пушкин томы. Ул аның битләрен ача һәм иреннәрен кыймылдатып укый:

И пусть у гробового входа
Младая будет жизнь играть,
И равнодушная природа
Красою вечною сиять.

Тукай кулына каләм ала, нәрсәдер яза. Аның каләме кулыннан төшеп китә.

Палатага Камал һәм шагыйрьнең башка дуслары керә. Алар арасында чәчәкләр тоткан Әминә дә бар. Ләкин ул соңга калган.

Камал шагыйрьнең соңгы юллары язылган кәгазь битен алып, аерылу һәм җырчының бурычы турындагы мәгълүм строфаны укый...

Үтерелгән Лена эшчесенең гәүдәсе ята...

Куллары богауланган ярсулы Васильев атлый...

Урам буйлап, кулларына байраклар тотып һәм сугышчан җыр җырлап, Михайлов җитәкчелегендә баш күтәргән эшчеләр уза.

Бу — Лена эшчеләрен атуга җавап.

Халыкның капитализм тарафыннан үтерелгән иң яхшы улларының каны өчен «кырыс үч алучы» әнә шулай күтәрелә.

*РСФСР*

*Татарстан Совет Социалистик Республикасы*
*Халык Комиссарлары Советы*
*Казан шәһәре, Кремль*
*№ 4129 15.VIII—1940 ел.*

*ССР СОЮЗЫ ХАЛЫК КОМИССАРЛАРЫ КАРШЫНДАГЫ КИНЕМАТОГРАФИЯ ЭШЛӘРЕ КОМИТЕТЫНА*

*Күчермәсе: иптәш Әхмәт Фәйзигә. Мәскәү, Герцен урамы, Калашный тыкрыгы, 10 йорт, 5 квартира.*

*ТАССР Халык Комиссарлары Советы иптәш Әхмәт Фәйзине «Тукай» кинофильмын чыгару мәсьәләләре буенча консультант итеп билгеләде.*

*ТАССР Халык Комиссарлары*
*Советы Председателе*
*урынбасары — имза (З. Тинчурин)*

*Хөрмәтле Михаил Ильич!*

*Иптәш Фәйзинең «Тукай» либреттосы яхшы сценарийның нигезе була ала. Бездә «Булат батыр»дан соң татар ленталары булганы юк. Бу әйбердә рус һәм татар культураларының бәйләнешен ныграк күрсәтергә кирәк. Казанда Ленин укыган, Горький, Киров, Лобачевский һ. б. лар булган.*

*Сценарий өстендә хәзер үк эшли башларбызмы — шуны хәбәр итүегезне сорыйм.*

*Виктор ШКЛОВСКИЙ.*

*11 июнь, 1941 ел.*

# ШАГЫЙРЬНЕҢ ОНЫТЫЛМАС ОБРАЗЫ

ИСТӘЛЕК

Тукайның замандашлары, шагыйрьне белгән кешеләр бәхетле: алар аны әдип, ялкынлы публицист буларак кына түгел, аңа гына хас булган кешелек сыйфатларын да, аның күңел тирәнлеген дә күргәннәр. Газетаның чираттагы санын чыгарып йөргәне дә, шатлыклы, кайгылы һәм ачулы чаклары да әле дә аларның күз алдында.

Икенче берәүләр Тукай белән, аның иҗаты белән китаплары, зур тәэсир көченә ия булган әсәрләре аша таныштылар һәм шагыйрь аларның бөтен гомер буена иң якын дустына әверелде.

Ә мин Тукай турында башлап әнием Газизә Мөхәммәтгариф кызы Зәбирова (кыз чагындагы фамилиясе Тукаева) сөйләвеннән белдем. Ә ул — Габдулланың бертуган апасы. (Укучылар, әлбәттә, беләләр: Тукайның олы апасы Газизә дә Кушлавычта туа, Габдулла кебек үк, әмма ике ел элегрәк Уральск шәһәренә килә һәм Галиәсгар Усманов семьясында тәрбияләнә.) Әлбәттә, мин Тукайның үзен хәтерләмим, ул Уральскида вакытта мин бик кечкенә булганмын. Шулай да, бала чакта ук, әнием һәм абыйларым сөйләве буенча, шигырьләр чыгаручы, яман кешеләрне дошман күрүче, тыңлаучан балаларны бик ярата торган туганнан туган абыем бар икәнен белә идем. Ул язган шигырьләр белән таныш түгел идем әле, алар белән укый-яза башлагач кына таныштым. Шунысын ачык хәтерлим: бу абыйның Уральскида түгел, ниндидер бер зур шәһәрдә яшәвенә бик гаҗәпсенә идем. Соңрак, азрак үсә төшкәч, аның шигырьләрен укый ала башлагач, мин абыем белән горурлана идем. Дөресен әйтергә кирәк, бәлки мин Тукайның шигырьләрен аңлап та бетерә алмаганмын, әмма шагыйрьнең минем әнинең туган энесе, ә минем өчен абый булуы күңелгә бик хуш килде. Мин бу дәү абый турында сөйләвен таләп итеп, әнине аптырата башладым. Ә әни Габдулла энесе турында, аның тормышындагы вак-төяк, гадәти вакыйгалар, хәлләр турында (минем өчен алар гадәттән тыш булып күренә иде) сәгатьләр буе сөйләргә әзер. Мин йотлыгып тыңлыйм. Мәсәлән, шундый вакыйга турында сөйләве хәтеремдә: мин туганда (1907 ел), абыйларым Вәли белән Галигә 8 һәм 6 яшь булган. Алар Габдулла абыйга сөенче алырга йөгергәннәр. Ул вакытта Тукай Камил Мотыйгый (Төхфәтуллин) типографиясендә эшләгән. Әмма абыйларым Габдулланың Газизә апасы кызмы, малаймы тапканын әйтергә онытканнар, бар белгәннәре шул булган: «Сөенчегә нәрсә бирәсең?» Тукай аларга, әлбәттә, сөенчегә илле тиен көмеш чыгарып биргән, әмма сеңелесеме, әллә энесеме дөньяга килгәнен бары тик кичен генә, безгә өйгә килгәч кенә белгән. Анары минем абыйлардан бик озак көлеп йөргән, мин хәзер, мәзәгрәк тоелса да, шулай дип әйтә алам: Габдулла абый мине күргән, ә мин аны юк (тиздән ул Уральскидан Казанга китеп барган).

Әни, абыйларым Вәли белән Гали, Әхмәтша учитель, Бәдри абзый, Алты-биш Сапый һәм башка кешеләрдән ишеткәннәрем турында укучыларга кайбер нәрсәләрне әйтеп китәсем килә.

Тукай белән Камил Мотыйгый (Төхфәтуллин) дус булып яшәүләре, үзара яхшы мөнәсәбәттә булулары, уртак максатка юнәлдерелгән эш белән шөгыльләнүләре укучыларга яхшы билгеле. Шулай да Габдулла аның кул астында эшли. Типография хуҗасы Камил Төхфәтуллин эшчеләрне кыерсыта башлагач, Тукай аларны яклап чыга. Ә Камил Төхфәтуллин Габдулланы типографиядән китәргә мәҗбүр итә. Әнием сөйләве буенча, Тукай моны бик авыр кичерә, әмма үзен горур тота: «Аңардан бүтәнне көтәсе дә юк иде, ул бит үзе турында гына уйлый, башкаларда аның эше юк»,— ди. Әнием дә моңа нык борчыла, бигрәк тә, Тукай аңа Уральскидан Казанга китү теләген белдергәч, тәмам кайгыга төшә. Бу урында шунысын да әйтергә кирәк: Тукай яшь булса да, үзе ачлы-туклы яшәсә дә, әледән-әле безнең гаиләгә ярдәм иткәләгән. Габдулла үзенең Уральскидан китәргә нияте барлыгын әйткәч, әни бөтенләй коелып төшә, әйтерсең ул аны бүтән беркайчан да күрмәячәген алдан сизенә. Энесе әнине тынычландырырга тырыша, безгә, берсеннән-берсе кечкенә балаларга, күрсәтеп: «Апа, кайгырма, үзем белгәнне аларга бирермен, алар чын кешеләр булып үсәрләр»,— ди.

Әни матур итеп, кызыклы итеп сөйли белә иде. Без зур үскәч тә аның сөйләгәннәрен тыныбызны чыгармыйча, йотлыгып тыңлый идек. Бик табигый: ул үзенең энесе белән горурлана, аңа авыр чакларда бик нык борчыла иде. Шунысын да әйтергә кирәк: кечкенә Габдулланың Усмановлар гаиләсенә килүе дә аның ярдәмендә булган. Ул гел Габдулланы сагынып, аны еш исенә төшергән. Шуның тәэсирендә Усмановның хатыны — шагыйрьнең әтисе ягыннан апа тиешле кеше — Газизә апа (ул әни белән адаш) һәм Усманов үзе дә Габдулланы Уральскига китерергә дип килешкәннәр. Галиәсгар абзый яхшы гына хәлле, кешелекле кеше булган, тормышның кыенлыкларын күп күргән Габдулла абыйның Уральскига килүен бик хуп күргән. Шактый еллар узгач та безгә: «Тукайның Уральскига килүе аны бала чакта ук кабергә керүдән саклап калган»,— дип сөйли торган иде. Аның уйлавынча (моның нигезе дә юк түгел), Габдулла Кырлайда вакытта ук үпкә чире белән авыру булган. Уральскида яшәгән вакытта чир тукталып торган, соңрак кына үзен сиздерә башлаган. Эш шунда: Кырлайда кечкенә Габдулла яшәгән Сәгъди абзый гаиләсендәгеләрнең барысы да шушы авыру белән дөнья куйганнар. Тукай һаман да алар белән яшәгән булса, мөгаен, Кырлайда ук үлгән булыр иде.

Уральскига күчеп килгәннән соң, кечкенә Габдулла турында кайгырту өлешчә әни җилкәсенә төшә. Мин моны әйтү белән әнине әллә кем итеп күтәрергә теләмим, әмма шунысы бар: нинди хатын-кыз ятим энесе турында кайгыртмас, аның язмышы өчен борчылмас икән. Ә безнең әни бик тә яхшы күңелле, авыр сүз әйтмәс кеше, Галиәсгар абзыйның хатыны, әнинең адашы Газизә апа, аның кызлары Фатыйма һәм Зөһрә белән бергә, кечкенә Габдулланың ятим малай түгел икәнлеген аңлата, ул үзен сау-сәламәт, көр күңелле тоеп яшәсен өчен тырыша. Әни өй җыештыра, керләр юа, ашарга өзерли, энесен карый, хәтта Габдрахман Зәбировка (минем әтигә) кияүгә чыкканнан соң да аңа мөмкин кадәр ярдәмен дәвам итә.

Әни кечкенә Габдулланың табигатьне бик яратуын искә ала иде. Ә Уральск тирәсендә табигать бик матур. Шәһәр Урал һәм Чаган елгалары уртасына урнашкан, тирә-ягында — урман, җиләк-җимеш бакчалары, болыннар, ә арырак — зәңгәр офыкка барып тоташкан дала. Минем уемча, соңрак язылган күп кенә шигырьләре дә аның Уральск шәһәре тирәсендәге гүзәл табигать тәэсирендә туган булырга тиеш. Еллар узгач, инде Казанга күчеп килгәч язган шигырьләрендә ул, мөгаен, Урал елгасы ярында яки урман буенда күргәннәрен сурәтләде:

**Галибанә яктырып, әкрен генә ал таң ата;**
**Моңланып, хәсрәтләнеп, ялкау гына ак ай бата.**

**Бер-бер артлы юк булып, күкләрдә йолдызлар сүнә;**
**Таң җиле куйды исеп, яфраклар аз-аз селкенә.**

**Пәрдәдән чыкты, ачылды ямь-яшел кыр һәм ялан;**
**Китте инде кап-кара, каплап ята торган чапан.**

**Тын гына яткан, ялыккан төн буенча көн көтеп,**
**Ялтырап, җәйлеп ята күлләр, сихерле көзге күк.**

**Шат үләнлекләр, тәбәссемдә чәчәкләр, лаләләр;**
**Сандугачлардая ява, яңгыр кеби, мәдхияләр.**

**Туктаганнар күрмәгә иртүк табигать күркене**
**Күктә аккошлардай ак, кучмә болытлар төркеме.**

**Каршыларга иң сәза чак, иң матур чак җәйге таң;**
**Шул вакытта уйла, шагыйрь: килде илһам, уйласаң.**

Г. Тукайның «Кечкенә генә бер көйле хикәя» исемле әсәре барыбызга да яхшы таныш. Бу әсәрнең язылу тарихы да кызык кына. Ул заманда Уральскида безнең ерак туган тиешле кешеләрдән ирле-хатынлы Сафый белән Фатыйма яшәгән. Тукай аларга еш кына барып йөри торган булган һәм, аларның тормышын күреп, бик борчылган. Көннәрдән бер көнне Габдулла әни янына килгән дә әнә шул шигырьне укыган. Әлбәттә, әни әсәрдә кемнәр турында сүз барганын шундук белеп алган. һәм, кәефе кырылып: «Кем язды моны, синме, Камилме?» (Камил Мотыйгый турында сүз бара) — дип сораган. «Камил аларны белми бит,— дип җавап биргән Тукай.— Ә мин аларга барып йөрим. Рәтләнмәсләрме, дим». Чыннан да, ул аларны килештерергә тырышып караган, әмма максатына ирешә алмаган. Шуннан соң инде бу әсәрен бастырып чыгарган. Ә әни озак вакытлар моның өчен Габдуллага үпкәләп йөргән.

Шуны әйтеп үтим: Тукай яшьтән үк әхлак мәсьәләсенә бик җитди караган. Мәсәлән, әни янына бер күрше кызы кереп йөри торган булган. Төскә-биткә чибәр генә булса да, үз-үзен тотышы мактарлык түгел икән. Габдулла да аны бездә еш кына очрата. Кем белә, бәлки кызның Тукай белән дуслашасы килгәндер: бер көнне ул әнидән: «Нигә энең минем белән сөйләшми, теле юкмы әллә аның?» — дип сорый. Әни аның сүзләрен Габдуллага җиткерә. «Үз-үзен тотышын яратмыйм мин аның,— ди Тукай.— Җилбәзәк. Сөйләшер сүз юк аның белән минем».

Әни Тукайны кыюсыз, гомумән, аз сүзле ди торган иде. Әмма, берәр нәрсә аны дулкынландырса, ул җанланып, сүзчәнләнеп китә торган булган. Бигрәк тә шигырьләр укырга, халык җырлары, әдәбият турында сөйләшергә яраткан. Ун-унбер яшьләр вакытында әнигә сер итеп кенә: «Апа, мин барлык җырларны да беләм, мин белмәгән җыр юк»,— ди икән.

Еллар уза, Тукай атаклы шагыйрь булып үсә. Безнең гаиләдә аның белән горурланалар, аның яңа шигырьләренең күбесен яттан өйрәнәләр. Ә әни аның тормышындагы һәр яңалыкны безгә сөйли торган иде. Аның шигырьләрен дә, югарыда әйткәнемчә, мин иң башлап әнидән, туганнарымнан ишеттем. Хәтеремдә: алар миндә зур тәэсир калдырдылар. Ә инде үсә төшкәч, алардагы фикерләрне бөтен тирәнлеге белән, һәрьяклап аңладым. Хәзер дә (миңа инде алтмыш яшьтән ашып китте) аның иҗатындагы дәртле омтылышка, илһамландыргыч көчкә, якты талантына сокланып туя алмыйм. Тукайның «Пар ат», «Шүрәле», «Туган илемә», «Туган тел» һ. б. әсәрләрен дулкынланып, кабат-кабат укыйм. Халык белән бергә сулаган, аның арасында яшәгән, халыкның үз улы булган Тукай безнең арада үз замандашыбыз булып яши, аның әсәрләре һаман да укучыларга рух һәм ләззәт бирә.

**ХӨСӘЕН ЗӘБИРОВ,**
**Г. Тукайның туганнан туган энесе, инженер.**

ооооооооооооо

## Нәкый Исәнбәт

# ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ МӘГЪЛҮМ БУЛМАГАН БЕР ШИГЫРЕ ҺӘМ МӘХМҮТ ДУЛАТ-АЛИ ХАКЫНДА

## I

Яшь шагыйрь Габдулла Тукай Казанның үзендә генә түгел, бөтен татар дөньясында зур исем тоткан бер кеше булып киткәч, ул заманның күзе ачык алдынгы татар кызлары, билгеле инде, бу атаклы егет белән танышырга омтылганнар. Алар арасыннан гүзәл Зәйтүнә туташ һәм аның Тукай белән бергә булган гыйшкый маҗаралары безгә бераз билгеле. Ул хакта, шулай ук Үлмәс ханым хакында да язылгалап үтелде. Билгеле, Тукай белән танышырга теләүче ханым һәм туташлар бу исемнәр белән генә чикләнеп калмый. Колак салганда, халык телендә бу хакта әле дә кайбер кызыклы хәбәрләр йөри кебек.

Мәсәлән, шундый үткен кызлардан тагын берсе Казанда Фатимаи-Зөһрә булган, диләр. Ләкин хатын-кыз никадәр генә җете булмасын, Тукай белән танышу ансат кына насыйп була торган эшме соң? Үзегезгә мәгълүм, Тукай — дөньяның бернинди шартлылык һәм рәсмиятләренә баш имәгән, аның ваклыкларыннан үзен «фәлсәфи югарылыкта» тоткан, «милли агачларга кунып» моңланучы, рухы белән бәйсез, хөр, азат бер сандугач. Билгеле инде, бу гүзәллек гашыйгы аңа карап үзен мәхәббәттән өстен тотканы юк. Шулай булса да ул үзен хатын-кыз җәмәгатеннән мөмкин кадәр ераграк тотуны алда күргән кеше: ул хатын-кызлы йорт-гаилә мәҗлесләренә гадәттә йөрми. Шуңа күрә Фатимаи-Зөһрә дә Тукай белән танышу юлын аның ир дуслары аркылы эзләгән.

Һәм шундый җай килеп чыккан. Бервакытларны Тукай Яңа бистәдә, Олы Сембер урамында, үзенең дусларыннан Мәхмүт Дулат-Алиләрдә торып ята икән. (Хәзерге Олы Ямаш урамы, 37 нче йорт, элекке Вахит мәзин йорты.) Тукай дусларыннан тагын Фатих Әмирхан, Вафа Бәхтиярлар [1], «Әлислах» һәм башка эшләр буенча, вакыт-вакыт шунда җыелалар икән. Шуны ишеткәч, Фатимаи-Зөһрә, күрәсең, Мәхмүт Дулат-Алидән сорашып, вакытын алдан белешеп, Тукайның шунда бер мәҗлестә

---

[1] Вафа Бәхтияр — «Әлислах» газетасы редакторы. Фактта редакторлары — Ф. Әмирхан белән Г. Тукай.

> Калды уң якта «Китаплар ханәсе».
> Сулда — «Әлислах» идарәханәсе.
>
> (Тукай, «Кисекбаш»).

Тагын:

> Йөрде «Әлислах» Вафасы барны юктан торгызып.
> Ниндидер бер көч белән кәрван күчеп, эт өрдереп.
>
> (Ш. Бабич.)

утырган чагында, аның белән көрәшә килә. Шул чакта аңа кереп хәбәр итәләр. Тукай:

— Яхшы, яхшы,— ди. Торып өс-башын рәтләгәндәй итеп әйләнгәли, ләкин туташ кергәндә инде ул, кай арададыр, эшләпәсен киеп сызган була.

Вакыйганың бу хәтлесендә әллә ни яңалык юк, Тукай биографиясендә мондый хәл тәүгесе булмаган кебек, соңгысы да түгел. Ләкин Фатимаи-Зәһрә дә, күрәсең, беренче уңышсызлыктан ук җебеп кала торганнардан булмаган. Тукай белән күрешү һәм олы шагыйребезгә ихтирамын белдерү өчен, ул аларның мәҗлесенә эләгергә яңа хәйләле чаралар эзләвен куймаган.

Беркөнне Мәхмүтләрдә Тукай дуслары яңадан җыелганда, моны алдан белгән Фатимаи-Зәһрә ул мәҗлескә бик һәйбәт зур бер таба гөбәдия пешереп алып килмәсенме! Гөбәдия өстенә камыр белән калкытып ике исемнең баш хәрефләре язылган була: «Г. Т.» һәм «М. Д.». Билгеле, язу гарәп хәрефенчә, һәм боларның беренчесе — Габдулла Тукай, икенчесе — Мәхмүт Дулат-Али исемнәре. Күрәсез, гөбәдия Габдулла Тукай һәм хуҗа исемнәренә багышлап пешерелгән булуга ишарә бу. Шул ук вакыт, үзара гына әйткәндә, икенче исем «М. Д.» дигәне монда әдәп йөзеннән һәм Тукайны дулатмас өчен өстәлгән булырга кирәк.

Гөбәдия дигәндә, яшьләр, билгеле инде, аны күтәреп алалар. Хәрефләрнең кызлар кулы эше икәне күренеп торса да, табынга килгән бу нигъмәттән, билгеле, Тукай да торып кача алмый. Халыкта «гөбәдиягә арка кую» дигән сүз дә бар бит әле. Анысы бездә үзе бер яман эш — шөкранасызлык санала. Эш анда гына калса! Үзегез беләсез, шундый милли күркәм нигъмәт шагыйрь исеменә багышлап язып пешерелгән булгач, гадәттә, андый чакта бездә мәҗлес халкы шагыйрьдән рәхмәт җавабы үтенә һәм шуны көтә башлый. Җавап, әлбәттә, шигырь белән бирелергә тиеш!

Шагыйрьгә мәҗлес алдында мондый таләп кую — бу үзе нәрсә соң? Шундый бер көтелмәгән хәл һәм мәҗбүрият алдында калган шагыйрьгә нишләргә, ничек булырга? Ул: «Мин сыйга каршы шигырь әйтеп йөрүче вульгар шагыйрь түгел, мәдхияче дә түгел, язып иҗат итүче шагыйрь...» дип үпкә белдерергә һәм мондый эштән баш тартырга тиешме, әллә мәҗлескә һәм сый-хөрмәткә ихтирам йөзеннән, әдәби йола таләп иткәнчә, шундук махсус берәр шигырь чыгарып әйтеп яки язып укып җавап бирергәме кала?

Болай карауга бу инде үзенә күрә бер әдәби уен шикелле. Ләкин, әйтәләр бит: уен да уен, «юкә үбеш» тә уен! Әгәр дә бу бездә борынгы илһами (импровизацион) шигырь сөйләү һәм шуның тарихи йолалары, әдәби ярыш традицияләре белән бәйләнешле булса, ул чагында мәсьәлә тирәнләшә. Безгә дә эшнең бу ягына тукталып үтми булмый.

> ... Хикмәт тә шунда, бездә мәҗлесләрдә (Акмулла әйткәнчә, «мәҗлесенә карай гына») илһами рәвештә тоткарсыз шигырь чыгарып әйтү элек-электән килгән эш. Иске заманнарда китап бастыру яки клуб-сәхнәләр, әдәби салоннар юк. Шагыйрьгә үзен мәҗлес-табыннарда күрсәтмәсә, кайда күрсәтергә соң? Шуннлыктан бу эш үзенә күрә кызыклы, хикмәтле, милли әдәби һәм иҗади бер йола. Шул юл белән аның шагыйрьлек сәләте, җитезлеге, тапкырлык һәм осталыгы сыналган.
>
> Әйтик, үткән йөздә шундый мәҗлесләр корырга бер бик комар кеше үз заманының берничә шагыйрен чакырган. Бер арада табынга бер тәлинкә бадам (миндаль) чикләвеге чыгарып куйган да ул:
>
> — Бу нигъмәткә каршы кайсыгыз булса да берегез ике юллык шигырь чыгарып әйтергә тиешсез, ләкин сүзләре татар, гарәп, фарсы, рус телләре катнаш булсын. Шуны чыгарып әйтмичә торып, беркем дә аңа кул суза алмый, минә ярышта кем отып чыкса, бу тәлинкәгә шул шагыйрь беренче булып кул сузა!— дип белдергән. Моның белән әллә ул бу шагыйрьләрне төрле телдән сүз таптырып, аны да үлчәүгә китерә алмыйча нык кына аптырашта калдырмакчы булганмы, әллә тагын төрле телләр белү ягыннан гыйлемлекләрен дә сынамакчы булганмыдыр, белмим, ләкин алар арасында утырган мәшһүр шагыйрь Кандалый әллә ни

алай аптырап тормаган, тиз арада калка биреп, күңелдән шундый ике юллык шигырь чыгарып әйткән:

**Нә хушбәнд килде, кур, тәрилдә орех,**
**Әгәр ләм йөәккәл, булыр зур грех.**

«Кур, нинди күркәмлек белән тәлинкәдә чикләвек килде, әгәр дә бу ашалмый калса, зур гөнаһ булыр», дигән мәгънәдә. Шуны әйтеп укыган да тәлинкәне үз алдына сузылып алып та куйган.

Инде, отыш иясе булгач, Кандалый хәзер үзе, тәлинкәне уртага куеп, иптәшләрен чикләвек белән сыйлый. Алар анда аны тәбрикләп көлешә-көлешә ашаган булырлар. Без әле бу шигырьнең үзенә килик. Ярышның шартына ул күпме дәрәҗәдә җавап бирә ала? Менә андагы сүзләр: **хушбәнд, әгәр** — болары фарсы теленчә; **ләм йөәккәл** — гарәпчә; **орех, грех** — русча; **тарель** — французча; калган бишесе — татарча. Шулай итеп, Кандалый бу шигырьне дүрт кенә түгел, биш телдә, аның да күпчелек сүзләрен татарча итеп, әмма ләкин грамматик һәм шигъри инверсия тәртибендә татар теле кагыйдәсенчә итеп төзеп биргән.

Бу илһами шигырь безнең өчен әле башка ягы белән дә гыйбрәтле. Үлчәве ягыннан ул тагы да кызыклырак: шигырь гарәп гарузы буенча **бәхри мөтәрәкыйб** вәзенендә һәм ул шул ук вакытта русча тоник үлчәүдә (әйтик, телисең икән аны Пушкинның «Вещий Олег»е яки «Варяг» көе калыбына суктырып җырлап җибәр); әмма ләкин шул ук вакыт ул борынгы (XI нче гасыргы) безнең тарихи монументаль әдәби һәйкәлебез «Котадгу белек» шигырь үлчәвенчә булуы белән әһәмиятле. Инде «Котадгу белек»нең элек безнең Идел буенда яратып укылган һәм бик кадерле тотылган китап булуына дәлил кирәк дисәгез, моңа мисалга Алтын Урданың Сарай шәһәре хәрабәсендә табылган бер тәлинкә кырыенда шул ук әсәрдән алып бизәкләп язылган шушы юлларны китерә алабыз:

**Кеше́ күрке — йөз ул, бу йөз күрке — күз;**
**Бу үз күрке — те́л ул, бу те́л күрке — сүз.**

(«Үз» сүзе монда җан мәгънәсендә. Ритмын басымнар буенча укырга.)

Шунысы да игътибарга лаек, XI йөздә язылган булуына карамастан, бу икеюллыкта төрки теленчә булмаган бер генә сүз дә юк һәм алар бар да бүгенге безнең татар телендә эштә йөргән актив сүзләр. Шигырьнең мәгънәсенә килгәндә дә ул шул дәрәҗәдә бүгенге һәм тирән афористик хикмәтле ки, бездә хәзер һәр вакыт Чеховтан китереп әйтелә торган: «Кеше һәр яктан да гүзәл булырга тиешле: йөзе белән дә, сүзе белән дә, эше белән дә», дигәнне гүя ки ул безгә XI гасырдан торып әйтә[1].

Инде баягы илһами шигырь сөйләү бәхәсебезгә әйләнеп кайтыйк. Эш бер Кандалыйда гынамыни? Ә соң шагыйрь Акмуллабызның атаклы казакъ акыны Җүсип (Юсыф) белән мәйдан тотып, телдән шигырь әйтеш[2] ярышы ясап, ул мәшһүрне җиңеп чыгып, дан казануын кайсыбыз ишетмәгән? Бу икәүнең шул кыйммәтле әйтеш шигырьләре, шактый озын булуларына карамастан, телдән-телгә отылып, әлегәчә сакланып килгәннәр һәм алар бүген безнең кулыбызда. Гали Чокрыйның кайбер импровизацияләре дә телдә билгеле. Казакъ-кыргыз кардәшләребездә акыннарның шушы гасыргача зур мәйданнар тотып, шигъри ярыш-әйтешләр

[1] Шигырьдә «эш» дигәне әйтелмәгән ич димәгез: ул заманнарда сүз — кешенең турыдан-туры рухи гамәле һәм тугрылык акты, сүз эштән аерылмый, ул тел белән эшләнгән чын эш, югары эш, шунлыктан сүз белән эш — бер нәрсә дип каралган, шуңа күрә бу шигырьдәге «сүз» эш мәгънәсен дә эченә ала икәнен онытмыйк. **(Автор искәрмәсе.)**

[2] Әйтеш (казакъча — айтес) — төрки халыкларда акын-жырауларның телдән илһами шигырь чыгарып әйтү ярышы һәм шул юл белән туган үзенә бер төр әдәби жанр әсәрләр. **(Автор искәрмәсе.)**

уздырып килүләрен, һәм ул акыннарның зур-зур бүләкләр белән бүләкләнеп сыйлануларын да шуңа китереп өстәсәк, күренә ки, мәҗлесләрдә тоткарсыз илһами (импровизацион) шигырь чыгарып әйтүчелек һәм каичагында шагыйрьдән шуны көтү, төрки халыкларда һәм шул җөмләдән бездә дә борынгы профессиональ җырау (Тукай әйткәнчә — җыручы) ларның мәҗлес-мәйдан, аудиторияләр тотып башкаруларыннан кала килгән зур әдәби һәм мәдәни йола булган. Ул, Иртыш-Җаек буйларындагы кебек, безнең Идел һәм Кама буйларында да шулай булган һәм без күптән утрак тормышка күчеп, мәгърифәтле халык буларак язма шигырь иҗатчылыгына күчкәнебез соңында да, ул бетеп җитмәгән. Дөрес, бездә думбра тотып телдән илһами дастан әйтүче халык җыручылары халыкны бунтка һәм батырлыкка өнди дип каралып, колонизатор-боярларның ут һәм кылычлары астында каты эзәрләнеп, XVII йөз башларында бетерелгән булса кирәк. Әмма ләкин язып шигырь чыгаручылык алымнарында илһами шигырь әйтүчелек, үзенә бер башкарак тестә булса да, бездә дә һаман сүнмичә дәвам итеп килгән булуын күрәбез.

...Үткәннәргә шундый кайбер экскурсияләребездән соң, хәзер без тагын Дулат-Алиләрдә барган мәҗлескә әйләнеп кайтыйк. Анда Габдулла Тукай алдында атаулы гөбәдия тора бит әле. Мәҗлес халкы атаклы шагыйрьдән, әлегечә, тиз генә телдән әйтелгән илһами шигъри җавап көтә. Шундый үзара мәҗлестә, шундый күркәм, зур күчтәнәчкә Тукай тикле Тукай тарафыннан бер җавап шигыре дә бирелми калсынмы? Әлбәттә, ни дә булса тиз генә язылмы, телдәнме әйтелгәндер. Телдән булса, дусларыннан берләре шундук аны язып алып кесәләренә салган булырлар. Шулай булганда аның язмасы кайда да, кемдә дә булса сакланып калган булуы бик мөмкин. Әнә Кандалый, Акмуллаларныкы сакланган бит. Ләкин нә Тукай шигырьләре, нә аның турындагы истәлекләр арасында без андый әсәре бар икәнен белмибез. Ләкин минә Гай иптәшнең[1] хәбәр итүенә караганда, Тукайның андый шигыре бар икән. 1923 ел ахырлары яки 1924 елның башларында ул, Мәхмүт Дулат-Алиләр архивы белән кызыксынып, кайчандыр Тукай кунгалап яткан теге чарлакта актарынып йөргәндә, шундагы төрле календарьлар, иске «Вакыт», «Тормыш» газеталары битләре, башсыз-ахырсыз кыйсса китаплары арасында буталып яткан дүртьюллык шундый бер шигырь кисәге табып алган:

**Бүләк килде гөбәдия капкачында,**
**Бисмилла дип керә торган капкасында,**
**Ике исем нәкышләнгән камыр белән,**
**Әйтерсең лә язган алтын тамыр белән.**

Тукай бу шигырен илһами рәвештә телдән генә әйтеп, шуннан берәр иптәше язып алып куйганмы, яки башта ук кулдан язып чыгарылганмы — анысы билгесез. Чөнки Гай иптәш аны хәзер хәтерендә калган буенча хәбәр итә. Ул экспромтның дәвамы да булырга охшый әле.

Мин аны аңардан ишеткәнемчә язып матбугатта игълан итәргә тиеш таптым. Чөнки шигырь, күрелүенчә, Тукай стилендә. Аннары мәҗлестәшләре һәм Фатимаи-Зөһрә — бар да Казанның мәгълүм кешеләре булгач, вакыйгасы да коры легенда гына булырга охшамый. Ничектер, заманына һәм яшьләр тормышына бик хас, бик ятеш туры килә. Тукайның шундый юллар белән башланган шигыре булуын тагын раслаучылар да бар.

Әле тагы шунысын да әйтик: шундый һәйбәт гөбәдия күтәргән, аның өстендә үзенең калку йөзен балкытып килгән Фатимаи-Зөһрәнең үзенә бу мәҗлескә әләгү һәм Тукай белән танышу насыйп булганмы — ул хәтлесе хәзергә билгесез. Ихтимал, ишеткәннән-күргәннән анысын да белүчеләр, бу вакыйганы яки бу шигырьне дә өстәмә юллары белән тәгаллаүчеләр табылыр. Чөнки бу дүрт юл әле шигырьнең башы гына булуы үзеннән-үзе аңлашыла. Бу шигырьнең 1909—1910 елларга бәглы булуы чамалана.

---

[1] Гай — Гобәйдулла Сәмигуллин. Ташкентта яши, пенсионер. 1928 нче елларгача татар матбугатында «Гай» псевдонимы белән язышкан. Шигырьләре дә бар.

## II.

**Мин кунакчыл бер җыручы: миндә бар ярлы, гидай,**
**Ханәмә яшьләр килә һәм сәүдәгәр, бай углы, бай.**

**Тукай.**

Әйе, бу кунакчыл бүлмәгә вакыт-вакыт беренче татар социал-демократ большевигы һәм җитәкчесе Хөсәен Ямашев та килеп кергән. Габдулла Тукай аны: «Күктән иңгән, ханәмә килгән (Хөсәен) тулган ай!» дип, шул бүлмәсендә кочак ачып каршы алган. Истәлек язучыларның берләре: «Болгар» номерында Тукай торган ул 40 нчы бүлмә ишеге һичбер вакытта бикләнми иде», диләр. Шулай дисәләр дә, Тукай гел шулай «ханә»сенең ишеген ачып куеп, кунаклар кабул итеп кенә утырмаган һәм ул дәрәҗәдә үтә беркатлы «демократ» та булмаган, билгеле. Вакыт-вакыт ишеге тыштан бикләнеп, үзе каядыр озак кына вакытлар күздән югалгалап торган. Бигрәк тә җәйләрен. Билгеле, аны эзләгәннәр. Үзе була торган редакцияләрдән карыйлар — юк; китап магазины артларында — юк; кемдер: «Тукта, аның кайбер чакта аста, йорт як асфальтта малайлар белән кузна уйный торган гадәте бар», дип төшә — анда да юк; хәтта Балык базарына каршы извозчиклар ашханәсендә утыргалый торган багана арты ышык өстәле артында да юк! Һәм ул шулай атна юк, кирәк булса, ике атна буе да юк. Бигрәк тә аны басып алырга яраткан әрсез «дуслары» эзлиләр. Кая югала бу? Ул хакта тарих әлегә дәшми.

Шул ук вакыт ул үзе Казанда. Редакция йомышлары белән күренгәләп китүе билгеле. Күрәсең, аның Казанда «Болгар» кунакханәсе өстенә тагын ятып-кунып йөри торган икенче бер үзәге бар. Ул үзәк бик ышанычлы, якын дусларыннан берәрсендә. Бәлки бу аның кеше күзеннән ераграк, яшеренрәк сәяси фикердәшләре үзәгедер? Чын Пушкинны декабристлар даирәсеннән башка танып белү мөмкин булмаган кебек, чын Тукайны да бу якын дусларыннан, фикердәшләре тирәлегеннән тыш якыннан белү авыр эш. Без Тукайның Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал, Габдулла Кариев кебек дуслары белән эш урыннарында катнашуларын белсәк тә, кара реакция елларында аның «Болгар»дан башка җирдә тагын үзенә бер әчке дуслык почмагы һәм даирәсе булуы турында аз нәрсә беләбез.

Менә Мәхмүт Дулат-Али өендә булган гөбәдия мәҗлесе уңае белән безгә хәзер шунысы да ачыклана төшә: 1909—1910 елларда аның вакыт-вакыт кеше күзеннән югалып яши торган бер почмагы да нәкъ шушы Яңа бистәдәге Дулат-Алиләр йорты булган. Бушка түгел. Монда, Тукайның иң якын дусларыннан булган бу Дулат-Али турында безгә аның саен якыннанрак белергә кирәк.

Менә Тукайның Мәхмүткә үз кулы белән биргән фоторәсеме. Артында язу: «Иптәшем Мәхмүткә ядкарь. Г. Тукай. 3 октябрь, 1912 сәнә»[1].

Тагын икенче рәсем. Анда Фатих Әмирхан, Тукай, Дулат-Али бергә төшкәннәр. Ф. Әмирхан аны Фатимаи-Зөһрәгә биргән булган. Фотокарточкалар күп булган. Кайберләре Кырлайдагы Тукай музеена тапшырылганнар.

Тукайның тагын башка берәүне «иптәшем» дип атап язып биргән фоторәсеме бармыдыр, миңа мәгълүм түгел. Ул заманда безнең интеллигенция арасында «мөхтәрәм», «әфәнде» дип эндәшелә, мондый ядкарьләр өстендә дә шундый сүзләр языла торган иде. Монда исә үз итеп, туп-туры гына, эшчеләрчә — «иптәшем».

Кем соң ул Мәхмүт?

Мәхмүт Алиев (Дулат-Али), безгә белдерүләренчә, Казанда туып үскән. Ул Яңа бистәнең Вахит мәзин улы. Хөсәен Ямашев, Фатих Әмирханнар кебек, ул да башта татарда беренче җәдит мәдрәсә булган «Мөхәммәдия»дә укыган. Фатих Әмирханнар белән бергә йөреп үскән. Бишенче елларда ул шул ук Фатихлар белән революцион-демократик рухлы «Әлислах» комитетын төзешеп, газетасын чыгарышып, шәкертләр күтәрелеше хәрәкәтен оештыручы, татар җәмәгатьчелеген шаулатучы-дулатучыларның алгы сафында булган. Аның белән дә калмаган, 1907 ел реакциясе башланганда, нәкъ шул кара дулкын өермәсенә каршы барып, социал-демократик большевиклар партиясе сафына кергән.

---

[1] Бу фоторәсемнең хәзер кайда, кем кулында саклануы хакында кара: «Казан утлары», 1970. 1 сан, 156 бит. Г. Әпсәләмовның «Шагыйрьнең тагын бер рәсеме» дигән мәкаләсе.

Шулай итеп, Мәхмүт Дулат-Али, Тукай Казанга килгән елдан алып, Ямашев, Коләхметовларның көрәштәше һәм Тукайның якын дусты була.

Тукай 1909—1910 елларда җәйләрен Дулат-Алиләр йортындагы печәнлек чарлагында тора. (Әйтелүенчә, әлеге шигырь парчасы табылган чарлак. Әпсәләмов иптәш «шул чарлакның базында яшерен прокламацияләр басылган» дип белдерә.)

Димәк, бу печәнлек күрер күзгә ике катлы булса да, асылда ул өч катлы: югарыгысы — чарлак, аның асты — печәнлек, иң аста — баз. Анысы кеше күзеннән яшерен һәм анда Ямашевларның яшерен эшләре бара. Әпсәләмов Габдулла Тукайны да ул эшләрдән читтә калмагандыр дип уйлый.

Инде Габдулла Тукайга бу җаваплы «печәнлек чарлагы» рөхсәт ителүгә килгәндә, ул хакта, әлбәттә, төрлесен уйларга була. Ләкин Тукайның ул хәтле ышанычны казанырга аның үз «Тукайлык» сыйфатлары, минемчә, бик җиткән. Беренчедән, Тукай бөек шагыйрь дип танылганның соңында да әле булса «хатыны-йорты юк», бала чагындагы кебек түгәрәкли ятим, ялгыз башына номерда ятучы бер байгыш. Социаль хәле буенча, Уральскида басмаханә эшчесе булса, Казанда «Әлислах» газетасын аркага йөкләп почтага ташучы экспедитор. Ләкин шул ук вакытта ул фикере белән дә бик шәплән «ислахчы»: чөнки «Әлислах», исеменә карагaнда, «реформа» гына булса да (анысы «вывеска» гына), ул «кәҗүнни эш» түгел, асылда ул кадими мәдрәсәләрне (ул чагында мәхәллә идарәсендә булган урта һәм югары уку йортларын) муллалар опекасыннан алып, дөньяви фән-гыйлем мәктәп-мәдрәсәләре итү өчен баш күтәртеп, шәкерт забастовкаларын оештыручы яшерен комитет органы, ягъни асылда ул бишенче ел җилләре белән кабынган һәм аның революцион методларын милли культура җирлегендә куллана белүче сугышчан комитет. Газетаның инициаторлары Ф. Әмирхан, Г. Тукай һәм аларның иптәшләре. Алай гына да түгел, революцион-демократ рухлы Тукай шул ук вакыт патша хөкүмәте изгән-талаган туган халкын гасырлар буена сузылган колониаль коллыктан, җәбер-золымнан коткарырга омтылучы милли азатлык хәрәкәте җырчысы. Бу да заманасының таләбе. Шуларның барысы өстенә дә Габдулла Тукай үзенең шәхси, рухи сыйфаты буенча аеруча нык ышанычлы, намус иясе кеше. Ул түбәннән күтәрелгән яңа тип һәм чинсыз татар интеллигенты — бер вакытта да кешене сатмас, үзе сатылмас, дөрес һәм принципиаль, олы җанлы кеше. Тукай кебек аз сүзле, күп эшле, халык мәнфәгатен яклап әйтергә кирәкле урында кешенең дәрәҗәсенә, байлыгына яки түрәлек урынына карамыйча, гаҗәп бер кыюлык белән йөзенә бәреп тәнкыйть итәргә, кул куеп язып чыгарга җөрьәтле, чын халык дусты һәм мөстәкыйль фикерле бөек шагыйрь, асыл бер затны үзләренә дус итү, аңа җылылык күрсәтү һәм аны урап алган һәртөрле сатлык, исерекбаш школьник «дуслары» мөхитеннән араларга тырышу Хөсәен Ямашев һәм Мәхмүтләр йөзенә бик килешә. Шунлыктан яшерен базлы печән өсте чарлагын вакыт-вакыт аңа зур хөрмәт белән тапшырып торган булырлар.

Тукай, Әмирхан, Дулат-Алиләрнең, шулай ук Тукай һәм Коләхметовларның да бергә-бергә төшкән фотолары булу, аерымнарын да бер-берсенә бирешүләре шуны күрсәткән кебек, Ямашевның Тукай номерына йөрүләре һәм Тукайның Хөсәен үлгәч аның хатирәсенә язган мәшһүр шигыре дә бу кешечә җылы мөнәсәбәтнең өзлексез булуын дәлилли.

Ләкин безгә моңа карап Габдулла Тукай үзе дә турыдан-туры социал-демократ, большевиклар партиясенең яшерен әгъзасы һәм аларның прокламацияләрен язышып ятучы кеше булган икән дип хөкем чыгарырга ярамый һәм ул чынбарлыкка да туры килми, минемчә. Чөнки моның өчен кулыбызда дәлилләр юк һәм татар социал-демократлары прокламацияләренең язу стилендә дә Тукай кулы бер дә сизелми. Аннары андый эш, бердән, Тукайның үз иҗат йөзенә, аның үз әдәби миссиясенә туры килеп җитмәгән кебек, икенче яктан, Ямашевларның партия эше яшеренлекләре һәм тактикалары белән дә сыеша алмый торгандыр дип беләм.

Кыскасы, 1910 елларга кадәр Казанда талантлы Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Камаллар әйдәвендә барган әдәби хәрәкәт татар әдәбиятының төп магистраль юлы булуы, татар революцион демократия юнәлешендә барган бу куәтле куч[1] яки өчлек үзәге белән татар социал-демократ большевиклары Ямашев, Дулат-Алиләрнең дусларча

[1] Куч — күчеп баручы ил димәктән. Бал кортлары ил аерып күчкәндә «корт күче» дип, «күче белән» дип әйтелә. (Автор искәрмәсе.)

мөнәсәбәттә булганлыклары хәзер шактый ачыкланган мәсьәлә. Югарыда әйтелгән чарлак һәм гөбәдия вакыйгаларын да шундый тактик багланышның бер күренешедер дип аңлау дөресрәк булыр.

Унынчы елларга кадәр Ф. Әмирхан, Г. Тукай, Г. Камаллар төркеме алып барган революцион-демократ фикерле бу әдәби үзәк унынчы еллардан соң акрынлап көчәреннән сына диярга була. Моңар сәбәп — шул елларда Россиядә яңадан көчәеп килүче революцион хәрәкәткә каршы хөкүмәтнең, реакциянең һөҗүме. (Лена эшчеләрен аттыру һәм төрле эзәрләүләр китү.) Милли азатлык хәрәкәте империянең колониаль сәясәтенә куркыныч тудыруын, мәдрәсәләрдә шәкерт забастовкалары алып барган ислахчылык артында татар революцион-демократ һәм сул фикерле язучыларның кулы уйнавын яхшы төшенгән патша хөкүмәте бу әдәби-мәдәни хәрәкәтләрне дә үзенә каршы алып барылган революцион көрәшләрнең бер тармагы итеп карый. Аның соңгы органы булган «Әлислах» ябыла. Алай гына да булмый, бишенче ел җиле белән бездәге дини мәдрәсәләрне рус һәм Европа гимназия, дарелфөнүннәре тибында милли, дөньяви гыйлем йортлары итү юлына аяк баскан ислахчы-җәдитчеләр хәрәкәтенә каршы патша хөкүмәте, доносчы Ишми ишан, яшерен миссионер, охранкачы, русификатор доктор Хәнәфи Кайбишев һәм башка татар провокаторлары коткысы белән, «пантюркизм», «панисламизм» дигән шаукымлы провокацияләр оештырып, мәдрәсәләрдә тентүләр башлый, полиция отряды белән Буби мәдрәсәсенә погром оештырыла, «Ватанга хыянәт» маркасы астында күргәзмә судлар ясап, берни исбат итә алмасалар да, мөгаллимнәре сөрелеп, мәдрәсә яптырыла. «Галия» мәдрәсәсендә дә зур шау-шулы тентүләр уздырыла.

1910—1911 елларда, мондый террор һәм погромнардан соң, Казанда татар яшьләре арасында барган революцион хәрәкәт зур авырлыклар кичерә. Нәтиҗәдә, шуңа кадәр үзәк урын тотып килгән Әмирхан, Тукай, Камаллар төркемендә дә нык имгәнүләр күрәбез: 1912 елда Хөсәен Ямашев, ничектер, серле рәвештә кинәт үлә, Дулат-Али Казаннан китә һәм шуннан ярты ел да үтми, Тукай да вафат була. Ф. Әмирханның үз аягы белән йөри алмас хәлдә авыру булуы һәм Г. Камал да либераль «Йолдыз» газетасында хезмәткәр булып яшәргә калулары белән, әдәби активлыклары нык кимеп, без инде уникенче еллардан соң бу әдәби «куәтле күч»нең элеккечә үзәк урын тотканын күрмибез.

Әдәби хәрәкәтнең шуннан соңгы юнәлешенә килгәндә, Казанда 1912 елда Тукай инициативасы белән оештырылган әдәбият-сәнгать органы «Аң» журналына ул үлгәннән соң куәтле яңа көчләрдән Г. Ибраһимов секретарь булып килә һәм аның тирәсендә М. Хәнәфи (Кайбишев)[1], Ф. Сәйфи активлаша, читтән Сәгыйть Рәмиев, Чыгтай һәм башкалар тартылалар. Казанда бу яңа әдәби төркем, Г. Ибраһимов китү сәбәпле, үзенең үзәклек ролен озак алып бара алмаса да, әдәби һәм иҗтимагый фикер тарихыбызда булып үткән бу юнәлеш үз заманы өчен төрле яктан игътибарга лаек, бик характерлы һәм, минемчә, әлегә кадәр ачылмаган катлаулы роль уйный. Бу юнәлешләр татар әдәбиятының эчтәлек һәм сәнгатьчә форма ягыннан үсешендә бик нык сизелерлек үзенчә тәэсир ясый. Ләкин аларга тукталу әлегә бу мәкаләнең мәсьәләсе була алмый.

1912 елда Хөсәен Ямашев үлгәч һәм Дулат-Али Казанда хөкүмәт эзәрлекләвеннән качып китәргә мәҗбүр булгач, ул чагында каты авыру хәлендәге Тукай «иптәшем Мәхмүткә ядкарь» дип атап әлеге фоторәсемен биргән була.

Ә инде Октябрь революциясеннән соң без Дулат-Алине татар революционерларының алгы сафында күрәбез. Аның исеме татар совет матбугатында еш телгә алына: ул Казанда Губком члены, Мөселман Коммунистлар мәркәз комитеты бюро члены. Ул бюро Мәскәүгә күчкәч, Дулат-Алине тагын анда, Мәркәз Мөселман эшләре комиссариатында, ул чагында Мулланур Вахитовлар тарафыннан проекты төзелеп, Үзәк тарафыннан расланган Татар-башкорт Советлар Республикасы һәйәтендә һәм башка делегацияләр составында күрәбез. Зәки Вәлиди хөкүмәте бу проекттан аерылып, Кече Башкортстан юлы белән киткәч һәм ул җирләр Колчактан тазартылгач, Дулат-Алинең (шул ук эшләр яки башка йөкләмәләр буенчамыдыр) Башкортстанда Стәрле Тамакта булуы күренә. 1920 елда Башкортстанда төрле фетнәләр, милли кү-

[1] Монысы соңыннан үзен дошман һәм провокатор буларак таныта. Аның кем икәнлеген белмичә журналга чакыруын Г. Ибраһимов, хаталык санап, үзе дә язып чыга. Карагыз: Г. Ибраһимов, «Татар студентлары хәрәкәтеннән». 1922 ел. Аерым китап.

тәрелешләр һәм кисешләр учагы булган Бәрҗән-Тангавыр кантонында хуҗалык эшләре тәмам таркалгач, Дулат-Али кантон үзәге булган Төмәчкә җибәрелә, анда Оренбурдан фетнә бастырырга килгән отряд тарафыннан хаталык белән кулга алына, 1920 елның 1 августында һәлак ителә.

Дулат-Али кебек зур фигура хакында документаль материаллар җитәрлек табылачак һәм ул хакта тарихчыларыбыз яза булыр.

1971 ел җәй Күн авылы яны «Кызыл яшьләр»дә ятканымда миңа Дулат-Али турында тагын шундый бер яңа эпизод ишетергә туры килде.

1918 елның җәендә Казанны ак чехлар алып, халык каһарманы бөек революционер Мулланур Вахитов үтерелгәч, дошманнар аның яраннарын, шул җөмләдән Мәхмүт Дулат-Алине дә, атарга эзлиләр. Мәхмүт үзенең иптәше Минһаҗ Күнов[1] белән, икесе ике атка атланыпмы — ничек, Казаннан 50 чакрымнар көнчыгыштагы Күн авылына килеп төшәләр. Минһаҗ Мәхмүтне үз авылында яшереп калдыру өчен алып килгән була. Алар халыкка Мулланурның аклар кулыннан үтерелүен, аклар мобилизация ясарга монда килгәндә, аларга гаскәр бирергә ярамавын сөйләп төшендерәләр. Ул арада Дулат-Али белән Минһаҗ эзеннән аклар килеп төшә. Минһаҗлар өендә тентү башлана. Ләкин ул авылның дөнья күргән, элек патшага ходатай булып йөргән, закон белгән кешеләре акларга ход бирмиләр. Минһаҗның китап-кәгазь сандыкларын «монысы кыз сандыгы», «тегесе килен сандыгы», «хакыгыз юк!» кебек сүзләр белән бик нык торып тентергә бирмәгәч, аклар бу авыл кешеләре үзләренә дошман икәнен күреп, сагаеп, тыйнаграк кыланырга мәҗбүр булалар. Аклар атна буе Күндә ятып эзләсәләр дә, Минһаҗ белән Мәхмүтне таба алмыйлар һәм игълан иткән мобилизацияләренә дә гаскәр җыя алмыйча, куркуга төшеп, килгән юлларыннан кире китәргә мәҗбүр булалар. Халык Дулат-Али белән Минһаҗ Күновны тентүләрдән мунчаларда яшереп, акларга бирмичә саклап алып кала. (Бу хәбәр кайда да булса язып теркәлгәнме-юкмы, миңа билгесез. Калганын тарихчылар ачыклар бәлки. Тукай дусларыннан булган Мәхмүт Дулат-Али хәлләреннән ишетелгән бер эпизод буларак, аны да монда теркәп үтү мәслихәт күрелде.)

Әмма Октябрьдан башлап егерменче елларгача халкыбызның сыйнфый һәм милли азатлык яулап алу юлында иң кайнар, иң дәртле революцион көрәш тарихы һәм аның баһадирлары, безнеңчә, әле җитәрлек өйрәнелмәгән. Башкортстанда В. Исхаков һәм Ф. Исәнгулов иптәшләр бу юлда зур һәм матур әдәби әсәрләр бирделәр инде. Бездә соңгы елларда бер профессор Р. И. Нәфиковның гына Мулланур Вахитов турындагы тарихи-монографик мөһим хезмәте чыкты. Вакыйгаларга бик бай, катлаулы һәм кызыклы бу чорыбыз, әлбәттә, матур әдәбиятта, романнар һәм пьесаларда, тирән итеп, тулы чагылдырылуын көтә.

---

[1] Минһаҗ Күнов — Күн авылыныкы. (Фамилиясе Күн шуннан алынган.) Большевик-революционер. Совет заманында укытучы булып та эшләгән һәм кайбер әсәрләр дә язган.

**Шерали Турдыев,**
филология фәннәре кандидаты

# РУХИ ТУГАНЛЫК

Татар әдәбияты һәм культурасы әле революциягә чаклы ук үзбәкләр арасында гына түгел, Урта Азиядә һәм Кавказда, хәтта Көнчыгыш Төркестанда яшәүче халыклар арасында да киң таралган була. Үзбәк, казакъ, төркмән, кыргыз һәм уйгурлар белән чагыштырганда, татар интеллигенциясе алдынгы рус әдәбияты һәм Көнбатыш культурасы белән иртәрәк таныша. Рус һәм Көнбатыш культурасы тәэсирендә татар телендә яңа газета һәм журналлар чыга башлый, беренче театр труппалары оеша.

Урта Азия һәм Казагыстан әдипләре Көнбатыш Европа һәм рус культурасы казанышлары белән беренче чорда татар әдәбияты аша танышалар. Бу бәйләнештә егерменче гасыр башында Россиянең әһәмиятле культура һәм политик үзәкләреннән саналган Казан шәһәре зур роль уйный. Казанның интернациональ миссиясе хакында Герцен 1836 елда ук инде үзенең «Провинциядән хатлар»ында телгә алып уза. Төркестанда тарала торган китапларның күп өлеше Казанда басыла. Революциягә кадәр татарлар чыгарган «Вакыт», «Тормыш», «Йолдыз», «Сүз» кебек газеталар, «Аң», «Ак юл», «Шура» кебек журналлар Урта Азия укучыларының игътибар үзәгендә булып киләләр. Үзбәк әдәбиятын һәм вакытлы матбугатын үстерүдә алар зур роль уйный.

Вакытлы татар матбугаты битләрендә даими рәвештә прогрессив язучылардан Габдулла Тукай, Галимҗан Ибраһимов, Мәҗит Гафури, Фатих Әмирхан һәм башкаларның шигырьләре, хикәяләре, публицистик мәкаләләре басылып килә. Әлеге татар язучыларының әсәрләре, шулай ук Көнбатыш һәм дөнья әдәбияты классикларының татарча газета-журналларда басылган үрнәкләре белән танышу үзбәк әдәбиятының башка милли әдәбиятлар белән бәйләнешка керүен тизләтә.

Татарларны һәм төрки телле башка милләт укучыларын дөнья әдәбияты казанышлары белән таныштыруда Оренбургта чыккан «Шура» журналы аеруча зур эш башкара. Аның битләрендә иҗтимагый-политик һәм фәлсәфи-эстетик мәкаләләр, төрле тарихи чорларда яшәгән алдынгы карашлы фикер ияләренең әсәрләре басыла. 1908—1917 еллар эчендә журнал үзенең укучыларын Кантимер, Ломоносов, Державин, Карамзин, Жуковский, Батюшков, Крылов, Пушкин, Грибоедов, Лермонтов, Кольцов, Гоголь, Гончаров, Тургенев, Островский, Толстой, Чехов, Горький һәм шулай ук Сен-Симон, Жан-Жак Руссо, Хафиз, Руми, Хәйям, Фозули, Нәвои һәм дөнья әдәбиятының башка классиклары белән таныштыра. Журнал битләрендә, моннан тыш, төрек, гарәп, һинд, япон, кытай әдәбиятларыннан яңа тәрҗемәләр бирелеп бара.

Бу урында шуны да әйтеп үтәргә кирәк, татар әдәбиятында Карамзинның «Бедная Лиза»сы, Островскийның «Гроза»сы йогынтысы астында язылган әсәрләр барлыкка килә. Фатих Халидинең «Рәдде бичара кыз»ы, Габдрахман Ильясиның «Бичара кыз»ы, Заһир Бигиевның «Меңнәр яки гүзәл кыз Хәдичә»се әнә шундый әсәрләр.

Икенче яктан, Гафур Коләхметовның «Яшь гомер», Галиәсгар Камалның «Бәхетсез егет» әсәрләрендә М. Горький әсәрләренең йогынтысы нык сизелә.

Татар әдәбиятының бу әсәрләре Төркестанда да киң тарала һәм, әлбәттә, алар 1905—1917 елларда үзбәк әдәбиятында яңа жанрлар — проза һәм драма жанраларының формалашуына, әдәбиятның һәм вакытлы матбугатның гомуми үсешенә этәреш ясамый калмыйлар. Шуның нәтиҗәсе буларак, Урта Азиядә 1905—1915 елларда «Сәмәрканд», «Төркестан авазы», «Фергано авазы» исемле газеталар һәм журналлар чыга башлый. Хәмзәнең «Агулы тормыш», «Яңа бәхет», Абдулла Кадыйриның «Бәхетсез кияү», «Уйнаш», Садретдин Айнининың «Бәхетле гаилә» кебек проза һәм сәхнә әсәрләре нәкъ менә шул чорда языла.

Үзбәк әдәбияты белән татар әдәбияты арасындагы бәйләнеш, әлбәттә, бер яклы гына булмый. Үзбәк шагыйрьләре һәм язучылары шул вакыттагы татар матбугатында да актив катнашалар. Алар ул заман өчен прогрессив уку йортлары булып саналган «Галия», «Хөсәения» кебек мәдрәсәләрдә укыйлар.

«Шура» журналында Суфизаданең «Хатын-кызлар исеменнән», «Мөселманнар» исемле шигырьләре, Мирмөхсин Ширмөхәммәдовның «Зиндан», «Төркестанның административ төзелеше», «Аяныч хәл яки дөреслек турында хикәят» дигән публицистик мәкаләләре, Лотфулла Галиминең «Туран кызларына», Зәвкинең «Туган», «Күпләрдән берәү» һәм башка язучыларның күп санлы шигырьләре, публицистик мәкаләләре, очерклары, хикәяләре басылып чыга. Бу әсәрләрдә дини хорафатлар, хезмәт ияләренә кайгы һәм бәлгенлек китерүче, кешенең горурлыгын кимсетүче җәмгыять тәнкыйтьләнә, көнчыгыш хатын-кызларының авыр хәле тасвирлана.

Татар әдипләре үзбәк әдәбиятын идея-тематик яктан баету һәм халык тормышына якынайту, шулай ук аның телен һәм стилен тормышчан итү эшенә дә күп өлеш кертәләр.

Татар матбугаты һәм интеллигенциясе белән танышлыгы, бу танышлыкның үз иҗатына уңай йогынтысы турында Хәмзә зур горурлану белән яза: «1907 елда әтине Кашгарга озата баргач, мин «Вакыт» газетасын укырга күнегеп киттем, — ди ул үзенең истәлекләрендә.— Шул көннән башлап әллә кайчангы хорафатлар, мәдрәсәләрдә укытуның куелышы, халык тормышындагы үзгәрешләр, экономика һәм культура мәсьәләләре хакында туктаусыз уйлана башладым.

1905 елгы революция турында да шул чакта ишеттем. Анда кул станогында кечкенә-кечкенә брошюралар һәм листовкалар басучы яшь кенә бер татар егете бар иде. Мин аның белән атнага ике тапкыр очраша идем. Күрәсең, миңа аның йогынтысы шактый көчле булган, чөнки нәкъ менә шушы вакытта элекке патшалар тормышыннан «Дөреслек кем ягында» дигән кечкенә бер роман яздым. Кызганычка каршы, ул романны югалттым һәм әле хәзергәчә таба алганым юк. Шушы вакыттан бирле минем шигырьләрем дә... революцион рухта языла башлады...»[1].

Әлбәттә, Хәмзә иҗатына Габдулла Тукайның да, Мәҗит Гафуриның да революцион рухлы поэзиясе тәэсир итми калмаган. Моны раслау өчен Хәмзәнең «Егетләр һәм кызлар диалогы», «Хатлар», «Рамазан», «Сагынам», «Сәлам әйтегез», «Уян, эшче!» шигырьләре белән Г. Тукайның «Мужик йокысы», «Бәйрәм бүген», «Тавыш хакында» һәм М. Гафуриның кайбер шигырьләрен чагыштырып карау да җитә.

Хәмзәнең 1914 елда басылып чыккан «Рамазан» шигыре белән Г. Тукайның «Нәсыйхәт» шигыре арасындагы охшашлык аеруча нык күзгә ташлана. Бу шигырьләрнең һәр икесендә халыкның бәлгенлектә, хәерчелектә яшәве сурәтләнә. Һәр ике шигырьдә ятимнәрнең авыр хәле, байларның комсызлыгы һәм кансызлыгы турында сөйләнә.

Һәр вакыт халыкка якын торган, аның авыр тормышын үз күзләре белән күргән Хәмзәнең татар халкының алдынгы карашлы шагыйре Тукайдан өйрәнгән булуы һич тә гаҗәп түгел. Тукайда без түбәндәге юлларны укыйбыз:

**Ихтыяҗын гарыз итеп килсә теләнче капкаңа,**
**Каты сүзләр белән инсаниятен син таптама.**

---

[1] Ю. Султанов. Хамза. Рус телендә. Ташкент, 1973 ел. 112—113 битләр.

**Син кеби һәм ул теләнчеләр дә — алланың колы;**
**Кул суза, мескен! — бәхетсезлек вә ачлык аркылы.**

**Күрмәгез, бер яклы, дип, бу вафасыз дөньяны;**
**Ул ике яклы: аның бардыр иләк һәм күн ягы.**

**Әйләнә, көпчәк кеби, байлык вә шөһрәт, мәртәбә, —**
**Син бүген бай, бәлки, шайтаннан да ярлы иртәгә!**

**Булса — бир, булмас исә, җайлап сөйлә булмаслыгын,—**
**Сизми калма ак сакаллы карт Хозыр Ильяслыгын!**

Хәмзә шигырендә дә шушыңа ук аваздаш фикерләр әйтелә. Шигырь капкорсакларга мөрәҗәгать иткән мондый юллар белән тәмамлана:

**Ни өчен соң ярлылар һәр урында**
**Газап чигә һаман синең кулыңда!**

**Шаһ булырга мөмкин берчак ярлы да,**
**Ә син аның колы булып калырга!**

Тема уртаклыгы (байлар һәм ярлылар), образларның бер-берләренә охшашлыгы, ниһаять, бер үк политик идея — боларның барысы да Тукайның үзбәк шагыйренә зур йогынтысы булганлыгы турында сөйли. Хәмзә иҗатын тикшерүче әдәбият галиме Л. Каюмов бу хакта болай дип яза: «Г. Тукай һәм Хәмзә иҗатларын бергә куеп тикшерү Тукайның Хәмзәгә, һичшиксез, зур йогынты ясаганлыгын, аның остазларының берсе булганлыгын раслый.

Тукайның үлеме үзбәк халкының да әйтеп бетергесез зур кайгысына әверелә. Үзбәк интеллигенциясе аны күмүдә катнашу өчен үзенең вәкилләрен җибәрә. Шул чакта ук инде Ташкентта, Сәмәркандта, Бохара, Хива һәм башка шәһәрләрдә Тукайның үлеменә багышланган кайгы кичәләре уздырыла. Бу вакыйгага уңае белән 1914 елда үзбәк шагыйре Таволлоның шигыре басылып чыга. Ул шигырьдә үзбәк халкының татар халык шагыйренә булган олы мәхәббәте турында сөйләнә.

Тукай поэзиясе үзбәк халкы арасында революциягә чаклы ук зур популярлык казана. Аның шигырьләрен оригиналда укыйлар. Ул шигырьләрнең күбесе, шул нәүбәттән «Туган тел» шигыре дә, Абдулла Авлани тарафыннан төзелгән беренче үзбәк дәресләкләренә кертелә»[2].

Татар-үзбәк әдәбиятлары арасындагы бәйләнеш, татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукай әсәрләре белән кызыксыну Октябрь революциясеннән соң тагын да киңрәк колач ала. Совет власте елларында үзбәк халкына СССР халыкларының алдынгы культурасын һәм әдәбиятын, шул нисбәттән татар әдәбиятын да, өйрәнү өчен зур мөмкинлекләр ачыла. Революциягә кадәр үк Төркестанга килгән татар интеллигентлары Хәмзә, Абдулла Авлани, Мирмөхсин Ширмөхәммәдов, Абдулла Кадыйри кебек күренекле язучылар, шагыйрьләр һәм журналистлар белән кулга-кул тотынып эшлиләр. Үзбәк дусларына алар әдәбиятны һәм журналистиканы үстерүдә булышалар. Бу эштә үзләренең әдәби-тәнкыйть, публицистик мәкаләләре, фельетоннары һәм хикәяләре белән Г. Сәгъди, З. Бәшири, С. Мәхмүт, М. Хәсән, Б. Әхмәт аеруча актив катнаша. Алар рус һәм Көнбатыш әдәбиятын үзбәк теленә тәрҗемә итәләр, үзбәк әдәбияты буенча дәреслекләр, хрестоматияләр төзиләр, үзбәк-татар әдәбиятын һәм культурасын пропагандалыйлар, үзбәк әдәбиятын, тәнкыйтен, театрын үстерү эшенә үзләреннән зур өлеш кертәләр.

1930 елда үзбәк теленә Галимҗан Ибраһимовның «Табигать балалары», 1932 елда «Кызыл чәчәкләр»е, Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури, Хәсән Туфан шигырьләре тәрҗемә ителде. Ташкентта татар-үзбәк дуслыгы кичәләре уздырылды, Габдулла Тукай юбилейлары киң билгеләп үтелде. Үзбәк театры сәхнәләрендә Г. Камал һәм башка татар драматургларының пьесалары куелды.

---

[2] Л. Каюмов. Габдулла Тукай и узбекская поэзия. «Габдулла Тукай» исемле җыентык. Казан, 1968 ел, 61—62 битләр.

Үзбәкстанда Тукай әсәрләре аеруча киң таралды. Шагыйрь турында республиканың үзәк газеталары күп тапкырлар язып чыктылар. 1920 елның 15 апрелендә «Коммунист» газетасы «Көнчыгыш шагыйре Габдулла Тукай» дигән мәкаләсендә, мәсәлән, болай дип язды: «Көнчыгышның Әль-Мәгари, Хафиз, Гомәр Хәйям, Сәгъди, Нәвои кебек бөек шагыйрьләре арасында Габдулла Тукай да мактаулы урын алып тора. Ул Россиядә төрек-татар хезмәт ияләрен революциягә хәзерләште».

Шагыйрьнең «Туган тел», «Шүрәле» һәм башка күренекле әсәрләре революциядән соң да «Уку китаплары»на, дәреслекләргә кертелде. Аның шигырьләре хәзер дә дәреслек битләреннән төшми. Укучылар, Абдулла Кадыйри, Чулпан, Фитрәт, Гафур Голәм, Абдулла Каххар, Х. Алимҗан, Уйгун, Зөлфия әсәрләрен яратып укыган шикелле үк, Тукай шигырьләренә һәм поэмаларына да әледән-әле мөрәҗәгать итәләр.

Утызынчы-кырыгынчы елларда чыккан газета-журнал битләрендә без Тукайның тормыш юлына һәм иҗатына багышланган хезмәтләрне еш очратабыз. Тукай мирасы белән кызыксыну Бөек Ватан сугышы елларында да, аннан соңгы чорда да кимемәде. 1946 елда үзбәк телендә Тукай шигырьләренең яңа тәрҗемәләре басылып чыкты. Шагыйрьнең 60 еллыгына багышланган «Сайланма әсәрләр»е үзбәк рәссамнары тарафыннан ясалган рәсемнәр белән бизәлеп чыгарылды.

Соңгы елларда, СССР халыклары әдәбиятларының һәм культура элемтәләренең үсүе уңае белән, үзбәк халкының Тукай иҗаты белән кызыксынуы тагын да артты. 1961 елда үзбәк матур әдәбияты нәшрияты 10.000 данә тираж белән аның «Сайланма әсәрләр»ен бастырды. Аңа сүз башын күренекле үзбәк язучысы Ә. Мохтар язды. Тукайның шигырьләрен үзбәк теленә Гафур Голәм, Уйгун, Миртимер, Ә. Мохтар кебек күренекле шагыйрьләр тәрҗемә итте. Үзбәкстанның танылган язучылары, Тукай исемен Пушкин, Лермонтов, Байрон исемнәре белән рәттән куеп, аның иҗатының роле турында күп санлы мәкаләләр яздылар.

«Тукай, — дип язды Үзбәкстанның халык шагыйре Уйгун, — үзбәк халкына күптән таныш һәм якын. Без элек-электән, мәктәп елларыннан бирле Тукай шигырьләрен укып үстек. Без аны ихлас күңелдән үзебезнең укытучыбыз, үзебезнең шагыйребез итеп саныйбыз».

Габдулла Тукайның 80 еллык юбилеенда катнашкан Гафур Голәм Тукай турында, аның иҗатының Урта Азия һәм Казагыстан әдәбиятларына шифалы йогынтысы турында, үзбәк халкының татар халкына ихтирамы, мәхәббәте турында җылы сүзләр әйтте.

Әйе, Ташкентта, Үзбәкстан ССР Министрлар Советы, Үзбәкстан ССР Верховный Советы, Үзбәкстан Фәннәр академиясе китапханәсе, А. Нәвои исемендәге Республика китапханәсе урнашкан үзәк урамнарның берсе юкка гына Тукай исеме белән аталмаган!

Габдулла Тукай урамы, үзбәк һәм татар халыкларының күптәнге дуслыгын чагылдырган символны хәтерләтеп, Алишер Нәвои проспекты белән кисешә.

**Солтанморат Акбиев,**
филология фәннәре кандидаты

# ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ҺӘМ КУМЫК ӘДӘБИЯТЫ

Габдулла Тукайның әдәби мирасы татар халкының милли байлыгы һәм горурлыгы булып тора. Татар әдәбиятының үсешен Тукай иҗатыннан башка күз алдына китерү кыен. Аның дулкынландыргыч лирикасы, үткен сатирасы, ялкынлы публицистикасы татар халкының гына түгел, күп кенә башка милләтләрнең дә рухи үсешенә зур йогынты ясаган. Бу йогынты кумык әдәбиятында аеруча ачык чагыла. Габдулла Тукай иҗаты тәэсирендә кумык әдәбиятында мәгърифәтчелек һәм революцион-демократик идеяләр формалаша.

Кумык халкының тугандаш төрки халыклар белән бәйләнеше турында сүз барганда тарихка күз төшереп алмый булмый. Кумыклар борын-борын заманнардан Каспий буе яссылыгының төньяк-көнчыгышында яшәгән. Көнбатыш һәм көнчыгыш халыкларын бер-берсе белән бәйли торган күп юллар кумык далалары һәм Каспий диңгезе аша үткән. Төрки телдә сөйләшүче кайбер күчмә кабиләләр соңра, шушы уңдырышлы җирләрдә төпләнеп, утрак тормышка күчкәннәр, терлек асрау һәм игенчелек белән шөгыльләнә башлаганнар. Тора-бара алар элек-электән бу далаларда яшәгән җирле халыклар белән аралашып беткәннәр. Әнә шул заманнардан бирле кумыклар күп кенә төрки халыклар белән тарихи-экономик бәйләнешкә кергән. Дагстанлылар, эш эзләп, Астрахань, Троицк, Уральск, Оренбург шәһәрләренә һәм бигрәк тә көнчыгыш халыкларының уртак культура үзәге Казанга бара торган булганнар. Алар белән бергә Идел буеннан тау иленә, кумык далаларына көрәш һәм азатлык идеяләре һәм аң-белемгә омтылыш хисләре кайткан. Соңра Каспий буе авылларында һәм шәһәрләрендә, татар мәктәпләре үрнәгендә, гомуми белем бирү мәктәпләре ачыла башлаган. Бу мәктәпләрдә башлыча татар дәреслекләре буенча укытканнар һәм күп очракта мөгаллимнәре дә татар мәгърифәтчеләре булган. Әйтик, 1768—1838 нче елларда Жаксай шәһәрендә Тажетдин Ялчыгол исемле татар мөгаллиме укыткан. XIX йөз ахырларында исә Исхак исемле Казан татары шул ук мәдрәсәдә укытучы булып эшләгән. Татар халкының мәшһүр әдибе, җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимов нугай балаларына аң-белем биргән.

...Тукай иҗатын һәм аның кумык әәдбиятына йогынтысын өйрәнгәндә татар һәм дагстан әдәбияты үрнәкләрен бер-берсе белән чагыштырырга, аларның идея-тематик үзенчәлекләрен ачыкларга туры килде. Язма әдәбият истәлекләре белән генә чикләнмичә, мин заманында Габдулла Тукайның үзен күреп белгән кешеләрне табарга, бөек шагыйрь турындагы сәхифәләрне аларның үзләреннән ишетергә тырыштым.

Каспийск шәһәрендә Шаше Зәлиев исемле бер карт очрады. Тукай һәм аның иҗаты белән кызыксынганымны белгәч, ул озак кына сүзсез утырды, аннары, кумык картларына хас басынкы тавыш белән, әкрен-әкрен хәтер йомгагын сүтәргә кереште. Сиксән алты яшьлек бу карт яшь чагында, эш эзләп, Идел буе шәһәрләрендә йөргән.

Самарада, Уральскида булган, Казанга барып чыккан. Тукайны ул беренче кат Кабан күле буенда очраткан.

«Кабан күле буендагы бер чәйханәгә кереп, капкалап чыгарга иде исәп, — дип сөйләп китте Шаше карт. — Аннары берәр якташны очратмаммы, дигән өмет тә бар иде. Карыйм, шунда сөйләшеп утырган яшьләр арасыннан чандыр гына бер егет еш-еш минем якка күз сала. Кай ягым белән аның игътибарын җәлеп иткәнмендер, белмим. Әмма ул озакламый, дус-ишләреннән аерылып, минем янга килде һәм ягымлы тавыш белән сәлам бирде: «Әссәламегаләйкем! Сез, туган, Кавказ ягыннанмы әллә?» — ди. Кумык икәнемне белгәч, хәл-әхвәл сораштыра башлады, үзенә кунакка чакырды».

Шаше Зәлиевнең сүзләренә караганда, шуннан соң Габдулла Тукай белән алар шактый еш очрашканнар. Тукай Дагстан халкының тормыш-көнкүреше белән кызыксынган, кумыкларда газета-журналлар чыга башлавын ишетеп, чын күңелдән шатланган.

Бу елларда Дагстаннан Казанга килеп эшләүче тагын күп кенә яшьләр Габдулла Тукайны күреп белгәннәр. Күренекле шагыйрь һәм мәгърифәтче Нухай Батырморзаев байтак вакыт Казан типографияләрендә хәреф җыючы булып эшләгән. Тукайның кайбер әсәрләре аның кулы аша да узган. Нухай Тукай шигырьләрен почта аша үз балаларына — уллары Зәйнәлгабид белән Әбделхәмиткә һәм кызы Рапишка җибәрә торган булган. Зәйнәлгабид Тукай шигырьләрен үз яшьтәшләренә кычкырып укыган. һәм ул әсәрләрдә Дагстан яшьләре үзләрен дулкынландырган күп сорауларга җавап тапканнар, алар йогынтысында соңра алдынгы интеллигентлар рәтенә, мәгърифәтчеләр сафына басканнар.

Тукайның беренче шигырьләре үк кумык яшьләрен тирән дулкынландырган. «Мужик йокысы», «Соры кортларга», «Китмибез», «Государственная думага» һ. б. шигырьләр Каспий далаларында, тау үзәннәрендәге ерак авылларда телдән-телләргә күчеп йөргән. һәркемгә мәгълүм булганча, бу шигырьләрендә Тукай, 1905 елгы революцион күтәрелеш рухы белән дәртләнеп, халыкны мәңгелек йокыдан уянырга, көрәшкә күтәрелергә, аң-белем алырга өнди, ярлыларга җир вәгъдә итеп тә коры сүз белән генә калган Дәүләт думасын тәнкыйтьли. һәм менә нәкъ шуның өчен дә халык теләкләренә, аның уй-фикерләренә аваздаш булган бу әсәрләр кумыклар арасында бик тиз таралып өлгерә.

Революцион күтәрелеш елларында, Тукай һәм татарның башка алдынгы әдипләренең дә йогынтысы белән, кумык әдәбиятында гражданлык лирикасы үсеп китә. Моңа мисал итеп шул ук Нухай Батырморзаев иҗатын китерергә мөмкин. Иң беренче әсәрләрендә үк Нухай үз халкын азатлык өчен көрәшкә, мәгърифәткә өнди, иске тәртипләрне аяусыз тәнкыйть итә. «Кавказның һәм бөтен Россиянең бүгенге хәле» исемле поэмасында шагыйрьнең дөньяга карашы аеруча ачык чагыла. Нухайның бу поэмасын игътибар белән укыганда аның беренче чыганагы, иҗади этәргече Тукайның «Соры кортларга» шигырендә икәнен ачыклау кыен түгел. Тукай кебек үк, Нухай да үз әсәрендә гади халыкны талап баеган комсыз байгуралардан, капкорсак ишаннардан көлә, кимсетелгән, изелгән хезмәт кешеләрен яклап чыга. Шулай ук Нухай патша хөкүмәтенең шовинистик идеяләрен шул сәясәткә каршы куя. Нухай фикеренчә, рус та, еврей да, әрмән дә, грузин да — һәммәсе тигез хокукта булырга тиеш. Шагыйрьнең бу юлларын укыган вакытта ирексездән Тукай сүзләре искә төшә:

**И кардәшләр, кул тотышып алга барыйк,**
**Башка милләтләрнең хәлен карап карыйк;**
**Мәдәният мәйданында урын алыйк, —**
**Егыла-тора алга таба атлыйк, имди.**

Нухай Батырморзаев Габдулла Тукайны кумык әдәбиятына зур йогынты ясаган башка күп даһи әдипләр белән тиң саный, аның исемен А. С. Пушкин, Н. В. Гоголь, Л. Н. Толстой, А. М. Горький исемнәре белән янәшә куя. «Алар полиция камчысыннан да, дар агачыннан да, җәллад балтасыннан да, зинданнардан да курыкмадылар, — дип яза Нухай. — Алар самодержавиенең барлык әшәке якларын аяусыз тәнкыйтьләделәр. Үзләренең бөтен иҗатларында, бөтен әсәрләрендә алар гади халык фикерен

алга сөрделәр. Алар өчен дәреслек, чын хакыйкать үз тормышларыннан да кадерлерәк иде һәм алар бөтен барлыклары белән шуның өчен көрәштеләр».

Иҗатының чәчәк аткан елларында Нухай Батырморзаев «Давыт һәм Ләйлә», «Бичара Хабәйбат» повестьларын, «Тамыр җәйгән агач» шигырен язды. Һәм аның бу әсәрләрендә шулай ук Тукай йогынтысы ачык сизелә. Әлеге әсәрләрне Г. Тукайның шул ук «Соры кортларга», «Мактанышу», «Ишан», «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр?» шигырьләре белән чагыштырып караганда, алардагы рухи якынлыкны һәм идея бердәмлеген сиземләү кыен түгел.

Бер Нухай гына түгел, кумык халкының башка әдипләре дә Тукайны үзләренең остазы дип санаганнар һәм Тукайдан өйрәнгәннәр. Әбүсуфьян Акаевның гаять бай әдәби мирасын тикшергәндә аның шигырьләре белән Тукай әсәрләре арасында фикер уртаклыгы, идея бердәмлеге ачык күренә. Ул үзенең күп кенә әсәрләрен Тукайга ияреп язган һәм кайбер очракта үз шигыренең тукымасына Тукай юлларын кертеп җибәргән. Мәсәлән, «Яшьләргә нәсихәт» поэмасында Акаев, иҗади эшкәртеп, Габдулла Тукайның «Толстой сүзе» исемле шигырен файдалана:

**Пайдасыз бош заман гетмесин воьре,**
**Билмейгенинг артдыр пагъмунга гёре,**
**Алтундан сыйлы бил гьар сагьатынгны.**

. . . . . . . . . . . . . . . . .

**Ашамакъ бил сен яшамакъ учун,**
**Тюгюлдюр яшамакъ ашамакъ учун.**

Габдулла Тукайның «Китап», «Бәхетле бала», «Мәктәп», «Мәктәптә», «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр?» исемле шигырьләрен Акаев, Дагстан җирлегенә яраклы рәвештә эшкәртеп, кумык телендә бастырып чыгарган.

Ул чордагы кумык әдипләренең күпчелеге, иҗат мәсьәләләрендә Габдулла Тукайдан өйрәнсәләр дә, дөньяга карашлары, сыйнфый аңнары белән Тукай дәрәҗәсенә күтәрелгәннәр дип әйтү кыен. Моның өчен аларга әле җитәрлек социаль шартлар тумаган булган. Чөнки күп санлы милли интеллигенциясе, Хөсәен Ямашев кебек өлгергән большевиклары булган татар халкы үзенең культура дәрәҗәсе, экономик һәм сәяси үсеше буенча башка төрки милләтләрдән шактый өстен торган.

Әмма, шуның белән бергә, кумык интеллигенциясе, үзенең культурасын, әдәбиятын үстерергә омтылып, рус һәм алдынгы бүтән милләтләр әдәбияты белән беррәттән, татар халкының да күренекле әдипләре һәм бигрәк тә даһи Тукае белән якын мөнәсәбәткә керергә тырышкан. Тукай турында соңра Н. Батырморзаев болай дип яза: «Ул бик иртә вафат булды. Әгәр тагын бераз гына яшәсә дә, ул бөек эшләр башкарган булыр иде. Әмма иҗат итеп калдырган шушы әсәрләре белән дә ул Казан татарлары арасында хаклы рәвештә мәңгелек данга иреште».

Кумык халкының тагын бер якынлы әдибе — Нухайның улы Зәйнәлгабид Батырморзаев Тукайны шулай ук үзенең остазы дип санаган. Шагыйрь һәм прозаик, драматург һәм тәрҗемәче, «Таң йолдызы» журналының һәм большевистик «Эшче халык» газетасының редакторы, гражданнар сугышы герое З. Батырморзаев Астраханьда, Казанда укыган, Стамбулга, Парижга барып югары белем алу турында хыялланган, татар демократлары белән якын элемтәдә булган, татар халкының борынгы культурасын һәм әдәбиятын яхшы белгән. Үзенең иҗат эшчәнлегендә ул һәр яктан Тукайга охшарга тырышкан. Хәтта, Тукайга охшатып, өстенә европача костюм, башына кавказ папахасы урынына татар кәләпүше киеп йөргән. Һәм бу ике шагыйрьнең гомер юллары да бер-беренә шактый охшаш. Тукай, үсмер чагыннан ук якты идеаллар белән янып, 27 яшендә үлгән, ә Зәйнәлгабид, шул идеаллар өчен көрәшеп, 22 яшендә һәлак булган.

Зәйнәлгабид иҗатында да әдәби-эстетик зәвык, җәмгыятькә, дөньяга караш нindидер дәрәҗәдә Тукай лирикасы тәэсире белән дә формалаша. Әйтик, аның иң көчле шигырьләреннән берсе — «Таң йолдызы» идея-тематик яктан да, төзелеше, сурәтләү чаралары буенча да Г. Тукайның «Иттифак хакында» исемле шигыренә якын тора. Ул да Тукайга хас күтәренке романтик пафос белән, халыкны өндәү, алга әйдәү рухында язылган:

Эй, насипсыз халкъ, гётер башынгны,
Гётер де, къара дёрт де янынга!
Ухлама, танг къатгъан, уху зарардыр,
Замансыз ухласанг алты санынга!

Бу әсәрләрнең рухи якынлыгын раслау өчен, мисалга Тукайдан да бер строфа китерик:

Тырышыйк, и хас вә гам,
Һәр көн үзгәрә заман,
Җитәр, йокламыйк һаман, —
Таңнар атты, бәдәвам.

Тукайдан үрнәк алып, З. Батырморзаев дагстан әдәбиятын революцион публицистика һәм иҗтимагый-социаль проблемаларга чыгышлар белән баета. Бу ике шагыйрьнең фикер бердәмлеге аларның иҗтимагый эшчәнлегендә дә ачык чагыла. Мәгълүм булганча, 1908 елда Г. Тукай Галиәсгар Камал белән берлектә «Яшен» исемле сатирик журнал чыгара башлый. Журналның беренче санында басылган «Август башы» исемле мәкаләсендә шагыйрь «Яшен» журналының әдәби һәм сәяси программасын билгели.

...Көннәр караңгы. Күк йөзен кара кайгыдай кue болытлар каплаган. Һәм менә кинәт, бу кара пәрдәне ярып, «Яшен» яшьни һәм ул адашкан кешеләргә юл күрсәтә.

1917 елның августында Дагстанда «Таң йолдызы» исемле әдәби журналның беренче саны басылып чыга. Аның беренче битләре З. Батырморзаев шигыре белән ачыла:

Күкне каплаган калын болытлар
Тузгып, таралып, читкә агылды.
Офык читендә бер якты йолдыз —
Өмет йолдызы балкып кабынды.
Балкып кабынды, сипте нурларын,
Үзәннәр буйлап исә таң җиле.
Аллана офык, тарала томан,
Көлеп уяна Дагстан иле.

Күрәсез, биредә дә шул ук романтик пафос, иске авыр тормышны гәүдәләндергән шул ук кара болытлар, адашканга юл күрсәтүче яшен урынына биредә Дагстан халкын йокыдан уятучы аллегорик таң йолдызы образы.

Әдәбиятның, сәнгатьнең халык тормышында, җәмгыятьтә тоткан урынын билгеләү буенча да бу ике шагыйрь бер-берсенә якын фикердәш. Бу җәһәттән Тукайның 1907 елда басылган «Театр» шигырен һәм Зәйнәлгабидның «Нәрсә ул театр» исемле мәкаләсен чагыштырып карарга мөмкин. Зәйнәлгабид театрны нәкъ Тукайча «тормышның көзгесе» дип бәяли. Тормыш чынбарлыгы һәм сәнгатьнең иҗтимагый әһәмияте турындагы бу фәлсәфи мәсьәләне Зәйнәлгабид кумык әдәбиятында гына түгел, бөтен Дагстан язучылары арасыннан беренче булып күтәреп чыга. Һәм аның барлык фикерләре Туктай фикерләре белән тәңгәл килә.

...Габдулла Тукай үзенең кыска гына гомерендә татар халык авыз иҗаты әсәрләрен җыю буенча да зур эш эшли. Бу мәсьәләдә дә Тукай хезмәтләре һәм аның теоретик фикерләре кумык әдипләренә зур йогынты ясый. Аның үрнәгендә кумык шагыйрьләреннән Н. Батырморзаев, Ә. Акаев, З. Батырморзаев, Т. Байбулатовлар халык җырларын, халык әкиятләрен, мәкаль, әйтем, табышмакларны җыюга зур көч куялар. Аларның хезмәтләрен үзара чагыштырып караганда, кумык һәм татар халкының культура уртаклыгы тагын да ачык күренә. Мәсәлән, «Кешегә баз казысаң, үзең төшәрсең»; «Сабыр төбе сары алтын»; «Әйткән сүз — аткан ук»; «Әйләнеч булса да юл яхшы» кебек мәкальләр Г. Тукай җыентыкларына да, Ә. Акаев китабына да кергән. Орфографик аңгыраштагы кайбер үзенчәлекләрне искә алмаганда, бу мәкальләр тугандаш татар һәм кумык халыкларында әле хәзер дә шул ук хәлендә, шул ук мәгънәдә саклана.

Тукай да, Батырморзаев та халык авыз иҗаты әсәрләрен җәүһәргә тиңләгәннәр. «Әгәр халкыбызның алтыннардан кыйммәт бу җәүһәрләрен бергә тупласаң, аларны мәктәпләрдә өйрәтсәң, балаларыбыз халыкның үткәнен, аның борынгы тарихын аңларлар, туган телебезнең кадерен белерләр иде», — дип яза Н. Батырморзаев.

Әйткәнебезчә, Тукайның эстетик карашы, аның әдәби мирасы, бу бөек шагыйрьне тудырып үстергән халыкның милли культурасы да кумык интеллигенциясе өчен тормыш һәм көрәш мәктәбе була. Татар халкының шатлыгы тау иле халыклары өчен дә шатлык, аның кайгысы — шулай ук уртак кайгы була. 1913 елның апрелендә Казаннан Дагстанга бөек шагыйрьнең вакытсыз үлеме турында хәбәр килгәч, лак шагыйре һәм җәмәгать эшлеклесе Сәет Габиев, Дагстан халкының уртак кайгысын белдереп, үзенең некролог-мәкаләсендә болай дип яза: «Рәхимсез үлем безнең яшь җырчыбыз Тукайны бик иртә кабергә алып китте. Аның күңел кыллары үзенең моңлы авазлары белән безнең йөрәкләрдә ышаныч һәм дәрт уяталар иде... Ләкин аның иҗаты мәңге үлмәс, аның артыннан яшь үсентеләр шытып чыгар һәм алар халыкка хезмәт итүдә бөек Тукай башлаган эшне дәвам итәрләр».

Һәм бу күренекле революционерның сүзләре озакламый чынга ашты. Шагыйрь үлеменнән соң дүрт ел узуга Бөек Октябрь революциясе җиңде. Революция Тукай шәкертләренә иҗатта киң һәм якты юл ачты. СССР халыклары әдәбиятларында бербер артлы бик күп яшь талантлар үсеп чыкты.

Совет властеның беренче елларында кулларына каләм алган кумык шагыйрьләре, өлкән буын әдипләре кебек ук, һәркайсы иң элек Габдулла Тукайның әдәби мирасын үзләренә иҗади өлге итеп алдылар. Әлим-Паша Салаватов, Аткай Аджаматов, Әнвәр Аджиев кебек дагстан совет шагыйрьләре әдәби osталыкка Тукайдан өйрәнделәр.

Дагстанның халык шагыйре, кумык культурасы тарихының җанлы энциклопедиясе Аткай Аджаматов иҗатында Тукай йогынтысы аеруча ачык чагыла. Әле хәзер дә кумык әдипләре, ярым шаяртып: «Тукай булмаса, Аткай булмас иде», — диләр.

Дагстанның тагын бер халык шагыйре Әнвәр Аджиев үзенең Габдулла Тукайга булган зур ихтирамын «Алты йолдыз» исемле шигырендә ачык әйтеп бирде:

**Татарларның таң белән дус Тукае,**
**Казакъларның кара тутлы Абае,**
**Ирыстанның ирек сөйгән Костасы,**
**Рус җиренең Пушкин — җырлар остасы.**
**Украинның озын мыек Тарасы,**
**Ирчи Казак — җырчы кумык баласы.**
**Алты шагыйрь — алты йолдыз балкышы,**
**Алты кардәш канның бердәм агышы.**

Күрәсез, Әнвәр Аджиев бу шигырендә Габдулла Тукайны Александр Пушкин, Тарас Шевченко, Абай Кунанбаев, Коста Хетагуров, Ирчи Казак кебек шагыйрьләр белән бер иш, алар белән бер үк дәрәҗәдәге якты йолдыз дип исәпли. Һәм, әйтергә кирәк, бу бер Аджиев сүзләре генә түгел, бәлки бөтен кумык әдипләренең, әдәбият сөюче бөтен кумык халкының уртак фикере.

# ШАГЫЙРЬНЕҢ СОҢГЫ РӘСЕМЕ

Бу рәсем 1913 елның 14 апрелендә Клячкин больницасында төшерелгән. Игътибар иткәнегез бардыр, шагыйрь иҗатына багышланган төрле китапларда һәм җыентыкларда ул еш очрый. Тик һәркайда диярлек Габдулла Тукай үзе генә, баш очында утырган дусларыннан башка гына була.

Ә дуслары аның — һәммәбез өчен дә кадерле кешеләр... Халкыбызның атаклы артисты Габдулла Кариев, күренекле язучы һәм галим Фатих Сәйфи-Казанлы, журналист Шиһап Әхмәров (сулдан уңга). Алар Г. Тукайның больницадагы соңгы көннәрен күргәннәр, аны соңгы юлга озатуда катнашканнар. Менә шуның өчен дә, ерак еллар хатирәсе буларак, бу рәсемне яңадан укучылар игътибарына тәкъдим итәбез. Беренче тапкыр ул «Яңалиф» журналының 1927 елгы 3 санында басылган. Биредә шуның фотокүчермәсе бирелә.

Д. ГАРИФУЛЛИН.



# ГОМЕР ШИГЫРЬЛӘРГӘ КҮЧКӘН ЧАК

Казанның яңа һәм шактый тыныч бер почмагында каләмдәшебез Хисам Камал яши. Матбугат йортында, газета-журнал редакцияләрендә башка шагыйрьләргә караганда сирәгрәк күренгән, шулай ук җыелышларда-кичәләрдә дә шаулап йөргәне ишетелмәгән шагыйрьне, ничектер, югарыда әйтеп узган тынычлык белән бәйле генә күзаллап була сыман. Әйтерсең бу шагыйрь — шулай тыныч туган-тыныч тормыш башлаган һәм бүген дә тын гына гомер итә. Ләкин шагыйрьнең биографиясе белән танышу шунда ук әлеге уйны юкка чыгара.



Хисам Нуретдин улы Камалов 1926 елда Әлмәт районының Кама-Исмәгыйль авылында туган. 1941 елда җидееллык мәктәп тәмамлагач, колхозда эшли, шуннан армиягә алына.

Ул 1944—1945 елларда сугышта катнаша, авыр яралана (шагыйрьнең «һәркемнең гомере бер генә» романы — шул еллар истәлеге)... 1946—1950 елларда Бөгелмә педагогия училищесында, 1950—1954 елларда Казан дәүләт педагогия институтында укый. 1954—1967 елларда — Татарстан китап нәшриятында редактор. КПСС члены. 1957 елда СССР Язучылар союзына кабул ителә... Күрәбез, шагыйрь Хисам Камаловның биографиясенә тынычлык бөтенләй хас түгел; аның януы-көюе, үсмерлеге-яшьлеге, ирлеге һәм тынгысыз хезмәте белән бәйле рәвештә генә еллары елларга тоташып бара икән. Шулай булгач, алда әйтелгән соңгы еллар тынычлыгын ничек аңлыйк?! Мин аны «Гомер шигырьләргә күчкән чак» дип атар идем: бу фикерем — шагыйрьнең барлык язганнарын — иҗатын яңадан күздән кичергәч туган бер уй.

Хисам Камал беренче шигырьләре белән әдәби журналыбызда 1954 елда күренә. 1958 елда «Яну» поэмасын язып бастырган шагыйрь шуннан соң чыккан 12—13 китабын эш көненнән соң калган көче белән, йокысыз төннәрдә уздырган гомере хисабына яза. Биредә әйтеп китү урынлыдыр: сугыш нык какшатып калдырган сәламәтлеген эш көннәренә дә һәм йокысыз төннәренә дә җиткерү өчен шагыйрьгә шактый тәвәккәллек, үз-үзен аямау, егетлек кирәк була.

Бәхеткә каршы, аның бу актив эше шигъри үткенлеге, көче киму исәбенә булмады. Иҗат эшләре белән генә шөгыльләнә башлаганнан соң да, ягъни 1967—1975 еллар арасында, Хисам Камалның әр-яңа иҗат уңышларының шаһиты без. Менә «Тормыш

дулкыннары», «Бәхет телим», «Өмет», «Каен суы», «Язмыш елмаюы» исемле китаплар. Бу китапларга аз гына яңадан күз салып узыйк. Чөнки, беренчедән, элегрәк язылган байтак әсәрләре дә, яңалары да, дөресрәге, шагыйрь гомеренең зур өлеше — шушы китапларда; икенчедән, шушы китаплар шагыйрьнең осталыгы һәм фикри тирәнлеге, дөньяга карашы һаман үсештә икәнне раслый; өченчедән, алар — Хисам Камалның иҗатта үз принципларына һәм тормышка мәхәббәте даими тугры булуына дәлил.

Хисам Камал бигрәк тә гади хезмәт кешеләренә, чынлыкка иң якын торып язуы белән, шушы якынлыкны һәр әсәрендә саклавы белән күп каләмдәшләреннән аерылып тора. Авторның үз әсәрендәге геройны сызыклар белән генә түгел, ә куе буяулар белән, тәфсилләп бирүе бу аерымлыкны — үзенчәлекне ачыграк, җетерәк итә. Мәсәлән:

**Сатучы кыз сөйли дус кызына:**
**— Әй, Мәгъшия, күрсәң, җаным син,**
**Кичә кергәч бер бик матур егет,**
**Ток суккандай каушап калдым мин.**
**Минем эштән нидер гаеп тапты,**
**Жалу язды миңа шушында,**
**Ә мин аңа шундый гашыйк булдым,**
**Яза яздым хәтта һушымнан:**
**Озаграк язсын диеп торам,**
**Бүтән берни килми башыма,**
**Кулларымнан вак акчалар коела**
**Чылтыр-чылтыр идән ташына.**

**(«Тормыш дулкыннары» китабыннан.)**

Хисам Камал шигырь өчен материалын күзгә дә чалынмаган гадәти урыннардан таба белә. Шигырьдә күрсәтәсе вакыйгаларны хезмәтнең теләсә кайсы өлкәсеннән алу осталыгына да, аны зуррак, масштаблырак итү һәм җирдән югары күтәрә алу осталыгына да ирешә ул:

**Атомны бомбалый**
**Кешеләр акылы...**

**(«Язмыш елмаюы» китабыннан.)**

Яки:

**Тугрылыкны бәяләми**
**Әй, кызлар, бивафалар.**
**Башта курчак вата алар,**
**Аннан безне ваталар.**

**(«Язмыш елмаюы» поэмасы.)**

Тормыштагы беренче карашка әллә ни әһәмияте дә юк кебек кечкенә эшләрне дә, иң гади хезмәт кешеләрен дә чын күңелдән яратуы, аларны үз йөрәге аша үткәреп, хисләнеп, бөтен нечкәлекләрен күрсәтергә тырышып язуы Хисам Камалны сюжетлылыкка һәм, ниһаять, зур поэмалар язуга китерде. Бу җәһәттән шуны да әйтмичә булмый: аның иҗатына тәнкыйтьчеләребез игътибары җитенкерәми әле; ә бит шагыйрьнең тормышчан якты иҗатыннан язуның күп серләренә өйрәнергә була. Шуңа күрә дә мин аның бүгенге иҗаты көннәрен — «Гомер шигырьләргә күчкән чак» дип бәялим... Юк, бу тыныч чак түгел, моңа шагыйрьнең Әлмәт яклары, КамАЗ төзелешләре үзәгеннән күтәреп күрсәткән прораб Нур, бетончы Илфат кебек егетләре шаһит...

**Кыскасы, тормыш корабым**
**Элекке өермәгә:**
**Дулкыннар дию шикелле,**
**Бортка китереп бәрә.**
**Корабым чайкала хәтәр,**
**Мин авам палубада,**
**Трослар өзелә шартлап,**
**Тик фикерем аек кала.**

«Язмыш елмаюы» поэмасында прораб Нур әйткән бу сүзләрне мин шагыйрьнең үз сүзләре итеп ишетәм. Хисам Камал бүген дә хисләре белән давылланып, элеккечә янып яши, заман белән бергә атлый. Әлеге «Язмыш елмаюы» дигән китабында аның «Пулеметчы» дигән кыска шигыре бар. Шигырь эчтәлеге белән яшьләргә адреслана. Автор фронтта булган бер хәлдән чыгып, пулемет төбеннән кузгала алмас дәрәҗәдә аяклары яраланган сугышчы турында сөйли. Автор әйткәнчә, яралы булса да, егет ахыргача пулемет янында кала:

**Папиросым аңа куеп киттем,**
**Ут белән ул нык ышыклады...**

Ә шигырьнең соңгы строфасында Хисам Камал үзен, бүгенге иҗат җырында солдат буларак, яралы пулеметчы итеп күрсәтә һәм яшьләргә болай мөрәҗәгать итә:

**— Калдырыгыз пулемет төбендә,**
**Мин чигенә алмыйм барыбер!**

...Әйе, безгә чигенергә ярамый, чигенмә, шагыйрь! Әдәбият кырларында поэзиябезгә алга барырга ярдәм итеп сафта, көрәштә кал, иҗат утларында безнең белән бергә ян, Хисам абый!

**РӨСТӘМ МИНГАЛИМОВ.**

# Хисам Камалов

## Бу төбәктә

### ИСТӘЛЕК

Хирурглар тәнне ярып алган
Пуляларны безгә бирүче
Шәфкать туташлары, сез кайларда?
Бармы икән сезне белүче?
Бу ярамнан чыккан эре укны
Ася салды учка: «Истәлек!»
Ә аннары ничә төннәр буе
Саклады ул, мине искәреп.
Улы кебек итеп карады гел,
Ак халаттан, чиста күңеле.
Тоташ нурдан торган кызлар булса,
Ася инде менә шул үзе!
Аны гомер оныта алмамдыр мин,
Аксыл йөзле, салмак, үзе тын...
Төшкә керә сүзсез елмаеп ул,
Ә пуляны күптән югалттым.
Аның бәхете булды микән? Юрыйм.
Ә бирелгән иде барысы мул.
Игелек өчен генә яратылган
Кешеләр дә була икән ул!

## Дию

Сугышта мин бүләк алалмадым,
Тик яралар гына, алар күп.
Сугыш миңа һаман бетмәгән ул,
Баш өстендә тора балта кук.
Сугыш бит ул әкияттәге дию!
Киссәң дә бер башын,
Яшерен
Икенче баш үстерә ул, явыз,
Белеп булмый һич тә мәкерен.
Мәшрикъта без дию башын чапкач,
Үсеп чыкты кинәт мәгърибтә...
Тәкъдиргәме әллә язылган дим?
Һаман безгә!.. Булмый ни дип тә!
Борчу били балаларың өчен.
Кайчан туктар исраф, кан кою?
Тагы кайда астан гына кыҗрап
Баш үстереп ята ул дию?!

## Сәхрә Салих

Авылда туган нигез бар
Сагынырга, дәвага:
Бәрелешләрдә яра алсаң,
Кайтып шунда аварга.
Тынлыкта ялгызың гына
Уйларга, хәл алырга.
Чәбәләнгән фикерләрне
Бер киләпкә салырга.

Бергә үскән дуслар белән
Утырасың гәпләшеп,
Кемгә язмыш мәрхәмәтле,
Ә кемнәр калган төшеп.
Кемнәре уңган хатыннан,
Кайсысы газап күргән?
Кем башына кемнәр җиткән,
Кемне кемдер күтәргән...

Сәхрә Салих сөйләп ала
«Нефтә»нең чыккан чорын:
Торбадан ташып нефтькә
Тулганын Дөм чокыры.
Шул тирәдә көтү йөргән,
Сарык моңа шаккаткан.
Көтүче Юныс йоклаган,
Бише чокырга баткан.
Кичен хатыннар ду килгән,
Тик көлгәннәр соңыннан:
Баткан сарыклар барсы да
Юнысныкылар булган...

Аннан кучә Сәхрә Салих
Аракыны тиргәргә.
Ник чыгарганнар шуны, дип,
Газап итеп ирләргә.
— Мин эчсәм дә кәеф өчен, —
Дип үзен аклап куя. —
Нигә яшь егетләр кәгә? —
Сәбәбен әйтә Зыя:
— Кем арбасына утырсаң,
Шуның җырын... беләсең...
Алар синең арбаңда бит,
Үзең үрнәк бирәсең!
— Юк,— ди Сәхрә,— ялгышасың!
Начар өлге таратмыйм.
Кәксәм дә тик җорлык өчен,
Җирдә аунап мин ятмыйм.
Арба хакында мәкалең
Искергән, дус, аңлыймсың?
Хәзер кемнең мәен эчсәң,
Шуның җырын җырлыйсың!..

...Сәхрәнең шаян сүзеннән
Көләбез: хак! дип әйтеп.
Көлке өчен ялганлавын,
Барчасын гафу итеп.

## Таныш буровой

Ял асты дигән калкуда
Бар девон буровое.
Тәүлегенә өч йөз тонна
Бирә иде җир мае.
Һәр җәйне буровой яны
Печәнен чаба идек.
Аның гүләп торуыннан
Без бер ямь таба идек.
Аның йөрәге бар сыман,
Пульсен гүя тоябыз.
Эшләвен тыңлап-кинәнеп,
Елмаешып куябыз.
Тамырыннан кара алтын
Акканына куанып,
Әти дә дәртләнеп чаба,
Чалгысын ялдан алып.
Буровойны ул да никтер
Үз итте әллә ничек —
Танышыдай, аның хәлен
Тора иде белешеп.
Тик әтине чире екты,
Яман шеш — мәрхәмәтсез.
Буровой янына бүтән
Баралмадык инде без...
Быел гына килеп чыктым
Буровойга бер иртә...

Девон беткән, вышкалар юк,
Тора чыгырлы сиртмә.
Шул суыра икән нефтьне...
Гигант бер челән гүя:
Томшыгын күтәргән чакта
Койрыгы җиргә тия...
Гаҗәпкә калуны минем
Күрде оператор да.
Бу үзгәрешнең сәбәбен
Телиме аңлатырга?
Әйтә: — Яшьлек кыска, брат,
Дөрләп аға да бетә,
Истәлеге генә кала,
Һәм шул гомереңә җитә.
Яшь чагында көч күп була,
Һаман фонтанланасың,
Ә соңыннан нәкъ шушылай
Качалкага каласың!..
Тамырларына парафин
Утырган, көч сүрелгән...
Әйе, картлык! Хикмәт эзлә
Яшьлегеңнең көленнән!
...Оператор китте, усал!
«Челәнгә» карап калдым.
Шунда никтер девонны да,
Үземне дә кызгандым.

## Аэропортта

Төенчек, чемодан
Күтәргән агайлар
Чуар бер агымдай
Каядыр агалар.
Ни калган бу карчык,
Кәкшәйган бу картка?
Оядан кузгатып
Аларны ни тарта?
Улларын шәһәр бит
Укытам дип алган,
Өйрәтеп, кеше итеп,
Үзендә калдырган.
Җибәрми авылга,
Кайтармый төп йортка.
Ихата таркала
Эшләрлек кул юкка...
...Сагынып шул улны
Очалар калага.
Юл әйбәт, чокырсыз,
Тузансыз аларга.
Карт тәгъсин кыламы
Замана юлына?
Могҗиза канатлар
Илтәләр улына!
Эчтән карт кычкыра:
Бир, шәһәр, улымны?!

Нигезем бетә бит,
Бир минем кулымны?!
Буыннан-буынга
Килгән ул бишегем
Җуелыр мәңгегә,
Бетәр бит ишелеп?!

...Карт кычкыра, шәһәр
Ишетми һаман да:
Үз хәле бик тыгыз,
Әйдәли замана!

## Ике исемлек

Ике исемлек була күңелеңдә,
Тормыш иткән чакта, авырда;
Дусларың язылган йөрәгеңә,
Дошманнарың утыра бавырда.
Бавыр чәнчи, ләкин бирешмисең,
Тугры дус бар, хәлне ул күрә:
Бәла сине сыткан мәлдә килеп
Кул суза да йолып өлгерә.
Учагыңда тагы утың дөрли.
Дус кадерле бәла кысканда...
Ләкин нигә тугры дусың кайчак
Әйләнә соң әле дошманга?
...Минем хакта нахак сүз йөрткән дус...
Гайбәтләргә ирек ул биргән;
Мондый чакта сүз дә тиз тарала,
Хуш килә ул кайбер күңелгә...
Ул сүз миңа ишетелгән чакта
Агулы иде. Күкрәк, тын кысты.
Исемлектән түгел, күңелемнән
Шытырдатып сыздым ул дусны.

# КамАЗ ЕЛЪЯЗМАСЫ

## АПРЕЛЬ, 1975 ЕЛ

Узган ел «Комсомольская правда» газетасы КамАЗда тимерчелек комплексы төзелешендә эшләүче комсомолецларның җыелышы турында язып чыккан иде. Төзүчеләр, монтажчылар һәм эксплуатациячеләр ул вакытта өстәмә йөкләмә кабул иттеләр: төзү эшләрен вакытыннан элек тәмамлау белән бергә, производство куәтләрен вакытыннан элек үзләштереп, продукция чыгара башларга! Җыю заводында эшләячәк эшчеләр һәм «Автозаводстрой» идарәсенең СМУ-5 төзүчеләре дә өстәмә план алганнар иде.

Бер ел узды...

1974 елның декабрь ахырында бөтен союз удар төзелешендә листовка-молния таралды. «Ф. Исянов җитәкчелегендәге комсомол-яшьләр бригадасы автозаводның төп конвейеры нигезенә миллион кубометр бетон салды», дип язылган иде анда. Бу иң яхшы профессиональ төзүче коллективларның күрсәткечләреннән дә артык. Кайбер көннәрдә коллектив сменага өчәр норма үтәде. Уңышның сәбәбе шунда: комсомолецлар икенче һәм өченче сменада хезмәтне оештыруга контрольлек итүне үз өсләренә алдылар. Иң яхшы балта осталары һәм бетончылар бригадалары белән төзелгән «бишлек договоры» да алга әйдәде. Бишьеллыкның билгеләүче елы ахырында биш коллективның һәрберсе иң югары хезмәт җитештерүчәнлегенә иреште. Беренче урынга Ф. Исянов бригадасы чыкты. Алар бишьеллыкның тәгәлләү елына киеренке планны Ленин комсомолы туган көнгә, вакытыннан элек үтәргә булдылар.

Республикаларның Верховный Советларына сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе составына кандидатлар күрсәтү башланды. Төзүчеләр җыелышында РСФСР Верховный Советына сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе составына СМУ-6 штукатур-малярлар бригадиры Гөлүсә Зөфәр кызы Ямалиева күрсәтелде. Ул — производствоны оста оештыручы, яшьләрне кайгыртучан тәрбияли белүче. Зур җәмәгать эшләре алып бара, партиянең Татарстан өлкә комитеты һәм «Камгэсэнергострой» парткомы члены.

«Социалистическая индустрия»
на строительстве Камского автозавода».

Вильнюс шәһәрендәге «Жальгирис» станоклар төзү заводында уннарча станоклар ел башыннан башлап экономияләнгән металлдан эшләнде. Алар барысы да КамАЗга җибәрелде.

Машина төзүчеләр яңа машиналар ясаганда станокларда металл куллануны киметергә тырышалар. Мәсәлән, яңа конструкцияләрдә фрезер станоклары ун килограммга җиңеләйде.

«Советская Россия», Мәскәү.

СССРның 50 еллыгы исемендәге Дмитровград автоагрегат заводында «КамАЗ» йөк машиналары өчен 42 исемдә узеллар һәм детальләр җитештерү үзләштерелде. Алар — кузов арматурасы әйберләре: ишек йозаклары, тоткалар, көзгеләр, пыяла йөрткечләр һ. б. лар. Боларны җитештерә торган цех әлегә вакытлы мәйданга урнашты. Бер үк вакытта заводта куәтле производство комплексы — КамАЗ нәрсәне төзелә. Анда йөк машиналары өчен күп кенә детальләр эшләнәчәк.

Инде механик-җыю корпусының беренче чираты төзелеп бетеп килә.

«Труд», Мәскәү.

Партком секретаре А. И. Коньков һәм профсоюзның завком председателе А. И. Георгиевский җитәкчелегендә Воскресенск химкомбинаты хезмәткәрләре делегациясе КамАЗда булып китте. Берничә көн дәвамында кунаклар Пресса үзәгенең эш тәҗрибәсен һәм күргәзмә агитация алымнарын өйрәнделәр.

**«Социалистическая индустрия» на строительстве Камского автозавода».**

Электроаппарат заводы коллективы Кама автогигантының мөһим заказын срогыннан ике айга элек үтәде. Чаллыга куәтле станоклар һәм югары җитештерүчәнлекле агым линияләре белән автомат идарә итү буенча йөзләрчә җайланмалар озатылды. Бу продукциянең күпчелегенә Дәүләт сыйфат билгесе бирелгән.

**ТАСС, Харьков.**

Ленин өмәсенә Чаллыда 60 мең 399 кеше катнашты. Тулы булмаган хәбәрләргә караганда, бер миллион 100 мең сумлык төзү-монтаж эшләре башкарылды. Автозавод төзүчеләре өмә көнне эшләгән эш 102,6 мең сумлык булды.

СССР Верховный Советы депутаты Рәис Сәлахов җитәкчелегендәге монтажчылар бригадасы иң зур күрсәткечкә иреште. Бу бригада тизләтелгән ысул белән җиде катлы йорт кора. Бригада членнары өч смена дәвамында 55 кубометр урынына 75 кубометр тимер-бетон конструкция монтажладылар.

**«Социалистическая индустрия» на строительстве Камского автозавода».**

«Тимерчелек заводының беренче чиратын ходка җибәрергә һәм 154 исемдәге продукция җитештерүне үзләштерергә» — 1975 елга Кама автомобиль комплексын төзүчеләр шундый социалистик йөкләмә алганнар иде. КамАЗның тимерчелек заводы кебек куәтле предприятие моңа кадәр бу тармакта юк иде әле: җитештерү күләме буенча ул илебездәге иң зур автомобиль заводларындагы тимерчелек цехларына караганда ике мәртәбә куәтлерәк булачак.

Тимерчелек производствосы корпусларының берсе. П. М. Баскаков бригадасы бетон кабул итәргә керешә. Үзбушаткычлар бер-бер артлы килеп тора.

— Әгәр эшләр болай барса, — ди бригадир, — смена ахырына 200 кубометр бетон салырбыз кебек.

Петр Михайлович Баскаков Чаллыга моннан өч ел элек килде һәм авто-җыю заводының күперләр цехына фрезерчы булып урнашты. Әмма әлегә заводта аңа үз һөнәре буенча эш юк иде. Заводның башка күп кенә эшчеләре үрнәгендә, ул төзелештә эшләргә керешә. Январь аенда аның бригадасы «Автозаводстрой» идарәсе коллективлары арасында социалистик ярышта беренче урынны алды. Бу уңышта бригадирның үз роле дә зур. Ул, тимерчелек заводы төзелешендә беренчеләрдән булып, бетон коюда металлдан эшләнгән форма куллана башлады. Бу монтаж эшләрен җиңеләйтә, бетон кабул итү өчен каркасларны әзерләү срогын кыскартырга мөмкинлек бирә. Элек бетонны кабул иткәнче, балта осталары — бетончылар эш вакытының өчтән ике өлешен бетон кою өчен такта тышлык ясап үткәрәләр иде.

Бу корпуста ике цех булачак. Берсендә төзүчеләр, арматурчылар нигез каркасын әзерлиләр. Балта осталары, бетончылар каркасларны тышлык белән төрәләр, икенчеләре аларны бетон белән тутыра, өченчеләре манолит стеналардан тышлыкларны ала. Бу цехта ярдәм җиһазларының күпчелеге, барлык коммуникацияләрне, производство калдыкларын чистарту системасы булачак.

Корпусның икенче яртысында — термит цехында — төзүчеләр бөтенләй күренми диярлек. Монда инде эстафетаны станокларны көйләүчеләр, эксплуатациячеләр кабул итә.

Запорожье шәһәреннән килгән 233 номерлы машиналарны көйләү идарәсе термоагрегатларны, прессларны һ. б. машиналарны монтажлый.

**«Труд», Мәскәү.**

Пресс-рам заводының рам цехында Япониянең «Камацу» фирмасында ясалган лонжерон линияләрен монтажлау башланды. Бу эшләрне «Двигательмонтаж» идарәсенең И. Зайцев бригадасы башкара.

**«Социалистическая индустрия» на строительстве Камского автозавода».**

## Мөдәррис Мостафин

# РӘХМӘТ, ДОКТОР



Мөслим район больницасына Әмәкәй авылыннан медпункт мөдире шалтыратты. Колхоз председателе Фатыйх Салиховның хатыны авыр хәлдә ята икән, ашыгыч хирургия ярдәме күрсәтергә кирәк. Язмышы кыл өстендә...

Язгы ташу вакыты. Ык ярларыннан чыккан. Боз ага. Ык аръягы авылларына чыгуы бик кыен вакыт.

Баш врач Александр Аркадьевич Смелов кичектергесез хирургия буенча эшләүче яшь белгеч Ильяс Хәбибуллинны чакырды. Һәм ни өчен чакыруын әйтеп бирде.

— Сезнең белән педиатр Рәисә Гариповна Зарипова һәм операция сестрасы Анна Степановна Смелова барыр, — диде ул. — Ә елга аркылы ничек чыгарга икәнен үзегез хәл итегез.

Ильяска артык аңлатуның кирәге юк иде, Ык буенда үскән егет ул. Казан медицина институтын тәмамлап кайткач, язгы ташкын вакытында да, кышкы ачы бураннарда, дөм караңгы төннәрдә дә, ат атланып һәм җәяүләп тә аңа күп тапкырлар авыр юлга чыгарга туры килгәне бар.

— Алайса, безгә җыена башларга кирәк.

— Хәерле юл телим!

Озакламый алар яр буенда иде. Ык ярсый, эре-эре бозлар, ташкын көченә буйсынып сөзешә-сөзешә, түбәнгә ага. Көймәчеләр бераз сабыр итәргә куштылар. Алар якындагы бозларның узып киткәнен, икенчеләренең еректарак чагын көтәләр иде.

— Я, иптәшләр, тәвәккәлләдек!

Болганчык салкын су тамчылары җил белән бергә биткә бәрә. Ык буе кешеләре яхшы беләләр: мондый чакта көймәдә кымшанмаска, тыныч утырырга кирәк. Врачлар куллары белән шытырдатып утыргычка ябыштылар. Ә ишкәкчеләр бөтен көчкә ишкәк калагы белән язгы суны актаралар. Аларга су да, дулкын да берни түгел, тик бозга гына бәрелмәсеннәр. Ниһаять, көймә ярга төртелде. Каршы алырга трактор килергә тиеш иде. Күренми әле. Әмәкәйдән бирегә ике-өч сәгатьсез килеп җитеп булмый шул.

— Атлый торабыз, аз булса да юлыбыз кыскарыр, — диде Ильяс иптәшләренә. Алар, медикамент сумкаларын күтәреп, кызу-кызу атлап, ике яктан да су эчендә калган таш юл буйлап киттеләр. Озакламый трактор күренде...

Йорт хуҗасы Фатыйх Салихов трактор тавышына урамга атылып чыкты.



*Ильяс Хәбибуллин*

— Сания апаның хәле ничек? — Ильясның беренче сүзе шул булды.

— Авыр. Аңын югалткалый.

Авыру хатын врачларның өйгә кергәнен тойды. «Сезне бер гомер көттем, җан кисәкләрем, инде тормышымны сезгә тапшырам», дигәндәй, күзен сүлпән генә ачып карады. Ул бала таба алмыйча интеккән, бик күп кан югалткан, бала дөнья күрә алмыйча үлгән. Хирург та, терапевт та тиз генә үз күрсәтмәләрен бирделәр: йөрәк тибеше бик начар — камфора һәм кардиамин уколы ясарга. Каны агып бетә язган — тизрәк кан бирергә кирәк... Анна Степановна шундук эшкә кереште. Авыруны операциясез коткарып булмаячагы көн кебек ачык иде. Ә моның өчен авылда шартлар юк. Димәк, Мөслимгә алып китәргә туры киләчәк, аңа тикле авыруның җанын сакларга, юлга алып чыгарлык һәм аннары больницага барып җитәрлек хәлгә китерергә кирәк. Менә алып килгән дүрт флакон кан да бетте.

— Бераз түзәргә туры килер, Сания апа. Үзәк больницага алып китәбез, — диде Ильяс, йомшак тавыш белән. — Терелерсез. Аңысына шикләнмәгез...

Бу сүзләрен ул аеруча басым ясап әйтте.

Трактор да, тракторчы да капка төбендә иде. Ничә сәгать буе шуннан китмәгән. Чанага урын-җир әзерләп, авыруны чыгарып салдылар. Алда — тагын ике-өч сәгатьлек юл. Аннары тагын Ык — бозы ага торган шаулы су. Тракторчы машинаны иң зур тизлек белән куа. Ә чанада авыру хатын, һәм врачлар үлем белән көрәшә. «Караңгы төшкәнче Ыкны чыгасы иде». — Ильясның күңелен шул уй борчый. Үзе һаман Сания апаны юата:

— Тагын бераз түзегез. Озакламый Мөслим. Ә анда без... — ул сүзен әйтеп бетермәде, авыру аны тыңламый иде инде. «Кызлар, бик тиз генә кофеин белән кардиамин бирегез», — диде хирург. Һәм кулына шприц алды.

Ниһаять, алар Ык ярына килеп җиттеләр. Елганың бер ярында — көймәчеләр, ә икенче ярында — «ашыгыч ярдәм» машинасы. Авыру кулдан-кулга күчте.

Больницада бөтен нәрсә әзер иде. Ильяс шунда ук операциягә керешүте. Сания ханымның тормышын саклап калу өчен көрәш иртәнгә кадәр дәвам итте. Операциядән соң да күп көч куярга, авыру тәненә шактый кан, глюкоза, полиглюкин, физраствор кертергә туры килде.

Ильясның гадәте шундый: операция ясаганнан соң, авыруның йөзендә яшәү чаткылары күрмичә, ул аның яныннан китми. Башкаларга ышанмаганнан түгел, өстенә җаваплылыкны күбрәк алганга, кеше язмышы өчен бөтен йөрәге белән борчылганга шулай эшли ул. Бүген дә операциядән соң авыру караваты яныннан сәгатьләр буе китмәде. Тереклек бирүче шифалы дарулар, минутларны озынайтып, тамчылап кына ага. Врач, авыруның беләген кулыннан ычкындырмыйча, һаман пульсын саный. Күзен кул сәгатенең секунд телләреннән алмый. Сания апаның күз ачуын, бер сүз әйтүен көтте ул.

Ничәмә сәгатьләр. Менә аның керфекләре тибрәнде, үзенең исән булуын, исән калуын тоеп, беренче сүзен врачка ирештерде.

— Рәхмәт, доктор!

Ильясның өстеннән авыр йөк төшкәндәй булды.

— Йокларга тырышыгыз! — дип, Ильяс урыныннан кузгалды.

Ул урамга чыкканда, таң сызылып килә иде инде. Аяк астында язгы боз шытырдый. Эфир һәм спирт исе аңкыган операция бүлмәсеннән соң иртәнге салкынча саф һава рәхәтләндереп җибәрде. Тизрәк кайтып, караватка сузылып ятып, онытылып йокыга китәсе килә иде аның. Ләкин аяклары тыңламый — талганнар, авырайганнар. Хәере белән йокларга язсын. Ә бит кайчакта кайтып керүенә телефон шалтырый: я яңа авыру китерәләр, я булмаса берәрсенең хәле начарайган була, чишенеп торырга да туры килми...

Район халкы арасында «доктор Ильясның кулы җиңел» дигән сүз бик тиз таралды. Бу инде врач хезмәтенә, бигрәк тә яңа эшли башлаучыга зур бәя һәм дәрәҗә бит. Кулы җиңел. Димәк, врач белә, кулы эшкә ятып тора, сүзе дә, биргән даруы да шифалы. Менә нәрсәне аңлата ул «кулы җиңел» дигән сүз. Казан медицина институтының дәвалау факультетында бик яхшы уку, Казанның зур тәҗрибәле һәм абруйлы хирурглары янында практика узу, катлаулы операцияләрдә катнашу, Бөек Ватан сугышы чорында хәрби госпитальләр мәктәбен узган оста хирург А. А. Смелов кул астында эшләү аңа авыруларны дәвалау һәм операция ясау осталыгына, врачлык хезмәтенә тәпле төшенергә, өйрәнергә мөмкинлек бирде. Остазларының күркәм сыйфатларын ул тиз кабул итте.

1962 елда, больницаның баш врачы А. А. Смелов күчеп киткәч, аны алыштыру өчен партиянең район комитетында да, республика Сәламәтлек саклау министрлыгында да Ильяс кандидатурасына туктадылар. Бу вакытка ул врач буларак кына түгел, районда сәламәтлек саклау эшен оештыруда да шактый тәҗрибә туплаган иде...

Мин аны Мөслимгә врач булып кайткан чорыннан бирле беләм. Үзен гади тота, аз сүзле, сабыр, игътибарлы, беренче очрашуда ук кешедә ышаныч тудыра һәм ягымлы мөгамәләсе белән үзенә бик тиз җәлеп итә. Ул шундый булды һәм шундый булып калды. Тик соңгы сүзләргә хәзер шуны өстәргә кирәк булыр — Ильясның күз тирәләрендә һәм маңгаенда җыерчыклар, ә чигәсендә көмеш бөртекләр күренә башлаган. Боларны бит халыкта «узган тормыш юлының эзе» диләр. Ә тормыш аңа, чыннан, җиңел юл әзерләмәгән иде. Ул авырлыклар белән көрәшеп, аларны җиңеп яшәргә өйрәнде.

Ильяс баш врач вазифасын кабул итеп алганда больница биналарының һәм кабинетларның ничек булуын бүгенгедәй ачык хәтерлим. Ул биналарны утызынчы елларны, Мөслим үзе район үзәге ителгәч, башка авыллардан күчереп китереп салганнар иде. Байлардан калган яки кулаклардан тартып алынган агач өйләр... Районда бер-ике фельдшер, күп дигәндә бер-ике врач (алары да вакытлы була иде) эшләп торган чакларда яраганнар, әлбәттә. Еллар узып, алар яраксыз хәлгә килделәр, утырдылар, җиргә сеңделәр. Алай-болай сипләп, «ямау салып» кына рәткә кертерлек түгелләр инде. Врачлар күбәйде, ә кабинетлар җитми иде. Авыруларны салырга урын бик аз. Врачларның күбесе институт тәмамлаганнан соң, тиешле ике елын эшли дә китү ягын карый башлый. Берәүләрнең яхшы җиһазланган больницада эшлисе, икенчеләренең бөтен уңайлыклары булган яхшы квартирада торасы килә. Әнә, күрше-тирәдә — Азнакайда, Әлмәттә, нефть якларындагы башка шәһәрләрдә — нинди больницалар кордылар. Исең китәр! Врачларга менә дигән торак бирәләр. Авыл җирендә яшәүче кеше, авыл врачы шуларга хаклы түгелмени?! Ә аның хезмәте аеруча кыен бит. Барлы-юклы рентген кабинеты да юньләп

эшләми — я электр тогы, я врачы, яки техникгы юк. Авыруларны Азнакайга, Бөгелмәгә йөртергә туры килә, күпме тапкырлар бөтен районга берничә врач белән үзе генә калгалады Ильяс. Ул әйбәт больница биналарын, яхшы шартларда эшләүче һәм яшәүче танышларын, дусларын күреп кайта да уйга кала. Әмма иң кыен чакларда да Мөслимнән китеп, кайдадыр җайлырак урнашу турында уйны башына да китерми ул. Чөнки районда үзенең кирәкле кеше икәнен белә иде. Иң башта үзенә таләпчән булды, бүтәннәрдән дә медицина кануннарын төгәл үтәүне, югары дисциплина таләп итте. Кайчакта район буйлап аркылыга да, буйга да чабарга туры килә: бер урында сырхау кеше көтә, икенчесендә хуҗалык йомышлары белән колхоз яки оешма җитәкчесен күрәсе бар, өченче җирдә медицина хезмәткәрләренең эше белән танышырга кирәк, район үзәгенә кайтып керсәң — анда операциягә көтәләр, ә өенә дуслары, туганнары килгән... Кеше кебек бераз күңел ачып утырырга иде дә бит. Кинәт телефон шалтырый һәм кемдер аның гаиләсенә хәбәр итә: «Ильяс Абдулловичны көтмәгез, ул ашыгыч операция башлады».

Менә бервакыт яңа больница төзү турындагы уй тынгы бирми башлады аңа һәм Ильяс катгый карарга килде: «Тәвәккәлләп, кора башларга кирәк. Нефтьчеләр төзегән комплексларга охшап торсын!» Көндез өстәл янына утырып, кәгазьгә сызып кына түгел, йокларга яткач, булачак больницаның корпусларын хыялы белән каршысына бастырып уйлана торган булды ул. Эшне кайдан, кемнән башларга?

Партиянең район комитетында, район Советында һәм республиканың Сәламәтлек саклау министрлыгында сүз кузгатты Ильяс. Берсеннән яңа больница төзүнең кирәклеген нигезләгән рөхсәт язуы, икенчесеннән югары оешмаларга тагын бер үтенеч, өченчесеннән башлап җибәрү өчен дип бераз акча алуга иреште. Аннары айлар, еллар буе төрле оешмаларның бусагаларын таптау... Проектлар эшләтү мәшәкате...

Авырлыклар бер-бер артлы артта калды. Мөслим авылы читендә ике катлы зур, биек, якты бина үсеп чыкты. Хәзер аның тирәсендә башка йортлар да хәтсез. Аерым итеп салынган балалар бүлеге бар. Биналар куакларга күмелеп бара инде. Төзелеш тә туктап тормый. Поликлиника өчен күршедә генә кирпечтән яңа бина җиткерелә. Врачлар һәм бүтән медицина персоналы өчен йортлар салына.

Күп нәрсә үзгә хәзер. Ильяс төзелеш белән шөгыльләнгәндә үк булачак кабинетларны җиһазлау турында кайгыртты. Байтак нәрсә юллап кайтарды. Бүгенге операция блогы менә дигән. Бөтен өр-яңа техника һәм инструмент бар үзендә. Физиотерапия, теш протезлау, электрокардиограмма кабинетлары эшли. Рентгеннан күрену өчен читкә йөрисе юк. Урыннарга барып тикшерү үткәрү өчен рентгенофлюорография аппараты урнаштырылган «Икарус» автобусына кадәр бар. Кайчандыр санаулы кешене генә сыйдыра алган больницада инде берьюлы ике йөз кеше ятып дәвалана ала. Үзәк больницада төрле белгечлек буенча 14 врач, ике йөзгә якын урта медицина хезмәткәрләре эшли. Карамалы һәм Михайловка участок больницалары да киңәйтелгән. Фельдшерлык-акушерлык пунктларының күбесе яңа биналарга күчкән.

Әмма аз гына тынычланырга да иртә әле. Ул үзен медицина хезмәте күрсәтүгә акча бирүне бермә-бер арттырган дәүләт алдында да, кайчандыр аңа булышка килгән танышлары, дуслары алдында да бурычлы саный. Башкача итсәң — гаделсезлек булыр иде. Медицина хезмәткәре тәүлекнең теләсә кайсы вакытында эш урынына килеп басарга әзер булырга тиеш. Бу таләп Ильясның канына сеңгән. Аның өстәлдәге ашын, карыйсы спектаклен яки киносын (кайчакта

исә хәтта керә торган мунчасын...) калдырып, беренче звонок белән больницага йөгергәне, саный китсәң, очына чыкмаслыктыр. Әлбәттә, һәр юлы операция ясау өчен дә түгел. Больницада башка хирурглар да булды, хәзер дә бар. Шундый сәгатьләр, минутлар була: теге яки бу авыруның язмышын хәл итү өчен тәҗрибәле врачның, баш врачның сүзе, күзе, карары кирәк. Ә районда андый доктор — Ильяс Хәбибуллин.

Мөслим районының халыкка медицина хезмәте күрсәтү буенча республикада яхшы исәптә торуы билгеле. Ул үзе «Почет билгесе» ордены, ә больница исә ТАССР Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм профсоюз өлкә комитетының Почет грамотасы, «Москвич» автомобиле белән бүләкләнгән. Медицина хезмәткәрләре халык арасында күп төрле профилактика һәм аңлату эше алып баралар. Донорлык хәрәкәте киң җәелгән. Кан бирүдә дә медицина хезмәткәрләре башлап үзләре үрнәк күрсәтә. Мәсәлән, медицина сестралары Фагыйлә Галимова, Люция Садреева, Зинаида Ускова һәм ясле мөдире Клара Смирнова, санитарка Фатыйма Җәлилова — иң актив донорлар.

Җәйнең бер матур көнендә — июнь башлары иде бугай—больницаның матур тасмалар һәм чәчәкләр белән бизәлгән машиналары Мөслим урамнарында һәм авыл араларында тыз-быз йөрделәр. Кызыксынып, без дә больница ягына атладык. Бер бүлмәдән ишегалдына, тирә-юньгә ямьле музыка тавышы агыла. Тәрәзә төбендәге савытларда — сирень чәчәге бәйләмнәре. Керүче-чыгучы күп. Донорлар көне икән!.. Больница коллективы аларны каршы алуны һәм озатуны, чыннан да, бәйрәм төсендә оештыра: барып алалар, илтеп куялар. Больницаның һәвәскәр артистлары, җырчылары һәм биючеләре гадәттә шул көнне кичен концерт яки спектакль куялар. Шул ук программа белән башка авылларда да чыгыш ясыйлар. Һәр тамаша алдыннан берәр врач донорлыкның әһәмияте турында сөйли, халык сәламәтлеге өчен кан бирүчеләрнең исем-фамилияләре әйтелә, алар исеменә җылы рәхмәт һәм ихтирам сүзләре яңгырый. Әйе, бу патриотик эш Мөслимдә нык тамыр җәйгән һәм республика Кызыл хач җәмгыяте, Сәламәтлек саклау министрлыгы район донорлары исеменә еш кына котлау хатлары җибәрә.

Ильяс Хәбибуллин эшләгән чорда районда хирургия хезмәте аеруча үсте, ныклы җирлеккә басты, күп кенә фән һәм техника казанышлары практикага кертелде. Ашказанына, бавырга, сөяккә катлаулы операцияләрне хәзер инде Мөслимнең үзендә ясыйлар. Ильяс Хәбибуллин үзе Мөслимдә эшләгән унсигез елда сигез меңнән артык операция ясаган. Гадәттә, аның җаваплырак, катлаулырак эшкә тотынуын исәпкә алганда, бу санның никадәр зурлыгын күз алдына китерүе кыен түгел. Күпме күз нуры түгәргә, нинди түзем һәм сабыр, рухи һәм физик көчкә ия булырга кирәк хирургка! Кайчак озак басып торудан аяк табаннары ут булып яна. Ләкин аның утырырга хакы юк. Чөнки кулында — кеше язмышы, кеше аңа өмет тулы күзләре белән карый... Шул күп санлы операцияләр арасында ниндиләре генә юк. Районның иң ерактагы Сәфәр авылыннан яшь егет Фәнис Мирсәлимовны китерәләр. Трактор көпчәге астында калган, бавыры сытылган. Егетнең хәле авыр, операция дә җиңелдән түгел. Әмма Ильяс аны оста башкара. Фәнис больницадан сәламәтләнеп чыга. Ашказаны чире, үт куыгы, талак шартлаудан ашыгыч операция ясау очраклары аз булдымы! Бервакыт больницаның үзендә медицина сестрасы булып эшләүче Люция бик кыен хәлдә кала: зарыгып көткән беренче баласын таба алмый. Эчен ярып алудан башка чара юк... Бу операцияне дә шулай ук Ильяс үзе башкара. Хәзер бала таза һәм шат булып үсә. Ә Люция больницада мактаулы хезмәтен дәвам иттерә.

Ильяс кешенең йөрәк түреннән чыккан, шатлыклы күз яшьләре белән әйтелгән рәхмәт сүзләрен еш ишетә. Һәм ул шуның белән үзен бәхетле саный. Кешене бәхетле итүдән дә зуррак бәхет бармы соң! Әйе, Ильяс Хәбибуллин тирәсендә аның шифалы кулыннан тазалык-саулык алып, дөньядагы эшләре белән җан-фәрман мәшгуль кешеләр нихәтле! Шуларны күреп яшәү, шулар белән очрашу аңа һәр вакыт көч һәм илһам өстәүче күпме шатлык китерә.

Бер кайтуымда төскә-биткә яшь кенә мөлаем бер ханымның урамда халык күзе алдында Ильясны кочып алып, аркасыннан сөя-сөя күрешүе сөендерде һәм сокландырды. Һәр икесе бер-берсенә сәламәтлек, эшләрендә уңышлар теләп аерылыштылар. Кем соң ул? Әллә туганымы? диярсез. Ул — Киров исемендәге колхозның Вәрәшбаш бригадасыннан колхозчы Фәния Исламова икән. 1974 ел башында, әче буранлы кышкы төндә, Фәнияне бик авыр хәлдә район больницасына китерәләр. Гинеколог Роза Хәмидуллина, авыруны карагач, эшнең җитдилеген аңлый, шунда ук баш врачка телефоннан хәбәр итә. Ильяс бик тиз килеп җитә. Тәҗрибәле күзгә бер караудан ук бары да ачык: хатын хәл эчендә, менә-менә тормышының өзелүе мөмкин, кичекмәстән бик тиз кан бирергә кирәк. Баш врачның беренче әмере шундый була. Ә кем бирә? Больницада булган запас флаконнар кичтән тотылып беткән. Ә кан булмый торып операциягә керешү мөмкин түгел. Роза күрше бүлмәдәге телефонга йөгерә. Вәрәшбаш авылы акушеркасына бик тиз арада донорлар җыеп алып килергә куша. Ә Ильяс ике «ашыгыч ярдәм» машинасын Мөслим авылына чыгарып җибәрә. Берсен операция өчен кирәкле кешеләр алып килергә, икенчесен донорларга хәбәр салырга. Болар барысы да секундлар белән саналган тизлектә эшләнә. Авылда һәм телефон чыбыклары аша «SOS» хәбәре тарала. Ә Фәния — яшәү белән үлем арасында...

Шул чак больница янында машина тавышлары ишетелде. Димәк, өлгерделәр. Арада больница хезмәткәрләре дә байтак. Сигез чакрымдагы Вәрәшбашныкылар — Фәниянең авылдашлары да килеп җиткән.

Үзләренең канын язмышы кыл өстендәге авыру хатынга бирергә теләп, бер сәгать дигәндә, егерме җиде кеше килгән иде. «Рәхмәт сезгә, иптәшләр, чын күңелдән рәхмәт!» — диде Ильяс аларның барысына да. Ишек ачып, сестраларның берсе хирургны операция бүлмәсенә дәште. Ә операция үзе бүленә-бүленә унике сәгать дәвам итте. Катлаулы операцияне ике тапкыр ясарга туры килде Ильяска. Кан группалары туры килгән донорларның берсе дә өенә кайту турында уйламады, кан бирергә үз чиратын көтте, биргәннәр дә китәргә ашыкмый иде — аларны инде операциянең ничек бетүе кызыксындыра. Һәм бу беренче очрак түгел. Мөслим үзенең донорлары белән чыннан да горурлана ала.

Эше авыр булса да, язмышы бәхетле Ильясның. Язмышыннан бик канәгать ул. Башта врач булырга исәбе юк иде кебек — унынчы классны тәмамлагач та Казан дәүләт университетының рус теле һәм әдәбияты бүлегенә керде. Хәтта ярты ел укыды да. Әдәбиятны бик ярата, хәтта шигырьләр язгалап карый иде. Шигъриятькә мәхәббәте бүген дә сүрелмәгән. А. С. Пушкин, М. Ю. Лермонтов, С. Есенин һәм Һади Такташ аның иң яраткан шагыйрьләре. Буш вакытларында бирелеп шигырь укый. Медицина, хирургия буенча махсус әдәбият белән рәттән, «Литературная газета»ны, «Казан утлары» журналын алдыруы һәм матур әдәбият әсәрләреннән, бигрәк тә совет кешеләренең Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыклары хакында язылган китаплардан китапханә туплавы бер дә гаҗәп түгел. Хатыны Ро-

заның рус теле һәм әдәбияты укытучысы булуы да бәлкем шул мәхәббәткә бәйләнгәндер, ягъни уртак максат, уртак омтылыштандыр.

Ләкин медицина тарта төшә. Апасы Динәнең ул вакытта ук инде врач булуымы, врач профессиясенең романтикасымы, аның абруйлы исеменә, ак халатына һәм ак калфагына мәхәббәтеме... үзе дә аңлата алмый, ниндидер тылсымлы көч яшь егетне медицина институтына китереп кертә. Ә берничә елдан сеңелесе Роза да медицина институтына гариза бирә (хәзер ул Мөслимдә балалар врачы). Шулай итеп, Абдулла агай Хәбибуллин гаиләсеннән өч врач чыга.

Менә унсигез ел инде ул халык сәламәтлеге сагында тора. Рәсми тел белән шулай диярга мөмкин. Бөтен тормышы, эше, уч төбендәге кебек, күз алдында. Ильяс бөтен барлыгы белән халык өчен яши. Чөнки больницага, врачка гозере төшмәгән кеше юк диярлек. Шуны кеше хәтере калмаслык итеп үтәргә, авыруларның барысына да вакытында ярдәм күрсәтергә кирәк. Ә бит ул үзе өчен генә түгел, барлык медицина хезмәткәрләренең эше өчен җаваплы. Коммунист Ильяс Хәбибуллин үз намусына һәр чакта тугры. Унтугыз ел бер очтан больница партия оешмасының секретаре булып эшләүче, өлкән акушерка Лена Ахунова үзенең хатында: «Ул кешеләр өчен яши һәм эшли белә. Шуннан үзенә тәм таба. Аның тәҗрибәсенә һәм киңәшенә һәр вакыт таянырга мөмкин», — дип яза.

Әйе, Ильяска районда ышаныч зур. Күп еллар рәттән аны район Советына депутат һәм КПСС райкомы члены итеп сайлыйлар. Ул партия һәм совет органнары тапшырган бөтен эшләрне дә зур җаваплылык тоеп, җиренә җиткереп башкарырга тырыша, барысына да җитешә. Профессиональ белемен һәм осталыгын арттыру турында да онытмый. Хирургларның Киевта булган бөтен союз съездында катнашты, анда исемнәре дөньяга танылган медицина әһелләренең төрле темаларга чыгышларын тыңлап, тәҗрибәсен баетып кайтты. Эш кабинетында һәм өйдәге өстәлендә һәр вакыт өеме белән медицина китаплары һәм журналлар күрергә мөмкин. Шигырь китаплары да укырга кирәк. Монысы, үзе әйтмешли, күбрәк йокы хисабына инде. Тәүлекне озынайтып булмый бит. Сәгать телләре туктауны белми.

Кайда авыр — ул шунда, кайда авыру — ул шунда. Менә шулай яши һәм эшли район больницасының баш врачы Ильяс Хәбибуллин.

# БЕРЕНЧЕЛӘРДӘН БЕРСЕ

Әстерхан һәм Баку шәһәрләренең Октябрь революциясенә кадәрге матбугат битләрендә еш кына артистка Суна ханым Сафиуллина исемен очратырга мөмкин.

Мәгълүм булуынча, революциягә кадәр Россиянең изелгән халыклары арасыннан чыккан артисткаларны бармак белән генә санарлык. Менә шушы мәсьәлә һәм Суна Сафиуллина исеменең күренекле әзербәйҗан революционеры, большевик Нариман Нариманов белән бәйләнештә очравы бездә аеруча кызыксыну уята.

Кем соң ул Суна Сафиуллина? Ул ничек сәхнәгә чыга алган? Соңгы елларга кадәр бу сорауларга тарихчылар да, сәнгать белгечләре дә ачык җавап бирә алмыйлар иде әле. Әзербәйҗан труппалары белән еш чыгыш ясавы кайберәүләрдә аның Кавказ халыкларыннан булуы мөмкин дигән фикер дә тудыра иде.

Тик эзләнүләр Суна Сафиуллинаның якташыбыз булуын ачыклады һәм безне республикабызның хәзерге Әлки районына кергән Карга авылына алып килде...

1890 елны Карга авылы крестьяны Гыйльфан ага гаиләсендә кыз бала дөньяга килә. Ул заманда кыз бала туу крестьян өчен зур хәсрәт саналса да, Гыйльфан ага семьясын бу хәл күңелсезләндерми. Киресенчә, гаиләдә аңа кадәр туып үсеп килгән 4 ир бала янында бер кыз булуы ниндидер бер шатлык өсти. Аңа Хәерелбәрия дип исем куштыралар. Дөрес, кыз балага бу тулы исеме белән, әти-әнисеннән башка, сирәк кеше эндәшә. Күбесенчә яшьләр Бәрия дип кенә йөртәләр.

Бердәнбер кыз булганга күрә, өйдәгеләр аның күп теләгенә каршы килмәскә тырышалар. Хәерелбәрия бик чибәр, кыю һәм сәләтле кыз булып үсә. Шушы ук авыл егете Хәбибзадә Сафиуллинга тормышка чыга. Күпләргә бу ике яшь йөрәкне дә авыл тормыш-көнкүреше, семья мәшәкатьләре басып китәр кебек күренә.

Ләкин алай булып чыкмый. Бу ике крестьян баласының тынгысыз җаннары аларны заман агымына каршы барырга өнди. Әйтергә кирәк, шушы юлда Хәбибзадә белән Хәерелбәриянең үз авылдашлары, соңыннан бөтен Идел буе татарларына яхшы таныш исем — революционер Касыйм Туйбактин белән дуслашулары хәлиткеч роль уйнаган булырга тиеш.

«Авыл бунтаре» Касыйм Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыганда ук аларны шактый гына дөньяви тәгълимат белән коралландыра. Соңыннан ул революцион эш өчен мәдрәсәдән куылып, Әстерханга киткәч, Хәерелбәрия белән Хәбибзадә дә бәхет эзләп аның артыннан Идел тамагына юл тоталар.

Ә анда исә заманының яктылыкка, яңалыкка омтылучы алдынгы кешеләре белән очраштырып, язмыш аларга тагын бер тапкыр елмая.

Унынчы елларда Әстерхан шәһәрендә Кавказдан революцион эш өчен сөрелгән Нариман Нариманов яши. Татарлар арасында ул вакытта соңыннан үзләренең демократик карашлары белән билгеле булган күренекле артист Зәйни Солтанов, шагыйрь Сәгыйть Рәмиев тә шунда торалар һәм эшлиләр. «Идел» газетасы чыга. Татар драма труппасы оеша. Аны оештыруда Нариман Нариманов роле аеруча зур. Дуслары, яңа танышлары Хәерелбәрияне дә драма труппасына эшкә тарталар. Һәм шуннан башлап Суна Сафиуллина татар драма труппалары эшендә катнаша башлый.

Сәхнә исемен аның «Суна» дип алуы да очраклы булмаса кирәк. Безнең уебызча, ул Нариман Наримановның халыклар дуслыгын чагылдырган «Сона һәм Бахадур» әсәре героинясының исеме булырга тиеш.

Татар театрының тарихы интернационализм рухы белән сугарылган. Моны репертуар сайлауда да, татар артистларының төрле миллэт культура эшлеклеләре белән тыгыз бәйләнештә торуларында да, шулай ук башка милләтләрнең прогрессив вәкилләре татар спектакльләрен якын итүләреннән дә күрергә була. Әстерханда барлыкка килгән татар труппасының эшчәнлеге бу яктан аеруча характерлы.

Мәсәлән, «Надир шаһ» әсәрен сәхнәгә куюда татар труппасына пьесаның авторы Нариман Нариманов режиссер буларак ярдәм иткән. Ул, халык соравы буенча, спектакльдән соң сәхнәгә дә чыгып күренә.

Спектакльгә төрле милләт вәкилләре: руслар, татарлар, әрмән, иран, казакъ, калмык тамашачылары да килә.



*Суна ханым Сафиуллина*

Әстерханда чыга торган «Идел» газетасы «Надир шаһ» пьесасында Гөлҗиһан ролен «мәшһүр артисткабыз Суна ханым уйнады һәм моңарчы күргәзә килгән сәхнәви мәһарәтен һич кимсетмичә, ролен гаять гүзәл чыгарды»,— дип яза[1].

1913 елның апрель аенда «Идел» газетасы Әстерханның кышкы театр бинасында татарча спектакль булачагын һәм аның «халыкка үзенең сәләтен күрсәткән», «шәһәребезнең иң гүзәл артисткаларыннан» булган Суна ханым бенефисына багышлануын хәбәр итә. Ул кичәдә рус, татар һәм әрмән пьесаларыннан өзекләр куелачагы әйтелә[2].

Берничә көннән соң шул ук «Идел» газетасы «татар һәвәсле артисткасы Суна ханым» катнашында «җирле вә Кавказ телләре» диалектында булып үткән спектакльгә рецензия бастыра. Анда язылганча, халык белән шыгрым тулы залның яртысын татар хатын-кызлары тәшкил итә. «Кырт-кырт» исемле әрмән комедиясе дә куелганга, әрмән һәм рус тамашачылары да шактый күп була. Спектакльгә гомумән уңай бәя бирелә. һәм, аерым алганда, Суна ханымның уңышлы уйнавы күрсәтелә[3].

Суна Сафиуллинаны Әстерханның алдынгы карашлы җәмәгатьчелек вәкилләре кайнар тәбрик итәләр, аңа бүләкләр тапшыралар. Алар арасында күренекле татар артистлары, приказчиклар, «Идел» матбагасы вәкилләре, Кавказ халыклары исеменнән тәбрик итүче дә була. Газетаның шул ук санында Суна ханымның Әстерхан мөселманнарына рәхмәт хаты да урнаштырылган. «Авылда тәрбияләнгән авыл кызы булсам да,— ди ул үзенең хатында,— театр күргән яшьләр, сәнаиг нәфисә илә таныш зур укыганнарыбызның күп ярдәмләре һәм җитәкләшүләре сәясендә башлаган көнемнән бирле, татар сәхнәсендә төрле рольләрне уйнап, гомумән, театр сөючеләренең дустанә ризалыкларын һәм дә мөселман кардәшләремнең миһербанлы алкышларын ишетә килдем. Мин үземнең бу алкышларны ишетерлек хезмәт итә алмаганымны һичбер вакыт онытмыйм. Үземчә аларга каршы тагын күп хезмәтләр итеп түләмәкче идем». Суна ханым соңгы бенефисның бу бурычны күп мәртәбәләр арттыруын һәм үзенең шушы юлда, бигрәк тә татар хатын-кызларын яктылыкка әтәрү юлында армый-талмый эшләячәген белдерә. Хатта кавказлы кардәшләргә, аеруча Нариман Наримановка, ярдәмнәре һәм бу бенефиста күрсәткән хезмәтләре өчен рәхмәт белдерелә.

Шул рәвешчә, Әстерхан шәһәрендә уйналган татар спектакльләренә даими

[1] «Идел», 28 февраль, 1913 ел.
[2] «Идел», 12 апрель, 1913 ел.
[3] «Идел», 23 апрель, 1913 ел.

рәвештә рецензияләр бастырып барган «Идел», ә соңрак «Солдат ялкыны», «Тартыш», «Кеч» газеталары Суна ханымның сәхнә уенына, кагыйдә буларак, югары бәя бирәләр, аның татар прогрессив театр культурасына зур өлеш кертүен билгеләп үтәләр.

Матбугат материалларыннан күренгәнчә һәм замандашларының сөйләүләренә караганда, Суна ханым еш кына әзербәйҗан труппаларында да чыгыш ясый.

Ниһаять, Суна Сафиуллина татар демократик культурасы тарихында тагын бер ягы белән искә алынырга тиеш. «Солдат ялкыны» газетасында бу хакта шактый киң языла, һәм аның әле белгечләр тарафыннан файдаланылмавы кызыксынуны арттыра.

Сүз 1917 елның 17 ноябрендә Әстерханда «Мөхтәрият» труппасы куйган татарча оперетта хакында бара. Оперетта күренекле әзербәйҗан композиторы Гөзәер Гаҗибековның «Ул булмаса, бу булсын» дигән әсәре буенча куела. Спектакльдә Сара Байкина, Габдерәхим Адаков һ. б. артистлар катнашкан. Рецензиядә күп еллар буе әзербәйҗан артистлары белән иҗади бәйләнештә торган Суна ханымның аеруча уңышлы чыгышы билгеләп үтелә [1].

1920 елның июнь аенда Хәрби эшләр комиссариаты янындагы Мөселман Коллегиясе үз тирәсенә күренекле сәнгать эшлеклеләрен туплый. Коллегия Әстерханнан Суна ханымны да Казанга чакыра. Суна ханымның Казандагы тормышы безгә әле җитәрлек дәрәҗәдә ачык түгел. Һәрхәлдә, монда ул озак эшләми. 1920 елның ахырларында булса кирәк, туган авылларына китә. Якташлары 20—30 елларда Сафиуллиннарның Карга авылында, берникадәр вакыт Спасскида, Чистайда, Базарлы Матакта яшәүләрен сөйлиләр. Истәлекләрдән күренгәнчә, 1931 елның җәендә аны Казанга, Татар академия театрына чакырып алалар. Озак та үтми, ул Габдулла Уральский җитәкчелегендәге 6 кешелек труппа составында халык театры оештыру максаты белән Чистайга китә. Соңыннан Суна ханым берникадәр вакыт Казанда, Татар академия театрында эшләгән булырга тиеш. Берничә елдан, сәламәтлеге начарлану сәбәпле, Базарлы Матак авылына кайтып китә.

Бу — авылда социализм төзү һәм культура революциясен тормышка ашыру өчен киеренке көрәш еллары була. Шушы мактаулы эшкә Суна ханым да үз өлешен кертә. Туган авыллары Каргага кайткач, Сафиуллиннар зур дәрт белән культура-агарту эшенә керешәләр. Хәбибзадә кооперация оештыру эшләренә чума, колхоз төзүдә актив катнаша. Суна ханым авылда китапханә мөдире булып эшли. Авыл яшьләреннән драмтүгәрәк оештыра һәм алар, спектакльләрне авылда гына куеп калмыйча, еш кына күрше авылларга да чыгалар.

Рольләрне бүлгәндә Суна ханым һәвәскәр башкаручыларның характерларына, шәхси сыйфатларына карап эш итә, йөкнең авырын исә үз өстенә ала. Тәҗрибәле артистканың баш рольләрдә уйнавы спектакльләрнең уңышын тәэмин итә. Түгәрәкнең актив членнарыннан берсе, Карга авылы егете Шаһи Садыйковка Суна ханым күбрәк хәрби кеше рольләрен бирә торган була. Кем белә, соңыннан Казанда хәрби мәктәп бетереп, Бөек Ватан сугышында һәлак булган Советлар Союзы Герое полковник Шаһи Садыйковның кыю йөрәге бәлки нәкъ менә Суна ханым җитәкчелегендә авылда спектакльләр куеп йөргәндә батырлык рухын үзенә сеңдергәндер?! Соңыннан, хәрби училищеда укыган елларында да ул, ял вакытларында авылга кайткач, спектакльләрдә уйнавын дәвам иткән. Спектакльләрдә, концертларда шулай ук авыл активистларыннан Суна ханымның тормыш иптәше Хәбибзадә Сафиуллин, Корбан һәм Габдрахман Туктамышевлар семьясы, Кәшиф һәм Зәмзәмия Туйбактиннар, Бану Чурашова, Вәли Хаҗиев еш катнашалар.

Суна ханым Сафиуллинаның тормышы (ул 1948 елны Базарлы Матакта үлә) киң катлау укучыларга хәзергә билгесез диярлек. Театр белгечләренә исеме таныш булса да, аның эшчәнлеге әдәбиятта әле яктыртылмаган дияргә мөмкин. Киләчәктә, әлбәттә, өйрәнелергә тиеш. Бигрәк тә әзербәйҗан артистлары, аеруча Нариман Нариманов белән булган интернациональ дуслык элемтәләре тарихы кызыклы сәхифәләр ачуы мөмкин.

**РИФ ХӘЙРЕТДИНОВ,**
тарих фәннәре кандидаты.
**ГАБДРАХМАН КӘРИМОВ.**

---

[1] «Солдат ялкыны», 29 ноябрь, 1917 ел.

# АЛАР ВАТАНГА ТУРЫЛЫКЛЫ БУЛДЫЛАР

Беренче бөтендөнья сугышы фронтларында мөселманнар, бигрәк тә татарлар, бөтен авырлыкны рус солдатлары белән бергә кичерделәр.

Патша Россиясендә барлык милләт вәкилләре дә бер үк дәрәҗәдә изелде, аларның һәркайсы сыйнфый эксплуатацияне үзендә тоеп яшәде. Фабрикаларда һәм заводларда, алпавыт утарларында руслар белән татарлар бергә эшләделәр, патшага һәм буржуазиягә каршы революцион чыгышлар вакытында да бергә булдылар. Төрле милләт вәкилләреннән торган солдатларга унтерлар һәм фельдфебельләр муштрасы да бер үк дәрәҗәдә эләкте, шулай ук алар җилкәсенә хәрби хезмәтнең авырлыгы да тигез төште. Болар барысы да хезмәт ияләре арасында дуслык мөнәсәбәтләренең үсүенә һәм ныгуына китерде. Төрле милләт эшчеләре һәм крестьяннары арасын никадәр генә бозарга тырышса да, царизм барыбер үзенең ниятенә ирешә алмады, эшчеләр һәм крестьяннар уртак көрәштә иптәшләр булып калдылар. Россия аларның барысы өчен дә уртак Ватан булды.

Сугыш елларында солдатлар арасында дуслык, интернациональ бердәмлек ныгыды. Бу турыда солдат Мусин фронттан болай дип язды: «Күптән түгел безгә элек Тула заводы эшчесе булган солдат Борисовны китерделәр... Менә ул безгә сугышны мал-мөлкәт туплау максаты белән байлар башлавын әкренләп төшендерә бара. Ә без, ахмаклар, сугышта кан түгеп йөрибез. Русмы, немецмы, мөселманмы — барысы да бер үк төрле хезмәт иясе ләбаса»[1]. Ә икенче бер солдат болай ди: «Сугышта да руслар белән бергә булдык, тыныч көннәр тизрәк килсен өчен сугышны туктатуны да бергәләп хәл итәрбез»[2].

Бөтендөнья сугышын рус солдатлары да, татар солдатлары да бер үк дәрәҗәдә дошман күрде. Иге-чиге күренмәгән бу сугышка карата солдатларда ризасызлык арта барды, төрлечә каршылыклар күрсәтелә башлады: фронтта солдатлар забастовкалар үткәреп, һөҗүмгә барудан частьлары белән баш тарттылар, дошман солдатлары белән туганлашуга бардылар. Солдатларның батальоны яки часте белән күмәк рәвештә дошманга әсир төшүләре дә сугышка каршы протестның үзенчәлекле чагылышы булды. Бөтендөнья сугышы елларында 3,5 миллионнан күбрәк солдат әсир төшә[3]. Рус армиясенең әсир төшкән хәрбиләре арасында татарлар да күп була.

Патша Россиясендәге халыкларның күп милләтле булуыннан файдаланып, немец властьлары әсирләр арасында милләтчелек рухында көчле агитация алып баралар. Алар рус армиясенең барлык әсирләрен лагерьларда милли төркемнәргә бүлеп урнаштыралар, бер милләт солдатларын икенче милләт солдатларына каршы котырталар, милләтләрне Россиядән аерылып чыгарга өндиләр.

Йоссен лагеренда хәрби әсирләрдән 16 мең татар туплана. Төрек офицерлары һәм муллалары озак вакытлар солдатлар арасында милләтчелек рухында агитация алып баралар, аларны Россиягә каршы куярга һәм Төркия армиясенә кушарга

---

[1] Р. Нафиков. Татарларда алдынгы иҗтимагый-политик фикер үсеше. Казан, 1964 ел, 174 бит.
[2] Шунда ук.
[3] Россия Беренче бөтендөнья сугышында (саннар). М., 1925 ел, 4 бит.

омтылалар. Лəкин ниятлəре барып чыкмый. Татарлар Төркия армиясенə барудан баш тарталар [1].

Мөселман солдатларына карата Австро-Венгрия властьлары да зур кызыксыну күрсəтə. Татарлар күп булган Эгер лагеренда мəчет салына, мөселманнар өчен мəктəп ачыла, газета чыгарыла. Төркия офицерлары һəм муллалары бирелə дə татарларны үз армиялəренə өндилəр. Лəкин монда да телəүчелəр табылмый. Шуннан соң татарлар арасында эш туктатыла башлый. Мəчет, мəктəп ябыла, ə татарлар үзлəре төрле лагерьларга күчерелə [2].

Большевиклар лагерьларда революцион пропаганда һəм агитация эшен киң җəелдерəлəр. Рус солдатлары белəн берлектə татарлар да политик тəрбия мəктəбе үтəлəр. Алар сугыш һəм аның башлану сəбəплəре турында чын хакыйкатьне чиксез зур авырлыклар һəм мохтаҗлыклар кичереп, үзлəре аңлыйлар. Большевиклар эшчəнлеге нəтиҗəсендə хəрби əсирлəр Октябрь революциясе һəм Совет власте идеялəренə төшенəлəр.

Брест солыхы төзелгəннəн соң, Германия һəм Австро-Венгрия лагерьларында миллəтчелек рухындагы агитация тагын да көчəя. Мөселманнарны Советлар властена каршы булырга котыртып һəм аларны революцион Россия халыкларына каршы сугышта файдаланырга ниятлəп, күп эш алып барыла. Татарлар арасында, төрек миллəтчелəреннəн тыш, Берлинда урнашкан мөселманнар комитеты членнары да зур агитация эшлəре алып бара. Бу акгвардияче эмигрантлар оешмасы членнары шəех Габдерəшид Ибраһимов, Тимур Җан, О. Сами, Рəшид Əхмəт һəм башкалар лагерьларда даими рəвештə булалар, мəкерле яла ягуга корылган вəгазьлəрен сөйлилəр, солдатларны большевикларга ышанмаска, «үз динен ныгытырга һəм мөселман дəүлəтенең мөстəкыйльлеге өчен көрəшергə» [3] чакыралар. Мөселманнар комитеты татар солдатлары арасында татар телендə һəм рус телендə язылган Советка каршы эчтəлекле бик күп əдəбият тарата. Лəкин бу миллəтчелек кампаниясе көтелгəн нəтиҗəне бирми. «Совет вəкиллəре лагерьларга килгəч, əсир татарлар үзлəрен Советлар Россиясенə кайтаруны тизлəтүне сорадылар» [4].

Йоссен лагеренда күпчелеге татар булган 12379 мөселман газап чигүдə дəвам итте. Лагерь күлəмендə үткəрелгəн митингта алар резолюция кабул итəлəр, анда үзлəренең Совет властен тулысынча тануларын, ə туган илгə кайткач республиканың хезмəт тормышында һəм аның байлыкларын саклауда актив катнашачакларын белдерəлəр [5].

1918 ел азагында, Германиядə һəм Австро-Венгриядə революция булып үткəннəн соң, солдатларның əсирлектəн күплəп кайту чорында, əсирлектəге мөселманнар да, рус солдатлары белəн бергəлəп, ташкын сыман булып Россиягə омтылалар. Үзəк мөселман комиссариаты, əсирлəр һəм качаклар мəсьəлəсе буенча Үзəк коллегия һəм аның культура-агарту бүлеге белəн берлектə, туган иллəренə кайткан мөселман солдатлары арасында эш башлап җибəрə [6].

1918 елның декабре — 1919 елның январь-февраль айларында əсирлектəн кайткан, лəкин, акгвардиячелəр фетнəсе һəм алар тарафыннан Урал һəм Себернең яулап алынган булуы сəбəпле, туган җирлəренə җитə алмаган бик күп солдатлар Казанда тупланa. Совет хөкүмəте Көнчыгыш фронт линиясе аша солдатларны үткəрү турында Колчак белəн сөйлəшүлəр алып барган арада, хəрби əсирлəр бу сөйлəшүлəрнең нəтиҗəсен көтəргə мəҗбүр булалар. Казан большевиклары бу вакытны əсирлектəн кайтучылар арасында политик агитация җəелдерү максатында файдаланалар. Мөселман солдатлары арасында эш алып бару өчен агитаторлар РКП(б)ның Казан мөселман комитеты тарафыннан билгелəнə. Мөселманнар эше буенча комиссариат членнары да актив эш алып баралар. Агитатор Садретдин Фəхретдинов язмалары бу чордагы эш турында беркадəр ачыклык бирə. Ул болай дип яза:

---

[1] Россиянең тышкы политикасы архивы, фонд II, департамент, 708 нче язма, 6194, 41 бит.
[2] Шунда ук.
[3] «Русский вестник» (Берлин), № 261, 1918 елның 21 марты.
[4] Октябрь революциясе үзəк дəүлəт архивы, Центропленбеж фонды.
[5] Шунда ук.
[6] Шунда ук.

*«13 февральдә кичке сәгать биштә эшчеләр клубында хәрби әсир мөселманнарның җыелышы үткәрелде. 50 кеше катнашты. Алар агымдагы вакыйгалар, шулай ук авыл хуҗалыгы коммуналарын оештыру тәртибе һәм аларның әһәмияте турындагы мәсьәләләр белән таныштылар. Әсирлектән кайтучы мөселманнар ана телендә язылган брошюраларга мохтаҗлар. Татар телендә брошюралар бик аз»*[1].

*«20 февральдә хәрби әсирләр клубында әсир мөселманнар өчен митинг үткәрелде, анда «Империалистик сугыш һәм гражданнар сугышы турында»речь белән Исхак Рәхмәтуллин һәм «Совет власте мөселман пролетариатына нәрсәләр бирде» дигән тема буенча иптәш Җиһаншин чыкты. Митингтан соң Казан мөселман труппасы артистлары көче белән концерт куелды. Әсир иптәшләр өзлексез алкышлап утырдылар һәм бик риза булып калдылар»* [2].

*«21 февральдә 2 нче тулай торакта «Коммунистлар партиясе нәрсә ул» дигән темага татар телендә әңгәмә үткәрелде. Әңгәмәдән соң татар телендәге китап һәм газеталарны уку оештырылды. Әсир иптәшләр бик канәгать булдылар»* [3].

*«Әсирләр арасында үткәрелгән эшләр аларда белемгә омтылыш уята. Әсир мөселманнарның күбесе зурлар мәктәбендә укырга телиләр»*[4], — *дип яза агитатор.*

Әсирлектән кайтучы мөселманнар арасында алып барылган агитация эше татар буржуазиясе агентурасының бөтен тырышлыгын юкка чыгара. Әсирләр үзләренең җыелышларында һәм митингларында Совет властен яклаулары турында резолюцияләр кабул итәләр. 1919 елның 10 мартында агымдагы момент буенча үткәрелгән җыелышта хәрби әсир мөселманнар кабул иткән резолюциядә түбәндәге юллар бар: «Без, элекке хәрби әсир мөселманнар, үзебезнең эшче-крестьян Совет властен яклау хакына бөтен чараларны күрербез. Яшәсен Революцион Кызыл Армия! Яшәсен юлбашчыбыз иптәш Ленин!» [5].

Әсирлектән кайтучы мөселманнар Совет власте казанышларын сакларга әзер торуларын Кызыл Армия сафларына басу белән расладылар. Агитатор болай дип яза: «5 кеше Кызыл Армия сафларына керергә теләк белдерде» [6]. Икенче бер донесениесендә: «Әңгәмәдән соң дүрт кеше Кызыл Армиягә язылырга, 18 кеше Юдино станциясендә тимер юл төзәтүдә катнашырга теләк белдерде» [7], дигән юллар бар.

1919 елның февраль-март айларында мөселманнардан күп солдатлар Кызыл Армиягә үзләре теләп китәләр. 1 нче татар укчы полкына үзләре теләп Шәрәпов Сабирҗан, Ильясов Сөләйман, Фәйзуллин, Шәйхетдинов, Анатов һәм башкалар язылa. Бу чорда үзләре теләп язылучыларның саны 55 кә җитә [8]. Соңрак, 1919 елның май-июнь айларында, Оборона советы карары белән, әсирлектән кайтучылар Кызыл Армия сафларына алына, меңнәрчә элекке әсир мөселманнар революция казанышлары сагына баса.

Антанта илләре хөкүмәтләре 1919 елның гыйнвареннан башлап Германия һәм Австро-Венгриядән рус армиясенең хәрби әсирләрен илләренә җибәрүне тыялар. Йөзләрчә мең солдатлар озак вакытлар әсирлектә тотыла. Антанта күрсәтмәсе буенча, лагерьларга тупланган акгвардияче агентура, террор һәм көчләү алымнарының төрлесен кулланып, акгвардияче гаскәрләр сафын әсирләр исәбенә тулыландырырга омтыла. Ләкин әсирләр, инде дөньядагы хәлне яхшы аңлаганлыктан, Совет дәүләтенә каршы көрәшергә теләмиләр. Рус армиясенең барлык солдатлары белән берлектә, мөселман солдатлары да акгвардияче агентларга актив рәвештә каршылык күрсәтәләр.

Хәрби әсирләрне үз якларына аудара алмагач, союзниклар, халыкара хокукның элементар нормаларын бозып, рус армиясе солдатларын илләренә җибәрмәүне дәвам итәләр. Аларны Германиядән үз лагерьларына күчерәләр һәм хәрби әсир немецлар белән бергә тоталар. Хәрби әсирләрнең бер өлешен алар Германиядән үз колонияләренә алып китәләр. Хәрби әсирләрне репатриацияләү буенча Совет хөкүмәте вәкиле М. М. Литвинов 1920 елның 21 июлендә Копенгагеннан болай дип хәбәр

---

[1] ТАССР үзәк дәүләт архивы, ф. 638, 1 нче язма, 83, 6 бит.
[2] Шунда ук, 61, 125 бит.
[3] Шунда ук, 175 бит.
[4] Шунда ук, ф. 638, 1 нче язма, 83, 6 бит.
[5] Шунда ук, ф. 638, 1 нче язма, 61, 201 бит.
[6] Шунда ук, 65, 249 бит.
[7] Шунда ук, 61, 253 бит.
[8] Шунда ук, ф. 638, 1 нче язма, 61, 320 бит.

итә: «Константинопольдә Германия тарафыннан әле 1914 елда ук Самсонов армиясеннән әсиргә алынган һәм Месопотамиягә китерелгән һәм бирерә инде британлылар тарафыннан яуланган 478 татар бар, әсирләрнең беркадәр өлеше Һиндстанга һәм Сүәешкә җибәрелгән»[1]. Чит ил эшләре халык комиссары Г. В. Чичерин Англия хөкүмәтенә җибәрелгән махсус нотада әсир татарларның кичекмәстән илләренә кайтарылуын таләп итә[2].

Әсирлектә солдатларның тормышы никадәр авыр булса да, аларда теге яки бу һөнәргә өйрәнү, илгә кайткач шуның белән Ватанга зур файда китерү омтылышы сүнми. Солдатлар бу өлкәдә оештыру формаларын да, әлеге бурычны хәл итүнең уңайлырак юлларын да үзләре табалар. Вюнсдорф лагерендагы татарлар «Укучы татарлар җәмгыяте» төзиләр. Җәмгыятьнең председателе итеп иптәш Алим Идрис сайлана. Җәмгыять члennары үзләре теләгән белгечлек буенча 1 айдан 14 айга кадәр һәм аннан да озаграк срокта курслар үтәләр. Вюнсдорф лагерендагы хәрби әсир татарлар түбәндәге белгечлекләрне үзләштерәләр: парикмахер — 2 кеше, шофер — 3 кеше, санитар — 2 кеше, аяк киемнәре тегүче — 1 кеше, музыкант — 2 кеше, тел белгече — 1 кеше, фотограф — 1 кеше, электротехник — 1, электроинженер — 1, монтер — 1, мич чыгаручы — 2 кеше, хәреф җыючы — 3 кеше, укытучы — 1, фармацевт — 1, тегүче — 1, столяр — 1, машина төзү заводы эшчеләре — 12 кеше, кинооператорлар — 8 кеше[3]. Кинооператор һөнәрен Госманов, Бәдретдинов, Галләмов, Юнысов, Фәхретдинов, Хәлимов, Удагулов, Гомәров иптәшләр үзләштерә[4].

1921 елның 21 январенда РСФСР белән Германия арасында төзелгән килешү нигезендә рус армиясенең әсир төшкән барлык солдатлары ярты ел дәвамында үз илләренә кайтарылырга тиеш булалар. Шуның нәтиҗәсендә укучы татарлар җәмгыятенең кайбер члennары (барысы 45 кеше) уку курсларын тәгәлләп өлгерә алмыйлар[5]. Җәмгыять председателе иптәш Алим Идрис, Татарстан республикасы Совнаркомына хат белән мөрәҗәгать итеп, билгеләнгән белгечлек буенча уку срогын тәгәлләү өчен әсирләрнең Германиядә калу срогын озайтуны сорый. Халык Комиссарлары Советы җәмгыять члennарының үтенечен хуплый һәм аларны яклау вазифасын үзенә ала. ТАССР Халык Комиссарлары Советы председателе иптәш Сәетгалиев Чит ил эшләре халык комиссариатына болай дип яза: «Укучы татарлар җәмгыяте рәисе иптәш Алим Идрис үзенең хатында барлык рус әсирләренең, шул исәптән татарларның, Германиядә укуларын дәвам итүчеләре быелгы июнь аенда гына Россиягә кайтарылачаклары турында яза. ТАССР Совнаркомы анда курсларда укучы татарларга, укуларын тәмамлаганчыга кадәр, Германиядә калырга рөхсәт алуда сезнең булышуыгызны сорый»[6].

Совет хөкүмәте укучы татарларның үтенечен канәгатьләндерә. Аларның Германиядә калу срогы озайтыла һәм алар илгә квалификацияле белгеч булып кайту мөмкинлеге алалар.

Шулай бик күп газаплар кичергән мөселман солдатлары да үз Ватаннарына турылыклы булып калдылар. Россиягә кайткач, алар яңа тормыш төзүчеләр сафында үз урыннарын табып, социалистик җәмгыять төзүдә актив катнаштылар.

**АЛЕКСАНДР МАЛЬКОВ,**
тарих фәннәре кандидаты

[1] Октябрь революциясе үзәк дәүләт архивы, ф. 3333, 2 нче язма, 168, 83 бит.
[2] Шунда ук, 70 бит.
[3] Шунда ук, ф. 3333, 2 нче язма, 168, 83 бит.
[4] Шунда ук.
[5] Шунда ук, 82 бит.
[6] Шунда ук, 185, 82 бит.

**Касыйм Фәсәхов,**
**Марат Мөлеков,**
тарих фәннәре кандидатлары

# ЧЫНБАРЛЫК ҺӘМ АНЫ БОЗЫП КҮРСӘТҮЧЕЛӘР

Социализм лагере белән капитализм лагере арасында идеологик көрәш елдан-ел кискенләшә бара. Дөньяның төрле почмакларында социализм илләренә, бигрәк тә Советлар Союзына каршы язылган дистәләрчә хезмәтләр чыгып тора. Советлар иленә, тынычлык һәм социализм дөньясына каршы көрәш пропагандасында иң куәтле техник чаралар һәм иң мәкерле алымнар кулланыла. Буржуаз идеологлар безнең илдәге дус халыклар арасында төрле низаглар, талашлар чыгарырга, милләтләр арасында ризасызлык тудырырга исәп тоталар. Шул максат белән алар Коммунистлар партиясенең ленинчыл милли программасын һәм халыкларның какшамас дуслыгына нигезләнгән политикасын тәнкыйть итәргә, СССР халыкларының экономикасы һәм культурасы үсешен, шулай ук алар арасындагы дуслык мөнәсәбәтләрен бозып күрсәтергә азапланалар.

Советлар Союзының милли мөнәсәбәтләрне хәл итүдәге гүзәл казанышлары капиталистик илләргә нинди йогынты ясавын, милли-азатлык хәрәкәтенең көчәюенә китерүен буржуаз идарәчеләр бик яхшы аңлыйлар. Һәм шуңа күрә дә алар безнең илебездә йөзләгән милләтләрнең бердәм гаиләдә туганнарча яшәвен рус халкының өстенлегенә корылган вакытлы бер хәл итеп күрсәтергә, шул юл белән аның тәэсирен киметергә тырышалар. Кыскасы, буржуаз идеологлар совет кешеләре арасында милли дошманлык хисләре уятырга, нинди генә юллар белән булса да, СССР халыклары арасындагы дуслыкны какшатырга өмет итәләр.

СССРдагы милли мөнәсәбәтләрне, милли экономиканың һәм культураның үсеш тарихын өйрәнүгә багышланган «хезмәтләр»дә Татарстанга, татар халкы тормышына да күп урын бирелә. Герхард фон Менде, В. Коларз, С. Зеньковский, В. Хостер, Т. Дәүләтшин, Г. Фәйзуллин, Б. Мусабай, Т. Уязбек кебек буржуаз авторларның китапларында Татарстандагы социалистик төзелеш, экономика һәм культура үсеше тарихына махсус бүлекләр багышлана. Әлеге авторлар Совет хөкүмәтенең татар халкының милли культурасын һәм экономикасын үстерүгә юнәлдерелгән һәр чарасында «милли хисләрне, милли теләкләрне кысу», «руслаштыру» политикасы күрергә тырышалар, республиканың экономика һәм культура үсеше өлкәсендәге һәр уңышына шул күзлектән чыгып бәя бирәләр.

Соңгы еллар матбугатында татар халкының культура тарихына багышланган махсус хезмәтләр дә күренә башлады. Мәсәлән, А. Беннигсен белән Ш. Лемерсье-Келькеженең моннан берничә ел элек Парижда француз телендә чыккан «Россия мөселманнарының 1920 елга кадәрге матбугаты һәм милли-азатлык хәрәкәте»[1] исемле китабы — шундый хезмәтләрнең берсе.

Исеменнән үк күренгәнчә, бу китапта Россия территориясендәге төрки халыклар матбугатының XIX гасырның 80 нче елларыннан алып 1920 елга кадәрге тарихы тикшерелә. Китапның үзендә «мөселман матбугаты» 1920 елга кадәр генә тикшерелә диелсә дә, чынбарлыкта авторлар, төрле искәрмәләр ясау һәм таблицалар китерү юлы белән, милли матбугатның үсеш тарихын 1960 елларга кадәр җиткерергә тырышалар.

Хезмәтнең күп өлеше татар матбугатының туу һәм үсү тарихын тикшерүгә багышланган. Моны авторлар «мөселман» журналистикасының башлангыч чорында татар телендәге матбугатның күчлерәк булуы һәм башка төрки халыклар матбугаты өстеннән «хакимлек итүе» белән аңлаталар (48 нче бит).

Без бу мәкаләдә әлеге китапта кузгатылган барлык мәсьәләләргә тукталып тормыйбыз. Төрки халыкларның матбугат тарихын, шулай ук буржуаз авторларның милли-азатлык хәрәкәтенә кагылышлы фикерләрен анализлауны да үз өстебезгә алмыйбыз. Бу мәсьәләләрнең һәркайсы махсус тикшерүне таләп итә. Безнең төп максат — А. Беннигсен белән Ш. Лемерсье-Келькеженең татар матбугаты тарихын бозып күрсәтүләрен фаш итү, аларның нигезсез уйдырмаларын ышандыргыч саннар һәм фактлар белән юкка чыгару.

Беренче карашка, А. Беннигсен һәм Ш. Лемерсье-Келькеже татар матбугатының тарихын тукми-чәчми, бик төгәл итеп тикшерергә тырышалар, дигән фикер тууы мөмкин. Китапта, беренче татар газетасыннан башлап, Татарстан АССР оештырылганга кадәр татар телендә чыккан барлык газета-журналлар санала, аларның кайда һәм кайчан чыга башлавы, редакторлары, актив сотрудниклары һәм авторлары күрсәтелеп барыла, байтак журналистларның фоторәсемнәре, журналларның тышлыклары бирелә. Шул ук вакытта авторлар бу темага карата СССРда, шул исәптән Казанда, чыккан фәнни әдәбияттан да киң файдаланалар. Китап ахырында китерелгән библиография шул хакта сөйли. Анда Г. Ибраһимов, М. Гайнуллин, М. Мөхәррәмов, Р. Нәфиков, Т. Насыйров һәм башка татар галимнәренең фәнни хезмәтләрен, «Татар поэзиясе антологиясе», «Татарстан АССР тарихы», «Татарстан комсомолы тарихы очерклары», «Пролетар революция өчен көрәштә Татарстан» дигән китапларны һәм бүтән әсәрләрне очратырга мөмкин. Болар барысы да авторларның китапка фәнни төс бирергә, үзләрен объектив тикшерүчеләр итеп күрсәтергә тырышулары турында сөйли.

Инде хезмәт белән җентеклерәк таныша башладыңмы, Беннигсен һәм Лемерсье-Келькеженең, «объектив» саннар һәм фактлар артына яшеренеп, татар матбугаты тарихы турында бөтенләй дөрес булмаган нәтиҗә ясаулары, турысын әйткәндә, чынбарлыкны ачыктан-ачык бозып күрсәтүләре ачыклана. Аерым алганда, алар укучыларны: «Совет чорында татар матбугаты елдан-ел кәчсезләнә, сан ягыннан кими бара, тирән «регресс» кичерә»,— дип ышандырырга тырышалар. Шул фикерләрен раслар өчен буржуаз авторлар 1880 елдан 1917 елга кадәр, 1917 елдан 1920 елга кадәр һәм 1935, 1938, 1960 елларда төрки телләрдә чыккан газета-журналлар санын китерәләр. Алар китергән саннар буенча фикер йөртсәң, 1960 елда татарча газета-журналлар саны 1917—1920 елларга караганда 2 тапкыр кимегән булып чыга (283—284 битләр). Хәлбуки, бу чынбарлыкка туры килми һәм татар вакытлы матбугатының үсешен һич тә дөрес чагылдырмый.

Беренчедән, татар телендә чыккан газета-журналларның саны хакында сөйләгәндә Беннигсен һәм Лемерсье-Келькеже фәннең иң элементар принципларын бозалар һәм чагыштыру мөмкин булмаган саннар белән эш итәләр. Мәсәлән, 283 биттә 1917 елның февраленнән 1920 елның ахырына кадәр ягъни 4 ел эчендә татар телендә нәшер ителгән газета-журналларның гомуми санын күрсәткән таблица китерелә. Бу таблицада ул елларда Россиянең төрле почмакларында чыккан татарча газета-журналлар, шул исәптән, бер-ике саны чыгу белән тукталып калганнары да искә алынган. Ә 284 нче биттәге икенче таблицада 1960 елда бары

[1] Alexandre Bennigsen et Ch. Lemercier-Quelquejay. La presse et le mouvement national chez les musulmans de Russie avant 1920. Paris, 1964. Француз телендә. Алга таба җәяләр эчендә китапның битләре генә күрсәтелеп барачак.

Татарстанда чыккан газета-журналлар гына китерелә. Әлбәттә, мондый юл белән эш иткәндә теләсә нинди нәтиҗә чыгарырга мөмкин. Күрәсез, Беннигсен белән Лемерсье-Келькеженең совет власте елларында татар вакытлы матбугаты сан ягыннан һаман кими бара, дип расларга маташулары бәхәссез фактларны бутап-бозып күрсәтүдән башка нәрсә түгел.

Икенчедән, буржуаз тарихчылар, татар матбугатының «регрессы» турында сүз куертып, иң мөһим бер мәсьәләне — газета-журналларның тиражы мәсьәләсен читләтеп үтәләр. Алар газета-журналларның күпме таралуын, хезмәт ияләре тарафыннан ничек укылуын күрсәткән бер генә сан да (революциягә кадәр чыккан берничә дини журналның тиражын сүз уңаенда әйтеп китүләрен исәпләмәгәндә) китермиләр. Ә бит матбугат хакында сөйләгәндә, тираж мәсьәләсе иң мөһим һәм принципиаль факторларның берсе булып тора. Ничә газета һәм журнал чыгуы гына түгел, бәлки аларның кем тарафыннан һәм күпме укылуы — иң мөһим нәрсә. Гомуми тиражы 20—30 меңгә дә җитмәгән 100 газета һәм журнал чыгуы яки, киресенчә, 20—30 исемдәге газета-журналның миллионлаган данә таралуы мөмкин. Соңгы очракта матбугатның тәэсир көче күп тапкыр артыграк булуы көн кебек ачык. Нәкъ менә шуның өчен дә Коммунистлар партиясе, милли матбугатны үстерү турында кайгыртканда, аны киң масса хезмәт ияләренә җиткерү буенча эшлекле чаралар күрә, бу юнәлештә зур эш башкара.

Совет власте елларында милли матбугатның тиражы үсүен күрсәтү буржуаз авторларның «татар матбугаты регресс юлыннан бара» дигән уйдырмаларын чәлпәрәмә китерер, аларга, татар матбугатының Октябрь революциясенә кадәр «шаулап чәчәк атуы» хакында сүз куертканда, татар телендә чыккан барлык газета-журналларның гомуми тиражы нибары берничә дистә мең генә булуын әйтергә туры килер иде. Шулай булгач, бу хакта бөтенләй дәшми үтү хәерлерәк.

Татар халкы чын матбугат ирегең бары Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң гына алды. 1920 елның июнендә Татарстанда 14 исемле татарча газета һәм журнал чыгып, аларның гомуми тиражы 55.900 данә иде. Алга таба республика матбугаты сан ягыннан да, сыйфат ягыннан да елдан-ел арта, көчәя һәм үсә барды. 30 нчы елларда уннарча исемдә район һәм күп тиражлы газеталар барлыкка килде. Шуңа өстәп, Бөек Ватан сугышының төрле фронтларында һәм төрле чакта татар телендә дистәдән артык махсус газеталар чыкканын да әйтергә кирәк. Ә сугыштан соң — 50 нче еллар уртасында — татар вакытлы матбугаты чолтәре тулысынча стабильләште. Республиканың партия оешмалары матбугатның идея-теоретик дәрәҗәсен күтәрү, газета-журналларның эчтәлекләрен баету, аларның тиражларын арттыру мәсьәләләрен хәл итүне үз алларына төп бурыч итеп куйдылар, КПСС Үзәк Комитеты күрсәтмәләрен тормышка ашыра барып, бу юнәлештә зур эш башкарылды. Нәтиҗәдә татар матбугаты да әлегәчә тиңе булмаган дәрәҗәдә үсте, хезмәт ияләренең чын трибунасына һәм мәктәбенә әверелде. Хәзерге вакытта республикабызда татар телендә 60 тан артык газета-журнал чыга, аларның гомуми тиражы 1 миллион данәдән дә артып китте. Моңардан тыш, Татарстаннан читтә 30 дан артык татарча газета чыга. 1920 елда гомуми тиражы 56 меңгә дә җитмәгән 14 газета-журналдан бүгенге көндә миллион данәдән артык таралучы алты дистә матбугат органына ирешү! Кая соң монда татар матбугатының «регрессы», Беннигсен һәм Лемерсье-Келькеже әфәнделәр?..

Октябрь революциясенә кадәрге татар матбугатын бүгенге көн белән чагыштырганда, тагын бер мөһим моментны истә тотарга кирәк. 1917 елга кадәр һәм Октябрь революциясеннән соңгы беренче елларда күпчелек төрки халыкларның үз телләрендә матбугат органнары юк иде. Шуңа күрә алар татар телендәге газета-журналлардан файдаланып килделәр. Бу фактны Беннигсен белән Лемерсье-Келькеже дә инкарь итми. Татар матбугаты Урта Идел буенда гына түгел, Урта Азиядә, Казагыстанда, Уралда һәм Себердә дә киң тарала иде, дип язалар алар (54 нче бит). Хәзерге вакытта бу республикаларда үз ана телләрендә дистәләрчә һәм йөзләрчә исемдә вакытлы матбугат чыгарыла, аларның гомуми тиражы уннарча миллион данә тәшкил итә.

Буржуаз авторлар СССРдагы бүтән төрки халыкларның (үзбәк, казакъ, төркмән һ. б.) культурасы, шул исәптән матбугаты үсә баруны начар күренеш, татар культурасы һәм матбугатының артта калуы һәм түбәнгә тәгәрәве, дип исбатларга тырышалар. 1870—1920 елларда нәшер ителгән 435 исемдәге мөселман газета-журналларының 66 проценты татар һәм әзербәйҗан телендә булган, дип язалар алар (278 нче бит). Казан

татарлары, гарәп алфавитыннан файдалану һәм культура дәрәҗәләре югарырак булу сәбәпле, башка төрки халыклар арасында хакимлек ролен уйнадылар, панмөселман идеологиясен таратучылар булдылар. Ә хәзер, дип кызганыч белдерәләр буржуаз тарихчылар, мөселман матбугатының үсеше «мөселман блогының» таркала бару тенденциясен күрсәтә. Беренче карашка, алар сүз уңаенда искәрмә генә ясап үтәләр кебек. Әмма бу көн кебек ачык нәрсәне бутаудан башка нәрсә түгел. Бүтән төрки халыкларның культурасы чәчәк ату һич тә бит әле татар культурасының «регресс юлы белән баруы» дигәнне аңлатмый. Тормыш дөреслегеннән аз гына хәбәрдар булган һәр кеше совет власте елларында, бүтән милләтләрнең культуралары бик нык алга киткән кебек, татар халкының да культурасы һәм матбугаты искиткеч зур уңышларга ирешүен, теләсә нинди ил сокланырлык дәрәҗәдә ныгуын һәм камилләшүен бик яхшы аңлый.

Бу хакыйкатьне расларлык берничә факт китерик. Бүген «Социалистик Татарстан», «Татарстан яшьләре», «Яшь ленинчы» газеталары һәм «Ялкын», «Азат хатын», «Чаян», «Казан утлары» журналлары һәркайсы 70 меңнән алып 350 мең данәгә кадәр тираж белән чыга. Ә бит 20 нче елларда аларның тиражлары 3—8 меңнән артмаган. Бүген хәтта күп кенә район газеталарының тиражы да 3—8 мең данәдән күбрәк. Ә Арча районының «Коммунизмга» газетасы 12 мең данә тарала. Әгәр Октябрь революциясенә кадәр татар хезмәт ияләренең бик азы гына газета-журнал алдырган булса, хәтта 1920 елда да әле Татарстанда 15—20 кешегә, ә татарлар арасында 30—35 кешегә нибары 1 данә газета-журнал туры килсә, бүген республикабызның һәр кешесе уртача 1,25 данә вакытлы матбугат алдыра. Шуңа өстәп, йөзләрчә мең хезмәт ияләре төрле китапханәләрдә, клубларда һәм башка культура учакларында күпме газета-журналлар укыйлар! Статистика мәгълүматларына караганда, Татарстан Советлар Союзындагы иң күп укучы республикаларның берсе булып тора. Беннигсен һәм Лемерсье-Келькеже әфәнделәрнең моны белмәүләре, дөресрәге, белергә теләмәүләре бик аяныч.

Алар китабының тагын бер җитди кимчелеге совет матбугатының ленинчыл принципларын бозып күрсәтүдә ачык күренә. Авторлар 1917—1918 елларда ачыктан-ачык контрреволюция ягына күчкән матбугат органнарының совет власте тарафыннан тыелуына үкенеч белдерәләр. Матбугат органнары аша совет властена каршы пропаганда алып бару җае калмаганга ачынып, алар: яңа совет матбугаты тулысынча монолит органга әйләнде, большевистик матбугат органнары арасындагы аермалык аларның функциональ аермалыгында гына чагыла башлады, политика һәм идеология мәсьәләләрен яктыртуда бернинди каршылыклар да калмады, дип язалар (277 бит). Ул гына да түгел, Беннигсен һәм Лемерсье-Келькеже, совет матбугатының партияле булуы аның эчтәлегендәге революционлыкны юк итүгә китерде, дип тәкърарлыйлар. Хәтта ачыктан-ачык: «1920 елда, совет режимының бөтенләйгә җиңүе белән, мөселман матбугаты тарихының революцион чоры бетә һәм яңа сәхифә — совет матбугаты тарихы сәхифәсе ачыла»,— дип тә язалар (180 бит).

Шулай итеп, партиялелекне революционлыкка, ә революционлыкны совет властена каршы куярга тырышалар. Шуның белән буржуаз идеологлар үзләренең өстән торып хакимлек иткән «ун меңләгән түрәләр» өчен генә кулай булган буржуаз демократия сакчылары булуларын тагын бер кат исбатлыйлар. «Партиясезлек» лозунгысы артына яшеренергә никадәр генә тырышсалар да, капиталның тугәүле ялчылары булулары һәр сүзләреннән ачык күренеп тора.

Әле 1905 елда ук, партиясезлек турындагы буржуаз уйдырмаларга кискен отпор биреп, В. И. Ленин болай дип язган иде:

«Буржуаз җәмгыятьтә партиясезлек — туклар партиясендә, хакимлек итүчеләр партиясендә, эксплуататорлар партиясендә торуның икейөзле, пәрдәле, пассив гәүдәләнеше ул.

Партиясезлек буржуаз идея ул. Партиялелек социалистик идея ул» [2].

Матбугаттагы партиялелек принцибы В. И. Ленинның «Партия оешмасы һәм партияле әдәбият» дигән мәкаләсендә тирән яктыртылган. Бу әсәрендә ул матбугат органнарына партия җитәкчелегенең зарури булуын, партия матбугатын эксплуататорларга каршы көрәштә, кешелекнең бәхетле киләчәге өчен көрәштә көчле коралга әверелдерергә кирәклекне басым ясап әйтә. «Әдәбият партияле булырга тиеш,— ди В. И. Ленин.— Буржуаз гореф-гадәтләрнең киресенчә, буржуаның предприниматель, сәүдә-

[2] В. И. Ленин. Социалистик партия һәм партиясез революционерлык. 4 нче басма, татар телендә, 10 том, 65 бит.

гәр матбугатының киресенчә, буржуаз әдәби карьеризмның һәм индивидуализмның, «барин анархизмының» һәм табыш кууның киресенчә — социалистик пролетариат **партияле әдәбият** принцибын алга сөрергә, бу принципны үстерергә һәм аны мөмкин кадәр тулырак һәм бөтенрәк формада тормышка ашырырга тиеш» [3].

В. И. Ленинның шушы күрсәтмәләрен кулланып, Коммунистлар партиясе совет властеның беренче көннәреннән үк хезмәт ияләре өчен чын матбугат ирегенә тәэмин итте, шул ук вакытта пролетар матбугатның партиялелек принцибын да тулы тормышка ашырды. Совет матбугатының большевистик партиялелеге контрреволюцион буржуазияне һәм аның түләүле ялчыларын Совет властена һәм Коммунистлар партиясенә каршы идеологик диверсияләр, яла ягу һәм каршы котырту алып бару мөмкинлекләреннән мәхрүм итте. В. И. Ленин матбугат ирегенә чикләнмәгән ирек дип аңларга ярамый дип күрсәтте. «Әгәр властьны кулга алсак, буржуаз газеталарны ябачакбыз, дип без элек тә әйткән идек,— дип язды ул.— Бу газеталарның яшәвенә түзеп тору — социалист булудан туктау дигән сүз» [4].

Димәк, матбугат ирегенең пролетар мәгънәсе хезмәт ияләренә үз уйларын һәм фикерләрен ирекле белдерүгә, матбугат аша пролетариат һәм хезмәтчел крестьяннарның интересларын яклауга кайтып кала. Шуңа күрә дә, 1917 елның ахырында һәм 1918 елның беренче яртысында контрреволюцион матбугат органнарының ябылуы закончалыклы процесс булды һәм халык интересларына туры килә иде.

Губерна партия органнары күрсәтүе буенча, татар буржуазиясенең дә контрреволюцион һәм буржуаз милләтчелек позициясендә торган газета-журналлары ябылды. Мәсәлән, 1918 елның гыйнварында, Казан губернасының совет органнары карары белән, «Чыңгыз баласы» дигән газетаны чыгару тыелды. Шул ук елның февралендә «Безнең тавыш», ә март ахырында «Идел-Урал өлкәсе» газеталары чыгудан туктатылды. Апрель-июнь айларында «Корылтай», «Алтай», «Иттифак», «Йолдыз» һәм «Кояш» газеталары ябылды.

Буржуаз газеталар ябылу белән бер үк вакытта, губернада партия-совет оешмаларының матбугат органнары булдырылды. Аерым алганда, хәзерге «Социалистик Татарстан» газетасының башлангычы булган «Эш», «Татарстан яшьләре» газетасының башлангычы булган «Кызыл яшьләр», шулай ук «Кызыл Армия», «Кызыл әләм», Минзәләдә «Игенче», Мамадышта «Киңәшче», Алабугада «Кызыл юл», Чистайда «Берлек» газеталары чыга башлады. Шулай итеп, матбугат аша контрреволюцион карашларны пропагандалау, милләтчелек фикерләрен алга сөрү мөмкинлекләре юк ителде. Татар телендә чыга торган газета-журналлар республика хезмәт ияләренә үз ана телләрендә Коммунистлар партиясенең программасын һәм политикасын, В. И. Ленинның үлемсез әсәрләрен аңлату, совет власте үткәргән чараларның пролетар асылын төшендерү, татар хезмәт ияләрен бүтән халыкларга дуслык, пролетар интернационализм рухында тәрбияләү буенча искиткеч зур эш башкардылар. Татар матбугаты үзенең эчтәлеген партия кушканча үзгәртә барды, республика алдында торган бурычларны тулы яктырту, хезмәт ияләрен социализм төзүгә туплау өчен тырышты. Кыенлыкларны җиңә барып, татар матбугаты да пролетар партиялелек принципларын тулысынча тормышка ашыру юлы белән үсте.

Ләкин бу, Беннигсен һәм Лемерсье-Келькеже исбатларга тырышканча, татар матбугатының революционлыгы һәм тәэсир көче югалу түгел иде. Әлбәттә, «матбугатта гомуми фикер йөртүләр, политик лыгырдаулар» [5] кимеде, аның каравы, В. И. Ленинның матбугат «сугышчан орган булырга: ул, беренчедән, экономикабыз турында даими һәм дөрес мәгълүматлар бирү белән бергә, (икенчедән) ул мәгълүматларны анализларга, промышленностьны һ. б. идарә итү максаты белән дөрес нәтиҗәләр алу өчен, аларны фәнни эшкәртүче һәм, ниһаять, өченчедән, экономика фронтының барлык работникларын әйдәүче, вакытында төгәл отчет биреп баруны булдырырга омтылучы, уңышлы эшне хуплаучы һәм теге яки бу предприятиенең, яки учреждениенең, яки хуҗалык тармагының һ. б. ш. игътибарсыз, артта калган, булдыксыз работникларын бөтен халык хөкеме алдына чыгаручы булырга тиеш» [6],— дигән күрсәтмәләре тулы тормышка ашырылды.

---

[3] В. И. Ленин. Партия оешмасы һәм партияле әдәбият. 4 нче басма, татар телендә, 10 том, 30 бит.

[4] В. И. Ленин. БҮБКның 1917 ел 4(17) ноябрь утырышында матбугат мәсьәләсе буенча сөйләгән речь. 4 нче басма, татар телендә, 26 том, 273—274 битләр.

[5] В. И. Ленин. Н. Осинскийга. 12 апрель 1922 ел, 4 нче басма, татар телендә, 36 том, 547 бит.

[6] В. И. Ленин. «Экономическая жизнь» газетасы редакциясенә хат. 4 нче басма, татар телендә, 33 том, 16 бит.

Билгеле, совет властена каршы булган матбугат органнары ябылу татар телендә чыга торган газета-журналларның эчтәлекләрен нык үзгәртте. Алар битләрендә Галимҗан Баруди, Гаяз Исхаки, Фуат Туктаров кебек капитал ялчысы булган журналистларның исемнәре күренми башлады. Беннигсен һәм Лемерсье-Келькеже әфәнделәр нәкъ менә Баруди, Исхакиларның матбугаттан читләштерелүләрен газета-журналларның революционлыгы бетү дип «исбатларга» маташалар. Алар матбугатка йөзләрчә яңа талантларның, эшче-крестьян арасыннан чыккан журналистларның килүенә күз йомалар, матбугатның чын-чынлап хезмәт ияләре интересларын яктырта башлавын күрмәмешкә салыналар. Чын мәгънәсендә матбугат иреге алган хезмәт ияләре масса төсендә матбугатка тартылды, кулына кәгазь-каләм алды, республикада, шул исәптән татарлар арасында да, эшче-хәбәрчеләр хәрәкәте киң җәелде. Газеталар халык өчен генә түгел, бәлки халыкның үзе тарафыннан чыгарыла башлады. Шулай итеп, В. И. Ленинның «редакторлык эшендә эшчеләрнең системалы рәвештә катнашуларына ирешергә кирәк»[7] дигән күрсәтмәләре тулысынча тормышка ашырылды.

Моны раслау өчен, бүгенге көндә республикабызда даими язышып торучы эшче-авыл хәбәрчеләрнең саны 30 меңнән артык булуын әйтү дә җитә. Алар газета-журнал битләрендә җитди, дәүләт-күләм әһәмиятле проблемалар күтәрәләр, партия, совет һәм хуҗалык оешмаларының эшләрен яхшырту буенча эшлекле тәкъдимнәр кертәләр, яшәп килгән кимчелекләрне кискен тәнкыйть уты астына алалар. Шулай итеп, хезмәт ияләре, матбугат ирегеннән тулы файдаланып, илебездә коммунизм төзүдә эшләре белән дә, каләмнәре белән дә актив катнаша.

Күргәнебезчә, совет матбугаты буржуаз-милләтчел матбугаттан тамырыннан аерыла. Ләкин бу аермалык, буржуаз фальсификаторлар расларга маташканча, совет матбугатының революционлыгын югалтуында түгел, ә бәлки Советлар илендә газета-журналларның киң хезмәт массалары трибунасына әверелүендә, матбугат ирегенең халыкка хезмәт итүендә күренә.

Беннигсен һәм Лемерсье-Келькежеләрнең, «төгәл» саннар һәм исемнәр китереп, шактый калын язмаларын җитди «фәнни хезмәт» итеп күрсәтергә тырышуларының нигезендә бер генә максат — бездәге милли матбугат үсеше хакында хәбәрдар булмаган кешеләрнең башын әйләндерү, КПСС-ның милли политикасын бозып күрсәтү, шуның белән күп милләтле Совет дәүләтенең башка илләргә революцион йогынтысын киметү максаты ятканлыгы һәркемгә ачык аңлашыла.

Буржуаз фальсификаторларның уйдырмаларын фаш итү белән бергә, үз галимнәребезнең игътибарын тагын бер мәсьәләгә юнәлтәсе килә. Билгеле булганча, татар матбугатының Октябрь революциясенә кадәрге тарихы Г. Ибраһимов, Р. Нәфиков, М. Гайнуллин, Ә. Кәримуллин һәм башка галим-тарихчыларның хезмәтләрендә шактый тирән һәм тулы яктыртылган. Татар совет матбугатының 20 нче еллардагы үсеше Т. Насыйров, А. Литвин иптәшләрнең хезмәтләрендә яктыртыла. Ә менә шуннан соңгы чорда татар совет матбугатының үсеш юллары турында фәнни тикшеренүләр юк диярлек. И. Рәмиевнең 1925 елда басылган альбомыннан башка, бу проблема буенча бер генә фундаменталь фәнни хезмәт тә күренми. Аннан да бигрәк, бүтән проблемаларга багышланган кайбер фәнни хезмәтләр авторлары, матбугат мәсьәләсенә сүз уңаенда гына кагылып, кайбер төгәлсезлекләр җибәрделәр, татар журналистикасы үсеше тарихын бозып күрсәткән ялгыш фикерләр дә әйтелгәләде. Мәсәлән, Ш. Саматның «Татарстанның 10 еллыгына татар матбугаты» дигән мәкаләсендә: «1921—1922 елларда республикада татар телендә нибары 2 газета, ә 1924 елда бер генә газета чыга иде».— дип языла[8]. Бу хата фикер шул ук елда чыккан икенче бер китапта да кабатлана[9].

Әлеге авторлар дөрес булмаган бу саннарны кайдан алганнардыр, анысы билгесез. Кызганычка каршы, аларның «кулы җиңел» булып чыга, әлеге саннар соңрак бер китаптан икенчесенә «күченеп йөри» башлый, соңгы елларда тикшеренү алып барган галимнәр тарафыннан да тәнкыйть күзлегеннән карамыйча файдаланыла. Мәсәлән, И. М. Климов үзенең Татарстан АССР төзелүгә һәм аның үсешенә багышланган шактый күләмле фәнни монографиясендә шулай ук: «1920 елда Татарстан республикасында

---

[7] В. И. Ленин. Безнең бурычлар. 4 нче басма, татар телендә, 36 том, 249 бит.

[8] Татарская художественная литература за десять лет (1920—1930 гг). Казань, рус телендә, 1930 ел, 109 бит.

[9] 10 лет социалистического строительства в Татарстане. Казань, рус телендә, 1930 ел, 163 бит.

6 газета һәм 2 журнал чыккан»,— дип яза [10].

Чынлыкта исә 1920 елда Татарстан АССРда газета-журналлар 8 исемдә генә түгел, бәлки 50 дән артык, шул исәптән татар телендә 14 исемдә чыга. Аларның гомуми тиражы 172.500 данә була [11].

Кайчакта республикабыздагы аерым матбугат органнарының эшчәнлегенә һәм эчтәлегенә дөрес булмаган бәяләр дә бирелә. Мәсәлән, Мәскәүдә чыккан «Газетный и книжный мир» (I выпуск, 1925 г.; II выпуск, 1926 г.) дигән китапта һәм «История татарской советской литературы» (Москва, 1965 г.) дигән китапның ахырында китерелгән «әдәби тормыш хроникасы»нда татар телендәге кайбер газеталарның һәм журналларның чыга башлау һәм тукталып калу даталары дөрес күрсәтелмәгән. «Многонациональная советская журналистика» (МГУ, 1972 г.) дигән зур күләмле монографиядә татар телендә чыга торган газета-журналлар хакында бер сүз әйтелми, бары тик бер урында гына «Социалистик Татарстан» газетасы телгә алына. ТАСС хәбәрчесе А. Дьяченконың «Йөз том поэзия һәм проза» дигән мәкаләсендә («Комсомолец Татарии» газетасы, 1972 елның 12 ноябрь саны): «Октябрь революциясенә кадәр татар телендә китаплар чыгарылмады»,— дигән хата фикер әйтелә.

Мондый ялгышлар һәм буталчык раслаулар татар матбугатының барлыкка килүе һәм үсеше турында дөрес булмаган фикер тудыралар. Андый хаталар Беннигсен һәм Лемерсье-Келькеже кебек буржуаз «тикшеренүчеләр»гә үз уйдырмаларын «нигезләү» өчен мөмкинлек бирә.

Димәк, татар матбугаты тарихын бозып күрсәтүче буржуаз фальсификаторларга каршы көрәштә, безгә дошман идеологларның уйдырмаларын фаш итү белән бергә, совет чорында милли матбугат, шул исәптән татар совет журналистикасы үсеше тарихын фәнни тикшеренүнең дә бик зур роле бар. Бу проблеманы җитди һәм һәр яклы өйрәнү буржуаз тарихчыларның уйдырмаларын тулысынча юкка чыгарыр, Коммунистлар партиясенең милли матбугатны үстерү хакында даими кайгыртканлыгын тагын да ачыграк күрсәтер иде.

---

[10] И. М. Климов. Образование и развитие Татарской АССР. Казань, рус телендә, 1960 ел, 303 бит.

[11] Татарстан үзәк дәүләт архивы, 273 фонд, 1 тасвирлама, 68 эш, 43, 46 һ. б. битләр.

# ҖЫЙНАК, ТАБИГЫЙ ТЕЛ БЕЛӘН

Саимә Ибраһимова — тәрҗемәчелек эшенә илленче еллар башында ук керешкән кеше. Ул — бер дистә чамасы тәрҗемә китапларының авторы. Алар арасында инглиз язучысы Р. Стивенсонның «Кара ук» исемле маҗаралы романы, А. Зегерс хикәяләре, Ян Козак әсәрләре һ. б. бар.

Үткән елны С. Ибраһимова тәрҗемәсендә рус язучысы С. Григорьевның «Александр Суворов» исемле зур күләмле тарихи-биографик характердагы әсәре басылып чыкты [1]. Халкыбызның героик үткәне, югары кешелеклеге, кирәк булганда үзен аямый батырлык эшләргә сәләтлеге, аның чын патриотизмы бу әсәрдә шактый калку сурәтләнеп, идарәче тар даирәнең комсызлыгы, булдыксызлыгы, кешелексезлеге дә кабатланмас мисаллар белән дәлилләп ачылган. Ягъни, тәрҗемә өчен сайланган әсәр үзенең темасы, эчтәлеге белән үк инде укучыны тартып тора.

Татар теленең киң мөмкинлекләреннән файдалану күзлегеннән караганда да, оригиналның эчтәлеген-идеясен һәм стиль үзенчәлекләрен саклау төгәллеге ягыннан алсак та, бу тәрҗемә матур тәэсир калдыра.

Саимә Ибраһимованың, тәрҗемәче буларак, күзгә бәрелеп торган төп сыйфаты — оригиналга сукырларча ябышып ятмау, штамплардан кача белү, сөйләмендә гадилеккә һәм җанлылыкка омтылу. Тәрҗемәләрнең күләме, гадәттә, оригиналныкыннан теге яки бу дәрәҗәдә артып китүен күздә тотсак, кыскалыкка омтылу һәм шуңа ирешүнең әһәмияте ачыграк аңлашылыр кебек. «На действительной службе» дигән бүлекчә исеме, гади генә итеп, «Хәрби хезмәттә» дип бирелгән. Кыска да, аңлаешлы да. Тәрҗемәнең башы да шушыннан башлана, чөнки күп сүз — чүп сүз диләр бит. Сөйләмнең гадилеген, җыйнаклыгын да, монысының кыйммәтен дә ясалма телле текстка тап булганда, кытыршы, авыр сөйләм белән очрашканда гына беләсең. Чөнки гади ул — нәкъ менә шул гади булганга күрә дә күзгә ташланмый.

Саимә Ибраһимова тәрҗемәсенең теле күңелгә ятышлы, табигый булуы белән отышлы да. «Үкенеп бетә алмый иде» (давно не рада), «үзләренә үпкәләсеннәр» (тем хуже...), «урнашасы итте» (решил поселиться) кебек тәгъбирләрне шаблоннан качуның уңышлы үрнәге дияргә мөмкин. Монысы грамматикага караган очрак. Лексикага килгәндә, тәрҗемәченең уңышлы табышлары тагын да ныграк күзгә ташлана. Мәсәлән, барлык тәрҗемәле сүзлекләребезне алып карасак та, гордость сүзенә туры китерелгән һәм мәгълүм дәрәҗәдә традицияләшеп үк киткән штампларны табарбыз. Бу әсәрдә исә без телебезнең бүтән мөмкинлекләре дә бар икәнлеген ачык күрәбез. Бер урында ул сүз, бик урынлы рәвештә, «мин-минлек» дип бирелгән, икенче бер контекстта «не будь горд» җөмләсе «эреләнмә» дип алынган (сүзлекләребез дә киләчәктә моны исәпкә алсалар, һич тә начар булмас иде).

Оригиналга ябышып ятмау дигәнне төрләчә аңларга була. Монда шуның түбәндәге бер очрагына басым ясыйсы килә. Метил выше — өмете зурракта иде (!). Бөтенләй көтелгәнчә түгел, ләкин төгәллеге чыннан да зур, шуның өстенә җыйнаклыгы-гадилеге дә бар. Мне почти шестьдесят — алтмышка җитеп килә, старик нашел самого себя — картның үз дигәне булды, поверьте — мин әйтте диярсез, кебек тәрҗемәләрнең кыйммәте аларның төгәллегендә генә түгел, бәлки җанлы сөйләм үрнәге булуларында да. Гомумән, җанлы сөйләм үрнәкләре бу тәрҗемәнең теле өчен бик хас.

[1] «Александр Суворов». Татарстан китап нәшрияты, Казан, 1975 ел. С. Ибраһимова тәрҗемәсе.

Тәрҗемәченең игътибарга лаек тагын бер алымы дикмә, үзенчәлеге дикмә: урыны-урыны белән ул нейтраль сөйләмне образлы сөйләм итеп үстерә, информация генә бирә торган тәгъбирләрне эмоциональ җөмләләр белән тәрҗемәли. Моңа ничек карарга? Әгәр без тәрҗемәне иҗади эш дип таныйбыз икән (моның белән килешмәүче юктыр, шәт), бу иҗадилык нәрсәгә кайтып калырга тиеш, дигән сорау туа. Оригиналның хәрефенә, сүзенә, җөмләсенә, абзацына (гомумән, текстына) ябышып ятып, шуны уңышлы бирүгә генәме? Кирәк дип тапкан очракта әчтәлеккә һәм мәгънәгә зарар китерми торган берәр өлешне төшереп кыскартугамы яки әсәрне куәтли торган әз-мәз өстәмәләр кертүгәме? Тәрҗемәчелек практикасы боларның берсен дә кире какмый; тәрҗемә уңышлы чыккан очракта алар, кагыйдә буларак, үзләрен аклаган исәпләнәләр. Әсәрнең теленә карата да аналогик алым кулланыш буламы? Мисалларга мөрәҗәгать итик. «При Ларге и Кагуле фельдмаршал Румянцев обладал всей полнотой власти» — «Ларга һәм Кагул янында сугышканда фельдмаршал Румянцев үзе баш, үзе түш булган иде». Берәр тарих дәреслегенме, я бүтән шундый (ягъни матур әдәбиятка кермәгән) хезмәтне тәрҗемә иткәндә, әлбәттә, бу рәвешле «киң күңелләләнү» белән килешеп булмас иде. Ә бу очракта, беренчедән, тәрҗемә үзенең яңгырашы, җанлылыгы белән һичшиксез уңышлы; икенчедән, оригинал сүзләреннән, текстыннан шактый читләшкән кебек күренсә дә, асылда аның рухына, мәгънәсенә якыная гына төшкән. Минемчә, моны тәрҗемәдәге иҗадилыкның бер конкрет чагылышы дип бәяләргә мөмкин. Яки менә «плохие стихи» «чиле-пешле шигырь» дип тәрҗемәләнгән икән, оригиналның мәгънә агышы моны тулы кабул итә.

Гамәлдәге сүзлекләребездә теркәлмәгән, матбугат битләрендә дә бик сирәк очрый яки бөтенләй очратып булмый торган түбәндәге тип сүзләрне тәрҗемәченең табышы дип карарга мөмкин: «чапкынлау» (балалар турында), «лечпелдекле» (җепшек кыш турында), «әлем-чалым гына» (берәр җирдә күренеп киту, тавышлар ишетелү турында), «кымырҗык», «лышт-лышт» һ. б.

Гомум кулланыш өчен искергән дип карала торган сүзләрне һәм тәгъбирләрне дә тәрҗемәче тиешле стильләренә уңышлы кайтарып куллана (мәсәлән, химаячы — покровитель, чирүе белән — целая кавалькада ординарцев һ. б. ш.). Диалекталь дип карала торган сүзләрне дә уңышлы кулланышка кертеп җибәрүнең бер мисалы итеп «Днепрның япан яры буенда» (пустынный берег Днепра) фразасын күрсәтергә мөмкин.

Телебезнең сурәтләү-сәнгатьләү чараларыннан берсе булган образлы идиомалар белән эш итүдә дә тәрҗемәче үзенең хәзерлекле икәнлеген күрсәтә. Әйтик, «в» сумерках» дигәнне ул «күз бәйләнгәч» дип бик уңышлы тәрҗемә итә. Ләкин тәрҗемә практикабызның бүгенге казанышлары югарылыгыннан караганда, мондый очракларны инде шаблонга кертергә мөмкин, чөнки бу, әлеге дә баягы — штамп. Ул — бүгенге түгел, кичәге көн казанышы. Бу баскычка ирешү — табигый һәм зарури күренеш. Тәрҗемәченең бу өлкәдәге төп уңышына мондый мисалларны кертергә мөмкин: человеческий род — адәм баласы (контекст чыннан да шуны таләп итә), подлил масла в огонь — күңелендә йөргән очкынны дөрләтеп кенә җибәрде, целкового за глаза довольно — бер тәңкә әйләнеп чыккан һ. б. ш. «Сила солому ломит» мәкале бер очракта (бүлек башында) «көчленеке замана» дип, икенче очракта «көчле белән көрәшмә» дип урынлы һәм хаклы рәвештә ике вариантта тәрҗемә ителгән. Гомумән, бу китапта мәкальләрне калькалау (ягъни сүзгә-сүз авыштырып «тәрҗемәләү») очраклары бик аз, мөмкин булган һәр урында телебезнең үз ресурслары файдаланырга тырышылган.

Күргәнебезчә, образлы сөйләмне тәрҗемә итүдә Саимә Ибраһимованың бу хезмәте игътибарга лаек. Менә русларның «где вода дорога?» дигән гади генә бер шаяртулы, сүз уйнатулы табышмак-тәгъбире. Моның ише фразаларны «чыктым аркылы күпер» дип тәрҗемәләгәннән соң юл астында аңлатма биреп катлауландыру очракларын әдәбиятыбыздан күп китереп булыр иде. Бу китапта «җиде яше тулгач кәҗә нишли?» дигән, шундый ук мәгънәле сүз уйнату тәгъбире шактый уңышлы сайлап алынган.

Тәрҗемәченең диалогларны бик уңышлы һәм матур, нәкъ үз телебездәге кебек җанлы итеп бирүенә дә игътибар итеп үтәсе килә. Менә бер генә мисал:

— Слезай с коня!

— Как бы не так!

— Слезай!

— Да ведь коня-то мы хотим от Суздальского полка Суворову в подарок!

Тәрҗемәсе:

— Төш атыңнан!

— Төшкән диярләр!

— Төш дим!

— Нишләп төшим, без бит бу атны Суздаль полкы исеменнән Суворовка бүләк итмәкче булабыз!

Кыскасы, татар теленең әле лексикографлар тарафыннан да барлап чыгылмаган мөмкинлекләрен чагыштырмача тулы файдалану тәрҗемәнең сыйфатын күтәрүдә Саимә Ибраһимовага зур ярдәм күрсәткән. Аерым алганда, гамәлдәге сүзлекләребездә теркәлмәгән яки чагылмаган күп кенә мәгънәләр һәм мәгънә төсмерләре яисә стилистик нюанслар бу хезмәттә үзләрен нык сиздерәләр. Алар үзләре генә дә, махсус тикшерү объекты буларак, аерым алып анализлауны көтәләр (тәрҗемә теленең үз законнчалыклары бар һәм киләчәктә бу моментка игътибар бирелер дип уйларга кирәк). «Александр Суворов» китабында, Саимә Ибраһимованың элгәрге тәрҗемәләрендәге кебек үк, телебезнең кыскалыгы-җыйнаклыгы матур гәүдәләнгән, оригиналның мәгънә һәм стилистик байлыгы татар теленә уңышлы күчереп утыртылган. Бу тәрҗемә үзенең гади-җыйнак теле, җанлы сөйләме, эзлекле стилистик яңгырашы белән хәтергә кереп кала.

Рецензияләнә торган бу тәрҗемәнең кимчелекләре юк дип әйтсәк, дөреслекне күрсәтми калудан тыш, тәрҗемәчене дә бераз рәнҗеткән булыр идек, чөнки болай әйтү тәрҗемәченең үсәр мөмкинлекләре калмаган инде дигән фикерне алга сөрү булыр иде. Китаптагы аерым уңышсыз абзацларны яки җөмләләрне берәмләп санап тормыйча, уртага салып карардай кайбер мәсьәләләргә тукталыйк. Шуларның берсе — күп тәрҗемәчеләребезне аптырата торган титулдәрәҗә төшенчәләре (һәм сүзләре, тәгъбирләре) мәсьәләсе. Ваше величество, ваше сиятельство, ваше превосходительство, ваше высочество, благородие, степенство, преосвященство, ваша светлость, сударь, государь кебек сүзләр бу китапта нигездә «гали җәнап» һәм «әфәнде» дип тәрҗемәләнгән. Соңгы ике сүзне «әфәнде» дип аңлатып булса да, калганнары өчен «гали җәнап»ларенең җитмәве күренеп тора. Татар милләтенең тарихына кайтып эзләп карасак та, без боларга тиң төшенчәләрнең канәгатьләнерлекләрен таба алмыйбыз. Руслар тарихының да мәгълүм бер (ләкин: үткән!) чорына гына хас бу төшенчәләр безгә рус төшенчәләре буларак кына таныш һәм шулай булып калачак та. Халык теленең тиешле стиле ваше благородие кебек тәгъбирләрне күптән инде шул килеш кенә куллана, чөнки попны мулла диме, чиркәүне мәчет диме. Бу мәсьәләне чишүнең нигезе шушыдыр кебек.

Тел ул — организм, аңа да вакыт-вакыт чир тигәли. Матбугат телендә хәзер шундый бер «кизү» бар диясе килә: стиль «кизүе». Телебездә «гаилә» сүзе юк дип булмый, билгеле, әмма җанлы сөйләмдә, көндәлек тормышта «семья» сүзе генә йөри. «Гаилә», «әсир» кебек сүзләрнең үз стильләре бар, һәм аларны барлык очрак өчен мәҗбүриләштерергә тырышу һич тә аңлашылмый. Бу «кизүдән» С. Ибраһимова да азат түгел икән. «Тапкыр», «мәртәбә», «кат», «чак», «вакыт», «юлы» һ. б. күп сүзләр белән бирер була торып та, тәрҗемәче ни өчендер «мәл» сүзен барлык шушы сүзләр урынына кулланып, тәрҗемәгә мул сипкән.

**ГАЛИМҖАН АХУНҖАНОВ**

# ТАРИХИЛЫК — ФӘННЕҢ ЗАРУРИ ТАЛӘБЕ

Узган чорларны өйрәнгәндә һәр галим күп тармаклы тарих фәненең конкрет берәр ягы белән эш итә. Берәүләребез социаль-иҗтимагый мәсьәләләрне, икенчеләребез тел-әдәбиятны, өченчеләребез гореф-гадәт һәм йолаларны, дүртенчеләребез исә борынгыдан калган эш коралларын, гомумән, матди истәлекләрне өйрәнә. Моннан тыш, тарихның җыр-музыканы, көнкүреш сәнгатен тикшерә торган яңарак тармаклары да бар. Безнең татар тарихы буенча соңгы елларда нәкъ менә шушы өлкәләрдә яңадан-яңа хезмәтләр күренә башлады. Сәнгать белгече Фуад Вәлиевнең «Урта Идел буеның борынгы һәм урта гасыр сәнгате» дигән зур күләмле китабы [1] — шундыйларның берсе.

Ул «Крайның борынгы чор сәнгате» һәм «Идел-Кама буе болгарлары сәнгате» дигән ике зур бүлектән тора. Сәнгать истәлекләрен тасвирлауга һәм анализлауга багышлан-

[1] Ф. Х. Валеев. Древнее и средневековое искусство Среднего Поволжья. Йошкар-Ола, рус телендә, 1975 ел.

ган бүлекләрдән тыш, китапта 83 таблица, 700 дән артык документаль рәсем һәм фотоиллюстрация китерелә [2]. Автор бу материалларны озак еллар җыйган, матбугатка бик зур таләпчәнлек һәм пөхтәлек белән әзерләгән.

Галим борынгыдан безнең көннәргә хәтле килеп җиткән көнкүреш сәнгате әсәрләрен, дөресрәге, шундый әсәрләрнең сакланып калган аерым үрнәкләрен бик җентекләп тасвирлый, төрле яктан анализлый. Истәлекләрнең үзләрен күзәтү белән генә канәгатьләнмичә, ул аларның чыганакларын ачыкларга, үсү-үзгәрү юлларын билгеләргә тырыша. Нәтиҗәдә Идел буе болгарларының нинди кабиләләрдән оешуы, кайсы халыклар белән мөнәсәбәткә керүе, кемнәрдән нәрсәгә өйрәнеп, кемнәргә үзеннән «өлеш бирүе» һәм, иң мөһиме, кайсы чорда нинди материаль казанышларга ирешүе яктыртыла. Көнкүреш сәнгате әсәрләре биргән өстәмә мәгълүматларга караганда, төрки телле борынгы болгарлар ул чор өчен югары культуралы сармат-алан кабиләләре, соңрак исә специфик традицияле фин-угорлар, ягъни хәзерге удмурт, мари, мордваларның бабалары белән эзлекле экономик һәм культура мөнәсәбәтләрендә яшәгәннәр икән. Шул рәвешчә, Идел буе болгарларының үзләренә генә хас көнкүреш сәнгате барлыкка килгән.

Соңрак исә, дәүләт үсеп, шәһәр мәдәнияте алга киткәч, болгарлар үзләре башка халыкларга йогынты ясый башлыйлар. Фуад Вәлиев борынгы чор болгар сәнгатен шул чакта көньяк далаларда яшәгән хазарлар һәм кыпчакларның тарихы белән тыгыз мөнәсәбәттә карап бик дөрес эшли. Җыеп әйткәндә, китапның беренче өлеше зур мәсьәләләр күтәрүе, аларны киң планда хәл кылырга омтылуы белән аерылып тора.

Хезмәтнең икенче өлешендә урта гасыр, ягъни X—XV йөз Идел буе болгарларының сәнгате тикшерелә. Үз чиратында бу кисәк ике бүлектән тора. Беренче бүлектә монгол яулап алуларына кадәрге дәвер яктыртыла, икенче бүлек Алтын Урда чоры болгар сәнгатенә багышланган. Әйтергә кирәк, бу чорларга караган бай һәм катлаулы материалны автор бик җентекләп, тәфсилләп тикшерә. Бу материаллар белән танышкач, без X—XII йөзләрдә болгар сәнгатенең тагы да үсә төшүен, ә Алтын Урда чорында исә, башка халыклар белән тыгызрак мөнәсәбәткә керү нәтиҗәсендә, байый, камилләшә баруын күрәбез.

Ләкин шул ук вакытта бу бүлектә безне канәгатьләндереп җиткермәгән урыннар да очрый. Әйтик, Алтын Урда чоры хакында сөйләгәндә Ф. Вәлиев каршылыклы фикерләр әйтә. Бер яктан, ул Алтын Урда империясе составына кертелгән Болгар җирен яңа оешкан гомум дәүләттән, андагы социаль-иҗтимагый үзгәрешләрдән аерыбрак карарга тырыша. Икенче яктан, Болгар калаларының, Алтын Урдадагы башка зур шәһәрләр кебек үк, эре мәдәни үзәкләр булуын танырга мәҗбүр. Минемчә, икенче караш дөреслеккә күбрәк туры килә. Димәк, Болгар сәнгатен Алтын Урдадан аерып, изоляцияләп тору файдасыз. Чөнки материаль тормыш продукты булган көнкүреш сәнгате, милли-этник фактор булудан бигрәк, социаль, политик һәм идеологик шартларга бәйле. Ә XIII йөздә, барыбызга да күптәннән мәгълүм булганча, Көнчыгыш Европада катлаулы үзгәрешләр барлыкка килә: монгол яулап алулары нәтиҗәсендә күп илләрнең политик һәм этник карталары үзгәрә, аларның социаль-экономик төзелешләрендә дә яңа мөнәсәбәтләр урнаша. Димәк, авторның «Яулап алу (ягъни монгол яулап алуы — М. Г.) Болгар җиренең феодаль төзелеш нигезләрен үзгәртмәде...» дип расларга тырышуы (135 бит) фәнни караш була алмый.

Икенчедән, XIII—XV йөзләрдә Болгар җиренең Урта Азия, Иран, Кавказ, хәтта Ерак Мисыр яклары белән культура мөнәсәбәтләре шактый төгәл карала. Бу — дөрес. Ләкин шул чордагы Урта Иделне дәүләт үзәге булган Түбән Иделдән, Болгар җирен Алтын Урдадан аерып карау һич тә тарихилык принцибына сыймый. Чөнки Болгар белән Урта Азия арасында кәрваннар гына йөргән, Мисырга исә кыю сәүдәгәрләр һәм сирәк сәяхәтчеләр генә барып кайткан, ә Түбән Идел белән Болгар җире 200 елдан артык бер дәүләт составында торган. Өстәвенә, Урта Иделдә дә, Түбән Иделдә дә кардәш халыклар яшәгән. Димәк, бер дәүләт эчендәге бу ике өлкәне бер-береннән аерып карау һич тә акланмый. Дөрес, кайбер авторлар Болгар җирен XIII—XV йөзләрдә дә мөстәкыйль ил сыманрак итеп күрергә телиләр. Теләкләренә реаль төс бирер өчен, гарәп чыганакларыннан Дунай болгарлары хакындагы хәбәрләрне йолкып алалар да Идел буена күчереп куялар. Мәсәлән, шундый карашны бик тырышып алга сөрүче археологларның берсе 1330—1331 елларда

[2] Һәр иллюстрациянең кайда саклануын, нинди чыганактан алынуын күрсәтү хезмәтнең кыйммәтен бермә-бер арттыра.

(димәк, XIV гасырда) Ибне Фазлан сүзләренән таянып, «болгар ханының» Мисырга илче җибәрүен әйтә[3]. Чынлыкта монда без белгән Ибне Фазланның бернинди катнашы юк. Югарыдагы хәбәр XIV гасырдан соң яшәгән гарәп язучысы Ибне Фазлуллаһ хезмәтеннән алынган. Һәм анда сүз **болгар** һәм **серб** патшасының илчелеге һәм аның госманлы төрекләр белән көрәше хакында бара[4]. Ф. Вәлиев тә шушы хәбәрне Идел буе болгарлары хакындагы факт сыйфатында кабатлый, Алтын Урданың бер өлеше булган XIV йөз Болгар җирен ерак чит дәүләтләр белән турыдан-туры **политик** мөнәсәбәттә яшәгән мөстәкыйль илгә әйләндерә. (136 һәм 197 битләр.) Бу мәсьәләдә сүзне артык сузмас өчен, безнең замандаш галимнәрдән шуны сорыйсы килә: Алтын Урда дәүләтендәге һәр политик вакыйганы эзлекле рәвештә күзәтеп, теркәп барган рус елъязмаларында XIII—XV йөз Болгар җиренең политик мөстәкыйльлеген раслаган системалы берәр хәбәр бармы? Юк. Әгәр булса, Ибне Фазлуллаһтан, Ибне Фазлан, һәм тәмам славянлашкан Дунай болгарларыннан татар бабалары ясамас идек.

Ни өчен болай килеп чыга соң?

Минемчә, вак-төяк сылтауларны читкә куеп, төп сәбәпне **политик** тарих белән **этник**, ягъни «милли» тарихны бутаудан, хәтта буташтырудан эзләргә кирәк. Гадирәк итеп әйткәндә, безнең кайбер тарихчыларыбыз Алтын Урдада гел илбасар ханнарны гына күрәләр (әйтерсең лә анда изелүче халык массалары юк!), Болгар җирендә исә бары «үз бабаларыбызны» гына табалар (гүяки монда «үз» изүчеләребез булмаган!!). Әлбәттә, мондый алымны, гәрчә ул нинди генә формада чагылмасын, тарихи эзлеклелек дип атап булмый.

Әгәр китап авторы кыеклап та, турылап та шундый бәхәсле карашны алга сөрмәсә, X—XII йөз өчен үзара якын һәм кардәш дип икърар кылынган «половец» кыпчаклары белән болгарларны (108 бит) чак кына соңрак, ягъни Алтын Урда чорында үзара каршы куеп тормас иде (192 бит). Бу исә авторны тагын да тирәнрәк каршылыкка китергән. Мисал өчен, китаптан өзекләр алыйк: «Степное искусство кыпчаков **не могло** привнести что-либо существенное в высокоразвитое художественное творчество булгар, как **и в целом в их культуру»** (192 бит). «Җирле патриотизм» принципбыннан чыгып, бу фикер белән килештек тә, ди. Ләкин Ф. Вәлиев алга таба әлеге фикерне тагы да үстерә төшә, тик шунда ук буталып кала: «Степная культура кыпчаков **не могла** оказать не только на искусство, но **и в целом на культуру** булгар какого-либо серьезного воздействия, **за исключением их языка — государственного языка Улуса Джучи»** (200 бит. Курсивлар минеке — М. Г.). Күрәсез, бу катгый фикердә, беренчедән, гомум культураның зур өлеше булган әдәби тел сәнгатькә каршы куела; икенчедән, феодаль җәмгыятьтәге **әдәби тел** белән **халык теле** диган төшенчәләр буташтырыла. Урта гасырларда — натураль хуҗалык хөкем сөргән җәмгыять таркаулыгы чорында — тар даирәнең әдәби телен киң халык массаларына бернинди декрет, бернинди ярлык белән дә тарату мөмкин булмаган. Бары җанлы кешеләр аралашу, кардәшләшү, этник берләшү һәм, иң мөһиме, бер нигездәге дәвамлы җитештерү мөнәсәбәтләренә керү нәтиҗәсендә генә халык теле үзгәрә алган. Һәм борынгы болгар теленең кыпчаклашу процессы, әгәр тагы да иртәрәк булмаса, XI гасырдан башланып, XVI гасырга кадәр дәвам иткән. Димәк, кыска вакытлы этнолингвистик «шартлау» нәтиҗәсе түгел бу. Шуңа күрә, этногенез кебек катлаулы мәсьәләләргә кагылганда, телне бер киштәгә, материаль культура элементларын бөтенләй башка шүрлеккә куярга ярамастыр. Китап авторы, Кавказ, Иран, Мисыр архитектураларына сәяхәт ясау белән бергә (мондый сәяхәтләр дә, һичшиксез, кирәк), күрше халыклардан нугай һәм каракалпак, башкорт һәм үзбәкләрнең көнкүреш сәнгатьләренә дә игътибар белән карарга тиеш иде. Автор шулай ук Болгар җиренең әлеге шәрык илләре белән мөнәсәбәте әллә нинди «һава күпере» аша түгел, ә дәүләт үзәге булган Түбән Идел һәм, гомумән, киң кыпчак сахралары, шундагы зур-зур шәһәрләр аркылы барганлыгын да онытмаска тиеш иде. Шулай иткәндә, хезмәттә көньяктагы кардәш халыкларны санга сукмау тенденциясе сизелмәс иде.

Ихтимал, татарларның борынгы көнкүреш сәнгатендә күчмә халык сәнгате элементлары чыннан да аз сакланган дыр. Бик ихтимал («ихтималны» болай кабатлау юкка түгел, чөнки Алтын Урда чоры кыпчакларының төп варислары булган нугайларның сәнгате, мәсәлән, җитәрлек дәрәҗәдә тикше-

[3] История Татарской АССР. Рус телендә. Казан, 1968, 57 бит.

[4] Амин аль-Хали. Связи между Нилом и Волгой в XIII—XIV вв. Мәскәү, 1962, 21 һәм 38 битләр. Бу автор үз аңлатмасында сүз, бәлки, Идел болгарлары хакында барадыр диган фараз тәкъдим итә. Безнең археолог исә аны шөбһәсез дөрес хәбәр сыйфатында китерә.

релмәгән бит әле)[5]. Ләкин мәсьәләне «кыргый» һәм «мәдәни» халыкларны каршы куюдан гына түгел, бәлки материаль шартлар, дөресрәге, тарихи-географик шартлар белән дә аңлатырга кирәк иде. Чөнки көнкүреш сәнгате көнкүреш әйберләре, эш кораллары белән генә бергә яши ала, алар белән бергә үзгәрә. Утрак тормышлы болгар кешесе агач йорт, ташпулат һәм чана белән урагын төрлечә сырлап бизәгән. Күчмә кыпчак та киез тирмәсен, ияр-өзәңгесен һәм камчысын төрлечә күркәмләгән. Туган иленнән сөрелгән болгар кешесе, үзе белән бергә, агач йортын өстерәп китә алмаган. Урта Идел буена килеп утырырга мәҗбүр ителгән көньяк кыпчагы да киез тирмәсе белән саубуллашкан, чөнки биш-алты ай салкын көз, карлы кыш хөкем сөргән җирләрдә киез өй кулай түгел. Шуңа күрә бу якларда күчмә тормыш элементлары археологик казынулар вакытында күпләп табылмаса, артык гаҗәп түгел.

Нәкъ шушы төштә укучының: «Бу якларга кыпчаклар бәлки, чыннан да, бөтенләй килмәгәндер?» — дип соравы бар. Мондый шөбһәгә, баксак, Ф. Вәлиев үзе дә каршы икән: «...на покинутых булгарами землях **массами оседали кыпчаки**, приток которых особенно усилился в середине XV в. после образования Казанского ханства и появления **кыпчакско-татарских дружин** золотоордынца Улу-Мухаммеда» (193 бит. Курсив минеке — М. Г.).

Шул ук вакытта китерелгән бу өзек авторның үз концепциясен дә нигездән җимерә. Әгәр XV йөздә кыпчаклар Урта Иделгә күпләп (масса рәвешендә!) килгән икән, ул вакытта тел үзгәрүне бары «дәүләт теле», ягъни әдәби тел тәэсиренә кайтаруның һич тә кирәге калмый бит. Бу — бер. Икенчедән, элекке Болгар дәүләте җиренә кыпчакларның күпләп утыруларын бары хәрби вакыйгалар, ягъни Казан җире мөстәкыйль дәүләт булып формалашкан чактагы тәхет яулап алу фактлары белән генә чикләп, автор тагы бер кат методик ялгыш ясый. Чөнки болай эшләп, ул Казан ханлыгы аерымланып чыкканга кадәрге 200 елны — Урта Идел белән Түбән Иделнең бер дәүләт составында уздырган ике гасырын бөтенләй «онытып» җибәрә. Хәлбуки, **халыклар белән** халыкларның аралашуы, якынлашуы сугышсыз-ызгышсыз шартларында түгел, бәлки солых, тыныч хезмәт хөкем сөргән чорда гына мөмкин. Бу — элементар хакыйкать. Шуңа күрә Ф. Вәлиевнең өченче методик ялгышы өлкәдәге кыпчак телле **хезмәт ияләрен** тарихтан берничә гасырга бөтенләй сызып ташлап, Олугмөхәммәтнең бер төркем сугыш чукмарлары алдында «тез чүгүеннән» гыйбарәт.

Мондый ялгышлыкларны ничек аңларга соң? Минемчә, беренчедән, автор этногенез мәсьәләләрен яктыртуга теоретик әзерлексез рәвештә алынган (күптән шушы тирәләрдә йөрсә дә, үзе нигездә архитектура, сәнгать белгече бит). Шуңа күрә ул гыйльми әдәбиятта яшәп килгән ике капма-каршы теорияне — иҗтимагый-политик обстановканы игътибарга алмаган, этногенез мәсьәләсенә бары этнографик планда гына караган «саф болгарчылык» белән халык язмышын бары политик тарих күзлегеннән генә яктыртучы «саф кыпчакчылык» теорияләрен механик рәвештә кушудан ары уза алмаган.

Икенчедән, Ф. Вәлиев үзе тикшерә торган объектларга нигездә бердәнбер этногенез яссылыгыннан карау белән чикләнә, бөтен материалны «бабаларыбыз кем?» дигән сорауга җавап формасында оештыра. Көнкүреш сәнгатенең конкрет тарихи, географик, материаль, экономик һәм политик шартларда ничек үсүе, үзгәрүе кебек тирән фәлсәфи мәсьәләләргә җитәрлек тукталмый. Сәнгать әсәрләренең социаль табигатен аңлата торган «заказчы һәм башкаручы», «иҗат итүче һәм файдаланучы» кебек проблемаларга да ул бары тик узып барышлый, өстән-өстән генә кагылгалый.

Уйлавыбызча, Казан татарлары, башка халыклар кебек үк, төрле кабиләләр, этник группалар берешүдән барлыкка килгән тарихи халык, яңарган һәм яңара баручы халык. Гадирәк итеп әйткәндә, анабыз болгар, атабыз кыпчак, яки киресенчә («кода-кодагыйларыбызның» берсе мари, икенчесе удмурт булса да бик табигый). Шул ук вакытта ул әби-бабаларыбыз политик тарихның караңгы тыкрыкларында, канлы мәйданнарында кыска вакытлы очрашулар нәтиҗәсендә түгел, бәлки гомер-гомергә, гасырдан-гасырга сузылган һәм **производство мөнәсәбәтләре нигезендә** нытылган тормыш нәтиҗәсендә генә безне барлыкка китергән. Шуңа күрә, берсен зурлап, икенчесен хурлаган төсле аларны «күчмә» яки «утрак» дип каршы ку-

[5] Казан ханлыгы һәм соңрак Казан өязе территориясендә «Нугай даругасы» дигән административ берәмлекнең («даруга» — якынча, өлкә) булуы үзе генә дә күп нәрсә турында сөйли. Кызганычка каршы, Ә. Булатовның күптән түгел басылган кечкенә күзәтүен (карагыз: «Материалы по татарской диалектологии». Казан, 1974, 186—190 битләр) исәпкә алмаганда, безнең тарихчыларыбыз татар-нугай этник мөнәсәбәтләренә тиешенчә игътибар итмиләр.

ырга хакыбыз юк. Ниһаять, эзлекле булсак, X—XIII йөз болгарлары үзләре дә бит VII—VIII гасыр күчмәләреннән утраклашкан. Дөресрәге, конкрет тарихи-географик шартларда утрак тормышка күчәргә мәҗбүр булган. Бәс, болгар һәм кыпчак сәнгатенең аермасын күчмәлек һәм утраклыктан түгел, бәлки мөмкинлектән һәм ихтыяҗдан эзләргә иде. Менә шуңа күрә XI йөздән башлап өлкәдә күренә башлаган кыпчаклар да, соңрак килүчеләре дә (тик ни өчен «татар-монгол гаскәре составы» белән генә чикләнергә?!) яңа шартларда материаль тормышларын үзгәртергә мәҗбүр булганнар.

Дөрес, яңа ватанда артык кирәге калмаган тирмә, ияр кебек күчмә тормыш әйберләренең сәнгать элементлары бөтенләй юк юкка чыкмаган, ләкин алар агач йортка, таш бинага, чана—арбага үзгәреп, яңа материалга яраклашып күчкән, тора-бара бөтенләй танылмаслык хәлгә килгән. Нәкъ менә шушы күчүне, үзгәрүне ачыклау һәм аңлату сәнгать белгеченең бурычы да инде!

Шул ук вакытта сәнгать әсәрләре барлыкка килүдә, яшәүдә, югарыда әйтелгәнчә, «заказчы һәм башкаручы» мәсьәләсе дә бар. Китап авторы үзе үк икърар иткәнчә, өлкәгә бер дәвердә кыпчаклар (дөресрәге, аларның мәгълүм өлеше) җиңүчеләр сыйфатында килгән, ягъни хакимлек итүчеләргә әверелгән булып чыга. Гәрчә Ф. Вәлиев аңлатуында бик гадиләштерелгән булса да, гомумән, бу — дөрес караш. Әгәр шулай икән, ул чакта заказчы-потребитель, ягъни хуҗа таләбен дә, аның традицион зәвыгын да онытмаска кирәк иде. Димәк, сәнгать белгеченең төп бурычы булган ачыклау мәсьәләләренә килгәндә, гел этник факторлар белән генә чикләнергә ярамый. Әмма ул факторларга бер кагылдың икән, эзлекле тарихилык принцибын да саклау зарури.

Җыеп әйткәндә, Ф. Вәлиевнең фактик материалга — сәнгать материалына — гаҗәп бай хезмәтенең зур кимчелеге, шул бай материалны бер генә максатка — этник тарих максатына буйсындырып бирергә омтылуында. Әйтерсең лә узганны өйрәнүчедән гел этногенез мәсьәләләрен ачыклау таләп ителә! Ә бит сәнгать әсәрләренең этник тарих кысаларына сыймый торган яклары да бик күп.

Менә шуңа күрә тарихның ерак дәверләрен тикшерүче галимнәр, язма истәлекләрне дә өйрәнүне туктатмыйча, материаль культура калдыкларына күбрәк мөрәҗәгать итәргә тиешләр. Чөнки матди культура истәлекләре, шул исәптән көнкүреш сәнгате әсәрләре дә, безгә борынгы кешеләрнең эш кораллары, хезмәт объектлары белән таныштырга ярдәм итә. Ә хезмәт объектлары исә төрле социаль катламнар арасындагы мөнәсәбәтләрне төгәлрәк аңларга булыша. Моннан тыш көнкүреш сәнгате әсәрләрен тикшереп, без борынгы кешеләрнең зәвыгы, бу зәвыкның үсү, үзгәрү үзенчәлекләре, чыганагы һәм нәтиҗәләре хакында да фикер йөртә алабыз. Бер җәмгыятьнең көнкүреш сәнгате өлкәсендәге зәвыгын аңлау аның әдәбият, музыка өлкәләрендә дә казанышларын күзалларга мөмкинлек бирә. Бу истәлекләр шулай ук идеологик процессның төсмерләрен дә чагылдыра. Ниһаять, көнкүреш сәнгате истәлекләре теге яки бу җәмгыятьнең нинди экономик халәттә яшәвен — прогресс кичерүен, яисә торгынлык хәленә төшүен яктырта.

Фуад Вәлиев җыйган фактларның әһәмияттен бары теоретик күзлектән генә бәяләү, минемчә, бер яклы булыр иде. Бу хезмәттә бирелгән материалларның практик әһәмияте дә зур. Аларны бер тарихчылар гына түгел, хәзерге практик сәнгать белгечләре бүгенге архитектура, бүгенге театр, бүгенге ювелирлык өлкәләрендә дә файдалана алырлар иде. Бу, һичшиксез, кирәкле һәм файдалы китап. Үз өлкәсендә — сәнгать өлкәсендә — гаҗәп бай китап. Ниһаять, зур хезмәт, искиткеч тырышлык нәтиҗәсендә генә дөньяга килгән китап. Ул уйландыра, бәхәсле хисләр уята, ә бәхәстә, мәгълүм булганча, хакыйкать туа.

Бәлкем, югарыдагы кырыс хөкемнән соң мондый җылы сүзләрне уку кайберәүләргә сәеррәк булып тоелыр. Ләкин монда бернинди каршылык юк. Мин меңләгән-меңләгән музей-архив материалларын актарып, күз нурларын түгә-түгә, йөрәк канын саудыра-саудыра, аларның серләрен ачкан, өлешләрдән бөтенне тергезгән, бүгенге укучыларны ата-бабаларыбызның зәвыгы белән таныштырган сәнгать белгече Фуат Вәлиевне тәкъдир итәм — мактауга лаек олы хезмәт башкарган ул. Ләкин бер яклы гына каралган материаллар нигезендә зур теоретик йомгакларга дәгъва итүче, мәгәр элементар логик каршылыклардан уза алмаган тарихчы Вәлиев тәнкыйтькә лаек, чөнки узганны өйрәнгәндә нәтиҗәләр изоляцияләнгән бер төр фактларга гына түгел, ә төрле характердагы фактлар комплексына һәм эзлекле тарихилык принцибына нигезләнергә тиеш.

**МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ,**
**тарих фәннәре кандидаты.**

## Фәнис Яруллин

### Минем чана

Такта-токта таптым,
Чана ясап аттым.
Бик шәп чыкты чанам,
Күз алалмыйм аннан.
Табаннары көзге,
Очып тора үзе.
Выж-выж менә үргә,
Туктап калмый бер дә.
Моторы юк — чаба,
Вәт, ичмасам, чана.
Батмый йомшак карда,
Мактый аны бар да.
Ничек йөри? Әйтәм:
Мин бит аны тартам.
Өстәвенә энем
Этеп йөри арттан.

### Бәби карыйм

Бәби карыйм, уйнатам.
Елады исә — юатам.
Җилкәмә дә мендерәм,
Шырык-шырык көлдерәм.
Син бик матур, тәти, дим,
Әйдә йөрик тәпи, дим.
Авыз-борының аппак, дим,
Тешкәйләрең вак-вак, дим.
Бер көн бәби чирләде,
Бер кызды, бер тирләде
Шырык-шырык көлмәде,
Чакырганга килмәде.

Әни әйтте: күз тигән!
Бигрәк матур бала, ди.
Гел сокланып карарга
Ярамый шул аңа, ди.
Ярамагач ярамый —
Хәзер алай карамыйм.
Син бик какай бала, дим,
Авыз-борының кара, дим
Иреннәрең кыек, дим,
Буыннарың сыек, дим.
Инде бәби терелә,
Тәтигә дә үрелә.
Терелмичә нишләсен —
Күз тидерәм кирегә.

## Су буенда

Малайлар су керә
Шатланып, куанып.
Зиннур яр өстендә,
Тик тора уйланып:
«Елгасы сай булса,
Су — җылы май булса,
Бик каты акмаса,
Дулкыннар какмаса,
Кермичә тирәнгә
Йөзәргә өйрәнсәм, —
Су керер идем лә
Мин дә зур Иделдә»!

## Каргалар теле

Күктә бик күп карга,
«Кар», «кар» килә бар да.
Телләрендә шул сүз
Кунсалар да талга.
Әни әйтә: «Димәк,
Тиздән яңгыр явар.
Шулай «кар-кар» килеп,
Яңгыр тели алар».

Каргаларның теле
Кызык кына икән:
Яңгыр дияр чакта,
Кар сорыйлар күктән.

## Нур Гайсин

### Халисә

Халисәгә Әнисә:
— Тешеңне чистарт! — дисә,
Бик тиз җавап кайтара
Әнисәгә Халисә:
— Чистартмыйм моннан ары,
Тешем тумыштан сары,
Агармый, — ди, — юсаң да,
Юу түгел, усаң да...
— Чистарыр, — ди Әнисә, —
Щеткалап юдың исә.
Тешеңне кеше күрсә,
Үзеңнән көләр! — дисә,
Җавап таба Халисә:
— Беләсеңме, Әнисә,
Тешләремне кешегә
Күрсәтми сөйләшәм, — ди, —
Дусларга да иренне
Мин ябып эндәшәм, — ди.

### Шар очырдым

Ал шар очырдым күккә,
Күтәрелде бик биек,
Йөзеп йөрде һавада
Ак болытларга тиеп.

Менде дә югарырак,
Җирне калдырды ерак,
Мин аны көткән идем,
Кайтмады кире урап.

Мин шатланам эчемнән:
— Айга менә,— дип,— шарым,
Очсын әйдә, уйнарга
Бик күп уенчыкларым.

### Ул миннән кыю икән

Безнең Актырнак бүген
Чыкты елганы кичеп,
Аның бит куллары юк,
Йөзә икән ул ничек?

Белдем, ул аякларын
Йөзгәндә ишкәк иткән,
Мин әле судан куркам,
Ул миннән кыю икән.

## Зәки Нури

# ОЗЫН СҮЗНЕҢ КЫСКАСЫ

### Үзем дип уйламыйча

Кайтавазын үзенең ишетә дә
Әйтә икән сүзчән Саескан:
— Бу нинди кош? Телен ник кисмиләр?
...Ай-һай, фикер тирән саеккан!..

### Сәер җыр

— Үз җырым бар. Исеме «Ай-һай» аның.
Гөлзәйнәпкәй — минем «Ай-һаем»,
Тик утыз көн бергә торган идек,
Утыз таңкә түлим ай саен...

### Янса янсын

«Каракның бүреге яна» дип
Кайгыртмыйлар бурлар:
— Янса янсын! Иртәгә ул
Бүтән бүрек урлар.

### Һаман яза

Әләкче суратенә штрих

— Һаман язам! Каурый-каләм йөртә
Аягымның ике бармагы. —
Почеркымны чөнки яшерер өчен
Бүтән чара инде калмады.

## Берсе терәү, берсе таяныч...

Үзенә үзе эпитафия
Язып калдырган, имеш, ди берәү:
«Барчагыз миңа кирәкле булды:
Әшнә — таяныч, ялагай — терәү!»

## Вакыт артмый

— Әткәң-әнкәң синең көндәлеккә
Бер ай инде имза куймыйлар.
— Ник шулай дип сорасагыз, әйтәм:
Телевизор карап туймыйлар...

## Мәсәл шулай туды

Бакчасына сакчы итеп берәү
Әрсез Билчән куйды...
Басты Билчән бөтен бакчаны!
...Мәсәл шулай туды.

## Гыйбрәтле этлек

Бүре куркытам дип өргән
Бер эт... почмакка поскан —
Үзе дер-дер калтырана,
Үзе койрыгын кыскан...

## Исерек... мылтык

Каравылчы карт мылтыгы
Кичә, ай-һай, шәп аткан:
Сөяп куйган чакта авып
Унбиш тәлинкә ваткан!..

## Төш күргәннән соң

— Тавык, кая барышың?
— Саклыйм колхоз тарысын! —
Киң басудан кайттым юк
Чүпләмичә барысын!..

## Берсе дә үзгәрмәгән

Аерылдылар. Хатны бары хатын яза:
«Ник дәшмисең, тискәре һәм кире шайтан?
Алиментың болай ярты-йорты килсә,
Көт тә тор дим, яннарыңа кире кайтам!..»

## Ата кеше борчыла

— Ни хикмәт бу? Кердең нинди мәктәпкә?
Ник нервамда минем шулай уйныйлар?
Минем күңел булсын өчен, ичмасам,
Ник соң сиңа бер бишле дә куймыйлар?

## Күрешә алмау

Качып йөрде башта улыннан —
Алименттан качты... Акча бит...
Инде хәзер үзе аптырый,
«Улым нигә миннән кача?» дип.

## Кермәде

— Башлык чакыра сезне! — ди секретарь.
— Ул кәгазьдә минем кулым юк. —
Дип башлый да мөдир, әйтә: — Кермим,
Чөнки янда валидолым юк.

## Моданы ошатмау

Йомыркадан әле генә чыккан Чебеш
Әйтә икән әтисенә, әнисенә:
— Аңлатыгыз, шундый ямьсез каурый кием
Кемнәр текте, әти, сиңа, әни, сиңа?

## Кем кемне ташлаган

— Хатыныңны ник аердың, кордаш?
— Кафеларда була башлады —
Мине эзләп шунда йөри-йөри,
Өй эшләрен тәмам ташлады.

## Загстан чыкканда

— Язылыштык! Инде мәңгелегем
Булдың минем! Син ул — хәзинә бит!..
— Исемемне һаман ник бутыйсың,
Мин Нәзирә түгел, Нәзинә бит?!.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ӘДӘБИ ЕЛ ЙОМГАКЛАРЫ

Язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында Татарстан язучыларының узган ел йомгакларына багышланган җыелышы булды.

Җыелышны кереш сүз белән ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов ачты.

1975 ел прозасы турындагы докладны Атилла Расих, поэзия турында Җәлил премиясе лауреаты Ренат Харис, драматургия турында Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры баш режиссеры, Г. Тукай премиясе лауреаты Марсель Сәлимҗанов, балалар әдәбияты турында Роберт Батуллин, русчага тәрҗемә ителгән китаплар һәм республикабызның рус язучылары иҗаты хакында Диас Вәлиев, очерклар турында Хәниф Хәйруллин сөйләде.

Фикер алышуларда Фатих Хөсни, Ибраһим Нуруллин, Зәки Нури, Габдрахман Минский, Аяз Гыйләҗев, Туфан Миңнуллин, Нәби Дәүли, Клара Булатова, Хәй Вахит, Гөлшат Зәйнашева, Азат Әхмәдуллин, Самат Шакир, Равил Фәйзуллин катнашып, татар әдәбиятының күп төрле проблемаларына кагылдылар, аерым әсәрләрнең уңай һәм кимчелекле якларын ачтылар. Ике көн барган җыелышка Гариф Ахунов йомгак ясады һәм чыгышларда әдәби осталыкны үстерүгә, әсәрләрнең сыйфатын күтәрүгә басым ясалуын хуплады, Язучылар союзы һәм язучылар алдында торган бурычларны билгеләде.

Әдәби ел йомгаклары, быел беренче буларак, зур әдәби-музыкаль кичә белән тәмамланды. Шәһәребезнең Төзүчеләр культура сараенда соңгы елда язылган шигырьләр һәм яңа җырлар яңгырады.

Ел йомгаклары җыелышында КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев, КПСС өлкә комитеты культура бүлеге мөдире М. М. Мусин катнашты.

## КОММУНИСТЛАР КИҢӘШӘ

Язучылар союзы партия оешмасының чираттагы ачык җыелышы бүгенге тәнкыйтьнең торышын тикшерде. Филология фәннәре кандидаты Флүн Мусин «Тәнкыйть һәм заман» дигән темага доклад ясап, Гали Халит, Хәсән Хәйри, Тәлгать Галиуллин, Фарваз Миңнуллиннарның соңгы елда чыккан китапларын анализлады, вакытлы матбугатта басылган тәнкыйть мәкаләләренә күзәтү ясады һәм аларга методология, теория һәм стиль ягыннан карап бәя бирде.

Фикер алышуларда Гомәр Бәширов, яшь тәнкыйтьче Мансур Вәлиев, филология фәннәре кандидаты Азат Әхмәдуллин, шагыйрьләрдән Мөхәммәт Садри һәм Рөстәм Мингалимов, «Казан утлары» журналының тәнкыйть бүлеге мөдире Фарваз Миңнуллин, партия оешмасы секретаре Вакыйф Нуруллиннар катнашты, алар тәнкыйтьнең бүгенге көн темасына, заманның олы героена йөз тотарга һәм яшь тәнкыйтьчеләргә күбрәк игътибар бирергә кирәклеген күрсәттеләр, тәнкыйть мәкаләләренең культурасы, кешегә ихтирамның артуы һ. б. турында сөйләделәр.

## РСФСР ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНДА

РСФСР Язучылар союзы идарәсенең январь аенда үткәрелгән секретариатында оештыру эшләре каралып, Россия әдәбиятының төрле тармаклары буенча советлар, яшьләр белән эшләү Советы, РСФСР Язучылар союзының литфонд идарәсе оештырылды.

Проза буенча төзелгән Советның председательләре итеп Сергей Залыгин һәм Гариф Ахуновлар сайланды.

## Ф. ӘМИРХАННЫҢ 90 ЕЛЛЫГЫ

В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы Казан дәүләт университеты һәм Татарстан Язучылар союзы күренекле татар язучысы һәм җәмәгать эшлеклесе Фатих Әмирханның тууына 90 ел тулуга багышлап фәнни конференция уздырды.

Конференциядә тарих фәннәре докторлары, профессор Р. Нафиков «Фатих Әмирхан — җәмәгать эшлеклесе», профессор В. Хаков «Фатих Әмирхан һәм стиль мәсьәләләре», филология фәннәре кандидатлары, доцент М. Мәһдиев «Фатих Әмирхан полиция күзәтүе астында», доцент Ф. Сафиуллина «Фатих Әмирхан хикәяләвендә стиль», кече фәнни хезмәткәр И. Бәширова «Фатих Әмирханның балалар өчен язылган хикәяләренең стиле» дигән темаларга докладлар сөйләделәр.

* * *

Татарстан Язучылар союзы, ТАССРның Культура министрлыгы һәм Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге Фатих Әмирханның тууына 90 ел тулуга багышланган тантаналы кичә уздырды.

Әдипнең тормыш юлы, әдәби һәм җәмәгать эшчәнлеге турында филология фән-

нәре докторы Мөхәммәт Гайнуллин доклад ясады. Кичәнең икенче бүлегендә шәһәребезнең сәнгать осталары зур концерт бирде.

## МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ 70 ЕЛЛЫГЫНА

### ЮБИЛЕЙ КОМИССИЯСЕ

СССР Язучылар союзы идарәсе секретариаты күренекле совет язучысы, Советлар Союзы Герое Муса Җәлилнең 70 еллыгын үткәрү өчен Бөтенсоюз юбилей комиссиясен төзеде. Анда илебезнең танылган язучылары һәм әдәбият белеме галимнәре, үзәк нәшриятлар һәм ведомстволар вәкилләре В. И. Анипович, С. Г. Арутюнян, Г. А. Ахунов, Н. М. Батрак, Ю. Н. Верченко, Б. Вагаб-задә, В. Н. Ганичев, В. Х. Ганиев, М. В. Горбачев, Ю. Г. Гребов, Е. А. Долматовский, М. А. Дудин, Зәки Нури, Ю. О. Збанацкий, Кайсын Кулиев, А. А. Кулешов, Мостай Кәрим, Н. В. Лесючевский, М. Д. Львов, С. В. Михалков, Жубан Мулдагалиев, Э. В. Матузевичюс, Ю. С. Мелентьев, Л. И. Матвеев, А. И. Пузиков, С. В. Сартаков, Н. В. Свиридов, К. М. Симонов, А. А. Сурков, Хәсән Туфан, М. Турсунзадә, Хәмит Голәм, Сибгат Хәким, Н. Е. Шундик, С. Иралиевлар кертелде. Комиссиянең председателе М. К. Луконин, председатель урынбасарлары С. С. Орлов һәм М. Ф. Вәлиев, комиссиянең секретаре итеп В. В. Синицын сайланды.

### ШАГЫЙРЬ ТОРМЫШЫ ПОЛОТНОДА

Татарстан сынлы сәнгать музеенда, Муса Җәлилнең 70 еллыгына багышлап, республикабызның Культура министрлыгы, Татарстан художниклар союзы һәм Татарстан сынлы сәнгать музее тарафыннан оештырылган күргәзмә эшләде.

Күргәзмәгә республикабыз рәссамнарының 70 кә якын әсәре куелган иде. Алар арасында портретлар, рәсемнәр, скульптура әсәрләре, спектакльләргә эшләнгән декорация үрнәкләре, шагыйрьнең китапларына иллюстрацияләр һ. б. куелды.

СССР Художество академиясе член-корреспонденты, РСФСРның халык художнигы Х. Якуповның «Хөкем алдыннан», А. Абызгильдинның «Азатлык өчен көрәшчеләр истәлегенә», ТАССРның халык художнигы В. Куделькинның «Политрук шигырьләре» дигән полотнолары, И. Язынинның график әсәрләре, ТАССРның халык художнигы М. Сутюшев, И. Фәйзуллин, Х. Нәфиковларның «Муса», «Алтынчәч», «Җәлил» спектакльләренә эшләнгән декорация эскизлары, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе В. Поповның керамикага ясаган эшләре һ. б. күргәзмәгә килүчеләрдә аеруча кызыксындыру тудырды.

### ГЕРОЙ-ШАГЫЙРЬГӘ БАГЫШЛАНГАН КИЧӘЛӘР

Муса Җәлилнең 70 еллыгы уңае белән Советлар Союзының төрле шәһәрләрендә әдәби-музыкаль кичәләр булып үтте. Язучылар, сәнгать осталары күп санлы хезмәт ияләре белән очрашып, шагыйрьнең героик тормышын, ялкынлы шигырьләрен халыкка җиткерделәр.

Шундый кичәләрдән берсе Мәскәүдә Лихачев исемендәге заводның Культура сараенда үткәрелде. Бу кичәдә Берлинның Моабит төрмәсен алган хәрби часть начальнигы Ф. Я. Лисицын, Освенцимда фашист тоткынлыгында утырган вакытында курку белмәс шагыйрь Гумеров (Муса Җәлилнең яшерен исеме) турында һәм аның шигырьләре хакында ишеткән язучы Анна Кот чыгыш ясадылар.

Кичәгә җыелган яшьләр Муса Җәлил шигырьләрен көчле алкышлар белән каршылады.

* * *

Куйбышев шәһәренең металлургия заводында һәм металл коючыларның Культура сараенда эшчеләрнең татар әдипләре белән очрашулары булды. Драматург Риза һәм Рәйсә Ишморатлар, шагыйрьләрдән Нәби Дәүли, Рөстәм Мингалимов, Мәхмүт Хөсәеннәр тыңлаучыларга Муса Җәлилнең тормыш юлы һәм иҗаты турында сөйләделәр, шагыйрьнең әсәрләрен укыдылар, үз иҗатлары белән дә таныштырдылар.

### ҖӘЛИЛ ШИГЫРЬЛӘРЕ ҺӘМ ҖЫРЛАРЫ

«Мелодия» фирмасының грампластинкалар язу буенча Бөтенсоюз студиясе Муса Җәлилнең 70 еллыгына 2 пластинка хәзерләде.

Беренче пластинкада — Татарстанның халык артисты Айрат Арсланов башкарыны «Моабит дәфтәре»ннән шагыйрьнең 19 шигыре.

Пластинкаларның икенчесенә Р. Яхин, З. Хәбибуллин, Л. Хәмиди, А. Монасыйпов, Ф. Әхмәтов, Р. Еникеевларның шагыйрь сүзләренә язган җырлары, Н. Җиһановның «Җәлил» операсыннан ике ария, А. Монасыйповның «Җәлил» симфония-поэмасы язылган.

* * *

«Молодая гвардия» нәшрияты 1975 елда чыгарган «Спутник пионерского вожатого на 1975—1976 годы» дигән китапта Муса Җәлил турындагы әдәбиятның исемлеге бирелгән.

### ӘДӘБИ ОЧРАШУЛАР ҺӘМ КИЧӘЛӘР

Шагыйрь Нури Арсланов «Татарстан яшьләре» газетасы каршында оештырылган «Яшьлек» әдәби берләшмәсенең чираттагы утырышында катнашты. Башка телләрдән татар теленә тәрҗемә ителгән шигырьләрнең сыйфаты турында сөйләп, яшьләрне үзенең иҗат тәҗрибәсе белән таныштырды. Яшь язучылар каршында торган бурычлар турында кызыклы фикерләр әйтте.

* * *

Казан шәһәренең 126 нчы мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучылары һәм укучылары белән СССР Верховный Советы депутаты, партиянең XXV съезд делегаты, язучы Гариф Ахунов очрашты. Ул аларга партиябезнең ике съезды арасында Татарстан язучыларының эшчәнлеге һәм татар совет әдәбияты алдында торган бурыч турында сөйләде.

* * *

Январь ае Пермь шәһәре укучылары өчен аеруча истәлекле булды. Шәһәрнең яшь җәлилчеләре герой шагыйрьнең 70 еллыгына багышланган слетка җыелды һәм алар слетта М. Җәлил премиясе лауреаты Илдар Юзеев, Г. Тукай премиясе лауреаты Шәүкәт Галиев, Глинка исемендәге РСФСР Дәүләт премиясе лауреаты композитор Фасил Әхмәтов, Татарстанның халык артисты Эмиль Җәләлетдинов, Казан консерваториясе доценты, концертмейстер Эльза Әхмәтовалар белән очраштылар.

Казан әдипләре һәм сәнгать осталары «Югары Курья» ял йортында, хәрби хезмәткәрләр янында, Уя районы авылларында да күп санлы әдәби-музыкаль кичәләр уздырдылар.

* * *

Гариф Ахунов «Әлмәтнефть» идарәсенә караган 2-РИТС коллективының почетлы операторы. Январь аенда ул шушы коллектив членнары белән очрашты, аларга әдәбиятыбызның яңа казанышлары турында сөйләде. Автографлар язып Татарстан язучылары бүләк итеп җибәргән китапларны тапшырды, күп кенә сорауларга җавап бирде.

* * *

Язучылардан Гариф Ахунов, Вакыйф Нуруллин, Рәис Даутов, Әдип Маликов Әлмәттәге җөйлә-спираль приборлар эшләү заводы эшчеләре белән очраштылар.

* * *

Язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында Глинка премиясе лауреаты Фасил Әхмәтов белән очрашу булды. Композиторның фортепианода уйнавы белән башланып киткән бу кичә чын мәгънәсендә музыка һәм әдәбият бәйрәменә әйләнде. Кичәне РСФСРның М. Горький премиясе лауреаты, Дәүләт премияләре бирү комиссиясе члены, шагыйрь Сибгат Хәким ачты, педагогия фәннәре кандидаты, музыка белгече Сания Рәимова Фасил Әхмәтовның иҗаты турында сөйләде.

Тукай премиясе лауреатлары Гариф Ахунов һәм композитор Заһид Хәбибуллин, Җәлил премиясе лауреатлары Илдар Юзеев һәм Равил Фәйзуллин, өлкән шагыйребез Нури Арслановлар композиторның иҗаты һәм, гомумән, республикабызның музыка сәнгате турында фикерләр әйттеләр, шигырьләр укыдылар.

Кичәдә Фасил Әхмәтовның инструменталь әсәрләре, җырлары башкарылды.

## ТАТАР ЯЗУЧЫЛАРЫ ТӨРЛЕ ТЕЛЛӘРДӘ

* * *

Праганың «Дилия» нәшриятында Диас Вәлиевнең «Сиңа тормыш бүләк итәм» пьесасы чех телендә басылып чыкты.

* * *

Шул ук авторның «Картлар, ирләр, малайлар» дигән китабы «Современник» нәшриятында чыкты. Бу китапка авторның «Син яңадан китсәң дә» дигән повесте һәм хикәяләре кергән.

* * *

«Современник» нәшриятында Әхсән Баяновның «Кышкы чәчәкләр» исемендә поэмалар һәм шигырьләр җыентыгы чыкты. Китапны русчага тәрҗемә итүче шагыйрь — Виктор Гончаров.

* * *

Мәскәүдә, Политиздат нәшриятында, Бөек Ватан сугышында катнашкан разведчикларның кайберләре турында «Люди молчаливого подвига» дигән очерклар китабы басылып чыкты. Бу китапта Саба егете Фәрит Фазлыйәхмәтов турындагы очерк та бар. Фәрит дошман тылында «Александр Матросов» псевдонимы белән йөри. Аның батырлыгына Советлар Союзы Маршалы К. К. Рокосовский үзенең «Солдат батырлыгы» дигән китабында «үз эшенең остасы» дип бәя бирә. Фәрит Фазлыйәхмәтов хәзер Мәскәүдә фәнни-тикшеренү институтында конструкторлар җитәкчесе булып эшли.

* * *

Мәскәүдә «Искусство» китап нәшриятында «Халкымның йөрәк тавышын ишетәм» дигән җыентык чыкты. Анда шагыйрь Ренат Харисның «Әтием турында шигырь» дигән әсәре кергән. Шигырьнең тәрҗемәчесе В. Кузнецов.

* * *

Мәскәүдә «Детская литература» журналының январь санында язучы Гариф Ахунов турында биографик белешмә һәм аның фотосы бирелгән.

* * *

«Литературная Россия» газетасының 30 январь санында «Без ничек язабыз» дигән рубрика астында Гомәр Бәшировның зур мәкаләсе басылды. «Иң беренчесе» дигән бу хезмәтендә автор тормыш һәм әдәби хезмәт турындагы уйлануларын биргән.

* * *

РСФСР Язучылар союзы органы булган «Волга» журналының беренче санында шагыйрь Зәки Нуриның шигырьләр циклы басылып чыкты. Шигырьләрне В. А. Лещенко тәрҗемә иткән.

* * *

Карел шагыйре Яакко Ругоевның «Карелиянең йолдызлы күге» дигән китабын җентекләп анализлаган чыгышын Зәки

Нури «Литературная Россия» газетасында бастырды.

* * *

Мохтар Ауэзов исемендәге Казакъ дәүләт академия театры Хэй Вахитнең «Күк капусы ачылса» комедиясен сәхнәгә куя башлады. Анда Казагыстанның халык артисткасы Бикән Римова, Атайбәк Жолымбәтов һ. б. катнаша.

Татар дәүләт академия театрында 300 тапкырдан артык уйналган бу әсәр Азизбеков исемендәге Әзербәйҗан академия театрында, Башкорт АССРның Салават театрында, Дагстанның кумык, авар театрларында, Орджоникидзе шәһәрендә осетия драма театрында, рус теленә тәрҗемә ителеп Балашов, Березники, Ставрополь шәһәрләрендә уйналды.

## КҮРГӘЗМӘ ЗАЛЛАРЫНДА

Талантлы рәссамчы Е. В. Киселева монументаль әсәрләр остасы. Шәһәребезнең химиклар культура сарае, культура институты, «Акчарлак» рестораны һәм башка биналар интерьеры аның әсәрләре белән бизәлгән.

Рәссамның тематикасы һәм сурәтләү чаралары гаять бай.

Е. Киселева Татарстан рәссамнарыннан беренче буларак витраж (төсле пыялалардан җыеп ясалган үтә күренмәле декоратив әсәр) техникасын үзләштерде. Ул зур полотнолы графика өлкәсендә дә, калайга чүкеп рәсем ясау, политик плакат һәм гравюра эшләү, рәсем сәнгатенең башка төрләрендә дә зур уңышка ирешкән рәссам.

Е. Киселева әсәрләренең төп темасы — бүгенге көн романтикасы. Аның геройлары — революция батырлары, КамАЗ төзүчеләр, космонавтлар.

Бу әсәрләрнең үрнәкләре январь аенда Татарстанның сынлы сәнгать музеена күргәзмәгә куелды һәм аларны күп санлы хезмәт иияләре тамаша итте. Күргәзмә рәссамга зур уңыш китерде.

* * *

Казанның Художниклар йортының күргәзмә залында яшь рәссамнарның VII республика күргәзмәсе булды. Күргәзмәне Татарстан Художниклар союзы, ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты оештырды.

## ӘЛМӘТТӘН ХӘБӘРЛӘР

Татарстан Язучылар союзының Әлмәт бүлегендә отчет-сайлау җыелышы булды. Бүлектәге язучыларның иҗатлары, партия куйган таләпләрдән чыгып, алда торган бурычлар турында бүлек җитәкчесе Әдип Маликов доклад ясады. Ревизия комиссиясе председателе Гамил Афзалның информациясе тыңланды. Фикер алышуларда Шамил Бикчурин, Хәниф Хәйруллин, Энҗе Мөэминова, Рафаил Төхфәтуллин, Эдуард Касыймов, Клара Булатова, Юныс Әминов, Сажидә Сөләйманова, КПССның Әлмәт шәһәр комитеты секретаре Сәүдә Хәкимова һ. б. катнашты.

Җыелышта Татарстан Язучылар союзы председателе Гариф Ахунов, союзның партия оешмасы секретаре Вакыйф Нуруллин, ревизия комиссиясе председателе Рәис Даутовлар катнашып, чыгышларында язучылар эшенә кагылышлы күп мәсьәләләргә тукталдылар.

Фикер алышулар тәмамлангач, сайлаулар үткәрелде. Яңа бюро составына Әдип Маликов, Рафаил Төхфәтуллин, Юныс Әминов кертелде. Татарстан Язучылар союзы Әлмәт бүлегенең җаваплы секретаре итеп Әдип Маликов, ревизия комиссиясе председателе итеп Гамил Афзал сайланды.

* * *

Әлмәт тамашачылары шәһәр театрында Юныс Әминовның «Сафура бураннары» исемле комедиясен карадылар. Сәүдә хезмәткәрләре тормышын чагылдырган спектакльне караганнан соң язучылар, театр коллективы белән берлектә, фикер алыштылар. Әдип Маликов, Сажидә Сөләйманова, Рафаил Төхфәтуллин һ. б. спектакльнең уңыш белән барачагына ышаныч белдерделәр һәм аерым кимчелекләрен күрсәттеләр.

* * *

Әлмәт шәһәренең 1 номерлы урта мәктәбендә Сажидә Сөләйманова, Энҗе Мөэминова, Клара Булатова иҗатына багышланган әдәби-музыкаль кичә булды. Шагыйрәләр яңа шигырьләрен укыдылар, укучыларга автографлар язылган китапларын бирделәр.

* * *

Юныс Әминов, Гамил Афзал, Сажидә Сөләйманова, Энҗе Мөэминова, Сәет Кальметов һәм яшь язучы Газиз Кашапов Баулы районы поселокларында, колхозларында һәм мәктәпләрендә әдәби очрашуларда булдылар. Район культура работниклары семинарына катнашучылар алдында чыгыш ясадылар. Һәр очрашуда китаплар сатылды.

## ХЕЗМӘТКӘ ХӨРМӘТ


Совет әдәбияты өлкәсендәге хезмәтләре һәм җитмеш яшь тулу уңае белән язучы **Газиз Сәләх улы Усмановка** (Газиз Иделле) КПСС өлкә комитеты һәм ТАССР Министрлар Советының **Почет грамотасы** бирелде.

* * *

Совет музыка сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре һәм җитмеш яшь тулу уңае белән СССР халык артисты **Натан Григорьевич Рахлин Октябрь революциясе** ордены белән бүләкләнде.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

Совет музыка сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен Муса Җәлил исемендәге татар опера һәм балет театры солисткалары **Әлфия Гафият** кызы **Заһидуллинага** һәм **Рәхилә Хәйдәр** кызы **Мифтаховага** Татарстан АССРның атказанган артисты дигән мактаулы исемнәр бирелде.




# БАШ КУЕП ИСКӘН ҖИЛЛӘРГӘ

САРА САДЫЙКОВА көе

СИБГАТ ХӘКИМ шигыре

Баш куеп искән җилләргә,
Йөрим кырда куанып.
Йөрим арышларым белән
Мин бергә дулкынланып.

Баш куеп искән җилләргә
Онтыл да онтыл икән.
Яшьлек ул җилдә уйнаган
Дулкын да дулкын икән.

## *Хөрмәтле укучыбыз!*

Партиянең XXV съездында сөйләнгәнчә, игътибар үзәгендә совет кешесе. Аның хезмәт уңышлары, шатлыклары, борчулары...

Журналыбызның 5 саны үзенең эчтәлеге белән әнә шул проблемаларга кагыла.

Ул КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Фикрәт Әхмәтҗанович Табеевның съездда сөйләгән речь белән ачыла.

Илдар Юзеевның яңа шигырьләре тормыш турындагы фәлсәфәләре белән кызыклы.

Әхсән Баянов «Төлке тоту кыен түгел» дигән повесть белән катнаша. Әсәр гади совет кешесенең мораль сафлыгына, фидакарьлегенә багышлана.

Май ае — фашист илбасарларын җиңгән ай. Шул уңай белән Фәннур Сафинның «Ак канатлы егет» дигән поэмасы, Илгиз Кәлимуллинның «Дан ордены» поэмасыннан өзек, Самат Шакирның «Муса белән очрашкан баһадир» һәм Зәки Әхмәтҗановның «Дала егете» дигән очерклары басыла.

Шигырь яратучыларга грузин шагыйрьләренең әсәрләрен һәм әзербәйҗан шагыйре М. Мөшфикъ шигырьләрен тәкъдим итәбез.

Очерклар бүлегендә КамАЗ елъязмасы һәм Барлас Камаловның «Ферма — лауреат» дигән очеркы белән танышырсыз.

Әдәбият тарихына материаллар, китап күзәтү, нәниләр өчен шигырьләр, сатира һәм юмор әсәрләре басылачак. Бу бүлекләрдә Гафур Коләхметов турында яңа материалларны, Рафаэль Мостафинның әдәбиятыбыз турындагы кызыклы фикерләрен, сугыш еллары юморына караган әсәрләрне һ. б. укырсыз.

Яшь тәнкыйтьчеләр конкурсын дәвам итеп, редакция Ф. Сафа һәм Р. Низамиев рецензияләрен урнаштыра.

Журналыбызның бу санында да әдәбият һәм сәнгать яңалыклары биреләчәк.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73310